# КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


Бу санда


БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ

Илфак ИБРАҺИМОВ. Яңа 2018 ел белән! ....................4

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Фәнис ЯРУЛЛИН. Яңа елга иске теләк. *Шигырь.* ....................3
Клара БУЛАТОВА. Төзәтәсе иде дөньясын. *Шигырьләр.* ....................7
Вакыйф НУРИЕВ. Кышның озын бер төне. *Сатирик бәян.* ....................11
Сания ӘХМӘТҖАНОВА. Татар кыйтгасының сагында. *Шигырьләр.* ....................32
Хәнәфи БӘДИГЫЙ. Җиләк чиләге. *Маҗаралы бәян.* ....................36
Вазыйх ФАТЫЙХОВ. Булу кирәк бергә үзәктә. *Шигырьләр.* ....................56
Фәрит ГАБДЕРӘХИМ. Намуска тимәсеннәр. *Шигырьләр.* ....................91

*Яңа исемнәр:* Зиннур ТИМЕРГАЛИЕВ. Сәмига. *Бәян.* ....................60

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИНЕҢ ТУУЫНА 200 ЕЛ

Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН. Ташкичүнең олуг абызлары. ....................94
Флүрә ДӘМИНОВА. Остазлар остазы. ....................107
Мәрҗани сабаклары. Рабит БАТУЛЛА тупламасыннан. ....................109

*100нче бит:* Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Яңа ел бит! ....................100

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

Гомер буе укый укытучы... *(Арча педагогия көллияте директоры Гөлнара ГАРИПОВА белән Вакыйф НУРИЕВ әңгәмәсе).* ....................112
Кайда да йөрәктә *(Кентау шәһәрендәге «Татар-Башкорт» милли оешмасының җитәкчесе Фәрит ӘЮПОВ белән Илфак ИБРАҺИМОВ әңгәмәсе).* ....................118

*Мөгаллим мөнбәре:* Әлфия ТӨХВӘТУЛЛИНА. Язучы дәрес бирә. ....................114

*Гөлшат Зәйнашеваның туууына 90 ел:* Рамил ХАННАНОВ. Китмә, сандугач!.. ....................121
*Шамил Маннаповның туууына 80 ел:* Мөдәррис ВӘЛИЕВ. Кечкенә әзи – зур абыем. ....................126
*Аяз Гыйләҗевнең туууына 90 ел:* Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА. Татар сәхнәсендә – Аяз Гыйләҗев прозасы. ....................130

ПУБЛИЦИСТИКА

Мөхәммәт МИРЗА. Җаннан бүленгән кыйтга. *Эссе.* ....................138
Гөлзәлифә ӘХМӘТГАЛИЕВА. Туган җирдә – канатлылар... *Очерк.* ....................151

*Шәхесләребез:* Госман ГОМӘР. Куш йөрәкле Хәләф. *Эссе.* ....................157

*Истәлекләр*: Габдулла ГАЛИЕВ. Кырынды авылы тарихыннан сәхифәләр. ....................161

*Әдәби берләшмәләрдә:* «Каурый каләм» иҗат берләшмәсеннән: Г.ШӘРИПОВА, Д.НУРИӘХМӘТОВ, М.КАШАПОВ, Х.ФӘЙЗРАХМАНОВА шигырьләре; Г.ЗӘКИЕВА хикәясе *(Халидә Фәйзрахманованың кереш сүзе белән).* ....................178

*Юмор-сатира:* Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ тупламасыннан. ....................184

*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....................188

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**
*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.12.2017, график буенча 29.12.2017.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-3328. Тираж 4100.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2018 ел

# ЯҢА ЕЛГА ИСКЕ ТЕЛӘК

Әй Яңа ел, Яңа ел,
Яңа туган бала ел.
Син шаян, син шук әле,
Гөнаһларың юк әле.

Ай үсәсен көн үсеп,
Туктамыйча гел үсеп,
Күп гамәлләр кылырсың,
Баһадир ир булырсың.

Тик берүк явыз булма,
Җиргә кан-яшь агызма.
Җыйма ләгънәт-каргышлар,
Чуалмасын язмышлар.

Мылтык тоткан кулларга
Кызганмыйча каты сук.
Кара мәкер-уйларга
Давыл булып каршы чык.

Өйсезләрне өйле ит,
Көйсезләрне көйле ит.
Җылы, йомшак кул белән
Үксезләрнең яшен сөрт.

Буең белән түгел син,
Эшең белән олы бул.
Һәр кешенең иң көткән
Иң бәхетле елы бул.

**Фәнис ЯРУЛЛИН**



# ЯҢА 2018 ЕЛ БЕЛӘН!

*...Минем кебек кемнәр генә*
*Көтеп аладыр тагын*
*Яңа ел туар таңында*
*Буранлап кар яуганын?!.*

*Бөтерелеп биеп торсын,*
*Сызгырыплар дуласын...*
*Һәркем, шуңа разый булып,*
*Ак бәхеткә юрасын...*

Нәкъ шагыйрь теләгәнчә, атна буе буранлап яуды да ап-ак юрганына төреп каршы алды Яңа ел таңын вакыт галиҗәнапләре!

Вакыт агышын иҗатчылар сизгеррәк тоя... Ел фасылларының һәр мизгеле мәңгелекнең бер төше булуын тасвирлап, рәссамнарның язган полотнолары, көйчеләрнең симфонияләре, шагыйрьләрнең шигырь, поэмалары туа... Ул иҗат үрнәкләре гомум сәнгать дөньясына тәкъдим ителә. (Сәнгать базарына дип әйтәсе килми.) Бөтен кешелекнең рухи казанышына әверелә.

Табигатьнең тәэсире, табигыйлек иҗатчының иң саф, иң самими халәтен уята, кайтара торган кодрәткә ия!..

Дөнья яратылышыннан алып, кешелек никадәрле колач җитмәс, акыл аныклый алмаслык үзгәрешләргә тармасын, Адәм баласында аның сабый хәлендәге табигый самимилеге сакланып кала икән... Шул табигыйлеккә якынаеп, аңа ягылган, ягылдырган саен, кешеләр арасында мөнәсәбәтләр сафланып, җылынып, матураеп китә...

Бүгенге глобаль дөньяда мондый җылылык, мондый матурлыкка ихтыяҗ бик тә зурдан... Изге китапларда әйтелгәнчә, фәкать мөнәсәбәтләр матурлыгы, гаделлеге, гуманлылыгы гына кешелекне алгарышка алып барачак. Кешелекнең рухи төсен, сурәтен, үсешенең дәрәҗәсен, аның мәгарифе, мәдәнияте, әдәбияты, сәнгатенең дәрәҗәсе билгели...

Узган 2017 ел халкыбызның рухи тормышында зур сынаулар елы булды. «Ә кайчан сынауларсыз яшәдек соң әле?» дигән сорау туа. Сынаулар, каршылыкларны җиңү аша гына алгарышка бара бу дөнья... Ачы тәҗрибә, үткәннәрне тирәнтен өйрәнеп, киләчәкне реаль-анык күзаллау, шуңа бердәм рәвештә омтылу, иҗтиһад итү белән ирешелә ул.

Бөекләребез Гаяз Исхакый, Габдулла Тукайлар йөз ел алдан күреп кисәткән афәттән котылу юлы да, алар күрсәткәнчә, йоклап ятмауда, рухи ялкаулыкка юл куймауда, тәрәккыйлектәге халыклардан үрнәк алып, дөнья барышы тизлегеннән калышмыйча иҗтиһад итүдә бит. Бүгенге глобаль дөнья – табигый сайланышның үзе. Аның төс-сурәте күптөрле. Шул күптөрлелекне аңламау, кабул итмәү, үз-үзеңә бикләнү – бөтен бер халык-кавемнең нәкъ Исхакый сурәтләгән Җәгъфәр хәлендә, берүзеңне ялгыз калдыруга – инкыйразыңа илтәчәк тә. Тукаебыз да, мондый шартларда нәрсә эшләргә, дигән сорауга үзенең «фикере касыйрын» әйтә: «Без иң алга киткән милләтләр сафында булырга тиеш!» – ди. Әлбәттә, үз йөзебез, үз төсебез, үз иманыбызга тугры калган хәлдә!.. Тукайча, милләткә үз хәлен, үз сурәтен көзгедәгедәй күрсәтү – рәссамнар хезмәте, музыка, әдәби сүз аша вәгазьләү, бертуктаусыз милли үзаңын үстерүгә юнәлтүдә... Аның: «Уртак Ватанда хаккыбыз шактый ук», – дигәне дә бүгенге глобаль дөньяда глобаль дәүләттәге хәлебез, халәтебезне чагылдыра ич.

Узып киткән ел республикабызның төп әдәби басмасы «Казан утлары» журналы өчен аеруча истәлекле булды – аңа 95 яшь тулды! 1922 елның май аенда тәүге саны «Безнең юл» исеме белән нәшер ителгән журналыбыз **әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси** басма буларак билгеләнә. «Атака», «Яңалиф», «Совет әдәбияты» исемнәре белән нәшер ителгәндә дә, шул миссияне үти ул. Әлбәттә, узган гасырның башында ук Ризаэддин Фәхреддин, Фатих Кәрими, Әхмәтгәрәй Хәсәни, Дәрдемәнд, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Җамал Вәлиди кебек зыялыларыбыз тырышлыгы белән дөнья күргән «Аң», «Шура» журналлары юл сапкан «Миллият дөньясы»ның «Безнең юл»га тәэсире хәлиткеч булуы ачык аңлашыладыр... «Безнең юл» – «Казан утлары» халкыбыз тарихында, **беренче тапкыр тулаем дәүләт тарафыннан нәшер ителгән милли әдәби басма** буларак, олы тарихи әһәмияткә ия вакыйгадыр.

Узган 2017 ел милли әдәбиятыбыз тарихына романнар елы булып кереп калыр, мөгаен... Аксакал язучыбыз Рабит Батулла үзенең «Илбашы» романында бер гасыр дәвамында халкыбызның үз дәүләтчелеген торгызуга омтылышы фонында замандашларыбыз – Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев һәм аның аркадашларының әдәби образын тудыруга иреште.

Язучы, галимә Фәүзия Бәйрәмованың «Һиҗрәт» романында узган гасырда Себер төбәгендә яшәүче милләттәшләребезнең тормышы, аларның, бөтен авыллары белән кубарылып, диннәрен саклап калу максатында, Төркия мәмләкәтенә һиҗрәт кылуы белән бәйле үтә дә катлаулы вакыйгалар, язмышлар сурәтләнә.

Вахит Имамовның «Карабәк» романы исә безне халкыбыз тарихына кан-яшь белән язылган урта гасырлар чорына – Алтын Урда дәүләтенең инкыйразы фаҗигасенә алып керә. Вакыйгаларның хәзерге, без көн иткән җирлектә тасвирлануы укучыларда аеруча кызыксыну уята.

Узган гасырның утызынчы елларында әдәби иҗатка беренче адымнарын ясаган Нәфикъ Яһудин «Атлы казаклар» романын беркайда да бастырып чыгарырга өлгерми – фронтка китеп һәлак була. Әлеге әсәр җитмеш җиде елдан соң «Казан утлары»нда басылып чыкты. (Авторның улы Марс Яһудинга кулъязманы саклап, журналга тәкъдим иткәне өчен рәхмәтебезне җиткерәбез.) «Атлы казаклар» романы укучыларыбызны дөнья буйлап сибелгән татарларның казаклар сословиесендә дә булуы, аларның яшәү-көнкүрешләре, гореф-гадәтләре белән таныштырды.

Марсель Галиевнең «Тимә, яшәсен!» романы, Фоат Садриевның романга тиң «Кышкы яшен» повесте бүгенге көнебез, яшәешебезнең әхлакый кыйммәтләрен күтәреп чыга.

Әлеге романнар турында тәфсилләп язуыбыз шуның өчен ки: аларны, кичекмәстән рус һәм дөньяның башка телләренә тәрҗемә итеп, киң даирәләргә чыгарасы иде. Бу романнарның һәркайсы үсешкә исәп тоткан милли кино сәнгатебез өчен әзер сценарийлар да була ала.

Проза елы журналыбызда басылып чыккан 11 повесть, 42 хикәя, 50 очерк һәм фәнни мәкалә белән тагы да тулылана.

Декабрь аенда Татарстан Язучылар берлеге үткәргән «Әдәби ел йомгаклары» корылтаенда әдәби барышның торышы тулысынча «Казан утлары»нда дөнья күргән әсәрләргә нигезләп тикшерелүе безнең олпат журналыбызның, милли әдәбиятыбызның барышын төп оештыручы буларак, мөһимлеген тагын да раслады. Бу уртак хезмәтебез язучы-шагыйрьләребез, нәшриятчылар һәм, әлбәттә, укучыларыбызның бер әдәби кырда, уртак рухи дулкында булуын билгели.

Әйе, әйе, заманча әдәби барышны оештыруда әсәрләребезне укучылар язучы, ягъни безнең белән бер биеклектә тора бүген. Укучылар даирәсенең киңлеге-күләме язган иҗат җимешләребезнең сыйфатына бәйлелеген галимнәр белән бергә укучыларыбыз да билгели.

Әдәбиятның хөкемдарлары кемнәр, дигәндә, бер икеләнүсез – укучылар, дибез. 2017 елда басылып чыккан роман, повестьлар, пьесалар, шигырь-поэмалар журналыбызга язылучылар санын ел башыннан 5250гә кадәр үстерде. Бу соңгы ун елда югары күрсәткеч иде... Укучылар дигәннән – без аларның даирәсе мәктәп укытучылары, укучылары, ата-аналар икәнен дә беләбез, тоябыз. Соңгы ике елда гына да редакциябез

хезмәткәрләре республикабызның йөзләрчә мәктәпләрендә очрашуларда катнашты һәм катнашабыз... Укучылар әдәби әсәрләрдә үзләрен, үз тиңнәрен күрергә тели. Бу да табигый. Бу да табигый сайланыш. Шуңа да «Казан утлары» үзендә укучылар өчен махсус яңа – «Каләм тибрәтүчеләр», «Ак җилкән», «Укытучы мөнбәре», «Укучы сүзе», «Хикәя яза аласыңмы», «100нче бит», «Яңа исемнәр» кебек рубрикалар ачты. Журналның өр-яңа сайты булдырылды һәм анда көн саен 1700-2000 укучы хәбәргә керә. Бер сүз белән әйткәндә, әдәби журналларның эчтәлеге милли мәгариф эшенә кайчандагыга караганда да ныграк җәлеп ителергә тиеш бүген. Шулай кирәклеген Тукаебыз әйткән, шуны бүгенге заман да таләп итә.

Хөрмәтле журнал укучыларыбыз!

Яңа 2018 елда журналыбыз битләрендә яңадан-яңа роман-повестьлар, поэмалар, хәтта шигъри романнар белән дә танышырсыз.

Яраткан әдипләребез, шагыйрьләребез сафына яшь талантларның кушылуына чиксез куанырсыз! Без исә сезнең белән Яңа елда да бергә булуыбыз белән чиксез бәхетле!

Тагын шуны да җиткерим әле: яңа елның тәүге басмасы минем баш мөхәррир буларак имзалаган соңгы нәшер саны булыр. Мин бу вазифамны бик тә яратып, җаваплылык тоеп башкарырга тырыштым. Журналның эшен оештыру, укучылар даирәсе белән элемтәләр булдыруда, авторларны «Казан утлары»бызга якынайту буенча ирешкән тыйнак кына нәтиҗәләребезгә дә ихластан куанам. Журналыбыз хезмәткәрләренә, редакция советы әгъзаларенә олы рәхмәтлемен!

Әлеге үзгәрешләр, шөкер, журнал редакциясенең эшчәнлегенә сәбәпле түгел. Алар фәкать минем шәхесемә карата булган мөнәсәбәткә бәйле... (Монысының инде әдәбиятка бернинди катнашы да юк.) Бу да, бездәгечә – «табигый» күренеш...

*...Шушы төндә зур җир шарын*
*Килә акка төрәсем.*
*Дөньяның бар халыкларын*
*Килә азат күрәсем.*

*Дулап торсын, бурап торсын,*
*Бер тынга да тынмасын.*
*Каралыгыннан арынсын*
*Илнең йорты-курасы.*

*Һәр Яңа ел өметләрнең*
*Яңарып туар чагы.*
*Күккә җитеп, балкып янсын*
*Өметләрнең учагы!*

*Даулап тусын, елап тусын,*
*Бер сүз әйтмә син аңа!*
*Тик сау-таза сабый гына*
*Елап туа дөньяга!..*

Яңа елда безне тагын да зуррак эшләр көтә... Барчабызга иминлек телим! Уртак ватаныбызда татулыкта, хөрлектә яшик! Амин!

**Илфак ИБРАҺИМОВ**



Клара
Булатова

# ТӨЗӘТӘСЕ ИДЕ ДӨНЬЯСЫН

## Булгандыр инде

Булгандыр инде…
Бар да булгандыр.
Сиксәнне үткән озын гомердә.
Фани дөньяда яшәү шулайдыр –
Хатадан хали түгел берең дә.

Булгандыр инде гөнаһларның да
Белеп кылганы, белми кылганы.
Яшәү – көрәш шул, шул ике нәрсә
Шул тарткалашу тота дөньяны.

Булгандыр инде, бар да булгандыр,
Көрәш алгандыр йөрәкнең көчен.
Булганнар өчен, кылганнар өчен
Аллаһы үзе берүк кичерсен.

Ул шәфкатьле бит, мәрхәмәтле бит,
Шуңа ышанып өмет итәбез.
Олыгайган көндә тәүбәгә килеп,
Иманлы булып җирдән китәбез.

***

Виллалар юк минем Сингапурда,
Акчам да юк чит ил банкында.
Фатир да юк Әлмәт каласында –
Калдырырга мирас артымда.

Клара БУЛАТОВА – *шагыйрә; «Язлар алда», «Әрнү», «Каурый канат – җил атым» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Әлмәттә яши.*

Бер нәрсәм юк минем, ә шулай да
Китапларым кала өелеп.
Шигырьләрем һәм җырларым кала,
Шәкертләрем кала иң элек.

Кем генә юк алар арасында,
Иманлысы, әйе, күберәк.
Шулар өчен янып гомер үтте,
Шулар өчен түзде бу йөрәк.

Без китәбез инде, алар кала,
Аларында безнең көй калыр.
…Үзе өчен генә яшәгәннең
Каберенә кемнәр гөл салыр?

## Мин пәйгамбәр түгел

Мин пәйгамбәр түгел,
Ә шулай да
Ни күрәсен бүген көннәрдә
Төнлә төштә күреп уянам бит,
Күрәзәлек яши миндә дә.

Күрәзәлек күктән иңәдер ул,
Алдан күрәм нәрсә буласын…
…Алдан күргәч күрсәтәсе иде,
Төзәтәсе иде дөньясын.

Үзгәртергә ләкин, төзәтергә
Җегәр көчем җитми бит әле.
Гомеремне кыскартмагыз әле,
Күп димәгез әле сиксәнне.

Ходай үзе өстәп биргән икән
Берничә ел гомер яңадан –
Мин үземне әле шагыйрь итеп
Танытырлык җырлар язалам.

***

Астагылар миңа үрелеп карый,
Өстәгеләр карый иелеп.
Үткән-барган борылып-борылып карый…
…Үзем генә йөрим бөгелеп.

Белеп-белми кылган гөнаһларның
Саллылыкны салган иңемнән.
Авырлыкны алыр тәүбәләрнең
Ни икәнен үзем мин беләм.

Бәндә генә итеп яшәтмичә,
Адәми зат булган Кешесен,
Тәкъдирендә шулай теркәгәчтен,
Хак Тәгалә үзе кичерсен.

***

Көзге көннәр көн дә кыскара шул,
Озыная көзге төн генә.
Көзге озын төндә йоклый алмый
Газаплану хәлен кем белә?

Озыная төне, озыная,
Кыскарта бит Раббым көз көнен…
Көзге көннәр чамасына үлчәп,
Кыскаруын сизәм гомеремнең.

Кыскаруы гына түгел инде,
Бетүе дә инде җитәдер.
Сиксәнгәчә яшим, дия идем –
Тулып үтте былтыр сиксән бер.

…Бүген әле әрәмәлек күрдем,
Әйтерсең лә кабат килгән җәй.
Гомер өстәп анда кәккүк йөри:
– Яшә әле бераз, – дигәндәй.

## Туфанга

Синнән калган гүзәл гамьнәр моңы
Күңел кылын кат-кат тибрәтә.
Кыш көне дә күңел әрәмәсен
Яздай яшәртергә өйрәтә.

Сыгылмалы февраль уртасында,
Кыш бөгелгән тымызык вакытта,
Син калдырган гүзәл гамьнәр нуры
Күңел күген назлап яктырта.

Дөнья минем яшәр юлларымны
Ничек санап-санап тормасын,
Син калдырган гүзәл гамьнәр җыры –
Гомерлеккә иҗат юлдашым.

***

Син яшьтәшем түгел, ярым түгел,
Сердәшем дә түгел –
каләмдәш.
Без барыбер бер чор балалары,
Бары үзең миннән бераз яшь.

Әмма мине (син беләсең инде)
Яшьләр аермасы беркайчан
Шагыйрьләрдән аерып сакламады,
Әгәр үзем киртә куймасам.

«Соңладым...» дип, әллә уйнап инде,
Әллә чынлап әйтеп куясың...

Кара аны, яшь Ләйләңне этеп,
Бер әкият тагын тумасын!

Искәндәрнең Тәнәкәсе яшь, дип,
Артык яшькә, егет, юлыктың.
Тарихта бит таяк ике башлы –
Зөләйхасы бар бит Йосыфның.

Зөләйхадай матурлыклар юк та,
Әмма чибәр – чибәр күренмәс.
Юләр шагыйрь җаны бездәйдән дә
Матурлыклар таба, бер сөйгәч.

Хас иткәндә (Маннур әйткән иде):
«Без беләбез аның хәйләсен:
Теләгәндә каратырга була
Ходайның һәртөрле бәндәсен».

Ә ул безне шагыйрь иткән икән,
Тыя алмый Мәҗнүн күңелдән. –
Мин тотам да, тагын гашыйк булып,
Җырлап яши башлыйм бүгеннән.

## Без бит бергә инде

Кайларда йөрсәң дә,
Кемнәрне күрсәң дә,
Кайтырсың барыбер үземә.
Без бит бергә инде,
Без бит бергә инде, гомергә.
Ялгызым чагында
Килсә дә кем генә,
Берсе дә кермәде күңелгә.
Син минем ирем лә,
Якыным – бер генә!
Без бергә бит инде гомергә!



Вакыйф
Нуриев

# КЫШНЫҢ ОЗЫН БЕР ТӨНЕ

САТИРИК БӘЯН

Кышкы төндә бер көйгә генә юыртып барган күндәм ат, алда хәвеф сизепме, өркенеп, кинәт кенә шып туктады. Төлке якалы калын толып эчендә талгын рәхәтлектә оеп барган конюх Илдар, кара туры туктаган шәпкә алга атылып, чанага түшәлгән солы саламына йөзтүбән капланды. Аннары тураеп утырды да, дилбегәсен шап-шоп тарткалап, атка дәште:

– Әйдә, анаңны корт чаккыры, нигә терәлеп каттың?..

Малкай кузгалырга уйламый. Кузгалу кая, дүрт аягын алга терәп чигенергә чамалый башлады. Башта Илдарның баш миенә «Бүре бардыр!?» дигән уй чиртте. Ул, чанадан янга каерылып, алга карады – юлда бер адәм заты басып тора иде. «Кем бу? Җиде төн уртасында кышкы япан кырда кем йөри. Берүзе бит. Стансага баручы, дияр идең – бу вакытта поезд юк, кайтучы дияр идең – поездан эт тә төшмәде. Артышлы тауга акчага киткән колхоз бухгалтеры Әсгать белән кассир Анжелика да кайтмады. Югыйсә Илдар, ат җигеп, стансага шуларны каршы алырга менгән иде. Юк, юньле кеше түгел бу. Ат хәтле ат өркенде үзеннән». Илдар тагын ниләр уйлаган булыр иде, ул арада шикле адәм, карны шыгырдатып, күңелне тагын да шомландырып, атка таба килә башлады. Килеп җитте. Озын буйлы, очлы борынлы, зур күзле, моңсу карашлы бер егет. Өстендә – шинель, башына кимәгән. Маңгаенда эчкә баткан ике тиен акча зурлыгындагы кутырлы-кучкыл яра. Ул килеп җиткәндә, кара туры арт аякларын алга сузып, чүгенгәндәй итте. Төнге юлчы беравык атка-чанага карап торды да Илдарга дәште:

– Өтермәскә шушы юлдан кайтасымы?

– Тек мин шунда кайтам, утыр әйдә. – Илдар, читкәрәк авышып, төнге юлчыга чанадан урын бирде. – Син каян, кемгә кайтасың соң?

– Мин – Сахап. Шул авылныкы. Фронттан кайтам. Гарифҗаннарга.

---

Вакыйф НУРИЕВ (1958*) — язучы. «Бүре кадәр бүрек», «Җиденче палата», «Ана догасы» китаплары авторы. ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре. Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

– Ә-ә-ә, Гарифҗан абыйларга, Әминә апаларга...

– Әминә мине онытКандыр инде. Беренче мәхәббәтем иде югыйсә. Гарифҗан – фронтташ дустым.

– Сугыш беткәнгә кырык ел бит инде. Күзгә-башка бер дә күренмәдең. Кайда йөрдең соң?

Фронтовик дәшмәде. Авылга җиткәнче, ул бүтән бер сүз дә әйтмәде. Зират янына җиткәч, атны туктатырга кушты.

– Әнинең каберен карап чыгам, – диде һәм төшеп калды.

* * *

Төн. Авыл өе. Көтмәгәндә тәрәз шакыдылар.Тавышка Әминә сискәнеп уянды, аннары ире Гарифҗанга төртте:

– Гариф, уян әле! Тор әле! Кемдер тәрәз шакый?!

– Саташасың мәллә, карчык. Төнлә кем йөрсен?

– Әле генә түрдән кырый тәрәзәне шакыдылар.

Икесе дә беравык тын гына яттылар. Тагын шакылдаттылар. Бу юлы түрдәге өч тәрәзәнең уртадагысын.

– Икенче тәрәзәгә килде, – диде Әминә, зәгыйфь тавыш белән. – Тор әле, сора әле. Кем икән ул? Сорамыйча ишек ача күрмә! Төн уртасында юньле адәм йөрмәс.

Гарифҗан акрын гына торып тәрәзәгә килде:

– Кем бар анда? Кем син?

– Кем ул?

Беркем дә юк.

– Чит кеше бу. Үзебезнең авыл кешесе булса, ишектәге звонокка басар иде.

– Үзе шакый, үзе дәшми. Әллә җен-пәриләр йөри инде. – Гарифҗан тәрәзәләрнең барысын да йөреп чыкты.

Әминә белән Гарифҗан бер-берсенә аптырашып карап тордылар да тагын караватка менеп яттылар. Ятар алдыннан Әминә раскладушкада йоклап яткан оныклары Артурның юрганын рәтләп япты. Бала бит, гел өстен ача. Төн буена әллә ничә тапкыр торып ябасы. Чү, өйдә тагын тавыш. Бу юлы кыңгырау тавышы яңгырады.

Гарифҗан, чоланга чыгып, ишеккә килде:

– Кем бар анда? Җиде төн уртасында вакытлы-вакытсыз кем йөри?

– Һайн Гитлер! – вакытсыз йөрүче әлеге дә баягы конюх Илдар иде.

Ул, «Уз!» дип әйткәнне дә көтмичә, туп-туры өйгә керде. Маңгаен кыеклатып каплаган чәчен, борын астында тар итеп калдырган кара мыегын сыпырып куйды, охшаса да охшар икән фюрерга! Абау! Абау!.. Кулында – ат йөгәне, Ул аны үзеннән калдырмый.

– Ах, Гитлер тәре, син икәнсең әле. Кеше уятып йөрмәсәң... Бая тәрәзәне син шакыдыңмы? – дип сорады Гарифҗан, аның артыннан өйгә кергәндә...

– Юк, тәрәзәгезгә якын да килмәдем. Кунак кайда? Кайтып җитмәдемени әле? Мин инде ат тугарып төштем. Ә ул һаман юк?! Алайса сөенче алам.

– Ниткән сөенче, ди?! Көткән кешем, кайтасы малым юк.

– Хәзер сиңа кунак килә. Стансадан төшкәндә, Либәдән урманы янында очрады.

– Кем?

– Фронтташ дустың, авылдашың Сахап.

– Сахап!

– Әйе, Сахап!

– Син, Гитлер тәре, башны бутап йөрмә әле, яме. Ярты гасыр элек сугышта үлгән Сахап кайта ди сиңа.

– Кайтты инде. Валлаһи газыйм.

– Бүтән кеше булса, ышаныр идек. Сугышта үз кулларым белән кабер казып, үзем күмдем бит мин аны.

– Кайтты, Кыяк абый, кайтты. Ышан миңа. Әгәр сүзем ялган булса, үземне җир упсын.

– Кеше ышанмаслык хәлне чын булса да сөйләмә, диләр.

– Гарифҗаннарга кайтам, диде. Гарифҗаны – фронтташ дус, Әминәсе – беренче мәхәббәтем, дип тә әйтте әле. Сахап исемен ишетүгә, сикереп торган Әминә дә сүзгә кушылды:

– Сахап, дисең, ә?! Сахап, Сахап... Кызык! Ул исәнмени? Син, Гариф, аны үлде, дидең. Ах, син мине алдагансың ич?!

– Нишләп алдыйм?

– Һи-и-и... Ышан сиңа!

– Үзем казыдым каберне. Гүргә үзем иңдердем. Үз кулларым белән. Урманда ята идек. Шунда гына бер авыл. Авыл уртасында – иске мәктәп. Безгә приказ: шул мәктәпне сүтеп, бүрәнәләрен урманга ташырга. Иң таза, иң гайрәтле егетләрне сайлап җыйдылар да җибәрделәр. Күбесе – татар. Барганда уйлыйм. Җә, баруын барабыз да инде без мәктәп сүтәргә. Тик фашист дөмектерәчәк бит безне. Беребез дә исән калмаячак. Белеп торам. Командирларын да әйтер идем инде, күрәләтә үлемгә җибәрәләр бит. Аларга тизрәк блиндаж, особняклар кирәк. Бер бүрәнә өчен башны саласы килми. Үлгәч-үлгәч, мәгънәлерәк үлем белән үләргә иде.

Барабыз. Алда – елга. Күпер чыгасы бар. Сахапка әйтәм, әйдә, минәйтәм, арттарак калабыз да шул күпер астына төшеп качабыз. Бетәбез бит, яшьти, бетәбез. Юк, тыңламады. Теләсә нинди утка барып керә торган, ни кушсалар, шуны эшли торган күндәм егет иде шул. Күпер астына берүзем төшеп утырдым. Берзаман китте атыш. Кыра гына немец безнекеләрне. Момент кырып атты. Кичкә кадәр утырдым күпер астында. Караңгы төшкәч, җирдә аунап яткан бер бүрәнәне җилкәгә салдым да кайтып кердем үзебезнекеләр янына. Кайттым да: «Там все умерихин, товарищ командир», – дип рапорт бирдем. Сахапны үзем үз кулларым белән җирләдем. Так что син, Гитлер туган, әкият сатып йөрмә, яме!

– Ярар, миңа ышанмасагыз, үз күзегезгә ышанырсыз. Мин аңа сезнең кайда торганны әйттем. Зираттан соң беренче өй, дидем. Хәзер кереп җитәр.

Әминәнең йокысын тиз качырды бу хәбәр. Ул сорау арты сорау бирергә ашыкты:

– Зиратка нигә кереп китте соң?

– Әнинең каберен карап чыгам, диде.

– Төнлә Либәдән урманында нишләп йөргән?

– Нишләп йөргәнен әйтмәде.

– Өс-башы нинди соң?

– Военный. Тәмәке кабызганда, маңгаенда эчкә баткан шрамын күрдем. Тартасыңмы, дигән идем. Тартмыйм, диде. Мин сугышта да тартмадым, диде.

Бу сүзләрне ишеткәч, Гарифҗан башын селкеп куйды.

– Чыннан да, Сахап ич бу, – диде ул һәм әле Әминәгә, әле Илдарга гаҗәпләнеп карап куйды. – Теге вакытта пуля нәкъ маңгаена тигән иде шул.

Тәмәке тартмавы да хак. Гитлер җебен-җептәрен белеп сөйли. Тукта, башыма сыйдыра алмыйм әле мин бу хәлне. Кабергә салганда, тәне йомшак, җылы иде. Без аны тере килеш күммәгәнбездер ич инде. Бездән соң каберләр янында көрәк сакаллы бер карт басып калды. Шул казып чыгармагандыр ич инде.

– Казып чыгаруы да бик мөмкин, – дип дәртләнеп сөйли башлады Әминә. – Мөхәммәт Мәһдиевтә бар бит... Бер авылда бер карт, мәет күмүчеләр зираттан кайтып киткәч, үзе генә калып, балчык өстенә ятып каберләрне тыңлап йөри торган була. Берсендә шулай күмәләр бер мәетне. Күмеп бетерәләр. Халык зираттан тарала. Бу кала. Колагын кабергә куеп тыңлый башлый. Берзаман сикереп тора да, кычкыра-кычкыра, авылга чаба. Кайтып җитүгә, һушын югалтып үлә. Иртәгесен үзен дә җирлиләр. Нигә чапкан ул? Теге кабердән нинди тавыш килгән? Карт әйтә-аңлата алмый. Теле бетә? Шулай итеп, карт теге кабернең серен дә үзе белән мәңгегә алып китте, дип яза Мәһдиев.

– Нүжәли теге карт... – Гарифҗан уйга калды.

– Кая соң, Кыяк абый, сөенче өчен йөз грамм салып бир инде. Синдә бар бит ул.

– Син шул йөз грамм өчен юри уйлап чыгаргансыңдыр әле бу әкиятне. Илдар түгел, Алдар син.

– Анысы, кеше алдаларга сиңа куш инде, Кыяк абый. Ул Сахапны күргәнем дә, ишеткәнем дә юк иде бит. Фронтовик дустың өчен йөз грамм жалкымы?

Әминә дә үгетләгәч, Гарифҗан салып бирде.

– Ярый, Гарифҗан абый, исәнлеккә-саулыкка.

– Исәннәрнең дә, үлгәннәрнең дә исәнлегенә?

Илдар чыгып киткәч, Гарифҗанны да, Әминәне дә бер үк сораулар борчыды. Бая тәрәз шакыган кеше Сахап булмады микән? Нигә ул дәшмәде? Шулай аптыраошта калып басып торганда, тагын кыңгырау чыңлады. Мәтәлә-кадала күрше карчыгы Маһибану килеп керде.

– Уф-үлдем. Сахап кайткан, ди. Дөес сүзме ул?

– Син каян ишеттең соң әле?

– Бе сыеым күшәми. Төннә тоып, шуның хәлен белеггә абзагга чыккан ием. Беочтан угамга да күз салдым. Гитлег кайтып бага. Шул әйтте Сахапның кайтканын. Ул үлмәгәнмени? Сугыш беткәнгә кыгык елдан атык бит инде. Кайда йөгән соң ул? Ник ул синең белән сугышты түгелме соң, Гаиф?

– Үзем җирләдем, үз кулларым белән.

– Әллә аххызаман җитә микән?! Аххызаман җиткәндә, мәетләг кайта башлый, имеш.

Ул арада, дәрәҗәсен белеп кенә, сул як күрше Гайшәбикә килеп керде. Башына чәшке бүрек кигән, аның өстеннән шәл бәйләп куйган. Яше дә бар инде үзенең. Шуңа карамастан, хәл-җегәре ташып тора. Бик оста алыпсатар. Тапмаган әйберсе юк. Кирәк булса, күгәрчен сөтен дә табып бирә.

– Исән-саулар гына торасызмы? Сахап кайда? – дип сорады ул, кирә-керешкә.

– Син дә ишеттеңмени? – диде Әминә.

– Ярты авыл ишетте инде. Яшьлек мәхәббәтен сагынып кайткандыр инде ул, име, Әминә?!

– Ой, белмим, белмим, Гайшәбикә, – аннары Әминә күршесен читкәрәк дәшеп алды, сүзләрен кыяр-кыймас кына әйтте. – Кершән, иннек-мазар кебек әйберләрең юкмы?

– Иң шәбе бар. Үземә генә дип алган идем. Бәясе дә арзан гына – өч сум. –

Гайшәбикә кесәсеннән иннек чыгарды. – Мә, шуны сөртеп җибәр әле. җитмеш биш яшьлек әбиеңнән унсигез яшьлек кыз ясый да куя.

Әминә, шкаф артына кереп, иреннәрен кызартып чыкты. Бераздан авылга кадәр кайтып та Сахапның өйгә кермәвенә аның эче поша башлады. Монда кадәр кайтып, зиратта үлеп ятсын тагын, дип тә курыкты. Ире дә чыгып бер әйләнеп керергә булды. Шушы сәер төндә зиратка китте.

– Сахап сугышта үлеп теелгәнне, монда кайтып үлеп ятсын тагын, – диде Мәһибану да. – Сыегга ашатыга печәнем бетте. Уф, үлдем. Бакча башындагы кибәнне сүтеп, печәннеккә кетәсе ба ие. Безнең авылда сәнәк тоталык мужик та юк бит. Сахап булышмас микән?! Ул астан сәнәк белән биеп тоса, Гитлег өстән алып тоса, дигән ием. Монда хәтле кайтканны сәнәк беән печән күтәгеглек кенә хуты бадыы әле. Уф, үлдем!

– Сиксәнгә җитәсең бит инде. Ул сыерларыңны бетерергә вакыт. Берәү генә дә түгел бит әле, ике сыер! – диде Гайшәбикә.

– Ике сыег. Җиде саык. Уф, үлдем!

– Ничек карап бетерәсең аларны?

– И Гайшә, малай. Йоклап ятып булмый. Йоклап ятсаң, сәке башы котлый. Казандагы кияү белән кыз дип чабам инде. Кияү ит ятата. Аңа Октяб бәйгәменә өстәлдә – каз башы, каз тәпие, каз бүтәкәсе, Яңа елга – сыег теле, 23 февгальгә – халадис, Сабантуйга какланган каз булсын. Шунсыз кеше түгел мин, ди ул.

– Аа-а, харап икән. Киявең ит ярата. Кайтып сиңа булышмый. Җәй көне печән әзерләшергә дә кайтмый бит. Берүзең чабасың.

– И малай, кайталмый шул. Эштә бит. Эш кешесе.

– Кайда эшли соң ул?

– Улмы? Ул завуд саклый. Бөтен завуд аның кулында. Бе тәүлек эшли, өч тәүлек ял итә.

– Өч тәүлек ял итеп, күт катындагы Казаннан сиңа булышырга кайталмыймы?

– Кайталмый шул. Уф, үлдем. Үзләенең дә бакчасы баг бит. Анда алагның игга дигән җимеш үсә. Нәкъ печән өстендә өлгеә. Шуны кагга ашый икән. Саклап ята.

– Һе, җәй буена карга кудым, диярсең.

– И тәмле җимеш ул. Компотка шәп. Бег ун ел элек компотын миңа да кайтагганнаг ие. Уф, үлдем, әле дә тел очында тоа.

– Киявең эшкә кайтмый. Мал суйган көнне ыжгырып кайтып җитә.

– И малай, үзе белә дег инде.

* * *

Илдар кайтып яткан иде инде. Күзенә йокы кермәде. Торды, киенде дә чыгып китте. Урамга чыккач күрде, Гарифҗан белән Әминәләрнең тәрәзәләрендә ут бар. «Димәк төнге кунак кайтып җиткән. Сөйләшеп утыралар булыр», дип уйлап алды. Хәзер барып кереп, «Күрдегезме?! Кайттымы?! Минем сүз дөрескә чыктымы?!» дип әйтергә иде. Чакырылмаган кунакның теге дөньядан ничек кайтканын да беләсе килә. Ул тагын Гарифҗаннарга китте. Хәлбуки, йөгәнен алырга да онытмады.

– О, монда сез байтак җыелган. Нихәлләрегез бар? Нихәл, Алам-сатам? – диде ул, ишектән керүгә.

– Кешедән көлеп йөрмә әле, Гитлер! – диде Гайшәбикә. – Өй алып, мунча сатканым юк.

– Уф, үлдем дә монда икән. Син үлмәдеңмени әле? Миңа быел кырык тула.

Мин сине белгәннән бирле «Уф, үлдем», дисең. Үзең һаман үлмисең. Хәлләр арудыр бит, Уф, үлдем?

– И-и-и. Илдаг малай, бик әйбәт түгел әле.

– Ни булды?

– Бег сыегым күшәми.

– Синең сыер күшәми, ә минем айгыр кешни.

Сүзгә Гайшәбикә кушылды:

– Син, Гитлер, нигә гел йөгән тотып йөрисең?

– Берәрсе бәйләнә калса, башына йөгән киертеп куям.

– Бу авылда кем бәйләнсен инде сиңа, Гитлер? Бөтен Өтермәсенә ике-өч мужик. Кайда соң синең стансадан алып кайткан кунагың?

– Белмим. Мин аны утырттым. Алып кайттым.

– Күзеңә генә күренгәндер ул. Бәлки, күзең дөрес түгелдер.

– Синең күз генә ул акчадан башка берни күрми. Минем күзләр, Аллага шөкер, дөрес күрә әле.

– Акча күрсәгез, барыгызның да күзе кыза. Сахапның, дим, өс-башы ниндирәк иде соң? Юньлеме? Бүреге нинди иде? Бүрегенең элә-танагы бар идеме?

Ул арада Маһибану да соравын биреп калырга ашыкты:

– Кулына сәнәк тотып печән ташый алыгмы?

– Тавык төшенә тары кергән, ди. Берегездә – печән, берегездә – бүрек сату кайгысы. Син, Алам-сатам, башыңдагы бүрегеңне шудырмакчы идең мәллә?

– Болай гына сорадым ла. Бу бүрек үземнең башта да бик ипле генә утыра әле.

– Бүек дигәннән, минем кияүгә бег шәп бүек киәк ие, – диде Маһибану, Гайшәбикәгә карап.

– Алып җибәр, әйдә. Бер дигән чәшке бүреге. Сатарга да жалкы. Үземә дип алган идем. Ирләрнеке булып чыкты. Урам буйларыннан һай киләсең, бүрекләрне әлчи киясең. – Ул, шәл астыннан бүреген салып, Маһибануга тоттырды.

– Кияүнең башына сыямы соң бу?

– Нишләп сыймасын, юләр. Бу бит – безразмерный бүрек. Эчендә бавы бар. Шуннан тартып кечерәйтеп була, зурайтып була.

– И малай, белмим инде, алыйммы-юкмы? Күпмегә сатасың?

– Өч йөз иллегә алдым. Өч йөз кырык бишкә бирәм.

– Уф, үләм. Кыйбат инде. Бег сыег бәясе.

– Базарда биш йөз тора.

– Алып, кияүгә бүләк итим микән? Биггәк кыйбат. Әй, аңа бүек алып үләг хәлем юк. Иске бүеген генә киеп йөгсен әле.

Әминәнең:

– Гарифка да бүрек кирәк. Фронтовик башы белән минем картның да бер юньле бүрек кияргә хакы бардыр, – дип әйтүе булды, Маһибану кырт кисте:

– Юк, кияүнеке бу бүек. Кияүгә алам! Аның да Казанда, уында эшләп, чәшке бүек киягә хакы баг.

– Гарифҗанга алам.

– И-и-и синең бе сәнәк печән дә күтәалмый тоган игеңә нинди бүек ди ул.

– Аның каравы, фашистларны Берлинга кадәр куып барган. Ә синең киявең бакчасыннан карга куып чыгара алмый.

– Бүген игең каз гына куа ала. Каз кияве булып йөгсен инде.

– Ә синеке карга куа. Карга кияве. Бүрекне мин алам.

– Юк, мин алам. Әйдә, мин өч йөз иллегә алам.

– Өч йөз илле биш.

– Өч йөз җитмеш.

– Өч йөз җитмеш биш.

– Дүт йөз!

– Дүрт йөз егерме.

– Дүт йөз кыык!

– Артыгын бирә алмыйм. Алсана. Шул кияү дип үләсең инде. Тумырган да сөягән, балта-пычак тимәгән бер киявең бар инде.

– Ах сине. Нәссә ди бит әле. Минем кияүне яманлап тога. Сыкы пескус сим етә кәсисен, гат. Птысыкыму, синамитекү семитайкаме суләможтуф. Кетеметенмату сафичахасимофакси хинаматы сыбыхабысбыду, заразы.

– Әч-чак теле. Әч-чак, әч-чак... Ни сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы соң син? Синең телеңә эләксәң, җиде еллык бизгәгең качар. Син, Мәһибану, үзеңне эттән алып эткә салсыннар – сүз әйтмисең, киявең белән сыерыңа тел тидергән кешене эттән алып эткә саласың. Ярар! Җитәр! Юк өчен талашмыйк. Бер бүрек өчен бер-беребезнең башын ашамыйк. Син бүрек дип төкерек чәчкәндә, Сахап килеп керсен тагын...

Бәхәсне бик тә мәмнүн булып тыңлап торган Гайшәбикә бүрекнең бәясен дүрт йөз җитмешкә күтәрде.

– Аласыңмы? – дип сорады.

– Алам, алам, – диде Маһибану.

– Акчаңны кайчан бирәсең?

– Бүген үк биәм. Чыгуга. Уф, үлдем.

Чоланда аяк тавышы ишетелде. Ишек ачылды. Гарифҗан икән.

– Син, Гитлер, – диде ул, Илдарга карап, – йөрисең шунда җил иләп, җил дагалап. Кысыр сөенче белән. Зиратта булдым, авылны әйләндем. Беркайда юк Сахап. Тучны кайттымы соң ул?

– Тучны кайтты. Менә – ипи!

Бүрек сату шатлыгыннан башы күккә тигән Гайшәбикә башта шаркылдап көлде, аннары сөйли башлады:

– Кайсыдыр бер авылда төнлә бер хатынның сугышта үлгән ире кайтып кергән, ди. Тужы шушы Сахап кебек бик күп еллар үткәч кайтып кергән, ди. Кайтып кергән дә төнлә хатынына мунча ягарга кушкан. Хатыны яккан. – Гайшәбикә озак кына пауза ясап торды.

– Шуннан... – Маһибану түземсезлек белән вакыйганың дәвамын көтә иде.

– Нәрсә шуннан?..

– Мунча яккач, нишләгәннәг?

– Нишләсеннәр?! Рәхәтләнеп мунча кергәннәр.

– Уф, үлдем.

– Мәһдиев тә шундый ук хәлне яза, – дип сөйләп китте Әминә. – Бер авылда төнлә бер хатынның күптән сугышта үлгән ире кайтып керә. Кайтып керә дә моңа мунча ягарга куша. Хатыны яга. Керәләр. Чишенәләр. Ире ләүкәгә менеп утыра. Хатыны идәнгә утырып чәчләрен сүтә башлый. Бервакыт иренә күтәрелеп караса... Ләүкәдә бер күзле Дию пәрие утыра ди. Хатын мунча ишелерлек итеп кычкырып җибәрә дә шәрә килеш чыгып чаба. Артыннан Дию пәрие: «Ярый әле миннән ычкына алдың. Бәхетең бар икән. Югыйсә, күрмәгәнеңне күрсәтә идем бит», – дип кычкырып кала.

– Минем дә укыганым бар. – Илдар йөгәнен бер кулыннан икенче кулына күчерде. – Туже шулай үлгән исәптә йөргән бер фронтовик кайта авылга. Кайтып бераз торгач – ка-ча. Сатлыкҗан була те-ге. Су-гыш бет-кәч, чит илдә яшәп я-я-я-т... – Илдар-Гитлер җөмләсен әйтеп бетерә алмады, урындыкта утырган килеш гырлап йокыга китте.

– Күр әле, Сахап та качты микән әллә?.. Әллә Сахап та?.. – Гайшәбикә шулай диде дә, җавап көтеп, Гарифҗанга төбәлде, тегесе дәшмәгәч, әйтеп куйды, – димәк, моның да кыңгыравы бар!

Аның сүзен Маһибану куәтләде:

– Әйе, шулай. Баг, баг. Кыңгыавы баг. Кыңгыавы булмаган кеше кыык елдан атык ауылга кайтмый йөгимени?!

– Гитлер үзе дә исән-сау, ди бит. – Гайшәбикә бу сүзләрне утырган җирендә эрегән Илдарга карап әйтте. – Чит илдә рәхәтләнеп яшәп ята ди. Бу Сахап та чит илдә яшәмәде микән? Аның кесәсендә безнеке кебек агач акча түгел, яшел акча – дәлләрдер әле. Ул немецка сатылып, моңарчы Ярман җирендә яшәп ятмады микән?! Ярманда нинди акча әле анда? Дәлләр түгел бит анда. Ә-ә-ә. Марка анда, марка. Дәлләре булмаганда, маркасы да эчне төртеп тишми.

– Күг әле син ә, сатлыкҗан буып чыкты бит әле бу Сахап. Шуңа киге киткәндег бу. Уф, үлдем. Шулай бит, Гайшә.

– Шулай! Сатлыкҗан – артык җан, диләр. Эт тырнагы!

Гайшәбикә тагын нидер әйтмәкче иде – Гарифҗан туктатты:

– Җитте сезгә! Сахап кебек чиста, саф күңелле кеше турында шундый сүзләр әйтергә ничек телегез бара?!

Гайшәбикәне туктатырсың, бар. Ул инде тәмам кызган иде:

– Синең, Кыяк, үзеңнең дә артың чиста микән әле?! Син Сахапны үлде, үзем күмдем, дип сөйләп йөрисең. Бактың исә, үлмәгән. Менә ышан сиңа. Анда, тегендә, минәйтәм, бергәләп шухыр-мухыр китермәдегез микән? Өряңа машина алып куюың да шикләндерә. Юк, син сугышта да әмәл-чөмәл китереп йөргәнсеңдер!..

Әминә дә түзмәде:

– Шул ике ишекле бөкре машинаны да күпсенмәгез инде. Минем ирем – Берлинга барып җиткән кеше. Ил өчен җилкәсен умырттырган кеше. Ике орден, биш медаль алган кеше, – диде горурланып.

– Әй, беләбез инде ничек сугышканын. Күпер астында качып яткан. – Гайшәбикә ихахайлап көлде.

– Тәк, сезгә өйләрегезгә кайтып йокларга вакыт түгелме?! – Гарифҗан сәгатькә карап куйды.

– Безне кайтарып җибәреп, Сахап белән тагын берәр афёра эшләмәкче буласыңдыр әле.

Гайшәбикәнең бу сүзләреннән соң Гарифҗан исән калган кулын селтәп куйды да киенеп тагын чыгып китте. Чыкканда, ишекне кинәт ачуы булды, Чатан Шәйхине бәреп ега язды. Шәйхи шыпырт кына чоланга кергән дә карчыкларның Сахапны сүтүен ишек аша тыңлап торган. Ул үзе чатан булуы аркасында сугышка бармый калган. Фронтовикларны сөйми. Гомер буена шикаять язып, тырнак астыннан кер эзләп, авылдашларының канына тоз салып яши. Гарифҗан аңа дәшмәде, чыгып китте. Шәйхи өйгә керде. Бусагага утырды да кыскарып беткән керле галстугын рәтләде, тонык күзләрен идән ярыгына текәп, җәенке борынын бертуктаусыз тарта-тарта сөйли башлады:

– Кыякны әйтәм, үзе Сахапны сугышта үз кулларым белән күмдем, ди, үзе авыл бетереп шул Сахапны эзләп йөри. Что-то монда не чисто. Гарифның орден-медальләре дә үзенеке микән әле? Тикшертәсе бар.

Шәйхигә Әминә:

– Их, син... Ходай бар бит! – дип кенә әйтә алды.

Ул арада Гарифҗан кире әйләнеп керде һәм карчыгына эндәште:

– Әминә, мин бая гараж ишеген ябып йөргәндә, бер ир заты безнең чоланнан нәрсәнедер урлап чыгып китте. Култык астына кыстырган иде. Артыннан чабып та карадым, кычкырып та карадым. Караңгыда юк булды.

– Безнең анда кеше тиярлек әйбер юк.

Мәһибану сикереп торды:

– Ах мөгтәтләг, минем сыегга башак болгата тогган таягымны алып чыгып китсеннәг тагы, Уф, үләм! – дип мәтәлә-кадала чыгып китте.

Гайшәбикә дә сикереп торып ишеккә ташланды:

– Бүрек, минем бүрек!..

Алар ни арада әйләнеп тә керделәр. Гайшәбикә, шәлен артка шудырып, чәчләрен йолкый-йолкый кычкыра башлады:

– Бүрек юк! Юк бүрек!!!

– Нинди бүрек иде соң ул? – дип сорады Гарифҗан

Гайшәбикә Мәһибану кулындагы бүреккә төртеп күтсәтте:

– Нәкъ менә шундый бүрек. Өч йөз тәңкәгә алдым бит мин аны. Каравыл! Милиция!!!

Мәһибану, йөзенә гаҗәпләнү билгеләре чыгарып, аңа карады:

– Өч йөз тәңкә! Безгә өч йөз иллегә алдым, диден бит. Ах, алдакчы тәге. Спикуянт! Җитмәсә, ике бүгеге булган. Бесен тышта калдыгып кегән. Хәессез. Күг әле син аны, безне Әминә белән талаштыгып, бүгегенең бәясен күтәгеп утыга бит. Оятсыз! Мә бүегеңне! Алмыйм. Ату үзеңә бег бүгек тә калмады. Нишшәп өч йөз сумлык бүгекне дүт йөз җитмешкә алыйм ди мин?! Башка тай типмәгән.

Ул бүрекне яңадан Гайшәбикәнең башына кидереп куйды. Тегесе ни әйтергә дә белмәде, аптырагач:

– Бәлки, Әминә, син алырсың? – диде.

– Юк, юк, кирәк түгел. Бабайга сарык тиресеннән тегелгәне дә ярар.

– Һай бүрегем, бүрегем! Тизрәк милициягә хәбәр итәргә кирәк.

– Нинди милиция турында сөйлисең син?! – диде Гарифҗан. – Милициягә әйтсәң, синең үзеңне эләктерәчәкләр. Спекуляция өчен!

– Һай Аллам. Кайсы якка китте соң ул, мур кыргыры?

– Күкчә ягына таба чапты.

– Син дә инде, Гарифҗан, шунда авызыңны ачып карап калмасаң...

– Чабып карадым – булмады. Кычкырып карадым – булмады. Кая инде ул, мин – инвалид, нишли алам?!

Гайшәбикә урындыкта мәлҗерәп утырган Илдар-Гитлерны якасыннан алып җилтерәтергә тотынды, яңагына йөгән сабы белән чәпелдәтте. Сискәнеп уянган, күзләре кызарган Илдар-Гитлер башта берни аңламый торды. Гайшәбикә аңа, ат менеп, Күкчәгә чабарга, бүрек карагын тотарга кирәклеген кат-кат әйтте. Тоткан тәкъдирдә бер ярты вәгъдә итте. Гитлер Гайшәбикәнең үтенечен «ярты» дигәнен ишеткәч кенә аңлады һәм әйтеп куйды:

– Җүнле аты да юк бит әле аның.

– Стансага җигеп менгән атың... – Гайшәбикә йөгәндәге авызлык белән Илдар-Гитлерның корсагына төртеп алды.

– «Бабушка»ны әйтәсеңме? Үшән бит ул. Аның белән авыл башына чыгып җиткәнче, теге «салкын тәпи»дән җилләр исәчәк.

– Туктале, – Гайшәбикә, нидер исенә төшкәндәй, пауза ясап торды һәм Гарифҗанга борылды. – Мин кергәндә, чоланыгызда ут юк иде бит. Ул мөртәт ничек күреп алган соң бүрекне?

– Бая чыкканда, утны мин кабызган идем шул.

– Ах, ахмак. Болай булгач, син урлаткансың минем бүрекне. Үзең урлаткансың – үзең түлисең!

– Кем кушкан иде соң сиңа минем өйгә бүрек ташырга?! Мин синнән бүрек сорамадым. Ут – минеке, теләсәм – яндырам, теләсәм – сүндерәм!

– Хәзер нишләргә инде? Ничек тотарга ул хәерсез каракны? Мин бүрекне кем урлаганын беләм. Беләм мин бүрекне кем урлаганын. Безнең авылда бүрек урларлык мужик юк. Аны урлаучы, беләсезме, кем? Аны урлаучы... Аны урлаучы... Сахап! Сез аның бүген төнлә колхозга акча алып кайтырга тиешле бухгалтер Әсгать белән кассир Анжеликаны стансадан алып төшәсе ат каршына чыгуын да юкка, дисезме?! Таларга чыккан бит ул. Юньле кеше төн уртасында Либәдән урманыннан чыгамы?! Ярый әле, Әсгать белән Анжелика кайтмаганнар. Әсгать акчага үзе генә китсә, шул көнне үк кайтып җитә, Анжелика белән китсәләр, өч-дүрт көнсез кайталмыйлар. Ярый әле кайтмаганнар. Бәхетләре бар икән. Шулар аркасында Гитлер да исән калган. Югыйсә өчесен дә атып үтереп, ат белән акчаны алып качкан булыр иде. Син аның кесәсендә коралы юк дип уйлыйсыңмы? Андый кеше төнлә, акча таларга коралсыз чыгамы?!

– Нинди талау, нинди корал турында сөйлисең, – диде Гарифҗан, тыныч кына.

– Белмәмешкә сабышып торма инде. Бүрекне дә, күрә торып, юри урлаткансың. Бер шайка, бер банда сез. Тентесәң, синең дә коралың бардыр әле. Юк, районга хәбәр итәргә кирәк моны. Өтермәстә кораллы бандитлар качып ята! Әйдә, Шәйхи, киттек. Районга хәбәр итәбез.

– Киттек!

Маһибану да аларга иярмәкче иде. Туктап калды. Әминәгә соравы бар икән.

– Каале, уф, үләм. Әминә, дим, сыег күшәмәсә ни була? Мәһдиевнең бегәг җигендә язылмаганмы?

– Сыер күшәмәсә, ни буласы язылмаган, ә менә бәхетеңне сыер сөзсә, ни буласы язылган.

– Ни була? Мәһдиев нәгсә дигән? Бәхетеңне сыег сөзсә...

– Көтү көтеп эшләгән акчаңны да җыеп алалмассың, дигән.

– Күг әле. Шулай дигән, ә?! Исән вакытта кайтыйм. Йә малга башак бия тогган таягымны апкитәгләг.

Гарифҗан әйтеп куйды:

– Бәхетеңне сыер сөзсә, малга башак бирә торган таягыңнан да колак кагарсың.

* * *

Чатан Шәйхи, Гитлер-Илдар, Гайшәбикә, Маһибану чыгып киткәч, өй тынып калды. Гарифҗан белән Әминә оныклары Артурны уятып, чоланга алып чыгып, чиләккә «пес» иттерделәр. Аптыраштa калып бераз утырдылар да яңадан йокларга яттылар.

Яттылар гына, тагын тәрәз шакыдылар. Тагын кырыйдагы тәрәзәне.

Гарифҗан белән Әминә берьюлы сикереп тордылар.

– Кем бар анда?

– Кем син?

– Ник дәшмисең?

Тагын яттылар – тагын тәрәз шакыдылар. Бу юлы уртадагы тәрәзәне. Отыры шакылдау тавышы түрдәге өченче тәрәзәгә күчте. Ул көчәйгәннән-көчәя барды. Әминә сәкегә утырып укый башлады:

– Әгузе билләхи минәш шәйтан ираҗим, бисмилләхир-рәхмән-ирәхим... Гариф, тагын шакыйлар!..

– Кара, кем, ник дәшмисең. Сахап, син мәллә?.. Сахап!..

– Карале, Гариф, әйдә, без дә дәшмибез. Кагар-кагар да китәр.

– Ничек дәшмисең инде? Туктаусыз кага бит ул. Йокы бирми бит ул. Кем булыр ул? Сахап булса, әйтер иде инде.

– Юк, Сахап та түгел бу, чёрт та түгел бу. Юк, чёрт бу. Җен! Җеннәр шулай күзгә күренмичә генә шакылдап йөриләр, ди, бит. Бәлки, бичурадыр.

– Алай дисәң, бичура нишләп тышта йөри әле ул?! Ул бит өйдә, өй эчендә булырга тиеш. Өйне сакларга тиеш.

– Кемдер бар инде.

Өйдә берникадәр вакыт тынлык булып алды. Әминә белән Гарифҗан да урыннарына барып яттылар. Тагын шакыдылар. Бу юлы тавыш – ишек янындагы тәрәзәдә.

– Гариф, ишетәсеңме? – Әминә иренә төртеп алды. Ул акрын-акрын ишеккә килә. Ишекне каерып керсен тагын. Син әйбәтләп бикләгән идеңме? Ә бакчага чыга торган икенче ишек яхшы бикләнгәнме? Җитмәсә ике ишек бит әле.

– Келәсен төшердем инде.

– Карале, Гариф, тере килеш күмгәнгә, Сахап сиңа ачу тотып йөрмидер ич?

– Уйлыйм-уйлыйм да уелыплар китәм, диярсең. Сахапны әйтәм. Пуля маңгаена тиеп тә исән калырга мөмкинме?

– Чынлап үлгән идеме соң ул?

– Без үлгән дип күмдек инде.

Ул исән булганмы?

– Үзен күрмәдек бит әле. Белмим, башым катты.

– Син беркайчан да югалып калмый торган идең бит, Гарифҗан. Бу Илдар-Гитлер сине дә аптыраштa калдырды, ә?! Чын Гитлерны Берлинга барып туздырганны, монда конюхка сүз әйтә алмыйсың.

– Илдар-Гитлер дөрес сөйли бит. Нүжәли теге карт ишетеп-белеп алып кабердән казып чыгарган инде аны, ә?! Ышанмас җиреңнән ышанырсың. Кабердән казып чыгарган тәкъдирдә дә кырык елдан артык хәбәр-хәтерсез йөрергә кирәк бит.

Өйдә кыңгырау тавышы яңгырады.

* * *

Өйгә атылып-бәрелеп милиционер килеп керде. Кулында – пистолет.

– Теге бандит кайда? – дип сорады ул Гарифҗаннан.

– Нишләп бандит булсын ул. Син сүзеңне үлчәп сөйләш.

– Белербез без аның кем икәнен.

– Тукта, без әле башта синең кем икәнне белик.

– Күкчәдән булам мин. Сезнең өр-яңа участковый. Менә кичә генә пушка бирделәр, – ул, башын югары чөеп, пистолетын үбеп алды.

– Шулайдыр шул. Синең кебек пистолет тотып йөргән кешене монда күргән юк иде әле.

– Тәк, кайда ул? Әйтәсеңме, юкмы? Әйтмәсәң – үзем табам.

Ул берара аркасы белән диварга ышкылып барган булды. Аннары идән буйлап тәгәрәп китте. Караватбашына чүгәләп тыңлап торган булды, өй эчендә тавыш-мазар юкмы янәсе. Кульбит ясады... Кискен хәрәкәт белән киемшкафына ташланды. Аны ачып, актарып карады. Шулвакыт тәрәз шакыдылар. Участковый, пистолетын сузып, урамга ташланды.

* * *

Артур да йоклый алмады... Аягына – бабасының киез катасын, өстенә бишмәтен киде дә тагын чоланга чиләккә пес итәргә чыкты. Бу хәйлә генә иде. Чоланга ике ишек чыга. Берсе – өйнеке, икенчесе – келәтнеке. Малайның исәбе – келәткә кереп, әбисенең берәр җимешен чәлдерү. Шуңа күрә әбисе белән бабасына берни сиздерми, шыпырт кына чыкты. Өрек, күрәгә ярата ул. Үскәч, эшли башлагач, бөтен акчасына җимеш кенә алып торачак. Артур келәткә керде. Утны кабызды. Җимешне тапты. Авызына капты. Үзе дә капты.

– Әһә, эләктеңме, җимеш карагы!

Өстенә шинель кигән бер солдат дәшә икән.

– Мин карак түгел.

– Ничек инде карак түгел. Җимеш урлап маташасың бит!

– Юк, карак түгел. Карак ул бөтен җимешеңне чәлдерә. Ә мин берне генә алам. Ә син нишләп йөрисең безнең келәттә? Син кем?

– Мин дә җимеш эзлим.

Йокы аралаш өйдәге төнге сөйләшүләргә колак салып яткан малай бу ят кешенең Сахап булырга тиешлеген чамалады.

– Син кичә станса юлында акча таларга чыккан абзый мәллә. Сатлыкҗан! Эт тырнагы.

– Эт тырнагы. Каян чыккан сүз ул? Кем әйтте аны?

– Алам-сатам Гайшә әби әйтте.

– Кайда, кемгә әйтте?

– Кичә төнлә безнең өйдә сине көтеп утырганда ,Уф, үләмгә әйтте.

– Алар мине нигә көтте соң?

– Алам-сатам сиңа бүрек сатмакчы булган иде. Уф, үләмнең бакча башындагы кибәнен сүтеп, печәнен печәнлеккә кертәсе бар. Шуңа көттеләр.

– Ул печәнне мин кертергә тиешмени?

– Кем кертсен инде аны тагын?! Безнең авылда сәнәк тотарлык мужик юк.

– Кая китте соң алар?

– Үлеп беттеләр.

– Тагын сугыш-мазар булмагандыр бит?!

– Саескан салган баштан таудан тракторы белән тәгәрәде, Әпчи салган баштан өшеп үлде, Тазторна салган баштан поезд астына эләкте, Донжуан салган баштан бер хатынның өендә начар аракы эчте. Бүре Мисбахы салган баштан түбәдән егылып төште, Берия салган баштан Казанда 7 нче катта яшәүче бер хатынның өендә балконнан егылып төште, Үтүк салган баштан электр тогына эләкте...

– Барысы да салган баштан. Ә салмаган баштан үлгән кеше бармы соң?

– Бар. Уф, үлдем бар. Ул гел «Уф, үлдем», – ди. Үзе исән. Мал асрый. Печән кертергә сине көтә.

– Әбиең көтмиме?

– Әби дә көтә. Бүген төнлә бизәнә-бизәнә көтте.

– Әбиең бизәнәмени? Бизәнмичә дә матур иде бит ул.

– Каян беләсең, абый?

– Без күршеләр идек. Синең әбиең авылның иң чибәр кызы иде. Әбиең белән бергә акбаш, какы җыеп, бергә су коенып үстек. Бар иде яшь чаклар. Җәйләрен капка төбендә кич утырулар, су буендагы кичке уеннар. Ул Сабантуйлары, печән өсләре. Әбиең белән бик дус идек без. Ул миңа, фронтка киткәндә үзе чиккән кулъяулык бүләк итте. Һай ул кулъяулык! Почмагына «Сахапка» дип язып куйган иде. Сугышта авыр вакытларда мин шул кулъяулыкны кулыма алып сагынуымны баса, күңелемне юата идем. Атакага күтәрелгәндә, бер кулымда – автомат, бер кулымда шул кулъяулык иде. Һай ул кулъяулык! Һай аның чигешләре! Синең әтиең-әниең дә шушы йортта яшиме?

– Әти – юк. Әни мине ташлап китте.

– Нигә ташлады?

– Ул кияүгә чыкты. Кияве мине алмады. Шуңа күрә мин әби белән бабайда яшим. Менә аның «подругасы» улын ташламады. Кияүгә улы белән чыкты.

– Сездә хәзер хатыннар башта бала таба. Аннары кияүгә чыгамыни?

– Юк, абый! Нишләп алай дип әйтәсез? Минем әни кияүгә чыккач та бала тапты. Хәзер шуны карый. Әби сине ярата иде мәллә?

– Белмим шул, яратты микән? Мөгаен, яраткандыр. Яратмаса, кулъяулык бүләк итмәс иде. Безнең заманда кызлар кулъяулыкны сөйгән ярларына гына бирәләр иде. Яраткандыр, яраткандыр...

– Мине күрше кызы Ләйсән яратмый.

– Яратадыр. Синең кебек матур, кыю малайны ничек яратмасын?!

– Юк, яратмый!

– Син аны берәр җиргә чакыр. Йә чана, йә чаңгы шуарга.

– Әй, җәй көне бер чакырган идем. «Әйдә, урманга каен җиләге җыярга барыйк әле», дигән идем. Бармады, ачуланды.

– Ни диде?

– «Пошёл ты, сексуальный маньяк», – диде. Сексуальный маньяк – ни дигән сүз ул?

– Маякмы?.. Маяк – ул юл күрсәтүче. Начар сүз әйтмәгән ул. Син аны тагын чакыр.

– Ачуланса...

– Ачулансын. Кызлар алар юри ялындыра. Ачуланган булалар. Белеп тор, барыбер яратачак ул сине.

– Сез, абый, чынлап әйтәсезме?

– Валлаһи.

– Абый, сезгә дә бер җимеш алып биримме?

– Рәхмәт! Мин җимеш ашамыйм.

– Мин яратам җимешне. Әби аны Казаннан алып кайткан саен миннән яшерә. Яшермәгән җире калмады. Мин барыбер табам. Эт белән бер инде мин. Ә син, абый, җимеш ашамагач, ник кердең соң бу келәткә?

– Кил монда, үзеңә генә шыпырт кына әйтәм. – Сахап иелде дә Артурның колагына пышылдап кына ниләрдер әйтте-аңлатты...

– Аңладым мин сине, абый. Аңладым! Эзләрмен!

* * *

Бүген бу өйдә йокы юк икән инде. Менә тагын Гайшәбикә белән Маһибану килеп керделәр. Берсе – бүрек, икенчесе башак таягын эзләп йөри. Гайшәбикә керүгә сорады:

– Сахап юкмы? Ың-шың да ишетелмиме? Вәйт сатлыкҗан, бүрекне алып качты бит?! Колхоз акчасын талый алмасам да, бүрек эләктердем, дип сөенәдер әле. Күр әле син аны, ә?! Төнге сәгать бердә Либәдән урманыннан акча таларга чыккан бит. Кесәсендә коралы да бар инде аның. Тәгаен генә. Андый кеше пистолетсыз йөрмәс. Алла сакласын!

– Сыегыбызны атып китә күмәсен тагын, – диде Маһибану, борчылып.

– Сыер, дисең син, – диде Гайшәбикә Уф, үлдемнең кысыр хәсрәт белән йөрүенә ачуы килеп. – Үзебезне атмаса, диген. Бөтен авылны кырып салырга мөмкин ул хәерсез.

Әминә, бүтән боларның сүзенә кысылмыйм, дип, үз-үзенә сүз бирсә дә, әйтергә мәҗбүр булды:

– Сез аның пистолетын күрдегезме? Бүрек урлаганын күрдегезме? Үзен дә күрмәдегез бит әле. Ничек телегез бара кешегә яла ягарга.

– Без яла якмыйбыз. Чынын сөйлибез. Гитлерны да үлгән дип чыгардылар. Бактың исә, бик җылы бер илдә, диңгездә су коенып ята, ди. Алма-хөрмә ашап… Шул Гитлер белән бергә ятмадылар микән әле алар?! Сугыш вакытында шимбә-якшәмбе шул Гитлерга кунакка йөргәндер әле. Тегесе мунча ягып, ит бәлеше салдырып, коймак, өчпочмак, бавырсак, кош теле, кыстыбый пешертеп көтеп торган инде. Башкалар окопта ачка интеккәндә, балда-майда йөзгән болар.

Бу сүзләрне ишеткәч, Гарифҗан укып утырган гәҗитен бер читкә куйды да, иңенә бишмәтен салып, өйдән чыгып китте. Озак йөрмәде тагын үзе. Тиз керде.

– Күпме акча җилгә очкан, – диде ул, ишекне ачуга. – Шуны җыйган кеше череп баеп калачак!

Акча сүзен ишетүгә, Гайшәбикә дерт кабынды:

– Ни сөйлисең соң син? Нинди акча, кая очкан?

– Ник, сез ишетмәгән идегезмени әле?! Безнең колхоз вертолёт сатып алды бит. Колхозчыларга хезмәт хакына өләшәсе акчаны районнан шул вертолёт алып кайтасы дигәннәр иде. Бухгалтер Әсгать белән кассир Анжелика кичә поезд белән кайтмауларының хикмәте булган. Төнлә вертолёт белән кайтканнар.

– Акча алып кайтканнармы?

– Алып кайтып җиткерә алмаганнар.

– Ни булган?

– Авария! Кирәмәт тавын хәвеф-хәтәрсез генә менгәннәр. Тау менгәч – һәлакәт.

– Әстәгъфирулла. Харап икән эш. Тагын теге мөртәтнең кулы бу. Төнлә станса юлында талый алмагач, вертолётны атып төшереп таламакчы булгандыр колхоз акчасын. Вертолётның, дим, кешеләре үлмәгәнме соң?

– Әсгать – катапульта.

– Әсгать катып үлгән?!

– Анжелика – катапульта!

– Анжелика да катып үлгән?!

– Катып үлмәгән. Катапульта. Катапультироваться итеп исән калганнар.

– Катып үлеп исән калганнар. Ә акча?!

– Капчыгының авызы ычкынып китеп, акча кырга сибелгән. Хәзер авылның эте дә, бете дә шунда акча җыярга чапты.

– Акча җыярга! Без нишләп монда утырабыз соң әле алайса?! Тиле саткан кеше кебек. Әйдә, Маһи, чаптык. Күбрәк җыйсаң, минем бүрекне алырсың.

* * *

Кирәмәт – хәтәр тау. Текә. Җитмәсә кырт киселә. Гайшәбикә белән Маһибану упкынга очтылар. Ярый әле, кар бар. Шул коткарды. Имгәнмәделәр. Кесәләре, җиңнәре, бөтен җирләре тулды. Акча белән түгел, кар белән. «Ах, Кыяк безне тагын алдады», – дип кайтырга чыктылар. Каршыларына Чатан Шәйхи очрады. Тауга вертолёттан акча сибелгәнен Гарифҗан аңа да әйткән иде. Шәйхи Гайшәбикә белән Маһибануны әллә күрде, әллә күрмәде. Тауга, акча җыярга чапты...

* * *

Тышта караңгы әле. Гарифҗан белән Әминә таң атканын көтеп тормадылар, мал карарга чыгып киттеләр. Гарифҗан абзарда сыңар кулы белән сыер астын җыештырып калды, Әминә өйгә суга кереп китте. Өстендә – мал янына кия торган иске-москы кием, кулында – яньчелеп-каралып беткән чиләк. Аның тыштан керүе булды – ишек янында басып торган Сахапны күреп алды. Ул нишләргә дә белмәде. Өй яңгыратып кычкырып җибәргәнен сизми дә калды:

– Сахап!

– Әминә!

– Сахап!

– Рөхсәтсез кергәнгә ачуланма инде. Тәрәзәне шакып карадым. Эндәшүче булмады. Күрәм – ишек ачык.

– Һай Аллам! Нишлим соң? Оятка калдым бит. Зинһар, миңа карамый тор. Өс-башымны алыштырыйм. Үземне рәткә китерим хет. И Аллам, иреннәремдәге иннекне дә әле генә мал карарга чыгар алдыннан гына сөртеп аттым бит.

Ул тиз-тиз генә өстен алмаштырды, чәчләрен рәтләде, калфагын, бәрхет күлмәген киде, битенә пудра сылады, иреннәренә иннек тартты. Кулларын җәеп, Сахап каршына килде:

– Күр әле, Сахап, син исән. Бер дә үзгәрмәгәнсең дип әйтимме соң? Әйдә, Сахап, кеше төсле күрешик инде. Яшьлекне искә төшереп кочаклашсак та, гөнаһысы булмас.

– Ярар, күрештек бит инде.

– Нишләп алай дисең. И-и-и, әллә ничек кенә булды әле бу. Үпкән-кочкан чакларыңны оныттыңмыни?

– Үпкән-кочкан җилгә очкан.

– Очмаган, бер дә очмаган, дип җырлыйлар бездә... Хәер, яшьлек хисләре суынгандыр шул инде. Күрешмәгәнгә ничә еллар? Туктале, Сахап, син исән-сау була торып та нишләп бер хәбәр дә бирмәдең. Кайларда йөрдең соң син? Гарифҗан сине үлде, диде бит. Үзем җирләдем, үзем гүргә иңдердем, үз кулларым белән, дип ант эчте. Алдаганмыни мине?!

– Юк, алдамаган. Гарифҗан – әйбәт кеше. Чын дус. Син аның кадерен бел. Андыйлар сирәк була. Фронтта аның белән бергә булуыма мин бик шат. Һәрвакыт бер-беребезгә терәк булдык, һәр тапканны бүлешеп ашадык. Бары

– бергә, югы уртак иде. Ул беркайчан да зарланмады, кеше белән әчелешле булмады. Шуңа да аның белән миңа рәхәт иде.

– Ничек болай булды соң әле бу? Гарифҗан алдамаган. Син исән. Үлеп терелдеңме, тереләй үлдеңме? Һаман башыма сыймый. – Башын Сахапның күкрәгенә куймакчы булды.

Шулвакыт өйгә Гарифҗан килеп керде. Ул баярак Маһибануның өйгә үк алып кереп, онытып калдырган башак таягын эләктереп алды һәм аны бер-берсенә елышып торган парның баш очында болгый башлады. Аннары Сахапка берне тартты. Таяк шыртлап сынды.

– Мин, юләр, – диде ул, Әминәгә күзенең агы белән карап, – сыерны җылы абзарга кертмичә, синең өйдән су алып чыкканыңны көтеп торам. Ә ул монда гыйшык-мыйшык уены уйнарга җыена. Күр әле син аны, ни арада чишенгән, ни арада бизәнеп өлгергән. Гомер кимәгән бәрхет күлмәген киеп куйган бит.

– Әстәгъфирулла. Ни сөйлисең син, Гарифҗан. Нинди гыйшык-мыйшык уены ди ул. Сахап кайткан бит. Ник күрешмисең? Ник кочаклашмыйсыз?

– Без күрештек инде.

– Әйе, әйе, күрештек.

– Күрешкәнегезне нигә миңа әйтмәдең? Сахап, чыннан да, кайтты, дип әйтергә була бит. Югыйсә, әллә ниләр уйлап бетердек.

– Сахап алдында түшләреңне, арт саннарыңны күрсәтәсең килдемени? Хәер, күрсәткәнсең ич инде. Күлмәгеңне аның каршында алыштыргансыңдыр ич.

– Авызыңнан җил алсын бу сүзләрне. Ничә ел торып ишетмәгәнемне ишеттем. Алла бар бит, Гарифҗан... Ул күреп тора. Юк, карап-карап торам да, бу арада бик сәер тотасың әле син үзеңне, Гарифҗан. Гайшәнең әйткән сүзләре дөрес, ахры. Юкка шикләнмидер ул. Ничәмә-ничә ел күрешмәгән, сугышта бергә булган ике фронтовик. Очрашуыгыз кешенеке төсле түгел. Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә, диләр. Сугыш беткәнгә кырык ел.

* * *

– Стоять. Коралыңны ташла! Кулыңны күтәр! – участковый пистолетын Сахапка төбәде.

– Мин коралны кырык икенче елда ук ташладым.

– Кесәңнең эчен чыгарып селкеп күрсәт.

Участковый каршына Гарифҗан килеп басты:

– Нигә бәйләнәсең син аңа? Нинди чебен булып тешләде ул сине?

– Молчать. Хәзер, абзый, сине дә арестовать итәм. Өеңдә кораллы бандит асрап ятасың. – Мент пистолетын Гарифҗанга төбәде.

– Син, энем, корал бирделәр, дигәч тә, алай бик масайма. Без күп күрдек инде андый коралларны.

– Үзең куркып калдың бит әле. Әнә кулларың, аякларың калтырый.

– Курыктым. Ых иттем. Култык астындагы өч бөртек җоным селкенеп куйды.

– Курка торган куян тиресен без кырык беренче елда ук салып аттык, энекәш. – Бу сүзләрне Сахап әйтте.

Участковый пистолетын Сахапка төбәде.

– Стоять. Атам хәзер.

– Безгә, энем, күп аттылар инде. Пистолеттан да аттылар, автоматтан да аттылар, пушкадан да аттылар, танктан да аттылар. Баш очында тимер козгыннар да очып йөрде. Куркыта алмадылар.

– Хәзер бер пуляны йөрәгеңә утыртып куям.

– Тимер кыйпылчыклар, ядрәләр миндә күп утырды инде. Башта да, аякта да. Син, энем, ул тимер, кәкре бармагың белән өеңә кайтып уйна.

– Ах син шулай дип торасыңмы әле? Атам хәзер.

– Ат!

– Атам!

– Ат, кабахәт!

Өйдә шартлау тавышы яңгырады. Әминә җан ачысы белән кычкырып җибәрде.

– Һай Ходаем! Сахап! Сахап!

Сахап йөзе белән өстәлгә капланды. Әминә аның янына йөгереп килде, аннары участковыйга ташланды. Мент, ике кулы белән битен каплап, идәнгә чүгәләде.

– Ай! Нишләдем мин, нишләдем мин, – диде ул, елый-елый. – Мин бит кеше үтердем! Ялгыш... Ялгыш аттым мин аңа. Кичерегез мине!

* * *

Ишегалдында рупордан тавыш яңгырады. «Место встречи изменить нельзя» фильмыннан Высоцкий тавышына охшаган тавыш:

«…Граждане бандиты!

Внимание!

Ваша банда полностью блокирована. Оба выхода перекрыты. Так что предлагаю вам сдаться. В связи с особой опасностью вашей банды, я имею указания руководства живыми вас не брать.

Выходи по одному.

Перед дверью останавливаться.

Стволы и ножи выбрасывать. Дверь под прицелом… Так что без всяких фокусов. Шаг в право, шаг в лево, попытка бегству, стреляем без предупреждения. Пошли…»

– Һай, Ходаем, Гарифҗан, нишлибез инде? – Әминә елый башлады. – Чыгарга кушалар бит. Һай, Ходаем, бар икән күрәселәр. Картлык көнемдә шундый хәлләрне күрермен дип башыма да китермәгән идем. Сахапны харап иттеләр, хәзер сине дә харап итәләр бит.

Шулвакыт Сахап башын күтәрмәсенме?!. Гәүдәсен өстәлдән алды. Тураеп басты. Горур атлап, акрын гына ишеккә килде һәм чыгып китте.

– Өнемме бу, төшемме? Нинди могҗиза бу? Сахап исән бит! Үлмәгән бит! Күр әле! – Бу юлы Әминә шатлыгыннан елый иде.

Рупор тагын телгә килде:

«Теперь Горбатый! Выходи, Горбатый!»

– Горбатый дигәне синдер инде, Гарифҗан. – диде Әминә. – Нишләдегез соң сез? Нинди ярамаган эш эшләдегез? Әйт инде. Алып китәләр бит сезне. Синсез нишләрмен мин, Гарифҗан?

Гарифҗан белән Сахап чыгып киттеләр. Аларга Сахапның исән булуына гаҗәпкә калган участковый да иярде. Аптыраште калган Әминә дога укый башлады: «Әгузе билләһи минәш-шайтани-ражим...» Шактый озак укыды ул. Гарифҗан белән Сахап кереп бүлдерделәр. Әминә шатлыгыннан кычкырып җибәрде:

– Сез исән! Сезгә тимәделәрме?

– Тимиләр, карчык, тимиләр безгә. Безнең намус чиста!

– Алар киттеләрме соң инде?

– Киттеләр. Участковыйны да алып киттеләр. Бер гаепсез кешегә аткан өчен. Үзе сөйләп бирде.

Ишек катында гаҗәпләнү белән тулы карашын Әминәгә төбәгән Сахап әйтеп куйды:

– Безнең заманда башта кешене кулга алалар, аннары төрмәгә утырталар, аннары аталар иде. Хәзер башта аталар, аннары кулга алалар икән.

– И-и-и, әйтмә дә инде, Сахап. Сорарга да онытып торам икән. Синең хәлең ничек соң, Сахап? Теге җүләр сиңа атты бит. Күкрәгеңә атты. Пуля шинелеңне тишеп керде. Нишләптер кан чыкмаган?!

– Борчылма, Әминә. Зыян юк.

– Уйлап-уйлап торам да гаҗәпкә калам мин, Сахап. Сине күмәләр, син кабердән чыгасың, сиңа аталар, син исән каласың?

Шулвакыт ишек ачылып китте. Өй тутырып Гайшәбикә белән Маһибану килеп керде. Гайшәбикә Гарифҗанга ташланды:

– Ах син, Кыяк, чукынчык, безне алдагансың ич. Күр әле нишли бит, акча сибелгән, дип, безне җәһәннәм тишегендәге Кирәмәт тавына җибәрә. Бардык. Анда вертолёт та юк, акча да юк. Чёрт та юк. Ну, Кыяк!

– Шулай итеп кенә котылмасаң сез гайбәтчеләрдән. Үземнең өемдә миңа, минем фронтташ дустыма яла ягып утырасыз бит. Алдап-йолдап кына котылып була сездән. Кусаң да китмисез бит сез.

– Шул Кыяктан алданмам дип үз-үземә күпме сүз биргәнем бар. Тәки алдый бит, нәгаләт. Бигрәк шома бәндә инде. Өстенә таракан җибәрсәң, таракан таеп егылачак, валлаһи.

– Ул сезгә әйтте бит, – диде бер читтә әле көлеп, әле елмаеп басып торган Әминә, – вертолёт тау менгәч һәлакәткә дучар булган, диде. «Вертолёт тауга ничек менсен инде?» дип сорарга икегездән берегезнең башына килмәде. Аннары колхоз вертолёт түгел, «уфалла» арбасы да сатып алалмый бит. Акча дигәндә, дөнья...

Ул сүзен әйтеп тә бетерә алмады, Маһибану сынган, идәндә аунап яткан башак таягын күреп алды һәм җәнҗал куптарды:

– Уф, үлдем! Таягым. Минем малларга башак бирә торган таягым. Кем сындырды? Үтерәм! Сыкы пгескус симетә кәсисен, гат. Кетеметенмату сафичаха симофакси хиномате сыбыхабысбыду, зараза.

Шулвакыт чаршау артыннан Сахап килеп чыкты. Маһибану, сынган таягының бер башын тотып, аның өстенә килә башлады. Гайшәбикә дә чәчрәп торды:

– Тәк, тәк, тәк... Син – Сахап! Бүрекне бир! Бир минем бүрекне! Бирмәсәң, белеп тор, башың – сары май.

– Нишләттең таякны? Миңа яңа таяк табып бирәсең!

– Бир бүрекне!

– Таяк!

– Бүрек!

Сахап тагын аптырашта калды:

– Нинди таяк, нинди бүрек сорыйсыз сез миннән?!

Бераздан Маһибану тынычланды. Ул Сахапның ничә көнгә кайтуын сорашты. Сыерының күшәмәвеннән зарланды. Кунакны, бакчадагы кибәнне аударып, печәнлеккә кертергә үгетләде. Сахап астан сәнәк белән биреп тора. Гитлер печәнлектә алып тора. Уф, үлдемнең планы шундый иде. Ахырзаман

җиткәндә, кем телеңә килсә, шул күзеңә күренер, ди. Маһибануның Гитлер исемен әйтүе булды – ишектә Илдар күренде.

– Һайн, Гитлер! – диде ул, кулын алга сузып.

– Хәлләр ничек, Гитлер? – дип сорады Гайшәбикә.

– Ал да гөл, калганын үзең бел. Бу арада акмаса да тама. Менә әле генә стакан махнул.

– Табигатьтә һәр көчкә каршы көч бар, Илдар. Тычканга – мәче, куянга – бүре, хатын-кызга – сәрхуш ир, сәрхушкә – Горбачёв, – диде Әминә.

– Горбач сүгеп тора – без салып торабыз.

– Каа әле, ул Гобачёв үзе сала микән? – дип сорап куйды Маһибану.

– Сала. Әмма нормасын белә, – дип җавап бирде Гайшәбикә.

– Номасы күпме икән соң аның?

– Ике рюмка.

– Илданыкы күпме?

– Ике стакан.

– Кү әле безнең Илдаг да номасын белә икән. Уф, үлдем.

– Ике стаканын белә. Аннары күпме эчкәнен үтерсәң дә белми. – Гайшәбикә Илдарга борылды. – Карале, Гитлер, мин сиңа ике стакан түгел, өч стакан салып бирәм. Авылга үзең алып кайткан шушы муркыргырыдан минем бүрекне генә алып бир. Шул урлады бит, мөртәт. Әйдәле, башына йөгән киерт тә...

– Бер литр куясыңмы соң?

– Куям, Гитлер, куям!

– Һи-и-и. Хәзер аны, айн момент. – Илдар ике кулы белән йөгәнне өскә күтәрде дә, чайкала-чайкала, Сахапка таба килә башлады.

Ул башта Сахапны – өйнең түренә, аннары, борылып, ишеккә таба кыса башлады. Йөгәнне киертәм дигәндә генә, Сахап ике кулы белән шинеленең изүеннән тотты да, күкрәген киереп, кискен селтәнү белән ачып җибәрде. Илдар һушын югалтып егылды. Йөгәнне үз-үзенә киертеп куюын сизми дә калды. Ыгы-зыгы башланды. Илдарны селкетеп, чәбәкләп карадылар. Ул һушсыз ята бирде. «Нашатырный» спирт иснәткәч кенә аңына килде. «Гитлер Гитлер инде ул, үз башына котыра», – дип әйтеп куйды Гарифҗан. Ишек төбеннән «Милиция! Милиция чакырыгыз!» – дигән тавыш яңгырады. Кирәмәт тавыннан Шырт Шәйхи кайтып җиткән иде. Аңына килгәч, Илдарның беренче сүзе шул булды:

– Скелет! – аннары өстәп куйды. – Ул үтә күренмәле!

Кемдер: «Өрәк!» – дип кычкырып җибәрде. Карчыклар: «Абау!» – дип читкә тайпылдылар.

– Күр әле, Гарифҗан, ул Сахапның үзе түгел икән бит, – диде Әминә, ачыргаланып.

– Үзе түгел икәнен мин башта ук белдем.

– Белдең, нигә әйтмәдең?

– Сезне сынап карыйсым килде. Кемнең кем булуын, ни уйлавын беләсем килде. Әйдә, кылансыннар әле, дидем.

– Син аның өрәк икәнен белә торып та көнләштеңмени?

– Мәхәббәт шундый инде ул, өрәктән дә көнләштерә.

– Аңа Маһиның башак таягы белән кундырдың бит...

Шулвакыт Маһибану: «Ах, Кыяк, син сындырдыңмыни әле минем таякны? Сыкы пгескус симетә кәсисен, гат! Кетеметенмату сафичаха симофакси

хинаматы сыбыхабысбыду, заразы!» – дип акырмакчы булган иде – өрәктән курыкты. Өрәк үзе дә бу вакытта сүз алып өлгергән иде:

– Әйе, минем инде ясин укылган. Җаным күктә минем. Мин аны 1942 елда ук бирдем. Илебез өчен, СССР өчен, Ватан өчен бирдем. Газиз җиребезне гитлерчылардан саклап калу өчен, соңгы тамчы каныма кадәр сугышкан фронтовик мин. Акча таларга да, бүрек урларга да кайтмадым. Фани дөнья белән исәп-хисапны мин күптән өздем инде.

Гариф, яшьти, дустым!

Син мине гафу ит инде. Син – җилкәңне умырттыра-умырттыра, Берлинга кадәр барып җиткән татар егете, орден, медальләр алган кеше – минем аркада күпме нахак сүз ишеттең. Ике тапкыр сиңа пистолет төбәделәр. Түздең, сабыр иттең, өрәк ул, дип акланып маташмадың. Рәхмәт, яшьти. Фронтовикларча тоттың үзеңне. Син хәйләкәр идең. Әмма акыллы, зирәк идең. Ул сугышта нәкъ менә шундыйлар җиңде.

Сез мине үлгәнемә үкенеп йөри дип уйлый күрмәгез тагын. Ил өчен үлү, ирләрчә үлү үкенечле була аламы? Мин бәхетле! Тормышның ваклыкларыннан өстен булуым белән бәхетле. – Аннары ул, Шәйхи, Гайшәбикәгә, Маһибануга карап, тавышын күтәрә төште. – Сез уйлаганча, сатлыкҗан да, эт тырнагы да, хыянәтче дә түгел мин. Сез мал өчен җаныгызны бирергә әзерсез. Ә менә ил өчен, халкы өчен җанын биргәннәр турында уйлап та карамыйсыз. Хыянәтчеләр – сез ул. Сез – хәтергә хыянәт итүчеләр! Хәтергә хыянәт итүчеләр – хәтәр кешеләр!

Син, Әминә! Чиста күңелле, ак-пакь кеше. Син укыйсың бит. Мине дә догаңнан калдырма! Үтенечем шул сиңа. Безгә хәзер бүрек тә, печән дә түгел, дога кирәк. Йәгез, бер дога!

– Күр әле, ә?! Менә гәеш. Җанлы җеназа булып чыкты бит әле бу, – дип әйтеп куйды Гайшәбикә.

Шунда Әминә бер авылда булган хәлне сөйләп алды. Малайлары әниләрен моргтан алып чыга. Анда мәетнең киемнәрен бер пакетка салып бирәләр. Болар мәетне туры авылның зиратына алып кайта. Пакетны сарайга аталар да оныталар. Әниләре кайта да килә, кайта да килә ди. Аптырагач, күрәзәчегә баралар. Теге әйтә, әниегезнең җан биргәндә өстендә булган һәм өйдәге кием-салымнары юылмыйча калган, ди. Шуңа борчылып кайта ул, ди. Безнең татарда мәетнең бер генә чүпрәген дә юмыйча калдырырга ярамый, ди.

Сахап китәм дигәндә генә, Артур торып чыкты.

– Абый, абый! Сез әйткән әйберне таптым. Сез келәттән чыгып китүгә таптым. – Малай кесәсеннән кулъяулык чыгарды. Артур аны Сахапка бирмәкче иде, Әминә эләктереп алды:

– Кулъяулык! Бәй! Сахап, син сугышка киткәндә, мин чигеп биргән кулъяулык бит бу. Бәй... Кайда яткан соң ул? – диде ул, табылдыкны әйләндереп карый-карый.

– Аны мин алып кайттым, – диде Гарифҗан. – Син, яшьти, ул кулъяулыкны беркайчан да үзеңнән калдырмый торган идең. Атакага күтәрелгәндә, аны учыңа кысып тота идең. Үлемнән саклый ул мине, дип әйтә идең. Тик менә мәктәп сүтәргә барган көнне аны алмагансың. Хәер, үлемгә барабыз дип беребез дә уйламады бит башта. Монда гына, диделәр. Эшкә, диделәр. Син хәтта гимнастёркаңны да кимәгән идең. Ялангач тәнгә шинель генә элгән идең. Бүген дә син шулай басып торасың. Кулъяулык гимнастёркаң кесәсендә

калган булган. Аны миңа соңыннан гына бирделәр. Мин ул кулъяулыкны саклaдым. Ул да мине саклагандыр. Чыннан да, талисман иде ул. Монда кайткач, мин аны Әминәгә күрсәтеп тормадым инде. Ни әйтсәң дә ышанмас дип уйладым. Ул кызга минем дә күз төшеп йөри иде бит. Кулъяулыкны келәттәге матчага кыстырып куйдым. Син, иптәш сержант, мине ачуланма инде.

– Нишләп ачуланыйм. Кулъяулыкны югалтмадың, ташлап калдырмадың.

– Сахап, син ул кулъяулыкны алып китәргә кайттыңмы?

– Юк, ул сездә калсын. Сезнең иминлегегезне саклап торсын. Һәм... Һәм мине дә искә төшереп торсын. Онытмагыз безне – әрвахларны!

– Менә бит бер чүпрәге юылмый яткан сездә. Шуңа кайткан ул, димәк, – дип әйтеп куйды Гайшәбикә.

– Юарга кирәк! Срочно! – диде Шәйхи.

– Әйе, кулъяулыкны юасы бар. Сезне дә юасы, күңелләрегезне юасы, җаннарыгызны чайкыйсы бар. – Аннары Сахап Артур янына килеп басты. – Ә сиңа, энекәш, рәхмәт! Чын егет икәнсең. Белеп тор, күрше кызы Ләйсән ярата сине. – Соңгы җөмләне ул малайның колагына пышылдап кына әйтте.

– Абый, чынлап әйтәсезме?

– Чынлап әйтәм! – Сахап ишекне ачты. – Мин китәм. Сезнең өчен ят бавыр мин. Озата чыкмагыз. Бу дөньядан адәм баласын ике тапкыр озатмыйлар.

Сахап китте.

Ул киткәндә, егет белән беренче тапкыр күрешергә баручы кыз кебек көттереп-ялындырып кына, кышкы таң атып килә иде.

Ниһаять, башкалар да өйләренә җыена башлады.

– Карале, Гайшә, син киткәндә, безнең чоландагы ватык суыткычтан бүрегеңне алырга онытма! – диде Гарифҗан.

– Нинди бүрекне?

– Теге Сахап «урлаган» бүрекне.

– Ах, Гарифҗан тәре, Кыяк тәре, үзе яшереп куйган икән. Мин шул бүрек дип төн буена чәчемне йолкыдым... Бер сүз әйтми бит, ә. Бу кадәр Кыяк булырсың икән!

– Сезне шулай акылга өйрәтмәсәң...

– Бөтен чоланыгызны капшап чыктым бит, югыйсә.

– Соң инде шунда... Суыткычны гына ачып карыйсы бит.

– Кайчан суыткычтан бүрек эзләгәннәре бар әле. Булмаганны...

– Бу тормышта әллә ниләр булырга мөмкин. Белеп тор!



Сания
Әхмәтҗанова

# ТАТАР КЫЙТГАСЫНЫҢ САГЫНДА

## Халкым мәрҗәне

*... Шиһабеддинебез бар иде. Кадер вә кыймметен*
*белү аның өчен түгел, безнең өчен горурлык...*
И.Гаспринский. «Тәрҗеман», 1889.

Кадер киче кемгә хәерхаһлы,
Кемгә чалма – милли горурлык?
Заманына күрә, бер Мәрҗани
Ничә «Мин»гә бүген торырлык!

Нахак, гайбәтләрдән сыену тапкан
Тәкъвалык һәм гыйлем юлында.
Хәкиме дә, гадел хөкеме дә –
Коръән-кәрим булган кулында.

Һәр адымда аңа сиздергәннәр
Үз кардәшен – кардәш сатарын...
Милләт мәрҗәненә – Мәрҗанигә
Кадер күрсәткәнме татарым?

Карун Ибрай[1] кебек кара байлар
Аермаган яхшы-яманны:
Мәдрәсәсен химаядән өзгән,
Хур итәм дип Шиһаб имамны,
Милләт бизмәнендә үлчәмичә
Шәкертләргә салган зыянны.

[1] Казан байларыннан Озын Ибрай буларак танылган Ибраһим Юнысов күз алдында тотыла.

Сания ӘХМӘТҖАНОВА – *шагыйрә; «Оч иреккә, җырым», «Пар алма», «Гәрәбә» исемле китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Язучыларның Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

Үз чорының галим вә хадиме
(Андый затлар тансык бүген дә),
Элгәр тарихыбыз йолдызларын
Балкыткан ул дөнья күгендә.

Тәкъвалылар таный Мәрҗанидә
Курсавиның алмаш-варисын.
Рухи иңдәш булып ачкан алар
Татарымның яңа тарихын.

Милләтемә Ислам нуры иңгән
Галәм гөмбәзеннән яңача.
(Алга алып беркем сансынмаган
Татар исемен әле аңарчы).

Чит мәмләкәт, ерак кыйтгаларда
Таныткан ул татар дөньясын.
Мәчетенең ае нурын җуймас,
Нинди җилгә заман куймасын.

Хәзрәтебез рухы тора кебек
Татар кыйтгасының сагында.
Ул утырткан гыйрфан орлыклары
Яшәр, яшьнәр милләт багында.

Дин галәме... Күге – Ай әләмле,
Дәһриләргә[2] урын юк анда...
Ислам нуры иңмәс яманга.
Халкың нинди – хакың шундый, диеп,
Әйттерәсе килми һаман да;
Мәргәне дә житә, мәрҗәне дә,
Бер Мәрҗани җитми заманга!

## Сабыр ит

Мендем дә гомернең үренә,
Төбәлдем хәтернең түренә.
Еракта – чигүле болыным,
Балачак – тиктормас колыным,
Уйнаклап-уйнаклап томанга күмелә.

Кашыма куеп мин кулымны,
Күзләдем кичәге юлымны.
Кайда сез, чакмадай чакларым,
Яшьлегем – йөгәнсез чаптарым,
Яшендәй, яшендәй, рәшәгә томылды.

Бер матур җыр кебек юл башым,
Сәламли бүгенге кояшым.
Көмештәй ак яллы ат кынам,
Кешнәмә, көт мине чак кына,
Сабыр ит, сабыр ит, иң тугры юлдашым.

[2] Дәһри – динсез, Алласыз.

## Әремле гамь

Яшь әремнәр, уйдык-уйдык булып,
Ызан буйларына тезелгән.
Сәлам биреп кенә китим, дисәм,
Кочып алды алар теземнән.

Иелдем дә шулчак, әсәрләнеп,
Әремнәрне алдым кочакка.
Әрем исләренең хисләремә
Иш килгәнен тойдым шул чакта.

И әремнәр – туган нигез гаме!
Тыйнак та сез, әрсез-ярсу да...
Елыйсылар килә үкси-үкси,
Тезләнепләр сезнең каршыда.

Иләсләнгән җанны гаепләмим –
Озын кышлар аны тилмертте.
Сыешалмый дөньям бер йөрәккә –
Әрем исе мине тилертте.

Учма-учма булып яшь әремнәр
Сибелгәннәр ызан буена.
Нәүмизләнеп әзерләнгән кебек
Аллы-гөлле чәчәк туена.

Янәшәдә әрем үскәнгәме,
Көяз балкып гөлләр очына...
Бәхеткә дә кайчак, кадерен бел, дип,
Әрем кирә сыңар уч кына.

## Килен-сеңелкәш

*Килен каенана туфрагыннан ярала.*
Халык әйтеме.

Кайттым әле… кайттым гүя кыз чагыма,
Аһ иттем дә, ишегалдын тутырып элгән,
Җилкән сыман киерелгән керләр күреп.
Әни, әни! Ник көтмәгән мин кайтканны?!
Кай арада керен элгән, кай арада киткән кереп.

Әнә генә кызыл эчле кәвешләрен
Салып куйган гәрәбәдәй баскычына,
Ашыга-ашыга: берсе – монда, берсе – анда...
Вак ком белән ышкый-ышкый идән юган,
Көтүгәчә өлгерим, дип, иртә таңда.

Саф керләрнең иснәп туймыйм хуш исләрен –
Әни җаным чишмәләрдә чайкагандыр,
Айкалгандыр җанкайлары бер тулышып.
Җил хисе дә, җәй төсе дә җилфердәшә керләрендә,
Туган авыл, болын яме, җир сулышы.

Сискәндем дә айнып киттем уйларымнан,
Дөньялыкка кире кайттым… кинәт дәшкән
Тавышка мин. Ә каршымда – әни түгел...
Киленебез. Мәрхүмәкәй каенанасы туфрагыннан
Яралгандыр… нәкъ әни шул. Саумы, сеңел!
Кочып алдым. Әни исе. Тулды күңел...

## Сөю фасылы

Керде Сөю фасылына бу тормышым –
Юк язларым, юк җәйләрем, көзем, кышым...
Тын да алмыйм, керфек какмыйм – ялгыш кына,
Куркытмыйм, дип, учымдагы Бәхет кошын.

Рөхсәт бирче, хис бакчаңа керим әле,
Сиңа атап, таҗ-такыя үрим әле.
Гомер уза, олыгайдык димә, зинһар,
Килде безгә Сөю яше – сөю мәле.

Син ул, беләм, мин сагынган, мин эзләгән –
Бизмәннәрне язмыш үзе тигезләгән.
Ярты сүздән аңлавыңнан сизеп торам:
Син бит минем җан тиңдәшем – игезәгем.

Керде Сөю фасылына бу тормышым –
Син – язларым, син – җәйләрем, көзем, кышым...
Калдырганмы шушы көнгә тәкъдиребез
Бүләк итеп, мәхәббәтнең соң алкышын?

## Бал оньк

*Баланың баласы – балдан татлы.*
Халык әйтеме.

Күкләр сөеп биргән бәхет –
Балдан татлы оныгым.
Сагыныплар көтеп торган
Иң кадерле кунагым.

Ул яраткан сый-нигъмәтне
Пешереп каршы алам.
Ә бабасы бал каптыра:
– Баллы телле бул, балам!

Умартачы бабасының
Сыен яратты онык.
Бал бабай, дип, муеныннан
Коча, тезенә кунып.

Балдан татлы оныгыбыз
Үз көенә йөгертә.
Бал бабай да бал әби, дип,
Сөйгән саен сөйдертә.

Озатканда оныгымны,
Теләкләр теләп калам:
– Гомер буе баллы телле –
Туган телле бул, балам!

## Бию дәресе

Кичә шомырт шау күбектә иде,
Аңа сирень килде алмашка.
Таҗын кою белән алмагачлар,
Купшы миләш керде алышка.

Хушбуй сөрткән, бигрәк көязләнгән –
Бу миләшне генә күр әле!
Касә-касә ак чәчәкләр чиккән –
Күпереп тора затлы күлмәге.

Менә-менә очып китәр кебек,
Җилкенәләр үсмер миләшләр.
Арагызга мине алыгызчы,
Биюдәшләр бит без, көйдәшләр...

Урынында басып торалмаган,
Дәрте ташкан ярсу туташ сез!
Сокланудан күңелем чәчкә атты –
Килешегез инде – охшаш без.

Читек кунычымда – чәмчә бизәк,
Бала итәк токкан күлмәгем.
Унсигезем зырлап әйләнсен бер,
Көегезне сезнең бүлмәмен.

Чү, миләшләр! Качыйм арагызга,
Үз-үземә калам хәйранга:
Гөләп таҗы кебек бөреләнгән
Яшь туташлар йөри сәйранда.

Яшьтәш түгел, беләм – өлкән апа...
Килешми ни – шул бит дөресе...
Тезелегез, миләш-сеңелкәшләр,
Бирәм сезгә бию дәресе!



Хәнәфи
Бәдигый

# ҖИЛӘК ЧИЛӘГЕ

МАҖАРАЛЫ БӘЯН

### Югалганны эзләү

Йокымсырап барган шофёр, сискәнеп китеп, кинәт тормозга басты. Юл кырыенда, кул күтәреп, кечерәк гәүдәле бер малай басып тора. Әңгерле куе урман томанында караңгы шәүлә кебек кенә иде ул. Шуңа күрә шофёр аны килеп җитәргә биш-ун метр чамасы калгач кына күреп өлгерде.

Малай чинап-сызгырып туктаган үзбушаткыч машина янына йөгереп килде. Ул арада, кабина ишеген ачып, шофёр да җиргә сикереп төште.

– Әй, малайка-ябалак, таң тишегеннән берьялгызың нишләп торасың урман юлында? – дип сорады ул, сагаю катыш кырыс тавыш белән.

Шофёрның кырыслыгына әллә ни исе китмичә, малай, аның татар кешесе булуына шатланып:

– Абый, миңа тизрәк Казанга, вокзалга барып җитәргә кирәк, алыгыз әле мине! – диде.

– Син нәрсә, адаштыңмы, әллә өегездән чыгып качтыңмы? – диде шофёр, малайның шактый тузган, таушалган киемнәренә шикле караш ташлап. Төсен салган көрәнсу кепкасы, шәмәхә вельвет курткасы, зәңгәрсу чалбары, коңгырт ботинкалары малайның юлда үз ирекеге белән түгел, нужа чигеп йөрүен күрсәтә иде.

– Юк-юк, адашмадым да, качып та китмәдем мин, абый, поездан төшеп калдым, – дип җавап бирде малай, ашыга-ашыга.

– Ничек инде поездан төшеп калдың? Егылыпмы, ялгышыпмы, әллә төртеп төшерделәрме? Кемнәр белән, кая бара идең соң?

– Ю-у-у-к, егылып та, ялгышып та түгел, тукталышта үзем төшеп калдым.

– Кая барышың иде, ник төшеп калдың? – дип янә төпченде шофёр, тагын да ныграк кызыксынып һәм гаҗәпләнеп.

– Абый, зинһар өчен, әйдәгез, тизрәк мине Казанга алып китегез инде! Нәрсә булганын юлда сөйләрмен.

Хәнәфи БӘДИГЫЙ (1941) – *шагыйрь, галим; «Күңел ялкыны», «Яшел чирәм», «Тормыш фасыллары» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

– Әйдә, алайса, минем дә Казанга кайтып барыш, мен кабинага, – дип, җитез генә руль артына кереп утырды шофёр.

Малай, үзбушаткычның биек, тимер басмаларыннан мәче кебек тиз-тиз сикеренеп менде дә шофёр янәшәсенә елышты.

Ярымкараңгы машина эчендә җылы, рәхәт иде. Мондый машинаның кабинасына беренче мәртәбә утыруы булгангамы, малай төрле рычагларга, компаска охшашлырак приборларга кызыксынып, бераз караштыргалап барды да:

– Безнең күрше авылда да бар мондый машина, ул да шулай, ата каз шикелле ысылдап-пысылдап йөри, – дип куйды, шофёрның нәрсә әйтәсен, нинди кеше икәнен белергә теләгәндәй итеп.

– Ата каз-машина! – дип көлеп җибәрде шофёр, ачылып, җанланып китеп. – Ишеткән юк иде әле андый сүзне.

– Шофёры да бераз сезгә охшаган әле: аның да кара чәчләре шулай дулкынланып тора.

– Үзе дә миңа охшаганмы әллә? – дип кызыксынып куйды шофёр, көлемсерәп.

– Бераз охшаган да шул. Ул да мыеклы, көләч йөзле. Сезнең кебек калын иренле дә. Яхшы кешеләр калын иренле була дип ишеткәнем бар минем.

– Алай икән, ул кадәресен үк белми идем әле, – диде шофёр, елмаеп.

– Тик өстендәге тузган, сырма киеме, үзе яшь булса да, бераз картайтып күрсәтә аны. Сезнең кебек күн куртка, ак күлмәк кисә, ул да шулай яшь, матур күренер иде.

Аның сүзен шофёр уйланып, тыйнак кына елмаеп тыңлады. Күзәтүчән, үткен зиһенле малайга сынап-текәлеп карап-карап алды да, сүзне икенче якка борып җибәрергә теләде:

– Синең ул машинага утырып караганың бармы соң?

– Ю-у-к! Без авылда үзебез машинадан тизрәк чатыр чабып йөрибез! – диде малай, ачыла төшеп.

– Йә, алайса, сөйләп җибәр: җиде төн уртасында, урман юлында, курыкмыйча нишләп берүзең басып тора идең? Безнең малайлар, синнән гәүдәгә дә, яшькә дә бераз зуррак булсалар да, төнлә түгел, караңгы капкач, ялгыз гына йомыш белән чыгарга да куркалар. Менә кайткач сөйләп күрсәтим әле мин аларга, юлда сине ничек итеп очратуымны. Пожалуй, моннан соң, оялуларыннан, куркулары бетәр.

– Сез кайда торасыз, шәһәрдәме, авылдамы?

– Шәһәрдә, үз йортыбыз белән.

– Бәлки, шәһәрдә төнлә тышка чыгу куркынычтыр ул, – дигән булды малай, аларны яклагандай итеп.

Шофёр, малайның сүзләрендә дөреслек бар бит, дип уйлап куйды, тик бу турыда сөйләшүне озайтырга теләмәде.

– Өс-башың юка күренә, туңгансыңдыр да инде син?

– Ю-у-к, туңмадым мин. Без – авыл малайлары, җәй көне күлмәк-чалбардан, яланаяк йөреп ияләнгән, чыныккан инде, – диде, бераз горурланып.

Шофёр, башын чайкый-чайкый шаккатып, таныш булмаган малайга кабат-кабат карап алды да:

– Тыштан туңган кебек күренсәң дә, эчең кайнар синең.

– Туңу турында уйлап та карамадым әле, миңа тизрәк Казанга, вокзалга барырга кирәк, – дип җавап кайтарды малай, карашы белән алга омтылып.

– Вокзал да вокзал, дисең, анда нәрсә калган соң?

– Тач өстенә туры китердегез!

– Чыннан да, берәр нәрсәң онытылып калдымы әллә вокзалда? Шуңа күрә Казанга кире кайту өчен төшеп калдыңмы поездан?

– Мин түгел, вагонга алып керергә тиешле малай онытып калдырган аны.

– Нәрсә иде соң ул?

– Эченә җиләк чиләге салынган капчык иде.

– Их, энекәш, энекәш! Кешегә ышанганчы, нишләп аны үзең алмадың соң? – диде шофёр, эшнең нәрсәдә икәнен аңлап бетермәсә дә. – Тик торганда гына башка бер малайга алырга кушмагансыңдыр бит инде син аны, берәр сәбәбе булгандыр, шулаймы?

– Әйе шул. Акчам җитәр-җитмәс булгач, билетсыз кайтырга уйлаган идем. Кулда әйбер булмаса, мин үзем тамбур арасында йә түбәдә барам. Шуңа күрә чиләкне теге малайга алырга куштым. Ул риза булды. Поезд Казаннан кузгалып киткәч, гадәттә, дүрт ревизор, беренче һәм соңгы вагоннарга икешәрләп кереп, билет тикшерә башлый. Берсе вагонның түр ягында торып кала, икенчесе тиз генә икенче башына барып баса да, билетларыгызны күрсәтегез, диләр... Алардан котылып булмый. Бераздан, тегеләр зур стансада чыгып күздән югалгач, түбәдән төштем дә малайлар утырган вагонга кердем. Шунда чиләкне алырга ризалык биргән малайдан, минем капчыкны кай тирәгә куйдың, дип сорадым. Ә ул, күзен дә йоммыйча: нинди капчык турында сорыйсың син миннән, ди. Соң, мин әйтәм, шул арада оныттыңмы әллә? Син минем капчыкны да үзең белән алырга сүз биргән идең бит, шуны сорыйм, дим. Мин болай гына әйтәсеңдер дип уйладым. Капчыгың шунда, идәндә калды, ди бу миңа, ваемсыз. Ишкәнсең икән ишәк чумарын, саңгырау ябалак, – дидем дә, ике дә уйламыйча, алдагы тукталышта поездан төшеп калдым.

– Юлга чыксаң, юлдашың үзеңнән яхшы булсын дип, юкка гына әйтмиләр шул. Егылып төшүдән курыкмыйча, ничек итеп вагон түбәсендә барасың син?

– Мин түбәдә йөреп ияләнгән инде, егылып төшүдән тамчы да курыкмыйм. Кеше талап йөри торган усал егетләр генә шүрләтә. Аларны күреп алсам, тизрәк түбәдән төшеп, тамбурда йә вагон арасында барам. Бер тапкыр чак кына туннель түшәменә бәрелеп очып төшмәдем...

– Билетсыз йөрүе кыен да, хәтәр дә икән. Чиләгеңдә әйберләр дә булгандыр инде?

– Әйе, бар иде шул. Барысын да сөйли башласаң, сүз озынга китә, абый. Шулай туры килде инде.

– Сүз башлагач, әйдә, аны җиләк чиләге кебек, ярты юлда калдырмыйк, дәвам итик. Башта ук сорарга кирәк иде дә, онытып җибәргәнмен, исемең ничек әле синең?

– Чытырман минем исемем.

– Фамилияң Урманов түгелме? Кечкенә булсаң да, хәйләкәр, үткен малай икәнсең, – дип елмайды шофёр. – Чын исемең ничек соң? Мин Фәсхи абыең булам.

Бу исемне ишеткәч, малай ничектер куркып, каушап китте. Аның шундый исемле шпанамы, жуликмы турында әнисеннән ишеткәне бар иде. Шуңа күрә, юлда йөргәндә, үз исемен дә, авыл исемен дә, Казанга кайчан килгәнен, кайчан кайтасын да чит кешегә сөйләп йөрмәскә кушты. ...Шулай бервакыт, төнлә, Казан вокзалында поезд көткәндә, өс-башы сәлперәйгән, күзе-башы акайган,

шактый кызмача бер шикле ир кеше кереп, алар тирәсендә туглангалап йөрде дә, авылларының исемен әйтеп:

– Монда фәлән авыл кешеләре юкмы? – дип, ялт-йолт карангалап, эзләнүен белде.

Бар иде авыл кешеләре. Тик, ачыгавызланып, берсе дә бу бәндәгә: без – шул авылдан, дип әйтмәде. Әмма аны-моны уйламаган, ваемсызрак бер яшь хатынның:

– Ул авылдан сезгә кем кирәк иде соң? – дип сорап куюы аны тәмам куркуга салган иде. Менә хәзер теге акайкүз әнисенең йә үзенең исемен әйтер дә, ачыгавыз хатын шунда ук аңа төртеп күрсәтер дип хафаланды ул.

Йолкыш моның сүзләрен шунда ук эләктереп алды:

– Син шул авылданмы әллә? Кемнәрне беләсең? – дип төпченәсе килде.

Әмма хатын, соң булса да, авызыннан кирәкмәгән сүз ычкындыруын аңлап, хатасын төзәтергә ашыкты:

– Юк-юк, ул авылдан да түгел, белгән кешеләрем дә юк. Болай гына сорап куйдым, – дип, сүзен очламакчы булды. Ләкин сәрхуш бәндә, зәһәрләнеп, хатынга аты-юлы белән сүгенде дә, ничек кинәт килеп кергән булса, шулай дуамалланып чыгып та сызды. Кыяфәтенә караганда, аның үзен дә кемнәрдер эзли, күзәтә кебек тоелды. Дөрестән дә, озак та үтмәде, вокзалга кизү торучы ике милиционер килеп кереп, теге кешене эзләгәндәй, бөтен җирне игътибар белән карап-тикшереп чыктылар. Шуннан соң гына бераз тынычлангандай булды. Тик бераздан, теге сәрхушнең кыяфәте әнисе сөйләгән кешегә туры килүен абайлагач, байтак вакыт пошаманга төшеп утырды.

Малайның эчтән генә үз уйларына бирелеп барганын чамалап алган шофёр:

– Чын исемең Хәлим түгелме синең? – дип сорап куйды.

– Нигә алай дип сорыйсыз? – дип кызыксынды малай.

– Язучы Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» дигән әсәрен укыганың бармы?

– Бар, билгеле, бик яратып укыдым. Хәлим дә безнең кебек бер авыл малае була бит башта.

– Хәзер Хәлим исемле малайлар шактый күп, шуңа күрә генә сорадым, – диде шофёр, көлемсерәп.

– Юк, минем исемем Хәлим түгел, Хәбир мин, – диде малай, җитдиләнә төшеп.

– Монысы да үз исемең түгелдер әле?

Китап белән кызыксынуын күргәч, малайның шофёрга шикләнеп каравы кимеде, шулай да чишелеп бетеп сөйләшергә ашыкмады.

– Ярар, ничек әйтсәң, шулай булсын, – дип килеште шофёр. – Ничәнче класста укыйсың?

– Җиденчегә күчтем.

– Мин әле сине бишенче класс укучысыдыр дип кенә уйлаган идем.

– Гәүдәгә кечерәк булгач, шулай күренәмдер инде.

– Менә хәзер син Казанга кайтырга ашыгасың. Онытылып калган капчыгың шунда торадыр дип уйлыйсыңмы? Вокзалда халык бертуктаусыз тыз да быз килеп йөреп тора бит.

– Мин үзем дә табарыма бик ышанып җитмим. Ләкин бөтенләй өметемне дә өзмим әле.

Шофёр да, малай да байтак вакыт сөйләшмичә генә бардылар. Хәбир,

кеше көлкесенә калып, капчыгымны югалттым, дип, хурланмыйча ничек өйгә кайтып керергә кирәк дип үртәлде.

Бу зур, биек үзбушаткыч машина тиз йөри торган түгел икән. Казанга барып җитәргә шактый ерак иде әле. Малайның хәлен аңлапмы, үзе дә тыныч кына барырга теләпме, шофёр бүтән сораулар биреп аны борчымаска булды.

## Йокылы-уяулы уйлар

Хәбир югалырдай әйберләрен күз алдына китерде... Таза тасма белән төйнәлгән капчык авызы, биштәр кебек итеп, аркага асарга җайланган. Аның эчендә – әнисенең баш яулыгы белән капланган, озынча әлүмин чиләк. Туза башлаган ул юка яулыкның чит-читләрендәге зәңгәр бизәкләре дә шактый уңган. Бер карасаң, әллә нәрсә юк та кебек тоелды аңа: уналтышар тиенлек ике кирпеч арыш ипие, егерме икешәр тиенлек ике күмәч, әнисенә дип алган ситсы күлмәклек, дус кызына дигән бизәкле ярымтүгәрәк тарак. Туган тиешле абыйсы белән җиңгәсе биргән бер кисәк пешкән казылык, ярты кило чамасы, эченә алма повидлосы кыстырган карамель конфеты.

Әмма, икенче карасаң, бар да бик кирәкле, кадерле әйберләр шул. Болар авыл кибетенә сирәк кайта һәм күпләрнең алырга акчасы да җитми. Каян килеп җитсен: аның әнисе, бер көн дә калмыйча колхоз эшенә йөрсә дә, хезмәт көненә бер уч арыштан башка нәрсә бирмиләр. Башкача беркайдан ярдәм дә юк. Әле өстәвенә әллә нинди салымнар, заемнар түләтәләр. Түләми кара! Әнисен һаман саен: түләмәсәгез, сыерыгызны алып чыгып китәбез, балаларыңны приютка бирәбез, үзеңне төрмәгә ябабыз дип куркытып кына торалар. Әби-бабаларының кулак дип таланганын, бабасының төрмәгә ябылганын әнисеннән ишетеп белә ул. Шуңа күрә әнисен, берәр каршы сүз әйтә башласа, атаң артыннан үзеңне дә озатырбыз, дип янап-куркытып тора түрәләр. Бушлай заем түләтеп җыйган акчалар хөкүмәткә бик файдалы булгандыр, билгеле. Хәтта шул турыда «Заем» дигән җыр да чыгарганнар. Хәбир аны авыл яшьләре кичке уенда җырлаганда ишеткән иде. Заемның нәрсә өчен җыелганы кушымтасында әйтелгән икән. Хәбиргә бик кызык тоелды, шуңа күрә ул аны отып та алды:

*Заем, заем, заем, заем,*
*Без заемнар алабыз.*
*Заем алган акчаларга*
*Завод-фабрик салабыз.*

Авыл активистлары да халыкны, «төрле төзелешләргә, бишьеллык план үтәргә, коммунизм төзергә кирәк» дигән сүзләр белән тәмам әгъвалап бетереп, ихтыяри-мәҗбүри сыманрак итеп, заемга яздырырга омтыла иде.

Аларны бу хәерчелектән, фәкыйрьлектән әнисенең тырышлыгы, кичләрен, керосин булганда, бишле лампаның тонык яктысында төннәр буе утырып шәл бәйләп сатуы гына бераз коткара. Ул – бик оста шәл бәйләүче. Хәллерәк ирле хатыннар, куян, нәзек йонлы кәҗә мамыгын үзләре юнәтеп китерә. Еш кына: фәлән вакытка өлгертсәң, яхшы булыр иде дип ашыктыра. Болай әйтүләре ярап та куя: андый чакта әнисе җайлап кына: «Белмим шул, өлгертеп булыр микән, алдан килешенгән кешеләр дә бар иде. Колхоз эшеннән дә калып булмый», дип искәртеп куя. Дөресе дә шулай. Гомумән, ул алдап-ялганлап сөйләшкәнне дә, тиешле-тиешсез сүз сөйләп йөргәнне дә яратмый. Салкын тидереп, бизгәк тотып ятканда гына, бөтен тәне туңып дерелдәгәнгә, энә-җеп тота алмады.

Терелә төшкәч, бераз бәйләштерә башлаган иде башлавын, тик тәрәзәдәге утларын күреп алып, кайбер куштан, көнче хатыннар: авырып ятмый ул, төне буе шәл бәйли, дип, бригадирга җиткергәннәр. Бригадир Гафур абый, бераз туган тиешлерәк, миһербанлы кеше булганга:

– Син, Рәхимә апа, төн утырып шәл бәйләвеңне кешегә күрсәтмәскә тырыш инде. Шулай дип килеп әйтүчеләр бар, – дигәч, тәрәзәләрен ут шәүләсе күренмәслек итеп, эчке яктан зур, көрәнсу-кара төстәге калын җәймә белән томалап каплый башлады.

Хәбир әнисенең озын энәләр белән кәҗә, куян мамыгыннан бик тырышып шәл бәйләвен күп тапкырлар күзәткәне булды. Һәр күзәнәкне бик тиз, бер дә ялгышмыйча төгәл итеп үреп бара ул. Башта тыгызлап һәр ягы дүрт-биш чирек озынлыктагы шәл уртасын бәйли. Челтәр күзәнәге ялгыш төшеп калса, бер кәрәз урыны ачык кала. Шәлне зур рамга тарттырып киергәч, көн яктысына куеп караганда күренеп тора – шул тары бөртеге яки киндер орлыгы кадәр генә ачыклык.

Хатын-кыз шәлне иң әүвәл шулай тикшереп карый да инде. Уртасы әзер булгач, бизәкләп, кырыйларына пычкы тешләренә охшатып дүрт челтәр үреләә. Шуларны тегеп чыккач, шәл бәйләү төгәлләнә. Юешләп, рамга тарттырып киерәсе генә кала. Рам кырыйларына тигез ара калдырып, вак кадак кагып чыгу, шуларга шәлне дүрт ягыннан тарттырып киерүне, кипкәч, рамнан алуны абыйсы Илнур белән Хәбир башкара. Әзер шәл матур булып, кабарып тора. Ул ярыйсы гына бәягә бик тиз сатыла. Ләкин аны башкарып чыгу өчен, бик күп вакыт та кирәк шул.

Тормыш авыр булса да, авыл халкы гармунсыз, җыр-моңсыз яшәми. Яшьләр шәл турында да:

*Килештереп бөркәнгәнең*
*Яулыкмыни, шәлмени;*
*Мин уртага чыккач кына*
*Бер җырыгыз җәлмени?*

– дип җырлый шаяртып.

Билгеле, әтиләре сугыштан кайткан булса, бу тормышны тартып бару ул кадәр үк кыен да булмас иде. Колхоздагы бөтен авыр эшне дә аңа кушалар шул. Ирле хатыннар авыр эшкә йөрми, яклаучылары булгач.

Авыл кибетендә тоз, шырпы, керосин кебек иң кирәкле әйберләр дә гел булып тормый. Әллә нигә бер арзанлы кием-салым, ситсы, ипи, чәй-шикәр кайткалый. Бигрәк тә керосин кытлыгы үзәккә үтә. Зур тимер мичкәләр белән бик сирәк алып кайталар аны. Кайткан әйберне чират торып шул көнне үк алып бетерәләр. Йә акчасы, йә әйбере җитмичә калган кешеләр дә күп була.

Ярый әле кибетче Морат абый: «Бер дә борчылмагыз, җәмәгать, аның каравы, икенче юлы башта сез алырсыз», дип, исемнәрен дәфтәренә язып куя. Шуның белән ризасызлык, тавыш-гауга зурдан купмый кала. Андый чакта кайберәүләрнең күрше-күләннәре бераз әҗәткә дә биргәләп тора.

***

Хәбир Казанга җиләк сатарга дип барган иде. Базарга кич кырын гына килгәнгә, янәшә-тирәдә җиләк сатучылар күренмәде. Бер стакан каен җиләгенең ничә сум торганын белергә теләп сораштырса да, төгәл генә әйтеп бирүче булмады. Чамалап

кына бер сум дигән иде, шундук әллә каян килеп чыгып, чиратка баса башладылар. Ничә сәгать буе юлда килеп, җиләге дә шактый изелеп-сытылган, стаканга да күп керә. Сатмыйча, иртәгә калдырып та булмый: мүкләнеп, бөтенләй бозылып бетүе бар. Шуңа күрә, арзан бәягә куйганын сизсә дә, бер сумнан сатарга туры килде. Соңыннан, җиләге бетә башлагач кына, бер татар карчыгы:

– Көндез стаканын ике тәңкәдән дә сатканнарые, олан, менәтрәк, – дип әйтеп уфтандырды.

Шуннан соң, күчтәнәчлек кенә калды, сатып бетермим, дип караган иде дә... Баштук әйтергә кирәк иде аны. Бишбылтырдан бирле чират торыйк та ату алмый китик ди, тагы. Сат җиләгеңне беткәнче, дип, усалраклары янап куркыта ук башладылар...

Чиләк төбендә ике-өч стаканлык калгач кына туктый алды сатуыннан. Ә бит ул җиләкне алар урманда абыйлы-апалы өчәүләп җыйганнар иде.

Ашъяулык кебек җәелгән, кып-кызыл җиләклек очрады аларга. Леспромхоз берничә ел элек кистергән диләнкедә булды андый җиләклек. Башта, эшчеләре үзләре өчен саклап тотмыйлар микән дип, куркыбрак тордылар. Кеше-кара күренмәгәч, тәвәккәлләп, шуннан бер чиләк җыеп алдылар да инде...

Кирәкле әйберләрне сатып алганнан соң, акчасының юлга җитәр-җитмәслек кенә калуын соңыннан гына абайлап алды Хәбир. Шуңа күрә билетсыз гына кайтырга теләде. Хәзер исә, ичмасам, ярты юлга гына булса да билет аласы булган икән дип, пошынып барды.

– Энекәш, уян, Казанга килеп җитәбез!

– Йокламадым мин, абый, черем итеп кенә бардым.

– Йокы килгәндә, черем итеп алу да ярап куя, энекәш. – Шофёр үзенең дә йокысы килгәнен сиздерде. – Миңа шәһәрнең икенче ягына кирәк бит, син вокзалга ничек барып җитәрсең икән инде, энем? Әле бу вакытта трамвай-троллейбуслар да йөрми бит...

– Җәяүләп барып җитәрмен әле, – диде Хәбир, үз-үзенә дәшкәндәй.

– Ай-һай, алай дип әйтергә генә ансат ул, – дисә дә, шофёр малайның хәленә керде. – Ярый, энекәш, тилмереп йөрмә, ашыгасың да, әйдә, мин сине үзем вокзалга ук илтеп куйыйм әле.

Бәлки, ул үзенең улларын күз алдына китергәндер.

– И-и абый, сезгә бик зур рәхмәт инде. Монда, җиде юл чатында төшеп калсам, капчыктан бөтенләй колак кагармын дип курыккан идем. – Хәбир, куанычыннан нишләргә белмәде.

Малайның шатлыктан яктырып киткән йөзенә карый-карый, юл уңае булмаса да, шофёр вокзалга таба борылды. Бәлагә тарыган бу малайны төнге шәһәр урамында ташлап калдырырга кызганды ул.

– Менә, «Чытырман» энекәш, синең вокзалыңа да килеп җиттек. Малайны монда кадәр китереп куюына үзе дә канәгать иде бугай ул.

– И-и абый, сезгә күпме рәхмәт әйтсәм дә аз булыр. Сезгә ничә сум бирсәм ярар икән, – диде ул, юклы-барлы акчасын чамалап.

– Миңа акча бирергә кирәкми, киресенчә... – Шофёр кесәсеннән күн тышлы портмонетын чыгарды да, шуннан ун сумлык акча алып: – Мә, ал, энекәш, – дип, Хәбиргә сузды.

– Юк-юк, абый, кирәкми, – дип караса да, шофёр ике уйлый торган кеше түгел иде күрәсең...

Ул малайның елмаеп, кул болгап, кызу-кызу адымнар белән вокзал ишегеннән кереп киткәнен карап торды да үз юлы белән китеп барды.

## Вокзалда

Ашыга-ашыга вокзалга килеп кергәндә, Хәбир йөрәгенең дулкынланудан дөп-дөп килеп типкәнен ишеткәндәй булды.

Әмма керү белән, вокзал эченең бушап калганын күреп, күңеле әрнеп куйды. Кешеләрнең күбесе, поездларын көтеп алып, таралышып беткән иде инде. Алар хәзер йокымсырап, рәхәтләнеп вагонда баралардыр, бәлки капчык та билгесез кеше белән, билгесез якка киткәндер дип уйлады ул.

Өметенең соңгы талпынышын сынап, вокзалның сул як түренә – «Милиция» дип язылган бүлмәнең ишегенә таба атлады.

Буш хыял артыннан куып йөрүен аңлап көрсенсә дә, шулай да өмете бөтенләй үк өзелеп бетмәгән иде әле. Менә хәзер ул өмет кинәт кенә сүнгәндәй тоелды аңа: ишек төбендә кешеләр дә, капчык та күренмәде.

Шулай да, берәрсе алып куймады микән, дип, янәшә-тирәдәге диварларга тезәп куелган утыргыч asларын, аулаграк почмакларны караштыргалап әрле-бирле йөренгәләде. Табылмагач, кабат шул ишек тирәсенә басып, берәрсенең килеп чыгуын көтеп тора башлады. Алай-болай, вокзалда тәртип саклаучылар, иясез калган капчыкны күреп, бүлмәләренә алып кереп куймадылар микән, дигән нәни генә өмет чаткысы калган иде әле аның күңел түрендә.

Шулвакыт ишектән милиция киемендәге яшь кенә бер кыз килеп чыкты. Малайлар белмәслек нәрсә түгел, кызның дәрәҗәсен чамалап алды ул. Сылу гәүдәле лейтенант апаның йөзе аңа ничектер бераз таныш сыман да тоелды. Якынрак килеп, капчык турында сораргамы, юкмы дип торганда, малайның бу тирәдә нәрсәдер эзләнгәләп йөрүен чамалапмы, һөнәри сизгерлегеме, йә булмаса башка берәр сәбәп беләнме, ул да кызыксынып караштыргалап алды.

Хәбир кыяр-кыймас кына аның янына килде дә:

– Апа, монда иясез калган берәр капчык-мазар күрмәдегезме алай-болай? – дип сорады.

Погонлы апа бу малайның йөзенә нигәдер бик озаклап, игътибар белән карап торды да, аннан татарчалап:

– Ишек тирәсендә калган әйберләр күп була. Син нинди капчык турында сорыйсың? – диде, тавышына бераз кырыслык чыгарып.

Югалган капчыгын табу турындагы соңгы өмете бөтенләй өзелгәндәй тоелды Хәбиргә.

Шунда тагын бер милиционер күренде. Ул апа аның янына килеп, нәрсә турындадыр урысча сораштыра башлады. Аларның үзара сөйләшүләреннән бөтен сүзләрен аңламаса да, Хәбир «мешок» дигән сүзне аермачык ишетеп алды. Эченә тагын җылы кергәндәй булды.

Милиционер кыз Хәбиргә текәлде дә, нәрсә әйтер икән дигән сынаулы караш белән, искәрмәстән сорап куйды:

– Син нинди капчык турында сораштыра башлаган идең әле? Эчендә нәрсә бар иде соң аның?

Хәбир, яттан шигырь сөйләгәндәге кебегрәк итеп:

– Капчык эчендә әлүмин чиләк... аның эчендә... – дип тезде, нәрсәләр барын бик яхшы белгәнен сиздерергә теләве иде, үзенчә.

Ләкин милиционер апа бу малайның сүзләренә тиз генә ышанырга ашыкмады.

– Йә, йә, шуннан? Чиләгең эчендә тагын нәрсәләр бар иде?

Болай җентекләп сораштырудан, Хәбир югалган капчыгының болар бүлмәсендә булуына чынлап торып ышана башлады һәм чиләк эчендәге әйберләрне ашыга-ашыга, тотлыга-тотлыга, тагын санарга тотынды:

– ...Ике арыш ипие-е, ике булки... – Күмәчне булки дип әйтүеме, әллә чиләктәге бүтән әйберләрнең ничек куелуын күз алдына китерүеме – аны бераз каушатып җибәрде.

– Шуннан-шуннан?.. Милиционер кыз, малайның әйбер санавыннан кызык тапкандай итте.

– ...Тагын ситсы, ...карамель конфеты, ...тагын...

Хәбир аның йөзенә күтәрелеп карады. Ул, матур елмаеп, Хәбиргә көлемсерәп карап тора иде.

– Апа, нигә көләсез?

– Карале, энем, син мине танымыйсыңдыр инде, мин сине таныйм булса кирәк, – дигәне Хәбирне тәмам гаҗәпләндерде.

– Болай гына, юатыр өчен генә әйтәсездер әле, – диде Хәбир, погонлы кызның үзенә дә бераз таныш тоелгандай зур, матур кара күзләренә карап.

– Бер дә болай гына түгел. Былтыр Беренче май бәйрәмендә мин сезнең авылга кунак кыз булып килгән идем.

– Чынлапмы? Кемнәргә килгән идегез?

– Рәмзияләргә. Беләсеңме авылыгызның ул кызын?

– Нигә белмәскә, Югары очтагы Рәмзияләрне...

– Әйе. Шул Рәмзияләргә, – диде кыз, үзенең милиция киемендә булуын оныткандай, туганнарча елмаеп.

Хәбир анысын гына яхшы белә: авылга килгән кунак кызларны егетләр озатмый калмый. Бу чибәр кызны да авыл егетләренең берәрсе озата кайткандыр дип уйлап алды ул.

– Беренче май көнне клубыгызда укучылар концерты булды. Син анда «Кошлар кебек» дигән җырны бик матур итеп башкарган идең. Гармунчыгыз, ...ай-яй, бигрәк оста уйный. Апаң да «Кара урманны» өздереп башкарды, шулаймы?! Мин аны сокланып тыңладым.

– Апа, минем дә исемә төште, укучылар концертыннан соң, кунак кыз Роза, дип, сезне дә сәхнәгә чакырдылар. Җырыгызның сүзләрен төгәл генә хәтерләмим, безнең авыл турында кебек тоелган иде ул миңа. Сез артистлыкка укыдыгызмы әллә?

– Юк, артистлыкка укымадым. «Халык моңнары» дигән ансамбльгә йөрдем. Шунда Рәмзия белән таныштык. Баянчыгызны да беләм...

– Уйнаганда, ул сездән күзен дә алмады...

– ...Гармунчылар шулай инде, җырчыга карап уйныйлар...

*Роза, Роза,*
*Роза гөлнең чәчәге;*
*Матур безнең тормышыбыз,*
*Күңелле киләчәге,*

– дип сезнең турыда җырлавы булгандыр әле...

Ул арада ишектән капитан килеп чыкты. Хәбир, аның кулында үзенең капчыгын күреп, шатлыгыннан кычкырып җибәрде:

– Менә минем капчык бу!

Капитан да бик канәгать иде.

– Не потеряй, сынок, больше свой мешок, – дип, Хәбирнең аркасыннан сөйде.

– Большое ыспасибо вам, рәхмәт сезгә! – дип, ул бер капитанга, бер лейтенант кызга карап, шатлыгыннан нишләргә белмәде.

– Менә, билетсыз йөрүең сиңа күпме борчу тудырды!

– Хәзер син ничек кайтасың инде? Акчаң җитмәгәч, тагын түбәгә менәрсеңме?

– Юк, хәзер акчам бар минем.

– Каян таптың?

– Теге шофёр мине вокзалга илтеп куйды, ун сум акча да бирде.

– Машинасына да утыртып килде, ун сум акча да бирдеме... Кем икән ул, шундый яхшы кеше?!

– Матур гына, яшьрәк татар кешесе иде.

– Юлга акчаң булуы яхшы. Синең ашыйсың да киләдер бит әле?

– Анысы шулай, карыным ачты...

Роза Хәбирне буфет янына алып килде. Сары чәчле, юантык сатучы марҗага, Хәбиргә таба күрсәтеп, итле пәрәмәчләр, кайнар чәй бирергә кушты да, ягымлы гына елмаеп, китеп барды.

Рәхәтләнеп ашады Хәбир. Юка камырлы, ите мул итеп салынган «ливерный» дигән мондый тәмле пәрәмәчне авылда беркем дә пешерми.

Капчыгын янәшәсенә терәп куеп, бауларын кулына җайлап урады да утыргычка урнашты. Болай тотканда, йокыга талсаң да, капчыгыңны шыпырт кына алып китә алмыйлар. Хәер, йоклау турында түгел, кайту турында уйлый башлады ул. Ләкин әле кайтырга да ашыгып булмый: таң атмаган, яктырмаган. Караңгыда урамга чыгасы да килми.

Шунда ул югалган капчыгы эзеннән йөрүен, юлына очраган яхшы кешеләрне – шофёр белән милиционерларны күз алдына китерде. Әлегә кадәр алар ниндидер усал кешеләр булып тоела иде. Ләкин бу очрашу аңарда тәртип сагында торучыларга карата ышаныч һәм ихтирам уятты. Курыкмаска, тиешле чакта ярдәм сорарга кирәклегенә төшенде.

...Казан – зур кала, ачыгавыз булып йөрү түгел, сакланып йөрсәң дә таманга килә.

***

Хәбирдән ерак түгел үсмер кызлары белән ирле-хатынлы рус кешеләре поезд көтеп утыра. Өс-башлары, яннарындагы чемодан-сумкаларына күрә, алар шактый яхшы тормышлы шәһәр кешеләре булсалар кирәк. Кызлары гәүдәгә таза, ләкин Хәбирдән ике-өч яшькә кечерәк кебек күренә. Ул өстенә шәмәхә төстәге купшы йон кофта кигән, каштан төслерәк кабарынкы чәче зәңгәрсу бантиклап, бик матур итеп үрелгән. Бу зәңгәр күзле, алсу йөзле матур кыз әти-әнисе уртасында тыныч кына, рәхәтләнеп утыра. Ара-тирә Хәбиргә дә караштырып ала. Бәлки ул, бу малайны кызганып, нигә ялгыз гына утыра икән, дип уйлый торгандыр. Менә ул кечерәк сумкасыннан матур, ялтыравык кәгазьгә төрелгән ике шоколад конфет алды да Хәбиргә таба сузды. Ул нишләргә белмичә аптырап торганда, әтисе конфетларны кызының кулыннан иплән кенә алды да малайга үзе бирде. Хәбир шунда тапкырлык, егетлек күрсәтте: «ыспасиба» дип, ике конфетны алгач, берсен кызның үзенә кире кайтарды. Бу шундый табигый килеп чыкты ки – кыз үзе биргән конфетны бик шатланып, бүләк кебек итеп алды да ашый ук башлады. Аңа кушылып, Хәбир дә тәмләп ашады. Кызның әти-әнисе әле бер-берсенә, әле малайга гаҗәпләнеп,

сокланып карап-карап алдылар. Шулай да бу матур шәһәр кызы Хәбиргә аңлый алмаслык дәрәҗәдә ерак, моңсу бер истәлек булып кына тоелды. Зәңгәр томан артындагыдай ул ераклык кызның ягымлы, елмаюлы күзләрендә чагылды.

Хәбир шунда дус кызы Фәйрүзәне күз алдына китерде, аның шаян, серле кара күзләрен күргән саен күрәсе килә, үзенә тартып тора. Әлеге карашлар арасында аңлый алмаслык зур аерма булуын Хәбир күңеле белән бик ачык сизде.

## Күз алдындагы авыл

Хәбир күзләрен йомып, йокымсырап, уйланып утырды. Вакыт иркен. Башта ул үзен авылда итеп күз алдына китерде. Андагы күренешләр, кинодагы кебек, бер-бер артлы еш алышынып торды. Бер караганда, авылда рәхәт. Кая телисең, шунда барасың. Билет сатып аласы да, поезд көтеп утырасы да юк. Теләсәң, иртүк торып, көтү кугач, көн эсселәнә башлаганчы, малайлар-кызлар белән бергәләп, җиләккә китәсең. Иртәнге урман юлында саф һава сулап баруы шундый рәхәт. Баш очында очып-очып берөзлексез тургай сайрый. Аның йомшак, дәртле җыры күңелне тибрәтә, иркәли.

Юл кырыендагы арыш, бодай, солы басуларыннан тәмле, хуш ис бөркелә. Ике-өч чакрым ераклыктагы урманга килеп җитүеңне сизми дә каласың. Башта каен, соңрак кура җиләгенә йөрисең. Бигрәк тәмле, шулкадәр дә хуш исле инде каен җиләге. Кура җиләге өлгергәнен кешедән сорап торасы да юк: тигәнәк чәчәге сыек алсу төстән кызыл, куе кызыл төскә кергәндә, кура җиләге дә өлгерә. Кура җиләге июльдә дә, августта да пешә.

Тик җиләккә күп йөреп булмый: «уфалла» дигән кул арбасын тартып, җәй буе урманга утынга, печәнгә барырга туры килә. Авылда машина юк. Берничә трактор бар барын, тик алар колхоз эшеннән бушамый. Кая, машина-трактор, утын-печән ташырга күп кешегә ат та эләкми. Һәрхәлдә, Хәбирләрнең ишегалдына бер тапкыр да ат кергәне юк. Бөтен эш: урманнан утын-печән алып кайту, бәрәңге бакчасына тирес чыгару, казу, утырту, төбенә өю, өлгергәч, аны капчыкларга тутырып алып керү – барысы да кулдан эшләнә.

Җиләккә йөрү дә уен эш түгел, бигрәк тә – кура җиләгенә. Ул чакта көннәр бик эссе тора. Җиләк эзләп, арып-талып, озак йөргән чаклар да була. Күпвакыт урманга яланаяк йөрелә. Бер тапкыр Хәбир яман каты курыкты. Биек куралык арасына кереп, үрелә-үрелә, берсеннән-берсе эре, кып-кызыл җиләкләрне ашыга-ашыга җыйганда, ничектер аска таба караса – аның аяк очында гына, бөгәрләнеп-уралып кара елан ята! Тагын бер адым алга атлаган булса, өстенә китереп баса иде. Тавышланмыйча, әкрен-әкрен генә артка таба чигенде ул. Кара елан кыймылдамады да, урыныннан да кузгалмады. Кем белә, бәлки ул кояшта җылынып, рәхәтләнеп йоклап яткандыр, ә, бәлки, ялан тәпиле малайны харап итәсе килмәгәндер.

Ул вакыйга бер сабак та булды аңа: шуннан соң урманга яланаяк йөрергә дә, сакланмыйча куралык арасына керергә дә кыймый башлады.

Урманнан утын-печән ташу да бик авырга туры килә. Үтәр-үтмәс кул пычкысы белән утын кисеп аргач, аны кул арбасына җайлап-төяп бәйләү, эссе кояш астында өч чакрым тартып кайту тәмам хәлдән тайдыра. Арбаны күп вакыт тәртә арасына кереп, абыйсы тартып кайтса да, Хәбиргә дә бик тырышып йөк артыннан этәргә туры килә. Кайвакыт алар, апасы белән бергәләп, утын-печәнгә өчәүләп тә баралар. Андый чакта да бер дә җиңел түгел: күбрәк төяләдә, тартып кайту тагын да авыррак була.

Кайтканда урман каравылчысы килеп чыкса, башта нинди утын кискәнеңне, кайда печән чапканыңны тәфтишли. Ул әле, бер сәбәпсезгә дә утын-печәнеңне кайда туры килсә, шунда бушаттырып, төягән йөгеңне арбасы-ние белән аударып ыргытырга мөмкин. Арбаны ватып ташларга да күп сорап тормас. Кайберәүләрнең йөген фермага алып кайтып та бушаттырганы бар.

Бервакыт, авылга кайтып җитәрәк, җигүле тарантасында кукраеп утырган лесник Бижан, искәрмәстән, аларның каршысына килеп чыкты да:

– Әйдәгез әле, рөхсәтсез кискән утынигызны ферма өенә алып барып бушатыгыз! – дип җикеренә башлады. Апасы Гөлзифа югалып калмады:

– Алайса, хәзер арбаны шушында юлда калдырабыз да өйгә кайтып китәбез. Әрмис балаларын җәберләвеңне белсәләр, үзеңнең дә күзеңне ачырмаслар, арбаны өйгә үзең тартып китереп куярсың! – дигәч, Бижан шүрләп калды:

– Ярар, ярар, ул кадәр үк ачы теллеләнмә. Үзегезнең арбагызны үзегез өстерәгез. Минем аннан башка да эшем күп! – дип, төкеренеп китеп барды.

Югыйсә ул аларга бераз туган тиешлерәк тә кеше бит әле. Апасының үзәгенә үтәрлек итеп: «Күзеңне дә ачырмаслар», дигән сүзләренең мәгънәсен бик яхшы аңлады ул. Шуңа күрә генә төкеренгәләп, капыл-копыл гына үз юлы белән китеп бару җаен карады.

...Авыл вакыйгаларын онытып торып, ул кабат үзенең вокзалда утыруын исенә төшерде.

Менә монда бер эш тә юк дип уйлады ул. Биек түшәмдәге галәмәт зур, әллә ничәшәр лампочкалы матур люстралар бөтен залга тигез, бераз тоныграк яктылык бөркеп тора. Авылда булсын иде ул шундый яктылык. Каян килсен ди – күп кешедә куыксыз, сукыр керосин лампасы. Чыра яндыручылар да бар. Хәбиргә дә туры килгәли чыра телергә. Иң яхшы чырагач – сөян. Кайрысы төшерелгән юкә утыны ул. Аның төтене дә аз, әллә ни исе дә чыкмый, чыкса да әче түгел, йомшак, күзгә керми. Чыра пычагы белән бик юка итеп тә телеп була сөянне. Бишле, җиделе лампалар акчалы, хәлле кешеләрдә бар барын. Унлылары клуб, мәктәп, кибеттә генә яна. Тагын да яктырак яна торганнары бар дип тә әйтәләр. Хәбирнең андыйларны күргәне юк әле. Караңгы төн тизрәк үтсен өчен, авыл халкы кичтән үк ятып йоклау ягын карый. Сирәк кешеләр генә кич утыра. Шәһәрдә урамнарда да электр лампочкалары янып тора. Их, авылда да булса иде ул электр утлары, электр лампалары! Кышкы озын кичләрдә утырасы иде рәхәтләнеп китап укып!

Хәбир китап укырга бик ярата. Мәктәп китапханәсендәге «Рөстәм маҗаралары», «Том Сойер маҗаралары», «Робинзон Крузо», «Гулливер сәяхәте», «Күзгә күренмәс кеше» дигән китапларны кат-кат укыды.

Җиләк сатарга Казанга чыгып китүенең дә сәбәбе бар. Кыз балага юлда йөрергә хәтәр дип, апасын җибәрәселәре килми. Абыйсы кайвакыт йокысыннан куркып уянгалый: сөннәткә соңга калып утырткannar үзен. Ул аны яхшы хәтерли, куркуы шуннан калган. Аны да юлга чыгарып җибәрү уңайсыз. Хәбир үзен сөннәткә утыртуны бөтенләй хәтерләми, аның нәрсә, ни өчен икәнен дә аңлап бетерми. Хәер, мөселман малайларының сөннәтле булырга тиешлеген ишетеп белә ул. Юкса урыс малае дип үчеклиләр – аны яшереп калып булмый. Яшерерсең, бар... авылда бөтен нәрсәне энәсеннән җебенә кадәр белеп торалар.Төпчек бала ачлы-туклы үсмәсен дип җәлләп, әнисе Хәбирне дүрт яшенә кадәр күкрәк сөтен имезеп үстерде. Шуңадыр, чандыррак күренсә дә, таза, хәрәкәтчән, үткен зиһенле, югалып кала торган малай түгел ул. Укуы да

яхшы. Дөрес, апасы белән абыйсыннан бераз калыша калышуын. Ата-аналар җыелышында укытучылар аларның өчесенең дә укулары яхшы дип мактый, тик Хәбирне генә, шаянлыгы аркасында, шелтәләп телгә алгалыйлар.

## Йокларга ярамый

Хәбир – сугыш чоры баласы, шуңа күрә батыр пионерлар турында да байтак китаплар укыды. Үзе дә шуларга охшарга тырыша, батырлыкларына соклана. Тик һәлак булгач, алар аңа бик кызганыч тоела. Андый вакытларда ул батыр малайларны, куркыныч, хәтәр вакыйгалардан коткарып, исән калдыру юлларын эзләп карый. Кайбер очракларда табарга да мөмкин кебек, ләкин, икенче караганда, чыннан да, котылып кала алмаганнарын күрә. Ул, курку белмәс, кыю пионерлар: Марат Козей, Володя Дубинин, Валя Котик, Зина Портнованың батырлыгы һәм һәлакәте турында уйлап, йокыга бирешми утырды.

Хәбирләрнең пионер отряды Марат Козей исемен йөртә. Мәктәптә Марат исемле малайлар булгангамы, ул аңа ничектер якын булып тоела. Марат Белоруссиядә туып үсә. Бөек Ватан сугышы башланганда, аңа – унике, һәлак булганда, әле ундүрт яшь кенә була. Хәбир белән яшьтәшләр дип әйтерлек.

1944 елның май аенда партизаннарның разведка отряды гитлерчылар тарафыннан чолганышта кала. Иптәшләре бер-бер артлы һәлак була. Тереләй әсир алу өчен, фашистлар аны «боҗра»га кыса. Патроннары беткәч, немецлар кулына әсир төшмәс өчен, ул үз-үзен һәм фашистларны граната белән шартлата.

Сугыш башланганда, алтынчы класста укыган Валя Котик батыр пионерлар арасында иң яше була. Шаян, шук, курку белмәс малай немецларның бик күп машиналарын, эшелоннарын шартлата. Хәтта фашистларның җәза отряды кулына килеп эләккәч тә югалып калмый: сакта торган немец солдатының билендәге гранатасын тартып алып, шартлата да, берничәсен юкка чыгарып, качып котыла... 1944 елда каты яраланудан һәлак була.

Алар яшендә булса да, кайчан да әлеге пионерлар кебек, берәр батырлык эшләргә туры килер дип уйламый Хәбир. Дөрес, кыюлык, тәвәккәллек күрсәткән вакытлары бар аның да.

...Җәйнең эссе бер көне иде. Күпер өстеннән узып барганда, тал-тирәкләр, зур, юан карт өянке үскән инеш буенда ялгызы гына су коенган бер малайны күреп алды ул. Янәшә-тирәдә бүтән беркем юк. Яр кырыена терәлеп үскән өянке төбендә тирән чоңгыл бар. Малай нәкъ шул чоңгыл тирәсендә коена иде. Авыл малайлары анда беркайчан да ялгыз гына коенмыйлар: чоңгылы да тирән, суы да салкын. Салкын суның тәнне куыруын, көзән җыеруын белә алар.

Өянке янына килеп җиткәндә, су өстендә малай бер-ике тапкыр гына күренеп алды да юкка чыкты. Аны-моны уйлап тормастан, суга сикерде. Хәрәкәтсез калган малайны терсәгеннән тотып алып, яр кырыена өстерәп меңгерде. Суга баткан кешене ничек коткарырга кирәклеген үз күзләре белән күргәне бар иде: тиз-тиз күкрәгенә баскалап, йоткан суын чыгарырга кереште. Йөзе, иреннәре күгәрә башлаган малай, тончыга-тончыга, әкренләп сулыш ала башлады. Бераздан калтырана-калтырана торып та утырды. Туңудан, куркудан малайның сөйләшерлек чамасы калмаган иде. Хәл керә башлагач, сораштырып белде: шәһәрдән кунакка кайткан Радил исемле дүртенче сыйныф укучысы икән. Юньләп йөзә белмәсә дә, яр буена үзе генә су коенырга төшкән. Инешнең күмелерлек тирән булмавын белсә дә, карт өянке төбендә тирән чоңгыл барлыгын белмәгән инде. Хәбир аны җитәкләп, өйләренә кадәр озатып куйды.

Әбиләре, бу хәлне белеп:

– Рәхмәт төшкере, син оныгымны үлемнән коткаргансың. Без аның әниләре алдында гаепле булып калган булыр идек, – дип, Хәбиргә күргән саен рәхмәт әйтеп йөрде.

Хәбир Радилне коткарып кына калмады, үзе кебек яхшы итеп чумып, су астында йөзәргә дә өйрәтте.

Хәбир, бер караганда, маҗаралы вакыйгаларны эзләп тә йөрми, алар аны үзләре таба иде булса кирәк. Ни сәбәптәндер, ул күпвакыт шул вакыйгаларның нәкъ үзәгенә килеп эләгә иде.

Бу юлы да шулай килеп чыкты.

Аларның сыерларын бөтен авыл мактый: иң күп, иң куе сөтле, дип әйтәләр. Аклы-каралы, зур җиленле, түгәрәкләнеп торган матур мөгезле, алпамша гәүдәле, токымлы сыер ул.

Хәбир аны бик яхшы хәтерли. Истә калырлык вакыйга булды бер.

Шулай гадәттәгечә, көтү кайтканда, кружка тотып ишегалдына, сыер каршыларга чыккан иде. Ул чакта аңа дүрт-биш яшь кенә иде әле. Әнисе сыер сауганда, җылы сөт биргәли иде, шуны истә тотып чыккандыр. Тик малайның каршысына килеп басуын ошатмады булса кирәк – сыер, башын аска иеп, ухват шикелле түгәрәк мөгезенә Хәбирне элеп алды да, күтәреп, аркасына таба чөйде.

Адәм әйтеп ышанмаслык хәл иде бу: моны күреп алган әнисе «аһ!» дигәндә, Хәбир, берни булмагандай, кулындагы кружкасын да төшермичә, сыер сыртында алга карап утырып тора иде. Мондый трюкны, циркта гомер буе өйрәтсәң дә, бер генә сыер да кабатлый алмас! Әнисе малайны күтәреп алды. Сыер исә, «минем эш бетте» дигәндәй, абзарга таба кереп китте.

Авылда кыш та үзенчә матур. Шәһәрдәге сыман, урамда, кибетләрдә, трамвай-троллейбус эчләрендәге кебек, юешләнеп, су җыелып тормый. Кыш көне шәһәргә киез итекләр киеп барсаң, авылдагыча рәхәтләнеп йөри алмыйсың: аякларың лычма су була, кинәт суытып җибәрсә, итек олтаны шакыраеп ката.

### Чыршы бәйрәмендә

Алар өчен чыршы бәйрәме көндез булды. Кәгазь уенчыклар, ялтыравык чылбырлар белән уралып беткән зур чыршы тирәсендә туйганчы әйлән-бәйлән уйнадылар, биеделәр, җырладылар.

Кыш бабай кулыннан алынган Яңа ел күчтәнәчләре укучылар кулы белән ясалган рәсемле-бизәкле кәгазь капларга салынган иде.

Хәбиргә, яшел яфраклары арасыннан елмаеп карап торгандай, зур, матур кызыл роза чәчәге ясалганы туры килде. Ул рәсемне игътибар белән карый башлаган иде, үзенең бит алмалары шул роза чәчәгедәй кызарып чыкты: анда матур итеп «Фәйрүзә» дип язылган иде. Ул бу исемне бик ярата, аны күңел түрендә саклый, тик бу турыда беркемгә, бернәрсә дә әйтми.

Хәбир өйләренә кош тоткандай шатланып кайтып керде.

Әнисенең:

– Артыңнан кудылармы әллә, чабыш аты шикелле пошкырынасың! – дигән сүзләренә җавапны тиз тапты:

– Кыш бабай күчтәнәчен юлда кайтканда малайлар талап алмакчы булган иде, шулар белән тартышып, куышып кайттым! – дигән булды.

Әнисе күчтәнәчләр салынган шул капны кулында әйләндергәләп карады.

– Кыш бабай аларга да күчтәнәч биргәндер бит, нигә синекен тартып алырга теләделәр соң? Әллә сиңа эләккән роза чәчәгенә кызыктылармы? – дип сорады да, аннан соң, серле генә итеп: – Кулыңнан ычкындырма бу роза чәчәген! – дип куйды.

Шушы бәйрәмнән соң Хәбир белән Фәйрүзә бик нык дуслашып киттеләр.

Чиләктәге матур таракны Хәбир Фәйрүзәгә дип алды да инде.

## Кайту юлында

Иртәнге алтылар тирәсендә Хәбир кайтырга әзерләнә башлады. Ул расписаниеләрне караштырды. Аңа кирәкле разъездда туктардай, Шәмәрдән ягына кайта торган пассажир поезды, төштән соң гына була. Шуңа күрә, ул аны көтмичә, пригородный дип атала торганына утырып, Арчага кадәр, аннан соң берәр товарныйга эләгеп кайтырга булды. Шулай туры килгәне бар. Товар поездлары ул разъездда туктамаса да, аңардан кирәкле җирдә сикереп төшеп калып була. Урман аша үткәндә, поезд биш минут чамасы тизлеген киметә – алда зур борылыш бар.

Кырык-илле вагонлы состав, менә шул җиргә килеп җиткәч, «ух-ах, ах-ух» килеп бара башлый да, бераздан, «үргә» менгәндәй итә, «у-у-х, а-а-х, а-а-х, у-у-х», дип көчәнергә керешә, җайлап төшеп калып була.

Хәбирнең бер-ике мәртәбә шулай төшкәне бар. Юл кырыенда печән үскән тигез җиргә чамалап, алга таба сикермичә, аскы басмадан артка егылган кебегрәк итәсең... Кулыңдагы чиләгең дә яньчелеп өлгерми.

Хәбир Арчага кадәр билет алды да, алдан икенче вагонга керде. Гадәттә, ул вагонга авылдашлары утыра. Иртәнге якта пассажирлар аз булганга, таныш кешеләр күренмәде. Хәбир, уртагарак барып, капчыгын янәшәсенә куеп утырды. Юлга дип Казан вокзалыннан калган ике пәрәмәчен ашап, тамак ялгап өлгерде. Алдагы тукталышларда кайтучылар өстәлә барды. Ревизорлар, кереп, билет тикшереп йөрде.

Бер тукталышта, Хәбир янына аңардан зуррак өч малай кереп утырды. Башларындагы ялтырап торган каты козырёклы, формалы фуражкалары, өсләренә кигән бертөсле зәңгәрсу сырмаларына карап, болар берәр төрле һөнәр училищесында укый торгандыр инде дип уйлады. Чаярак, усалрак күренгән берсе, билет тикшерүчеләргә охшатыбрак:

– Куда едем? – дигән булды.

– Арчага, – диде Хәбир, аның тынгысыз күзенә игътибарсыз гына карап.

– По-русски знаешь?

– Нет!

– Как нет, отвечаешь же.

– Плохо знаю.

– Учись!

– Ә син үзең кайда укыйсың?

Ул малай, иптәшенә карап:

– Что он говорит? – дип сорады.

Тегесе:

– Спрашивает: сам где учишься?

Хәбир монысының татар малае икәнлеген белеп алды:

– Сез ФЗӨ дигән җирдә укыйсызмы әллә?

Теге баштагысы: «Про что он говорит?» – дип кызыксынды, бәйләнергә чамалап.

– Спрашивает: в ФЗО ли мы учимся?

– Спроси, знает ли он что такое ФЗО?

– Син ФЗӨнең нәрсә икәнен беләсеңме?

– Беләм.

– Белсәң, әйт, нәрсә ул?

– Файдасыз зимагурлар өере.

– Ах, м... тәре, нәрсә дигән була бит!

– Что он говорит такое?

– Говорит, что ФЗО – это, как бы, БКЗ, то есть: бесполезная куча зимагуров.

– Что такое «зимагур»?

– Как «бродяга», «вольнонаёмный».

– Скажи, он сам бродяга.

– Нәрсә ди ул?

– Син үзең сукбай, ди.

– Аның «Бродяга» дигән фильм караганы бармы икән, сора әле?

– Спрашивает: смотрел ли ты фильм «Бродяга»?

– Смотрел! – Хороший фильм!

– Закурить есть?

– Юк!

– Деньги есть?

– Юк!

– Щас карманы обшарим, если найдём – вырвем!

– Нәрсә ди ул?

– Кесәңне капшап тапсак, ул акча синеке түгел, безнеке булачак, ди.

– Кагылып карасын, хәзер караул кычкырам!

– Вот п...!

Ул арада поезд тегеләрнең тукталышына якынлашты булса кирәк, урыс малае:

– Давай, бери мешок, выйдешь с нами! – дип, Хәбирнең сул кулының беләзек турыннан кысып тотты да алга таба тарта башлады.

– Хәбир аның өскәрәк чыгып калган имән бармагын авырттырып тешләп алды.

– Ах ты, татарчонок! – дип кизәнә башлаган иде, аның бу сүзләре теге ике татар малаеның мин-минлегенә тиде булса кирәк, алар:

– Хватит, Саша, пошли, выходить пора! – дип, урыс малаен ике яктан җитәкләп, Хәбиргә йодрыкларын болгап янаган булып, ишеккә таба алып киттеләр.

## Стансада

Арчага кайтып җиткәч, Хәбир станса буфетына кереп, йомырка салып пешерелгән яшел суган сумсасы алып ашады. Бераздан шул тирәдәге краннан су эчәргә дип килде. Берсе Хәбирдән зуррак, икесе аның чамасындагы өч малай, колонканың нәзек торбасына ялгап, якындагы яшелчә бакчасына су җибәреп тора иде.

Яннарына Хәбир килеп баскач, теге зуррагы:

– Эчәсең киләме? – дип сорады.

– Да, – диде дә Хәбир, ни өчендер русчалатып, һәм көтеп тора башлады.

Теге зуррак малай, шлангны тартып алды. Эчәргә дип якыная башлагач, шаулап агып торган салкын суны, бармагы белән басып, Хәбир өстенә сиптерде. Шактый чыланса да, Хәбир югалып калмады, үзе дә тегеләр өстенә, лычма булганчы, су сиптерде.

Аңышып алганда, өс-башлары чыланып беткән иде инде. Шунда малайларның зурысы Хәбирне кран янына өстери башлады, аңа теге ике малай да кушылды. Шулвакыт якындагы капкадан бер апа су алырга чыгып килә иде.

– Ах, оятсызлар, өчәүләп бер кечкенә малайга ябышкансыз, хәзер әти-әниләрегезгә кереп әйтәм, күрсәтерләр алар сезгә күрмәгәнегезне! – дип, тегеләрне орышыпмы-орышты. Малайлар аклана башлады:

– Менә кара, Фәүзия апа, ул безне үзе манма суга батырды!

– Шулайдыр, берүзе, сезнең янга килеп, су сиптерә башлагандыр. Ялганлап тормагыз, ичмасам! Мин дөрес әйтәмме, энем?

– Әйе, дөрес әйтәсез апа! Мин су эчәргә дип килгән идем, бу малайларның әнә теге зурысы, краннан шлангны тартып алды да минем өскә су сиптерде. Аннан соң мин...

– Маладис, энем, булдыргансың, шул кирәк аларга! Бар, капчыгыңны ал да сыпырт моннан! Син берәр поезд көтәсеңдер. Бу малайлар артыңнан керсәләр, милициягә әйт. Вокзал эчендә милиция гел йөреп тора. Мин үзем дә кереп тикшереп чыгармын әле аларны.

Хәбир вокзалга таба китте.

Ул товар поездларын күзәтте. Менә бер паровоз водокачкадан су алды да, состав алдына тагылырга манёвр ясарга кереште. Шәмәрдән ягына таба барырга тиеш ул. Вокзал тирәсендәге дежурларны, машинистны, кондукторларны барларга кирәк. Поезд кузгалып киткәнче, ашыгып барып утырырга ярамый. Күреп алсалар, өстерәп төшерәчәкләр. Аннан соң ул тирәдә буталып йөри дә алмыйсың: милициягә тотып бирүләре бар. Биредә инде, югалган капчыгыңны табарга булышкандагы кебек, ярдәм итмәячәкләр, киресенчә, бүлмәләренә алып кереп, нишләп йөрүеңне әнәсеннән җебенә кадәр төпченәчәкләр.

Хәбир вокзал тирәсеннән читкәрәк китте дә вагон астыннан икенче якка чыкты. Монда вокзал да күренми, күзәтүчеләр дә йөрми. Тимер юлдан кырыйдарак, калку урында өелгән бүрәнәләр өстендә, берничә егет тәмәке тартып утыра иде. Хәбир, аларның күзенә чалынмаска теләп, игътибар итмәгәнгә сабышты.

Менә, ун-унбиш минуттан, кемдер бик каты куркыткандай, вагоннар дерт итеп селкенеп куйды. Гадәттә, паровозга вагоннар таккач шулай була. Аннан соң состав бераз артка таба чигенде дә туктап калды. Озак көттерми, поезд әкрен генә кузгалып китә башлады. Бу вакытта дөрес итеп чамалый белергә кирәк: ашыксаң – ашка пешүең, җебеп торсаң – утыра алмыйча, авыз ачып калуың бар.

Поезд тизлеген арттыра башлады. Аркасына аскан капчыгы йөгергәндә уңайсызласа да, Хәбир тамбур тоткасына тотынып өлгерде, биек басмалардан саклык белән күтәрелеп, тимер идәнгә менеп чүгәләде. Ул арада товар поезды станция тирәсен узып та китте. Хәзер инде тынычлап барырга да мөмкин иде.

## Товар вагоны

Ләкин тынычлык әллә ни озак дәвам итмәде. Поезд урман эченнән бара башлагач, аның колагына ниндидер чит-ят авазлар ишетелгәндәй тоелды. Башта ул поезд тавышы урманда шулай яңгырап ишетеләдер дип уйлады. Ләкин игътибар беләнрәк тыңлап карагач, түбәдә атлап йөргән, сөйләшкән тавышлар барлыгына инанды. Шәмәрдән егетләре дип уйлар иде, вагонга утырганнары күренмәде.

Ул тагын бүрәнә өстендә утырган егетләрне исенә төшерде... Әйе, нәкъ менә шул өч Шәмәрдән егете түбәдән Хәбир утырган вагонга таба килә дә инде.

Болар, ул утырып кайткан тамбурга килеп төшсәләр, Хәбирнең капчыгын да, барлы-юклы акчасын да табып, талап алып бетерәчәкләр.

Хәбиргә нишләргә хәзер? Сикереп төшеп калыйм, дисә, әле кайтасы юл да ерак, поезд да кызу бара. Әгәр алар монда төшеп, кая кайтасың, кайсы авылдан, дип сораштырганда, мин шул авылдан, дисә, аны, ике дә уйлап тормастан, талап, тибеп төшереп калдырачаклар.

Чыннан да, теге станциядә, бүрәнә өстендә тәмәке тартып утырган өч егет, түбәдән бер-бер артлы җиңел генә сикергәләп, Хәбир утырган тамбурга килеп төште.

Җилдә, кояшта күп йөреп, кагайган бу егетләр шактый шыксыз күренә. Өсләрендәге ярым эш, ярым спорт киеме, башларындагы күн, сукно кепкалары, аякларындагы төрле фасондагы туфлиләре – барысының да юлда күп йөрүдән таушалганлыгы күренеп тора.

Килеп төшүгә, авыз читендә ялтырап күренгән алтын тешлесе, Хәбиргә якын килеп, төксе генә:

– Куда шастимся, ежечок? – дип куйды.

Дәшми торган икесе, аңа кушылып, ха-ха-хайлап көлеп җибәрде.

Теге егетнең сүзләрен юньләп аңлап бетермәсә дә, күңелләре булсын дип, аларга кушылып Хәбир дә көлгән кыяфәт чыгарды.

Малайның үзләренә ияреп көлүе тегеләргә ошады булса кирәк:

– Ладно, пастись в своей хате, не бойся, езжай! – дип, тагын көлешеп алдылар.

Икенчесе, татарчалап:

– Кая хәтле кайтасың, йолкыш? – диде.

– Шәмәрдәнгә хәтле! – диде Хәбир, «йолкыш» дигәне өчен үчекләп.

Шәмәрдән сүзен ишеткәне, русчалап:

– Вот, земляк нашёлся! – дип көлде. – Кая кайтасың, – дип сорыйбыз без синнән, шпингалет?

– Каенсарга! – диде Хәбир, «шпингалет»ның юньле сүз түгеллегенә җавап итеп.

– Каенсарский, что в мешке, не кот ли?

– Чиләк.

– Эчендә нәстә?

– Ипи!

– Ещё?

– Булки!

– Ещё?

– Вак-төяк!..

– Мелочи, говорит.

– Давай, купец! Капчыгыңны, карыйк, алдамасаң? Нәстәләр бар икән тагын?

– Ярар, – диде Хәбир, капчыгын чишәргә әзерләнүен күрсәтеп.

Ул арада товар поезды, «у-у-х, а-а-х» килеп, борылышка якынлаша башлаган иде инде. Шәмәрдән егетләре, Хәбирне чынлап та Каенсарга кадәр кайта дип уйлапмы, капчыгын чишәргә ашыктырмадылар, иркенләп тәмәке көйрәтә башладылар.

Хәбиргә шул гына кирәк тә: сиздермичә генә, капчыгын әкренләп тамбур кырыена шудырып алып килде дә, тегеләр нәрсә булганын абайлап өлгергәнче, вагоннан сикереп төшеп калды.

Бу шундый көтелмәгән хәл булды ки, алар, берсен-берсе этә-төртә, тамбур кырыена килеп җиткәндә, Хәбир, сикергән хутка абына-сөртенә, юл кырыеннан йөгерә иде инде. Егетләрнең берсе, ачуы кабарудан ярсып, хәтта аның артыннан сикермәкче дә булган иде, тик аны иптәшләре тотып калды.

***

Тукталышта да, вокзал бинасы янында да ни поезд көтеп торучылар, ни ат җигеп берәрсен каршы алырга килүче дә күренмәде. Кибет тирәсендә генә берничә малай селкенгәләп йөри. Болар кайтучы да, китүче дә түгел, станция малайлары булырга тиеш.

Хәбиргә юлдаш юк иде. Аңа алты-җиде чакрым юлны ялгызы гына кайтырга туры киләчәк. Башта урман аша чыгарга, аннан соң күрше авыл аша үтәсе. Калган ярты юл киң басу буйлап сузыла. Аның бер ягында, астарак – тирән чокырлы ерганаклар, коры елгалар. Икенче ягында – тигезлек. Еректарак – агачлыклар, урыс зираты, томанланып урман күренә.

Бу юлдан Хәбирнең күп тапкырлар үткәне бар, әмма бер иптәшсез йөрергә туры килгәне юк иде әле.

Ничектер билгесез, тынгысыз, күңелсез юл булып тоелды ул аңа. Кем, нәрсә очрамас?! Хәбир фәкать үз-үзенә ышанып кына кайтырга чыкканын аңлады. Шунысы гына азрак юлдаш сыман булып тоела: бер кесәсендә – абыйсы бүләк иткән дүрт япьле пәке, икенчесендә «даймон» дигән немец фонаре бар. Пәкесе, төшеп югалмаска, сәгать чылбыры белән кесәсенә каптырып куелган. Ярый әле кайтканда, кесәләрен капшап, теге егетләр талап алмады. Иртәнге якта, каршыга ач бүреләр килеп чыкса, алар кешегә дә ташланырга мөмкин. Пәке белән фонарь булганда, сакланырга була.

Хәбир кибет тирәсендә калган малайлардан да шикләнде. Алар аның ялгыз икәнен, аркасына аскан капчыгын да күрделәр, аның эчендә әйбер барын да бик яхшы беләләр инде алар.

Әгәр аркасында биштәре булмаса, Хәбир аларга тоттырмас иде. Ул йөгерү ярышларында күпвакыт баш килә, аның тыны бетми, сулышы капмый. Ләкин аркадагы капчык белән әллә кая качып булмас. Куып тотсалар, урман эчендә ул аларга берүзе каршы да тора алмаячак. Чиләкне ташлап качасы да килмәс. Пәке күрсәтсә, аны да талап алып китәчәкләр. Алып китеп кенә калсалар әле. Болар, авыл малайлары шикелле, сугышып авыз-борын канагач туктый торганнар түгел...

## Урмандагы хәлләр

Чыннан да, юраганы юш килде. Урман эченә кереп, ярты чакрым чамасы юл үтүгә, әллә каян гына теге малайлар килеп чыкты. Хәбирнең аркасындагы биштәренә ябырылып, салып та ектылар. Ярый, капчык бавы шуып чыгып, өстә

калган уң кулы белән берсенең чигә тирәсенә яхшы гына тондырып өлгерде. Икенчесенең, якага ябышканының, чәнти бармагын тешләп алды. Үзеннән бер-ике яшькә олырак булган ул малайларның зәһәрлеге артса да, гайрәтләре сизелерлек сүрелде. Ләкин өченче малай аның өстенә менеп атланган иде. Хәбир аны, аста яткан килеш, этеп-йолкып та өстеннән бәреп төшерә алмады. Ул арада теге икесе дә, авыртуларын онытып, яңадан Хәбиргә ташландылар: авыз-борынын төяргә керештеләр. Кесәләрендә, каян килгән тасмалар булгандыр, шулар белән Хәбирнең аяк-кулларын бәйләделәр дә зур гына кырмыска түмгәге янына өстерәп китерделәр. Болар бик ярсыган иде. Хәбирне шул кырмыска оясы янында үскән бер яшь каен агачына бәйләп куйдылар. Үзләре, кеше-кара килеп чыкмасын дип, китәргә ашыга да башладылар. Тизрәк капчыгын алып качу белән мавыгып, Хәбирнең кесәләрен тентергә кирәклеген дә оныттылар.

Хәбир шунда герой-пионерларны исенә төшерде, шундый хәлгә эләксәләр, алар нишләр иделәр микән дип уйлады. Болар бит немецлар да, сатлыкҗаннар да түгел, нигә әле тик торганда өчәүләп ябырылып, аны шундый хәлгә калдырдылар, капчыгын да алып киттеләр.

Хәбирнең хәле бик мөшкел иде. Кычкырып ярдәм дә сорап булмый, аяк куллары бәйләп куелган. Үзе генә котыла да торган түгел. Ул арада тәнен кырмыскалар сарып алып, зәһәр әчеттереп тешли башлады, тыпырчынган саен ныграк ябырылдылар.

Шунда, әкияттәге шикелле, көтелмәгән гаҗәеп вакыйга булды.

Хәбир кесәсендә пәке булуын исенә төшерде. Артка каерып бәйләнгән кулларын уң як чалбар кесәсенә таба бөтен көченә шудырып, пәкесен тартып алды да кулларын бәйләгән бауларны кисте. Ул да булмады, янәшәдә генә елан шуышып барганын күреп алды. Иң гаҗәбе шул иде: еланның башы буш консерва савытына кереп кысылган иде. Ул Хәбирне дә, кырмыска түмгәген дә күрерлек түгел иде, тоеп-сизеп кенә килгәндер. Хәбир тиз-тиз генә аяк богауларын кисте дә елан башы кысылган савытның капкачын кысып тотып алды. Елан аның кулына уралды, ләкин зыян китерә алмады.

Хәбир, еланны тотып, теге малайлар артыннан йөгерде. Алар, урман авызында тукталып, Хәбирнең күмәче белән казылыгын ашый башлаганнар иде. Аның елан тотып йөгереп килүен күргәч, котлары очты, өнсез калдылар. Шул арада Хәбир еланны аларның өстенә ыргытты. Консерва банкасының кысылган калае ачылып китеп, елан башын тартып алды да берсенең кулын чагып өлгерде. Малайлар, акыра-бакыра, станция ягына йөгерделәр.

Хәбир күмәч-казылыгын чиләгенә салды, капчыклы биштәрен янә аркасына асты да юлын дәвам итте. Әле аның бу кадәр үк хәтәр хәлләрне төшендә дә күргәне юк иде.

Әнә ул – аның газиз туган авылы! Ул шундый якын – ике арага инде шпаналар да, елан-бүреләр дә сыярлык түгел...



Вазыйх
Фатыйхов

# БУЛУ КИРӘК БЕРГӘ ҮЗӘКТӘ

## Догалы хатирә

Миңа өч яшь иде. Иртәнге өч –
Әни белән йөрдек үләнгә.
Ул утыртып йөрде «уфалла»га,
Яклар көче итеп күргәнгә.

Чалгы чыңы, печән кыштырдавы,
Бишек җыры булды җаныма.
Хәле беткән чакларда да әни
Алып сөяр иде алдына.

Чык тамчысын кояш киптергәндә,
Без кузгала идек кайтырга.
Йөк өстендә мин бастырык булдым,
Буй җитмәгәч арба тартырга.

Үрләр менеп, үрләр төшкән чакта,
Авыл өсте учка сыйганда,
Әни һәрчак нидер укый иде,
Куш учларын төбәп җиһанга.

Кайтып җиткәч, күңле тынычлангач,
Сала мине түшәк өстенә.
Мин талганмын татлы йокыларга,
Ә ул киткән колхоз эшенә.

Күпме сулар хәтерләрне юган,
«Уфалла»лар иңгән туфракка.
Тик бәгырьдән китми йокы тәме,
Калсалар да еллар еракта.

---

Вазыйх ФАТЫЙХОВ (1958) – *шагыйрь; «Тормыш – ормыш», «Яшерен сөю», «Язлар көтә күңел» исемле китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Балык Бистәсендә яши.*

…Машинада икәү. Әни дә мин.
Үткән юллар буйлап барабыз.
Үр өстенә туктап дога кылдык –
Кабул булсын изге догабыз!

## Бер йодрык булыйк!

Кеше җаны шундый серле бит ул,
Авыр чакта бергә сыена.
Бергә ишү җиңел көймәләрне,
Каршылык юк кебек тоела.

Үзгә бүген вакыт агышлары,
Дөньялары шактый катлаулы.
Бергә булсак авызлыкларбыз без,
Ияр салдырмаган атларны.

Тормыш баскычларын аз менмәдек,
Язмыш безне шактый иләде.
Ә без бергә җилкән була белдек,
Шуңа салкын җилләр тимәде.

Кендек каның тамган туган җиргә,
Тугры калу – нинди мәртәбә!
Шушы җирне матур бизи алсак,
Бәхет калдырырбыз иртәгә.

Аерылганны – аю ашый, диләр,
Бүленгәнне – бүре күзәтә.
Берләшүләр кирәк һәр адымда,
Булу кирәк бергә үзәктә.

Ун чыбыкмы, әллә бер чыбыкмы,
Кайсысы соң сынмый бөккәндә?
Бер йодрык булыйк, җиңел булыр,
Язмыш сынауларын үткәндә.

Нинди генә чаклар булганда да,
Өметләнәсең  бит яхшыга.
Онытмыйкчы, без җаваплы бүген
Туар буыннарның каршында.

Шөкер кылыйк изге гамәлләргә,
Тынычланмыйк тормыш-чаптарда!
Иңнәр – индә булсын, җиңел булыр,
Кыенлыклар килгән чакларда.

## Кайтаваз

Көн көнләшә миннән: Йөзең нигә,
Нурлырак, ди, хәтта Кояштан?!
Җавап кайтарамын: Билләһи, дим,
Күңел кояш белән охшашкан.

Төн көнләшә миннән: Шәүләң, әнә,
Иң чибәрне кочып югала!
Җавап кайтарамын: Билләһи, дим,
Һәрчак мәхәббәттән көч алам.

Йолдызлар да миннән көнләшәләр,
Ай, Кояшны якын күргәнгә.
Җавап кайтарамын: Билләһи, дим,
Якын якынрак һәрхәлдә.

Чулманым да еш көнләшеп дәшә:
– Дулкыннар, дип, үлеп китәсең!
Җавап кайтарамын: Билләһи, дим,
Дулкын – рухым, ни хәл итәсең?

Сандугачлар кайчак көнләшәләр:
– Безне уздырырга телисең?
Җавап кайтарамын: Билләһи, дим,
Җаным моңлы булгач, нишлим соң?

Кычытканнар кайчак көнләшәләр,
Әремнәргә башым игәнгә.
Җавап кайтарамын: Билләһи, дим,
Туган туфрак тәме килгәнгә!

Көнләшәләр, кайчак көнләшәләр,
Дус-туганнар, читләр көнләшә.
Читен булыр иде дөньялары,
Үз бәһасен кеше белмәсә!

Җавап кайтарамын кайтаваздай:
– Билләһидер серле һәр халәт!
Көнләштереп яшик дөньяларын –
Миннән сезгә изге әманәт!

## Юкка чыккан авыл нигезендә...

Нигезләрдә әрсез кычытканнар,
Өтеп-өтеп ала карашны.
Искән җилне чага зәһәрләре,
Саркып куя язмыш ярасы.

Нигезләрдә сантый тигәнәкләр,
Килүчегә – ачык «хуҗалар».
Чалбар балагыңнан тоталар да
Иңбашыңа куллар сузалар.

Нигезләрдә татлы әрем исе,
Ул – хушбуе авыл җиренең.
Исни-исни атлыйм авыл буйлап,
Монда тагын кайчан килермен…

Морҗаларда чәүкә патша бүген,
Канат кагышлары гел үзгә.
Бөкресен тезләренә салып,
Авыл кереп бара бу көзгә.

Авылларда буш нигезләр ята,
Булган – авыл, бүген юк менә.
Кычытканнар чаккан җилләр генә
Арка кашытырга иелә.

## Гомер юлыннан

Сипләп барам нигез ниргәләрем,
Гомер дигән тормыш-диварның.
Бер ниргәсе күтәрелгән саен,
Капшап карыйм тирә-җиһаным.

Ерак китмәдемме өч аршыннан –
Анысы минем төшәр бер ноктам!
Күбәләк тә кайта учагына,
Туңа калгач ачы суыктан.

Оча-оча кошлар арып  төшә,
Ял итәргә табып ноктасын.
Күтәрә җир сине, мине, аны,
Күчәреннән генә чыкмасын!

Кайчакларда, «вай» чакларда кайчак,
Хәлләр киткән хәлсез бер чакта,
Иеләм дә җиргә кулым бирәм,
Ихлас кысам, алып кочакка,
Шундый рәхәт була шул чакта!

Җирдән иңгән җанга җир якын шул,
Җир – имчәге, сулар һавасы.
Әҗәл дәшсә, җиргә күбрәк елыш –
Яшәүләрнең шунда дәвасы.

Басып торам, ныклы басып торам,
Гомер дигән тормыш юлында.
Уңда – язмыш, сулда ниләр көтә,
Безнең  гомер Тәңрем кулында!

Саный калсам нигез ниргәләрем,
Биек кебек инде тоелыр.
Җиргә төшәм, бары шунда гына,
Бар урыным мәңге сыеныр.

Мин – җир улы. Такташ оныгымын,
Җирдә минем бөтен тотнагым.
Ниргәләре ныклы, бер зурлыкта –
Беләм җирдә уртак йорт барын,
Өч аршынлы соңгы йорт барын!

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Зиннур
Тимергалиев

# СӘМИГА

БӘЯН

Авыл башына килеп кергәндә, уфалла арбасын Рөстәм чак тотып барды, чөнки тау төшәсе. Байтак печән төялгән арбаны керәшен аланыннан тартып кайтасы юк. Таудан аска таба үзе йөгерә ул, тотып барырга гына өлгер. Өлгермисең икән, үзеңә үпкәлә. Арба кулыңнан ычкынса, сине таптап китеп, алдагы тоткычына терәлеп каплануы да бар. Изеп китмәсә дә, бик күңелле түгел, барыбер берәр җиреңне имгәтәчәк. Узган ел шулай булды инде. Рөстәм тотып кала алмады, кулыннан ычкынуга, арба аны таптап китте дә әйләнеп капланды. Аннары ике атна көчкә сулыш алып йөрде малай. Берәр кабыргасы сынгандыр, диделәр күршеләр. Бәлкем, шулай да булгандыр. Әнисе, больницага барыйк, дигән иде дә, малай киреләнеп баш тартты. Шул гына җитмәгән. Җәй уртасында больницада ятарга тагын. Үтеп китте бит, сынган кабыргасы да төзәлде.

Авылда йорт саен мал-туар асрыйлар үзе. Тик керәшен аланында авыл халкы бик сирәк печән чаба. Олылар әйтүенчә, анда патша заманында ук алты керәшен семьясын китереп утырткан булганнар икән. Тик җирле халык белән аралашып китә алмаганнар, бик аз гына торып караганнар да кире туган якларына күченеп киткәннәр. Бәлки шулай, бәлки юк – ул заманны кем белсен инде хәзер?! Печәне бик яхшы ул аланның. Рөстәмнәр ике сыер асрыйлар. Әнисе колхозда эшләмәгәч, аннан процент печәне тими. Өстәвенә ул сыерларның бозаулары да бар бит әле. Ә сарыклар – унике баш! Җәй көне көтүдә булсалар да, кышка кергәч, печәнлекне бик тиз бушаталар. Сарай янындагы ике богыл да бик тиз юкка чыга. Җәе эссе торса, бик шәп инде ул. Рөстәм төшке ашка кадәр берүзе барып чаба печәнне, унбиш яшьлек авыл малае чалгы тота белә инде билгеле, әлегә аны печән чабуда авылда бер генә малайның да уза алганы юк. Аннары печәнне бер барып әйләндереп кайта. Кичен уфалла арбасына төяп алып та кайтып куялар. Әйе, җәе эссе булгач, печәне бик тиз җилли.

Арба артыннан чак өлгереп барган Сәмига улына эндәште:

– Улым, тотып бара аласыңмы, булышыйм!

– Кирәкми, әни, төшеп җиттек бит инде!

– Аяк астыңа карый күр, узган елгы кебек булма тагын.

---

Зиннур ТИМЕРГАЛИЕВ (1974) – *язучы. «Кичә яраттым» китабы авторы. Арчада яши.*

– Ярар, әни.

Шулай арба, малай, Сәмига – өчесе дә, чабышып, авыл урамына килеп керделәр. Таудан төшеп җитүгә, арба йөгерүдән туктады, алга таба инде аны тартып барырга кирәк. Печән төялгән арбаны урам юлыннан тартып бару бик үк җиңел эш түгел шул. Чокыр да чакыр, авыл урамына таш җәйдерергә колхоз рәисенең кулы җитми. Үзе үк шушы урамда тора бит инде. Улына бераз җиңел булсын, дип, Сәмига да арбага килеп тотынды. Йөкнең җиңеләеп киткәнен сизгән малай, артына борылмый гына, әнисенә эндәште:

– Әни, кирәкми, тартам мин аны.

– Авыр бит, улым.

– Булсын, булышма.

Шул гына җитмәгән иде тагын, әнисе белән тартып бара арбаны – хәлсез, дип, авыл малайлары көләрләр иде бугай Рөстәмнән. Малай, икеләтә үҗәтлек белән, арбаны тарта башлады. Авыр, каһәр. Шулай да, шыңшып, әнисенә эндәшмәде.

Җитмәсә, турыларыннан узып барганда, капкаларыннан Рәхилә килеп чыкты. Рәхилә – Рөстәмнең классташы. Кыз аз гына аларга карап торды да, чабып килеп, арбаның тоткычына бер яктан ябышты.

– Җибәр, комачаулыйсың.

– Күп итеп төягәнсең, Рөстәм, авырдыр, әйдә булышам.

– Төясә ни, үзем дә тартып бара алам мин аны.

– Улым! Рәхилә белән алай сөйләшмә инде.

– Җибәрсен, кем кушкан аңа килеп ябышырга.

Малай каты итеп тарткалый торгач, кыз тәки кулын ычкындырды, арткарак калып, Сәмига белән беррәттән бара башлады.

– Исәнмесез, Сәмига апа!

– Исәнме, сеңлем! Апаңны кияүгә бирдегезме?

– Бирдек.

– Туй күңелле булдымы соң?

– Шундый күңелле булды, Сәмига апа.

– Апаң да матур идеме?

– И-и-и Сәмига апа, апа, туй күлмәген кигәч, шундый чибәр булды.

– Менә сине улыма килен итеп алырмын да, син дә, туй күлмәге кигәч, бик чибәр булырсың әле, – диде Сәмига, елмаеп.

Кыз, оялып, башын читкә борды.

– И-и-и Сәмига апа, көлмәгез инде.

– Абау, ник көлим ди, улыма бик тә чибәр, уңган килен аласым килә бит.

– Әй лә, сезне.

– Ник, минем киленем буласың килмимени?

Арба көпчәге, ташка килеп терәлеп, кызны бу уңайсыз сөйләшүдән коткарырга булды ахры. Рөстәм җан көче белән тартса да, арба селкенеп тә карамады. Сәмига белән Рәхилә арттан этә торгач кына, көчкә кузгалып киттеләр.

– Урамы бигрәк инде, җәй көне дә йөреп булмый, – дип, кыз тизрәк сүзне икенчегә борды.

– Әйтмәсәнә, сеңлем, кайда ташы бар, кайда юк, таш салган җирен дә рәтләп тигезләмәгәннәр.

Инде арба колхоз рәисе торган йорт турысын узып бара башлады.

– Гадел абый үз тирәсен тигезләткән ул.

Сәмига эндәшмәде. Рәис яшәгән хуҗалыкны аналы-уллы дәшми генә узып киттеләр.

Рәхилә дә кирәкмәгән сүз ычкындырганын чамалап туктап калды.

Алга таба бер-берсенә дәшми генә үз йортларына кайтып җиттеләр. Аларның йортлары урамның икенче башында ук дияргә була. Бу яктагы аланнан печәнне бик тиз чабып бетерәләр, шуңа күрә керәшен аланына йөрми чара юк.

Киртә капканы киң итеп ачып куйгач, Рөстәм арбаны иске лапас янына якын ук китереп туктатты. Лапасның печәнлегенә, ишегалдына караган ягына, ишек ясалган. Печәнне сәнәк белән, ишегалдында торып, өскә таба ыргыту бик җайлы.

– Сәмига апа, печәнлеккә үзем менәм, яме, – дип, Рәхилә лапас эченә йөгереп кереп китте.

Кызның классташына беренче генә булышуы түгел, шуңа күрә бу хуҗалыкта кайда ничек икәнен биш бармагы кебек белә Рәхилә.

– Алайса миңа эш тә калмый икән монда, – дип, инде буй тартылган балаларга сокланып карады Сәмига. – Рөстәм улым, Рәхиләне кыерсытма.

– Нәрсә, әле бер сүз дә әйтмәдем бит.

– Менә шулай, әйтмә дә. Мин күәс алып чыгам хәзер, – дип, Сәмига йортка кереп китте.

Ул арада печәнлек ишегеннән кызның башы күренде.

– Рөстәм, ыргытмый тор әле.

– Нәрсә булды инде тагын?

– Мин сезнең качып күкәй салып йөргән кыртый тавыгыгызның оясын таптым.

Атнадан артык эзлиләр инде аның оясын.

– Кайда, ничек таптың?

– Аягым тишеккә ялгыш чумды да, шунда кәрниз астына күзем төште. Кая, берәр нәрсә алып бир әле, у-у-у, андагы йомырка.

Рөстәм як-ягына күз йөртеп алды, мунчаны сүткәндә чыгарып куйган табак ята, малай шуны кызга бирде. Кыз үрелеп алды да кабат эчкә кереп китте.

– Менә, – диде ул, кабат печәнлектән башын чыгарып. Йомырка белән яртылаш тулган табакны малайга сузды.

Ишегалдында башка малайлар карап тормагач, Рөстәм кыз белән иркенрәк сөйләшә. Моны Рәхилә дә бик яхшы белеп өлгерде инде. Бер класста укысалар да, Рөстәм аның белән бүтәннәр каршында сөйләшеп торырга ояла.

– Әни белән бар җирне актарып чыккан идек, рәхмәт, Рәхилә. Мин хәзер печән ыргыта башлыйм, син сакланыбрак, сәнәккә кадала күрмә.

Кыз белән малай эшкә тотындылар, авыл баласы өчен күптән өйрәнелгән эш, шуңа күрә, ашыкмыйча, җаен белеп эшләделәр.

Авылда халык шаккатарлык ике йорт бар. Берсе – колхоз рәисе Гаделнеке, шыңгырдап торган нарат агачыннан бурап күтәргән зур гына йорт, икенчесе – колхоз рәисе йортыннан да зуррак, кирпечтән салынган Сәмига йорты. Берсе – колхоз рәисе, икенчесе почтальон булып эшли. Аерма бик зур. Шуңа күрә рәиснең хуҗалыгы инде төзелеп беткән, зур урыс капкасы да ясап куелган. Рәис үзе йорт салганда, кулына балта тоту түгел, йомычка да җыймады. Ә менә Сәмиганың башкачарак: кирпечен дә ташыды, осталарга измәсен дә изеп торды, ашарларына да әзерләде. Билгеле, күптән кул арасына кергән улы Рөстәмгә дә таякның иң юан башы эләкте. Әле хуҗалыкта эшләр...

Мунчасы сүтелеп, яңасы өчен нигез салынып куелган килеш тора. Озакламый бурасын китерергә тиешләр, әтисе күрше авылда тора Сәмиганың, ул да көтә. Бура килеп җитүгә, оныгы белән бабай икәүләп мунча күтәрәчәкләр. Мунча эше бетсә, иске лапас көтеп тора. Киртәсен алыштырырга кирәк, өр-яңа капка да ясап куярга кирәк. Инде егетләр төсе куна башлаган малайны да киендерәсе бар. Ялгызы яшәгән хатын өчен кирәкнең иге-чиге юк. Шул кирәге күп булганга, Сәмига ике сыер асрый, сөтен сатсаң, акчасы килеп бара, сарыклары да бар, кыш чыгасы ике үгезе дә әнә арканда тора. Улы белән икесе генә яшәгәч, ит алай күп ашалмый, шуңа күрә, артыгын сатып, акча эшлиләр. Рөстәме булдыра. Кечкенәдән эшләп үскән малай, бу – авыр хезмәт, дип, башына да китерми. Аныңча, дөнья фәкать шулай гына бара ала. Узган Сабантуйда үсмерләр көрәшендә беренче урынны алды улы. Рәис үзе бүләкли, дигәч, кулындагы сөлгесен ташлап, мәйданнан бүләкне алмый чыгып китте Рөстәм. Кичкә кергәч кенә, бригадир бүләккә тиешле тәкәне китереп китте.

– Ай, кара боларны, шул арада бетереп куйгансыз бит, – дип елмайды Сәмига, кулына күәс салынган савыт тотып, кире ишегалдына чыккач.

– Бетте, әни, көтү кайтканчы өлгердек бит тәки.

– Сез булдырасыз инде барын да. Рәхилә сеңлем, сиңа бик зур рәхмәт. Әтиәниең орышмас микән инде?

– Юк ла инде, Сәмига апа, өйдәге эшләрне күптән эшләп бетердем. Тагын нәрсә кирәк инде аларга...

– Уңган кыз да инде үзең. Мәгез, балалар, сусагансыздыр, күәс эчегез, – дип, хатын балаларга кулындагы савытын сузды.

Рәхиләнең, эссе печәнлек эчендә торып, тамагы кипкән иде инде. Шулай да кыз, ымсынуын җиңеп, малайга эндәште.

– Рөстәм, башта син эч.

– Үзең эч башта.

Кыз, юк дигәндәй, башын чайкады.

Рөстәм күәсне алды да йотлыгып эчәргә кереште. Рәхилә, малайдан күзен алмыйча, аның эчкәнен онытылып күзәтте. Кыз үзенең карашын әлегә яшерә белми иде. Шуңа күрә бу карашны, хатын-кыз буларак, Сәмига бик тиз тотып алды. Кызның ике күзе дә мәхәббәт очкыннары белән мөлдерәмә тулган. Әтегесен кара! Рәхиләнең карап торуына кинәнеп, ничек ирәеп эчкән була.

– Бәхетләрегез генә булсын инде, балалар, – диде әни кеше, үзалдына сөйләнеп.

Сүзнең ни турыда барганын аңламаган кыз, елмаеп, аңа таба борылды:

– Рәхмәт, Сәмига апа.

Рөстәм, салкын күәстән аерылып, савытны кызга сузды:

– Мә, Рәхилә, эч.

Инде күзләрен яшереп, кызны малай күзәтте. Сәмига үзалдына оялып китте. «Болай балалар янында басып тору ярамас»? – дип уйлады ул.

– Ярар, балалар, сез күәс эчегез, минем өйдәге эшләрне карыйсым бар әле, – дип, йортка кереп китте.

– Уф, – диде Рәхилә, ниһаять, күәстән аерылып, – шундый каты эчәсем килгән иде, әниең күәсне тәмле итеп ясый, бик яратам мин Сәмига апа ясаган күәсне... Рөстәм, көтү кайткач, әйдә каенлык артындагы борчакка барабыз, бүген әти белән узып киткәндә, үрелеп, бер-ике кузагын ашап карадык, шундый тәмле, сусыллар.

– Белмим. Теге колхоз тәкәсе көтүдән көн дә йортка кайтмый, башка сарыкларга ияреп киткәли.

Сүз Рөстәмнең Сабантуйда көрәшеп алган тәкә турында бара. Аның тәкәсе дә галәмәт зур, әллә нинди сурәттә бөгәрләнеп килгән мөгезе дә бар. Каршына килгән хатын-кыз, бала-чаганы шул мөгезе белән сөзәргә дә булдыра. Әнисе, нәселе әйбәт дип, көзгә кадәр тимәскә булды тәкәгә. «Рәисе шундый булгач, колхозның тәкәләре дә шундый була торгандыр инде, улым, малдан үч алма», – диде.

– Абау, мин ул тәкәдән куркам, Рөстәм. Кичә, Филүс абый, сарыклары белән бер төн кундырыр өчен, тотып, сарыклары янына япмакчы булган аны, – Рәхилә көлеп җибәрде. – Тәкә хәтта туктап та тормаган, тегенең ике бот арасына мөгезе белән бер генә төртеп алган икән, Филүс абый урамда тәгәрәп калган, тәкә китеп барган.

Кызга кушылып, Рөстәм дә көлде.

– Шәп иткән, кеше малына, сорамыйча, кулын сузмас тагын.

– Ул тәкә болай да йорт саен кунып йөри бит инде.

– Үзләре ич, нәсел өчен берәр көн кунсын, дип алып калалар. Аннары кешедә төн кунгач, ике-өч көн шыпырт кына көтүдән үзе кайтып керә ул.

– Бөтен урамның котын алып йөри инде.

– Йөрсен, – диде Рөстәм, үз малы өчен горурланып. – Әнә Гаделне дә егып салып тәгәрәтеп сөзсен.

Кызның кәефе китте.

– Алай димә, Рөстәм, ярамый ич алай.

– Әйе, аңа ярый, миңа ярамый.

– Рөстәм, үпкәлим.

– Үпкәлә шунда, – диде һаман суынып бетмәгән малай.

Рәхилә кырт борылды да капкага юнәлде.

– Барыбер алай ярамый, – диде кыз, капкага җиткәч борылып.

– Бар әйдә, бар, мин үзем белермен, кемгә нәрсә ярамаганын, – дип, кыз артыннан кычкырып озатып калды малай.

– Улым, кемгә кычкырасың анда шулай каты итеп? – Тавышка йорттан Сәмига килеп чыкты.

– Әнә Рәхилә Гаделгә: «Гадел» дияргә ярамый, ди.

Сәмига улына «ә» дә димәде, «җә» дә димәде, ничек чыккан булса, шулай ук кире борылып кереп тә китте. Алай да ярты юлда, борылып, улына эндәште:

– Рәхиләнең анда гаебе юк инде, улым, менә тик торганда үпкәләшкәнсез.

– Үпкәләшсә, үзе гаепле, өйрәтмәсен.

– Көннән-көн үзгәрәсең син, улым, әшәкеләнеп китмәсәң ярар инде.

– Әшәкеләнмәм, әни, – диде малай, йомшара төшеп, – мин Гадел түгел.

...Көтүне каршы алганда, тәкәнең кабат башка сарыкларга ияреп киткәнлеге билгеле булды.

– Бар инде, улым, минем сыерларны савасым бар, син эзләп кайт, кемнең сарыкларына ияреп киткән икән, – диде Сәмига, улына карап.

– Ну бу Гаделне, күз генә җитсен.

– Кая, нинди Гадел турында сөйлисең син? – дип сорады әнисе.

– Тәкәне әйтәм әни, «Гадел» дип исем куштым мин аңа.

– Үзгәрдең син, улым, – дип, баягы сүзен кабатлады ана кеше, – ирәеп киләсең.

Малае тәкәне эзләп киткәч, Сәмига улы артыннан байтак карап торды.

Әтисе кебек озын буйлы, киң күкрәклегә әйләнеп бара бала, борын астындагы ак төкләре дә каралып киләләр. Кечкенә баланы көйли белде Сәмига, ә менә инде үсеп җиткән егет белән нишләргә кирәген башына китерә алмады. Көзгә Рөстәмгә уналты тула. Тәмам үсеп, бәлигъ булып өлгерде. Инде кызларга да күз салгалый.

– И Ходаем, улыма акыл белән тәүфыйкны кызгана күрмә, – дип, авыз эченнән генә дога укып алды әни кеше.

Йорттагы кечкенә малай ир-атка әйләнде, бер карасаң – әнисенә терәк, икенче карасаң – егет кеше, ә егет кеше әнисенең сүзенә колак салмый да башлавы бар. Бала түгел, дөньяга үз карашы, үз фикере.

– Аллага тапшырдык, улым юньсез бала түгел, дөрес тәрбияләдем бугай инде, укуы да яхшы билгеләргә генә бара, укытучылар да тәртибеннән зарланмый, Аллага тапшырдым, – дип кабатлады Сәмига.

Йорт саен:

– Ят тәкә кермәдеме? – дип сорашып бара торгач, Рөстәм Филүсләр капкасына килеп җитте.

Йорт хуҗасы капка төбендә тәмәкесен пыскытып утыра иде, Рөстәмне ерактан ук күреп, көтеп алды ул.

– Нәрсә, парин, тәкә кайтмадымы? – дип сорады Филүс, малай килеп җиткәч.

– Әйе, шуны эзлим инде.

– Миндә ул, эзләмә, каршы килмәсәң, минем сарыклар янында бер кич кунсын. Кичә мине чәберчек калдыра язды, бүген үзе сарыкларга ияреп кереп китте. Ну, урамда бер тәкә синең!

– Туйдырды инде, Филүс абый, ике көннең берендә, урам бетереп, шуны эзлим.

– Ярар, нишлисең инде, рәисе нинди, тәкәсе дә шундый була инде аның, – дип, Сәмига сүзен кабатлап, авызын ерды абзый кеше.

– Шулай була икән шул, исемен дә «Гадел» дип куштым әле мин аның.

– Кем, кем, кем дип куштым, дисең, энем?

– «Гадел» дип.

Филүс капка баганасына сөялеп утыра иде, эчен тотып, капка төбенә тәгәрәп китте.

– Ха-ха-ха, «Гадел» дип куштым, дисеңме, ну, егет, мач та китергәнсең, икесе дә бер үк юлда йөриләр, молодец, каян башыңа китергәнсең, ха-ха-ха. Тегесенең кушаматы Тәкә, бусыныкы – Гадел, алмашканнар икән.

Абзый кеше капка баганасын төя-төя көлеп калды, Рөстәм борылып кайтып китте.

Икенче көнне Сәмига, почтага кереп, таратасы газеталарын олы сумкасына тутырды да ишеккә таба кузгалды. Почта белән колхоз конторасы икесе бер бинада, өске яктан төшеп килгән колхоз рәисе ишектән чыгып барган хатынны туктатты:

– Сәмига, тукта әле!

Хатын, туктап, рәискә таба борылды.

– Нәрсә кирәк?

– Син нәрсә кыланасың анда, бөтен авыл миннән көлеп йөри икән.

– Ярар, бер бүген генә көлмиләр бит, тагын нәрсә ошамый сиңа?

– Нигә тәкәгә минем исемне куштың? Иртүк фермага төшкән идем, сыер савучы хатыннар сөйләшкәнен тыңлап тордым.

– Хатыннар сүзен тыңларга яратасың инде син, башкасын булдырмасаң да.

– Синең белән әйбәт кенә сөйләшәләр түгелме әлегә?

Рәиснең кычкырып эндәшкән сүзе үзенекен эшләде. Почта начальнигы Харис абзый эчке яктан шыпырт кына почта ишегенең артына килеп басты. Авыл фельдшеры бүлмәсенең ишеге дә нигәдер азрак ачыла төште, кырт-кырт итеп атлап барган хатын-кызның үкчәле туфли тавышы да шып итеп туктап калды. Колхоз конторасына кинәт тынлык урнашты, барысының да колаклары кызык ишетү өчен әзер. Мондагы халыкны Сәмига да, Гадел дә бик яхшы беләләр, баш хисапчы Замира инде бер кулы белән өстәл телефонына үрелгәндер.

Авылда әле кәрәзле телефон белән интернет дигән нәрсә юк. Шуңа да карамый, яңалык авыл буйлап яшен тизлеге белән тарала.

Гадел конторда урнашкан тынлыкның юньлегә түгел икәнен бик яхшы белә, шуңа күрә:

– Әйдә, чыгып сөйләшик әле, – дип, ишеккә таба ишарәләде.

Әйе, рәистә генә ди баш. Сәмига белән ир, ишекне ачып, урамга чыгып басуга, конторның урам якка караган тәрәзә форточкалары шарт-шарт килеп ачылырга тотынды. Гадел, тавышын әкренәйтеп, сүз башларга мәҗбүр булды.

– Нигә тәкәңә минем исемне куштың?

Сәмига көлеп җибәрде:

– Кушса ни булган, Сабантуйда үзең бүләк иттең ич.

– Искә төшермә Сабантуйны, анысы тагын бер: мәйданны ташлап чыгып китте Рөстәм. Районнан килгән түрәләр каршында мине хур итеп.

– Дөрес эшләде.

– Ә печәнне?

– Нәрсә печәнне? Колхозныкына тигәнем юк, Рөстәм үзе керәшен болыныннан чаба аны.

– Миңа үч итеп, көн саен минем капка төбеннән уфалла арбасы белән тартып үтәсезме аны?

– Тагын нәрсә, синең күзгә күренмик, дип, бакча башыннан әйләнеп үтикмени?

Гадел хатынның олы сумкасына ябышты.

– Сәмига, әйдә алай йөрмәгез, ә? Печән кирәк, дисәң, бүген үк күпме кирәк, шуның кадәр алып кайтып аударачаклар капка төбеңә, кирәк, дисәң, печәнлегеңә урнаштырып та бирерләр. Әйт, күпме кирәк, бер олау, ике, өч-дүрт?

Хатын сумкасын рәистән кире тартып алды:

– Җибәр сумканы.

– Әйт, печән әзерләп азапланып йөрмәссез.

– Һы, алай бик азаплаттырасың килмәгәннәр җитәрлек синең, Гадел. Авылда да, күрше авылда да. Барсына да печән тарата башласаң, колхозыңдагы сыерларың ач калыр. Ә тәкәгә килгәндә, мин түгел, Рөстәм кушты аңа шундый кушамат. Синеке – Тәкә, ә тәкәнеке – Гадел. Икегез дә бер үк юлдан йөрисез.

– Ничек Рөстәм кушты?

– Менә шулай.

Сәмига, рәисне калдырып, югары очка менеп китте.

Югары оч урамына менгәндә, Сәмиганы хатирәләре яшьлек елларына алып китте.

Ул бу авыл кызы түгел, аның туган авылы моннан өч чакрым ераклыкта. Барлы-юклы кырык хуҗалыклы кечкенә генә авыл шунда. Әнисе сыер сауды,

этисе колхоз сыерларын көтте. Балачагы да башка авыл балаларыннан аермалы түгел. Башка балалар эшләгәнне ул да эшләде. Коедан җәй көне көянтә-чиләк белән суын ташыды, кыш көне агач чанага этисе бидон утыртып бирде. Коедан су чыгарып, кыз бидонны тутыра да, тартып кайтып, ишек янына китереп куя иде. Әтисе эштән кайткач, бидонны, чанадан алып, йортка кертеп куя. Бакча чүбе, печән өсте... Авыл баласына өелгән эшне санасаң, бик озакка китә. Үзе гаиләдә беренче бала булып, аннан соң туган ике энесен тәрбияләргә әнисенә булышты дип өстәү генә кирәктер. Гаиләдә олы бала кыз кеше булса, әнисенә зур терәк инде ул. Сәмига да әнисенең күп кенә эшләрен үз өстенә алды. Фермага барып, әнисенә сыер саварга да булыша иде. Аннары унынчыны бетергәч, кыз ярты еллык курсларда укып кайтты да клуб мөдире булып эшли башлады. Авылы кечкенә булгач, клубта яшьләре дә бик аз, шуңа күрә кыз өстендә өелеп торган эш тә чамалы. Көн саен кич клубны ача, иң төп хезмәте шул. Элекке мәчетнең манарасын кисеп ясаган клуб инде шунда. Тагын кечкенә генә бүлмәдә бер илле китаптан гыйбарәт китапханәсе бар. Кыш көннәрендә кич белән клубта яшьләр бик аз була, ә менә җәйгә башкачарак, башка авыл егетләре дә килеп чыккалый иде. Шундый җәйге кичләрнең берсендә клубка күрше авылдан өч егет килеп керде. Шимбә көн булгач, авылда яшьләр байтак иде, Сәмиганың авылдаш кызлары да, шәһәрдәге укуларын калдырып, каникулга кайтканнар. Башка авыл егетләренә ияләнеп беткән кызларның чит егетләргә бик исләре китми иде. Тик бу юлы ике егет арасында, өченче булып, озын буйлы, киң күкрәкле, борын астында сызылып киткән кара мыеклы егет бар иде. Кызлар аны бер күрүгә «ах» итеп куйдылар. Менә ичмасам егет дисәң дә егет. Егете дә үз дәрәҗәсен белеп кенә кызларга эндәште.

– Кызларга күп сәламнәр.

– Сәламне алдык, кесәгә салдык, – дигән булды кызлар, исләре китмәгәндәй кыланып.

Шулчак клуб ишеге ачылып китте дә, ишектән Сәмига килеп керде, кыз егетләр ягына күтәрелеп тә карамый, алар яныннан узып, үз бүлмәсенә кереп китте. Гадел кызның бу гамәленнән аптырап калды: моңарчы аның яныннан, «ах» итмичә, бер генә кызның да уза алганы юк. Егет үз дәрәҗәсен бик яхшы белә, туган авылындагы кызларны җитәрлек елаткач, кызык эзләп, күрше авылга сугылган иде. Ә монда, кара син, ничек? Бу авыл кызлары аны күрүгә әйләнеп төштеләр, ә бусы, «ых» та итмичә, аның яныннан узып китте. Кызның үзен болай тотышы егетнең мин-минлегенә килеп тиде.

– Кем бу? – дип сорады ул кызлардан, клуб мөдире бүлмәсенә ишарәләп.

– Сәмига ул, этисе көтүче аның, – дип җавап бирде кызлар, егетнең Сәмига турында сорашуын яратмыйча.

«Ярар, Сәмига булса, – дип уйлады Гадел. – Исең китмәсә, китерербез». Ул кыз бүлмәсенә таба атлады.

– Безнең авылда башта исәнләшәләр иде, – дип сүз башларга булды егет.

Сәмига бу вакытта, өстәлгә иелеп, үз эшләре белән утыра иде.

– Сез бит кунакка килгәнсез. Егет кеше дә булгач, әдәп саклап, башта сез исәнләшергә тиеш, – дип җавап бирде кыз, эшеннән аерылып.

– Ярар алайса, исәнмесез. Ә исемегезне белергә ярар микән?

– Кызлар әйтмәдемени?

– Әйттеләр.

– Соң?

– Минем сезнең үзегездән ишетәсем килә.

– Сәмига.

– Ә мин Гадел абзаң булам.

Сәмига көлеп җибәрде.

– Абзый кеше булгач, кызлар янында нишләп йөрисез, кайтыгыз да әбиегезне кочаклап ятыгыз.

«Кара син моны, бер дә ачылып китәргә теләми бит әле бу», – дип уйлап алды кызларны бер карашы белән аяктан егарга иярләнгән егет.

– Мин бригадир булып эшлим.

– Ә безнең күрше Фатих абзый фермада тирес чыгара, – дип җавап бирде кыз.

– Монысы нәрсә дигән сүз инде? – дип, тагын да аптырабрак калды егет.

– Кемнең кайда эшләве турында фикер алышабыз түгелме соң?

– Юк, туктагыз әле, ә сез кем булып эшлисез?

Кыз пырхылдап көлеп җибәрде.

– Мин? Чишмәдә сөт батырам.

– Клуб мөдире бит син, башымны катырма әле.

– Үзең бит кеше башын катырып утырасың, җыен кирәкмәгән сүз сөйләнеп.

Менә сиңа кирәк булса, Гаделнең тозсыз-борычсыз шаяруларыннан эчләре катып көлеп утырган кызлардан бик нык аерыла икән бу кыз.

– Ярар, – егет торып басты, – иртәгә абзагыз тагын килеп хәлегезне белер, – дип клубтан ук чыгып китте.

Матаен кабызганда:

– Карап карарбыз, җаный, – дип, үзалдына сөйләнеп алды Гадел.

Бар кызлар аңа баштанаяк гашыйк булганда, бер кыз гына аннан борын чөеп калырга тиеш түгел. «Барыбер минеке булырсың, җаный».

– Карап карарбыз, – дип кабат сөйләнеп алды егет, кузгалып киткәндә.

Гадел, бернигә дә карамый, кызны үзенеке итәргә уйлады, анда үзенә күрә бер комарлык уянды.

– Гадел алдында алынмаслык бернинди дә крепость юк, – дип күкрәк какты.

Сәмигага исә ул егетне мотоцикл белән килеп туктагач ук күреп алган иде. Егетне бер күрүгә үк ошатты ул. Шуңа күрә клубка егетләр артыннан ук диярлек килеп кергәч, кабат аңа күтәрелеп карамады. Чибәрлектә кайтыш булмаса да, клуб эчендә аннан чибәррәк тә, чаярак та кызлар бар иде. Шуңа күрә бу егет үзенә насыйп булмасын бик тиз чамалап алды. Ләкин егет икенче көнне дә килде, өченче көнне дә, көн саен килеп йөри башлады. Килгән саен клуб мөдире бүлмәсендә утырган Сәмига янына керде. Башта кыз үз бәхетенә ышана алмый йөрде, аннары егетне сагынып көтәргә ияләнде. Инде егет кызны, матаена утыртып, өенә кадәр озата ук башлады. Төн узганчы аерылыша алмый капка төбендә дә озаклап утыра башладылар. Үзенең җиңүен Гадел кара көздә туй белән билгеләп үтте. Кызны тәки үзенеке итә алды бит. Сәмиганың әти-әнисе булачак кияүләренең хәйран гына кызларга карата эшләгән этлекләрен белеп алдылар. Әтисе туйга ризалыгын бирми йөрде. Хатынының: «Өйләнгәч, егетләр суына»? – диюе, аннары кызының яшьле күзләре үзенекен эшләде. Гадел белән Сәмига гаилә корып җибәрделәр.

Яшь киленгә эше бик тиз табылды, авылда почта тарата башлады. Озак көттерми, Рөстәм уллары да дөньяга килде. Менә шулай, акрынлап, тормышлары җайга салынып килгәндә, Гаделне колхозның чираттагы җыелышында рәис итеп сайлап куйдылар. Авыл хуҗалыгы институтын бетергән, белеме бар. Элеккеге рәис пенсиягә чыкты, шуңа күрә яшь тә, белемле дә Гаделне рәис итеп куюга берәү дә каршы килмәде.

Берара колхоз эшенә кереп киткәнче, Гаделнең бер минут та вакыты калмады дисәң дөрестер. Кара төнгә кадәр яшь кияү колхоз эше белән мәшгуль иде. Хуҗалыктагы эшләрнең барысы да яшь килен өстенә өелеп калды. Кая ул рәис хатыны булып, кәттә киенеп, урамнан узу! Тиз генә почтасын таратып бетерә иде дә муеныннан хуҗалык эшенә чума иде. Билгеле, яшь киленне үзен генә калдырмадылар. Гаделнең әти-әнисе дә, энесе дә ярдәм кулын һәрчак сузып тордылар. Колхоз эшенең тәртибенә кереп беткән Гадел генә үз хуҗалыгыннан бизгән булып чыкты. Халыкның «бөкрене кабер генә төзәтә» дигәне дә хак сүзләр булып чыкты.

Колхозга институттан яшь агроном кайтып төште. Агроном кыз кеше булып чыкты. Чибәрлеге дә чамасыз, үзенә сыланып торган киемнәре дә кызның фигурасы менә дигән икәнен күрсәтеп тора. Кызны беренче күрүгә үк, рәис тамагын кырып куйды. «Иртәрәк өйләндем ахры, дөньяда әнә күпме кызлар калган икән»? – дип уйлап куйды бу вакытта Гадел. Алга таба яшь агроном һәм рәис бергәләп «Нива» машинасы белән колхоз басуларын карарга чыгып китә башладылар. Яшь белгеч Халидә дә үзен алай төшеп калган кызлардан түгел икәнен күрсәтә белде. Ә нәрсә булган, рәис яшь тә, чибәр дә. Билгеле, басулар карарга чыгабыз, дисәләр дә, алар утырган машина кукуруз басуыннан ерак китә алмый иде. Колхоз идарәсендә шулай сөйләшү гадәткә кереп китте.

– Рәис кайда икән, белмисезме?

– Агроном белән кукуруз үстерә.

Әйе, халыктан берни дә яшереп калып булмый шул. Бер булмаса, бер күзгә чалынасың барыбер.

Бу хәбәрләр Сәмигага да бик тиз барып ишетелде. Яшь килен почтаны авылның бер башыннан тарата башлый, йорт саен йөреп, ике сәгать дигәндә, авылның икенче башына килеп чыга. Ике йортның берсендә Сәмиганы авыл яңалыклары белән таныштырып торалар. Башка гайбәтләрне кычкырып сөйләсәләр, ә менә аның ире турындагы яңалыкны пышылдап кына сөйлиләр. Янәсе, бик тә яшерен сер икән бу. Бар авылга билгеле булган сер.

Өзелеп сөйгән ир канаты турында шундый гайбәт ишетү авыр иде Сәмигага.

– Әйт әле миңа дөресен, агроном кыз турындагы сүз дөресме ул? – дип, Гаделнең күзләренә туры карап сорады Сәмига.

– Нинди сүз ул тагын? – дип, карашын читкә юнәлтеп, белмәмешкә салынды ире.

– Синең белән чуала, диләр.

– Кем әйтә аны, юкны сөйләмә. Кайчак басулардагы уҗымнарны карарга чыгып китәбез, гайбәтчеләргә шул җитә инде.

Сәмиганың иренә ышанасы килсә дә, күңелендә барыбер шиге калды.

Ә Гадел ул көнне тагын төн уртасында гына кайтып керде.

Халык сөйли торды, Сәмиганың күңелендәге шом көннән-көн арта торды. «Юк, болай яшәп булмый»? – дип уйлады хатын. Почта таратып йөргәндә, иренең машинасы кукуруз басуына таба китеп барганын күреп алды. Бар горурлыгын җиңеп, басуга таба кызу-кызу атлап китте Сәмига.

Кукуруз биек булып үскән, машина кая килеп туктаганын күреп булмый. Ире белән сөйләшкән хатын-кыз тавышын ишетмәсә, таба да алмаган булыр иде, бәлки. Колхозга үзе хуҗа булгач, Гадел, кукурузны таптап, басуның эченә үк кергән икән. Кергән дип инде, таныш җиргә йөреп, басу эченә машинасы белән юл да салып бетергән.

Сәмига, сакланып кына, машинага якынлашты. Машина эчендәгеләрнең

эшләре бик кызу ахры, аның якынлашканын берсе дә сизмәде. Хатын кисәк кенә машинаның ишеген тартып ачты. Ишекне ачуга, аның аяк астыннан җир шуып киткәндәй булды. Ике азгын да ялт итеп Сәмигага борылып карады. Агроном кызның лифчигы эченнән чыккан күкрәкләре Сәмиганың борынына ук килеп төртелделәр. Бу күкрәкләргә Сәмиганың лачкылдатап төкерәсе килсә дә, үзен тотып кала алды.

– Алла куәт бирсен, җаный, – дип, хатын ишекне шапылдатып япты да кайтыр якка борылды.

Авылга кайтканда, Сәмига чайкалып торган җир өстеннән атлап барды. Җаныннан да якын яраткан кешесенең хыянәте хатынның җанын пычак күк телем-телем телгәләде.

– Юк-юк, – дип кабатлады үз-үзенә Сәмига. – Авылда минем кукуруз басуына кереп киткәнне кем дә булса күреп калгандыр, юк-юк, еламаска, еламаска, халык күрмәсен.

Хатын атылып чыгарга әзер яшьләрен эчкә йота барды. Тышка бәреп чыга алмаган кайнар яшьләр Сәмиганың җанын ташка төрергә тотынды.

– Юк, еламаска, бирешмәскә!

Кич белән ире кайткач, хатыны Гаделгә актан-карадан бер сүз дә эндәшмәде. Гадел дә акланунын файдасы юк икәнен аңлап, хатынының чәрелдәп ябышуын көтте. Тик Сәмига йортта бернинди дә тавыш чыгармады. Бары тик урынын гына икенче җиргә җәеп ятты. Алдагы көндә дә иренә бер сүз дә эндәшмәде хатын, аннары да. Гадел хатынының мондый мөнәсәбәтен үзенчә хәл итте.

– Чәрелдәп нишләгән булыр идең, кемгә кирәк син бала белән? Ирләр бераз уҗымга йөрсәләр зыян юк, – дип уйлады ул.

Хатынның аягына егылып, гафу үтенергә кирәклеген башына китермәде.

«Димәк, минем читкә йөрүемә хатын каршы түгел, бик яхшы».

Тик менә булган хәлләрдән соң дүртенче көндә Гадел үзенең буп-буш йортына кайтып керде.

Йортта шәүлә кебек йөргән хатын да юк, идән уртасында уйнап утырган малай да. Ир, атыла-бәрелә, йорт эчен карый башлады. Сәмига бирнәгә алып килгән сандык юкка чыккан, ике мендәр, яшь киленнең юрганы, матрасы, савыт-саба ише әйберләрнең яртысы... Хатын-кыз, бала киемнәре торган шкаф бушап калган. Ир, атылып, сарайга чыкты. Әле бер генә бозау китергән сыер да юк, ике сарык белән бер тәкәне дә Сәмига үзе белән алып киткән.

Ул эш белән йөргән вакытта, авылдашлары аның йорты каршында нindидер йөк машинасы тора, дип хәбәр иткәннәр иде итүен. Тик барсына риза булган хатыны шулай чыгып китәр дип башына китерә алмады ул вакытта.

Сәмиганың йортта тавыш чыгармавы бары тик авылдашларына кызык күрсәтәсе килмәүдән иде. Иренең хыянәтен кичерергә уйламады да хатын. Шулай ук, акырып-елап, әти-әнисе йортына кайтып китәргә дә җыенмады.

Сәмига, ирен тотканның икенче көнендә үк, авыл советына барып, үзләре яшәгән урамның теге башында күптән ташландык торган йортны белеште. Йорты әле бик иске түгел, торырлык, хуҗалары шушы авыл кешеләре икән, йорт хакын артык күп сорамый, көтеп торырга риза булып, Сәмигага ачкычын тоттырдылар. Сәмига ике көн җыенды да, туган авылыннан машина белешеп, әлеге йортка күченде.

Кечкенә малаен кочагына кысып, яңа йортта беренче төнен кунганда, хатын үз-үзенә сүз бирде.

– Бик шатланма мин китте дип, ерак китмәдем мин. Яшәрмен, синсез

дә яшәрмен, йортны да, каралты-кураны да синнән яхшырак итеп салып куярмын. Минем йорт яныннан үткән саен, үтең сытылыр әле, җаный. Үткән саен җаныңнан тамчы-тамчы аккан каның белән түләрсең. Карап карарбыз, кем-кемне.

Ә Гадел, хатынының авылдан чыгып китмичә, үзләре урамында ук йорт алып тора башлаганын белсә дә, гафу үтенеп килмәде.

– Кайтыр, ике яшьлек бала белән тора алмас, үзенә бәя генә арттыра, – дип уйлады ир.

Тик атна үтте, ай да узды, Сәмига кире кайтмады. Өч ай узгач, почтальон буларак, Гаделнең почта тартмасына судка чакыру кәгазен хатын үз куллары белән салып китте. Сәмига аерылышырга гариза биргән иде. Шул көнне Гадел кич белән аның ишеген какты.

– Нәрсә кирәк? – дип сорады Сәмига, болдыр баскычына чыгып баскач.

– Син нәрсә юләр сатып йөрисең анда? – дип җавап бирде ир, хатыны белән каты итеп сөйләшергә исәп итеп.

– Минме юләр сатып йөрим?

– Син, бу нинди кәгазь тагын? – диде ир хатынына, почта тартмасыннан алган суд кәгазен күрсәтеп.

– Югары белемең бар бит, укы.

– Укыдым мин аны.

– Укыгач, нигә сорыйсың?

– Ник юләр сатып йөрисең, дип сорыйм мин синнән, – диде ир, кыза башлап.

– Юк, мин түгел, ә син юләр саттың, җаный.

– Ну ярар инде, һәрбер ирдә бераз гына андый гөнаһ була.

– Димәк, ярый дисең инде аз гына?

– Билгеле, ярый, башка рәисләр кимен куя дип беләсең мәллә?!

– Минем башкаларда эшем юк. Димәк, дәрәҗә үстерү өчен, гөнаһ кылырга туры килде, дисең син алайса.

– Ну, анысы дәрәҗәне дә төшерергә ярамый инде, – дип акланырга тырышты Гадел.

– Ярар алайса, мин дә синең яныңда дәрәҗәңне төшереп йөрмәм, сау бул, судта очрашырбыз, – дип, Сәмига йортка кереп китте.

Гадел башка килеп йөрмәде.

Яңа тормыш башлап җибәрү җиңел бирелмәде хатынга. Йорт хакын түләп бетерү өчен генә дә ике ел вакыт кирәк булды. Ике ел буе тиенләп җыя торгач, бу әҗәттән котыла алды ул. Ә менә яңа йортка тотыну өчен, ай-һай, күп тир түгәргә туры килде. Хайван сатып, акча эшләп була дип әйтүе генә җайлы. Ә эше күпме? Җитмәсә, көннән-көн үсә барган Рөстәмнең үзенә генә дә күпме акча кирәк. Быел алып куясың өстенә кирәген, икенче елга инде ул киемнәргә сыймый малай. Кабаттан баштанаяк киендерергә туры килә. Мондый тормышның ни икәнен аңласа, шул ялгыз хатыннар гына аңлый аладыр.

Ялгыз хатынга кармак салып карарга теләүчеләр дә булды авылда. Читкә каерырга яраткан бер Гадел генә түгел бит. Законлы аерылышып, ике ай үтмәде, урамда аның каршына колхозның баш инженеры чыгып басты.

– Сәмига, мин сине күптән ошатып йөрим инде, үзең бик уңган да, чибәр дә син.

Хатын тиз төшенеп алды инженерның ниятен.

– Самат, берәр әйтер сүзең бар иде мәллә миңа? – дип уйнаклап сорау бирде аңа.

– Бар иде шул.

– Әйт алайса.

– Урам уртасында әйтә алмам инде, син бүген ишегеңне бикләми ят, яме? Төнгә килеп чыгармын.

– Соң ярар, бикләмәм, – дип, сөйләнүен дәвам итте Сәмига да, – сый да әзерлисе юкмы соң?

Саматның күңеле күтәрелеп китте: эшләр пешә болай булгач...

– Әзерләсәң начар булмас иде, – диде ул, хатынга елмаеп.

– Ярар, кичкә кадәр, озак көттермә, – дип сабуллашты хатын аның белән.

– Кошлар кебек очып килермен, – дип сөйләнеп калды Самат аның артыннан.

Кич төнгә авышкач, Самат, бакча артыннан килеп, башта бәрәңге сабагы арасына кереп посты. Берара як-якка карап торгач, бернинди дә шикле нәрсә булмагач, иелгән килеш кенә йөгереп, Сәмиганың ишегалдына килеп керде. Әнә җәннәт бакчасы белән ике араны бары тик дүрт-биш кенә адым аерып тора. Ир һаман да иелеп кенә Сәмиганың ишегенә якынлашты, ишекне акрын гына какты. Җавап бирүче юк. Самат тагын шакыды.

Эчтә ишек ачылган тавыш ишетелде.

– Кем бар анда?

– Сәмига, бу мин – Самат.

– Килдеңмени, җаным?

– Килдем, сине күрергә тилмереп, төнне көтә-көтә саргаеп беттем, ач ишегеңне.

– Хәзер. – Ниһаять, өйалды ишеге ачылып китте. Аның артыннан ук өстенә иске курткасын кигән Сәмига күренде, хатынның кулында нәрсәдер бар иде.

– Сәмига, нәрсә ул кулыңда?

– Сиңа дип әзерләп куйган сый.

– Ә!

– Мә! – Саматның маңгаена камыр җәя торган уклау килеп төште.

Көтелмәгән һөҗүмнән гашыйк кисәге акырып җибәрде.

– Нишлисең син?

Ул арада Сәмига, маңгаен тотып иелгән ирнең якасыннан эләктереп алды да, уклау белән аркасын каезларга тотынды.

– Сиңа хатының, ике балаң өстенә сөяркә кирәкме? Мә сиңа сөяркә! Ялгыз хатын итәген җәеп тора дисеңме? Мә сиңа итәк! Кызык кирәкме? Мә сиңа кызык!

Төн уртасында Сәмига Саматны ишегалдында, акыртып, уклау белән ярды. Ирнең акырган тавышына бөтен күрше-тирә уянып бетте. Хатын кулыннан көчкә ычкынып, кире бакча ягына таба сыптыра алды Самат.

Бусы әле баласы гына булган икән, икенче көнне Самат эшкә ике күзе дә күгәргән килеш килде. Димәк, үз артына кызыкны җитәрлек тапкан ир кисәге. Өенә кайтып керүгә, Сәмига биреп бетермәгәнне Саматка хатыны да өстәгән булып чыкты. Ул җәйдә Самат кара көзгә кадәр мунчасында кунды. Хатыны беренче карга чаклы ирен өенә кертмәде.

Ә менә Сәмигага авыл халкының хөрмәте генә артты. Бигрәк тә ирле хатыннарның. Аларны аңлап була, авылда ялгыз хатыннар аз түгел, ирләре булган хатыннарның каннарына тоз салганнары да җитәрлек.

Гадел хатынсыз күп тормады. Ир янында бушап калган урынны агроном Халидә бик тиз биләп алды. Гадел, Сәмигага үч итеп (моңарчы авылда булмаганны), туйны район үзәгендәге ресторанда үткәрде. Килен төшергәндә, туй машиналары Сәмига йорты яныннан юри сигналларын кычкыртып

уздылар. Тик хатынның моңа әллә ни исе китмәде. Алга куйган максаты бар, тормышка ашыру өчен бар көчен шул якка таба борды.

Ун ел дигәндә, колхоз рәисеннән дә уздырып, кирпечтән йортын салып куйды. Инде менә Рөстәме дә үсеп җитте. Бүген мунча бурасын китерергә тиешләр, акчасы түләп куелган. Хатын, кызу-кызу атлап, йорт буенча почта таратып, өенә кайтып керсә, аның капкасы каршына «КамАЗ» машинасы туктаган икән. «КамАЗ»га Сәмиганың этисе Салих абый да утырып килгән. Рөстәм белән машина кузовындагы мунча бурасын бушатып яталар.

– У-у-у, китереп тә җиткергәнсез икән, – дип эндәште хатын «КамАЗ» шофёрына. Аннары этисенә борылып:

– Әти, исәнме! Әни ни хәлләрдә? – диде.

– Ярый, бер килеш, – дип җавап бирде Салих абзый. – Рөстәм улым, аскы ниргәләрне читкәрәк куй, аларны фундаментка беренче саласы.

– Ярар, бабай.

– Сәмига, кышкы абзарга бура дигән идең, кире уйламадыңмы? – дип сүзгә кушылды шофёр.

– Югын юк та, әле булмас инде, бәлки көзгә, ике үгезне саткач...

– Ник, анысын гына килешеп булыр иде әле. Йорт өчен бар нәрсәне миннән алдың, әнә мунча тагын, үз итеп, бәясен төшәрмен, клиентларны кыерсытып булмас инде.

– Рәхмәт, тик барыбер акчасы юк.

– Юк, тукта, ашыкма, Сәмига, минем әзер бурам бар, урын алып тора, шуңа әйтүем. Әйдә, иртәгә сиңа китереп куям мин аны, акчасын көзгә бирерсең, әйткәнемчә, бәясен төшәрмен тагын. Миңа өй бурасына заказ биргәннәр иде, абзар бурасы урын алып тора. Сиңа китереп калдырсам, урын киңәер иде. Аннары китереп бирү – китереп бирү инде ул, үзең техника артыннан чабасы түгел бит.

– Ярар, көтеп торырга риза булгач, китереп куй. Кара көзгә кергәч, акчасын килеп алырсың.

– Алайса, килештек.

– Килештек.

«КамАЗ» кузгалып киткәч, Сәмига этисе янына бүрәнә өстенә килеп утырды.

– Мунчаны иртәгә күтәрә башлыйсызмы, эти? Үзегез генә булдыра алырсыз микән? Авыр булыр, дисәң, кешегә әйтәм.

Салих абзый көлемсерәп куйды.

– Һы, мунча бурасы өйнеке түгел ул. Рөстәм белән икәү дә күтәрәбез аны. Бүген үк, бурасын өеп, бәбкәсен күтәреп куярбыз.

– Шулай тизмени?

– Соң, аның бар нәрсәсе әзер бит инде, бары җыеп күтәрәсе генә бар. Әнә идәненә дә, түшәменә дә тактасын китергән. Ахры, башта мунчаны ясап күтәргәннәр, аннары, кире сүтеп, сиңа китергәннәр.

– Ярар, эти, үзең беләсеңдер инде, синең сүзеңә каршы килмим, – дип, Сәмига йортка кереп китте.

– Чибәр егеткә кияүгә чыкканда, атаң сүзенә колак салырга иде, – дип, үзалдына мыгырданып алды бабай кеше.

– Бабай, башлыйбызмы?

Оныгы Рөстәм артына килеп баскан икән.

– Әйдә, улым.

Онык белән бабай эшкә тотындылар. Сәмига ашарга чакырырга чыкканда, мунча бурасын күтәреп куйганнар иде инде.

– Тиз буласы икән бу, – диде хатын, осталарның эшен күзәтеп.

– Билгеле, тиз, әле миңа эләкми дә эше, Рөстәм эшләп бара барсын да. Мин менә командир кебек карап кына торам бугай монда, – дип кеткелдәп алды әтисе.

Осталар, ашап, кире ишегалдына чыкканда, аларны Рәхилә көтеп тора иде.

– Исәнмесез! – дип, тыйнак кына исәнләште кыз.

– Шөкер әле, кызым.

– Сәлам, Рәхилә.

– Рөстәм, синең вакытың юк икән, әйеме?

– Нигә?

Кыз, тартынып, бабай кешегә карап куйды, моны аңлаган Салих абый җирдә аунап яткан такталарны караштыргандай итте. Янәсе, сөйләшегез, сезне тыңлап торырга вакыт юк әле монда.

– Иртәгә безгә кунаклар кайтасы.

– Соң?

– Керәшен аланына барып, мунчага каен себеркесе җыеп кайтсаң, әйбәт булыр иде, ди әни. Рөстәм, мин урманга үзем генә барырга куркам.

– Мин белмим инде, – дип, иңнәрен җыерды Рөстәм.

– Барырсың, улым, – дип сүзгә кушылды бабасы, – бәбкәләрне күтәреп куйгач, түбәнең ике яклап каршысын ябасы булыр, аны үзем дә эшләп куя алам мин, икәү барыбер бер-беребезгә комачаулыйбыз гына.

– Алайса көтү кайткач, яме Рәхилә?

– Синең тәкәң кайтыр микән соң, аны эзлисең булса?

– Көтүгә аркылы басып торырмын, әнә бабай да бар. Карышса, мөгезеннән эләктереп әллүр капкага аны.

– Алайса көтү кайткач киләм.

– Кил.

Кыз кош тоткандай кайтып китте. Кызны күзе белән озатып калган малай артында тавыш яңгырады.

– Яп авызыңны, әнә каргалар очып йөри, кәкәй итеп куймасыннар.

– Әй лә сине, бабай.

– Нәрсә әй, кызлар күргәч, эш онытылды, марш бура өстенә.

Ике оста кабат эшкә тотындылар.

Гаҗәп, бүген тәкә көтүдән, бер якка да каермый, үзе кайтып керде.

– Кичә Филүстә бете басылган икән моның, – дип, үзалдына сөйләнеп алды Рөстәм.

Кичке ашны ашап кына бетергәннәр иде, Рәхилә дә килеп җитте.

– Рөстә-ә-ә-әм! – Ишегалдыннан кызның тавышы ишетелде.

Ачык тәрәзәдән, башын тыгып, Рөстәм аңа җавап бирде:

– Чыгам.

– Улым, кая җыендың?

– «Керәшен аланыннан мунча себеркесе җыярга барыйк»? дигән иде Рәхилә.

– Ә мунча?

– Барсын, – дип сүзгә кушылды бабасы да, – бүген кирәге юк аның.

– Алайса безгә дә җый инде, улым, яңа мунчага яңа себерке булыр.

– Әни, мин уфалланы алам.

– Ал.

– Шул уфалла инде безгә, – дип әңгәмәне дәвам итте Салих абзый, – мин дә җитәрлек өстерәдем аны, анаңа да эләкте, хәзер син тартасың. Малаеңнан соң оныгың да тартыр әле аны.

– Башка чара юк бит, әти.

– Рәсәйдә уфалладан башка бернинди дә чара юк, кызым. Уфалла йортыңны җылыта, хайваның белән бергә синең тамагыңны туйдыра.

– Миңа да өй салып бирде менә.

– Салуын салды да, тик аны бит ун ел тартырга туры килде үзеңә.

– Зарланмыйм.

– Зарланып нишлисең, кызым, әйттем бит, Рәсәйдә шул уфалла гына бар дөньяны тартып бара.

– Бәлки, Рөстәмгә эләкмәс.

– Әйе, эләкмәгәнгә күрә, шул арбага җигелеп чыгып китте әнә.

Сәмига түр тәрәзә аркылы урам якка күз салды. Анда Рөстәм белән Рәхилә, уфалла арбасын тартып, урманга таба китеп баралар иде. Хатын көрсенеп куйды.

– Быел соңгы елын бара инде мәктәпкә, аннары армия, диярләр, кемнеңдер бердәнбер баласы, димәсләр. Әнә, дөньялар тыныч түгел ди. Түрәләр дөнья бүләләр, безнең малайлар канга батып сугыша шулар өчен.

– Бәлкем, бердәнбер бала булгач, алып китмәсләр әле, кызым.

– Аллага тапшырдык инде, әти, Аллага тапшырдык.

Рөстәм белән Рәхиләне урман тоташ диңгез шавына күмелеп каршы алды. Читтән карап торышка, чынлап та, шомлы шул урман. Куе яфрак белән капланган агачлык эче бөтенләй күренми. Әллә нинди серле дөнья. Ә эченә кереп китсәң, никадәр гүзәллек анда. Агачларга кунып, күпме кош сине сайрап каршы ала! Кыз Рөстәмгә сыена төште.

– Куркасыңмы?

– Юк, син барында курыкмыйм мин, Рөстәм.

– Курыкма да. Әнә тегендә кечерәк каеннар үсә, шунда барыйк әле, син ботакларын кисеп торырсың, мин себеркесен бәйләрмен, монда ук эшен бетереп кайтырбыз.

Алар каенлыкка килеп туктадылар да эшкә тотындылар. Рәхилә, буе җиткән кадәр үрелеп, каен ботакларын ботарлады. Ә Рөстәм, үз эшенең чын остасы кебек, алардан каен себеркесе бәйләргә тотынды. Күнегелгән эш, бик җәһәт эшләделәр егет белән кыз.

– Рөстәм, ә син мәктәпне бетергәч, кая укырга кермәкче буласың?

– Әнинең үзен генә калдырып китеп булмас инде, район үзәгенә ПТУга керергә исәп. Ун чакрым гына ераклыкта бит, сварщик начар эш түгел. Әнә Филүс абыйның хуҗалыгыннан халык өзелгәне юк. Акча сугып ята, – дип көлемсерәп алды Рөстәм, эшеннән бүленми генә.

– Югары уку йортына керергә исәбең юкмыни?

– Әй, ул дипломны, нишлисең аның белән? Дипломнары шкафларында тузан җыеп ятканнар авыл тулы. Бар кеше дә югары белемле булып бетте. Ә менә гади эш белүче юк. Һе, кая инде гади эш, ни балта, ни чалгы саплый белмиләр. Яшиләр алар да, мин авылда яшим дип.

– Акчага кызыгасың, ахры. Бәхет акчада түгел, тазалыкта бит.

– Әйе, шулай, әни белән ни эшләргә генә тотынмыйк, шул каһәр суккан тазалык җитми һаман, – дип кеткелдәп алды Рөстәм.

– Өйдә дә шул акча турында гына сүз, колхоз бер тиен дә акчасын түләми.

– Каян түләсен, Гаделнең уҗымга йөрисе бар бит, акча шунда китә.

– Рөстәм, әйтмә алай, әтиең ул синең.

– Әйе, әти! «Улым, ни хәлләр?» – дип тә эндәшкәне юк бит аның. Сез аңламыйсыз аны, сезгә «улым-кызым» дип кенә торалар.

– Кичер, Рөстәм, ялгыш ул турыда сүз башладым.

– Әй лә, әйтмәсен, кирәге дә юк. Бер синнән генә ишетмим инде мин аны. Әнә укытучылар миңа рәис малае дип карыйлар, сизәм бит мин. Һе, рәис малаеның гына атасыннан «улым» дигән сүзен ишеткәне юк.

– Укырга керәм, дисәң, барыбер ярдәм итәр ул сиңа. Синнән башка баласы юк бит аның.

– Агроном Халидәнең кукурузлары үссә дә, бүксәсе үсми, – дип, авыл халкының сүзен кабатлады Рөстәм. – Кирәге юк, яшәдек бит әле моңарчы ансыз. Аннан ярдәм сорасам, әни дә хурланыр, бар нәрсәсен сатып бетереп, мине югары уку йортына укырга кертер.

– Әллә нишләдең син, Рөстәм, зур абзыйлар кебек сөйләшә башладың.

Рөстәм иңсәсен җыерып куйды:

– Ә син, Рәхилә, нишләргә уйлыйсың?

– Минеке билгеле инде, апа белән җизни янына шәһәргә китеп, пединститутка укырга керәм.

– Авылда тагын бер югары белемле сыер савучы арта икән алайса.

– Булса ни?

– Булса ни шул.

Кыз белән егет талашып та киткән булырлар иде бәлки, тик өлгерә алмый калдылар. Кинәт күкнең гөрелдәп тавыш биргәне ишетелде.

Рөстәм белән Рәхилә бер-берсенә карашып алдылар.

– Яңгыр килә, – диде кыз, урман эченең караңгылана башлаганын күзәтеп.

– Яшенле яңгыр, озак эссе көннәрдән соң мондый яңгыр бик әшәке була.

Күк йөзе кабат гөрелдәп куйды.

– Рөстәм, әйдә, авылга чабыйк.

– Өлгермибез барыбер, яңгырны үткәрергә кирәк, әнә теге карт чыршы астына качарбыз.

Рөстәм, кызны ияртеп, карт чыршы астына кереп басты. Чыршы бик карт иде инде, аның салынып төшкән ботаклары яшьләрне тулысы белән яшерә алды.

Карт чыршы өстендә үк каты итеп яшен яшьнәде.

Рәхилә куркып кычкырып җибәрде дә, үзе дә сизмәстән, Рөстәмнең кочагына атылды. Моңарчы кызларның кулын да тотып карамаган егет кинәт каушап калды. Коеп ява башлаган яңгыр салкыныннан түгел, ә кисәк кызыша башлаган тән ялкыныннан калтыранып куйды. Нишләргә тиеш соң ул хәзер? Ә кыз, егетне үчекләгәндәй, катырак сыена төште. Рөстәмнең күкрәгенә кызның тыгыз күкрәкләре килеп төртелде, шома ботлары аягына килеп сарылдылар. Егет сакланып кына кызның аркасыннан кочып алды. Рәхиләнең еш-еш сулавы кисәк туктап калды. Егет кызны кочагына катырак кысты, кыз карышмады. Нидер эзләгәндәй, Рөстәмнең иреннәре кызның бите буйлап йөри башлады. Кыз бәхетле күзләре белән Рөстәмгә күтәрелеп карады. Аннары ике кулы белән егетнең муеныннан кочып алды да башын үзенә таба тарткандай итте. Алар көткән мизгелләр, ниһаять, килеп җитте. Тәҗрибәсез иреннәр, бер-берсенә җавап биреп, бергә кушылдылар.

Их син, беренче мәхәббәт! Нинди татлы да син, нинди назлы да, сагышлы да син. Тәүге тапкыр сөйгәнең кочагында сарылып үбешү юкка гына адәм баласын гомере буе эзәрлекләп бармый. Никадәр наз, никадәр хис, никадәр мәхәббәт синдә – беренче үбешү мизгелләре?!

Рөстәм белән Рәхиләнең иреннәре бер-берсеннән аерыла алмый азапландылар. Әйтерсең, бу минутларны озаккарак сузарга тырышалар иде.

Ике гашыйкның мәхәббәт очкыннары, күкләргә атылып, яшен булып яшьнәде; күкрәкләреннән чыккан кайнар дулкыннар, давыл булып, биек-биек агачларның башларын түбән иде.

– Әйт! Менә хәзер әйт, – дип, егетнең иреннәреннән көчкә аерылып, пышылдады Рәхилә.

– Мин яратам сине, Рәхилә!

– Тагын әйт, Рөстәм.

– Мин яратам сине, Рәхилә!

– Әйт, тагын-тагын әйт! – Кыз егетнең күкрәгенә башын салды.

– Мин я-рат-там сине, Рәхилә! Ишетәсеңме, урман, мин я-ра-там!..

* * *

«Уйланган эш, беткән эш», – дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Чыннан да, әзер мунчаны кире күтәреп кую озак булмады. Дүрт-биш көндә эшен дә бетерделәр. Инде эш мунча миченә терәлеп калды. Элеккеге кебек кирпечтән булдырасы килмәде Сәмиганың. Хәзер тимердән дә менә дигән итеп эшләп куялар икән аны. Йорттагы ике бөртек кеше өчен кочак-кочак утын тутырып ягасы килми бер дә. Тимер мичкә бер кочак утын да бик җиткән, диләр. Шул турыда сүз чыккач:

– Авылда безнең йорттан ике өй, уң яктагы йортны беләсең бит, кызым, – диде этисе.

– Беләм, эти, анда яшәгән әби белән бабай үлеп киткәннән бирле буш тора бит.

– Әйе, шул йорт. Анда бер егет күчеп кайтты, егет дип, яше утыздан узган инде аның, бер тапкыр да өйләнгәнем юк дигәненә күрә, егет дип әйтәм инде.

– Соң?

– Шул сварщик та, тимерче дә икән үзе. Чынлап әйтәм, тимер эшенә куллары алтын, колхозга чыгып эшләп йөрми, өендә тимер эшләрен эшләп ята. Мунчага дигән тимер мичләрне дә ясый.

– Кыйбат сорар микән, эти?

Салих абый иңбашын җыерды:

– Белмим, әниең белән миңа шул кирпеч мич ярап тора, шуңа бер дә кызыксынганым булмады.

– Ә каян, нигә күчеп кайткан?

– «Тулай торакта егерме ел тараканнар белән яшәдем, булды, җитте»? – ди.

– Ә үзе кайсы яктан?

– Казан янындагы авылларның берсеннән бугай. Ник шунда кайтмадың дигән идем, шәһәрдән бөтенләй ерак торасы килгән.

– Әти, бәлки, сөйләшеп карарсың?

– Ярар, белешермен алайса.

Икенче көнне карсак буйлы, коңгырт кара йөзле, кырык яшьләр тирәсендәге бер ир-егет Сәмиганың болдыр ишеген какты.

Сәмига, ишекне ачуга, бераз куркынып арткарак чикте.

– Исәнмесез, сезгә кем кирәк?

– Исәнмесез! Сәмига дигән хатын шушында яши, дигәннәр иде, – дип, җайлап кына endәште ир.

– Мин булам инде ул Сәмига.

– Салих абый сезгә тимер мич кирәк, диде, мунчаның эчен карап чыгасы иде, размерын алырга кирәк.

Сәмига бу сәер кеше белән мунчага икәү генә керергә курыкты:

– Рөстәм, улым!

Җавап бирүче булмады. Сәмига, улын эзләп, йорт артына чыкты. Уфалла арбасы урынында юк. Аңлашылды, Рөстәм тагын печәнгә киткән.

– Әйдәгез, – диде ул, иргә эндәшеп. Аннары мунча ишеген ачты да керергә дип ишарә ясады. – Үзегез кереп карагыз инде.

Ир ялындырмады, кесәсеннән рулеткасын ала-ала, кереп тә китте.

– Булды, – диде ир, мунча эченнән чыккач. – Биш-алты көннән китереп куярмын.

– Бик тиз, минем акчам җитәр микән?

– Борчылмагыз, кыйбат алмыйм мин. Берүзем генә яшим, эшсез ятып тилермәс өчен генә эшләгән булам инде шунда.

– Ә???

– Нәфис, – дип, үзе белән таныштырды ир, хатынны аңлап алып.

Нәфис! Үзе бер дә нәфискә охшамаган. Охшамаган дип, бер нәфисне ошатты инде ул, гомерлеккә үкенеч булып калды. Кешене тышкы кыяфәтеннән билгеләп булмый, монысы хак.

– Ә???

– Сәмига, беләм, – дип елмайды ир.

Хатын әллә нишләп китте. Моңарчы аңа елмайган ирләр аның күзенә «татып карарга иде сине бер» дигән кебек күренәләр иде. Ә бу күптәнге танышы кебек елмайды. Күзләре белән капшап чыкмады, ялгыз хатын икәнен беләдер инде. Тик бернинди кинаясез елмая ир.

– Ярар алайса, китерсәгез, мин өйдә булмасам да, улым булыр, – дип, үз-үзен бик тиз кулга алды хатын.

– Мин озак тотмам, Сәмига.

– Ярар, ярар, мин риза.

Ир капкага таба борылды.

Нәрсә соң бу? Сәмиганың ирне капкадан чыгарып җибәрәсе килми түгелме соң? Беренче күргән кешене, нишләде соң ул?

– Юлда килгәндә сусагансыздыр. Бәлки, күәс эчеп китәрсез.

«Нишлисең син, тиле хатын»? – дип, үз-үзен эчтән битәрләргә тотынды Сәмига.

– Күәс, дисезме? Начар булмас иде.

Хатын, кабаланып, йортка кереп китте.

Ул күәс күтәреп кире чыкканда, ир урыныннан кузгалмый да басып тора иде. Сәмига сузган күәсне, рәхмәт әйтеп, күтәреп эчеп куйды.

– Ай, квасны тәмле ясыйсың икән, Сәмига.

– Рәхмәт, – диде хатын, үзен мактаганга куанып.

– Сау булыгыз.

– Әйе, сау булыгыз.

Сәмига, ирне озаткач, хәле китеп, капка коймасына сөялде.

«Тик торганнан ни булды соң сиңа, Сәмига? Бер күрмәгән, колак ишетмәгән ир каршында нишлисең син?

Тик гомерең буена көчле хатын булырга, барсына да үзең генә ирешергә, дип сүз бирсәң дә, ничә еллар мәхәббәткә сусаган җаның бар икәнен, тәнеңдәге бар күзәнәкләр сөяргә-сөелергә яратылган хатын-кыз дигән затныкы икәнен онытмадыңмы син, Сәмига?»

Мичне Нәфис белән Рөстәм икесе урнаштырдылар. Сәмига, эш беткәнче, ничә мәртәбә генә мунча эченә кереп чыккандыр. Улы белән оста килешеп эшләделәр. Рөстәм Нәфис абыйсыннан сварщик һөнәре турында сораштырды.

– Эшенең рәтен белсәң, бернәрсәсе дә юк инде аның, Рөстәм, – дип җавап бирде аңа Нәфис. – ПТУга керсәң, килгәләп кит минем янга, өйрәтермен. Күрәм, син шулай тиеш булган өчен генә түгел, һөнәрен өйрәнергә телисең.

– Акчасызлыктан котылырга иде, Нәфис абый, – дип җавап бирде егет, – әнинең иртәдән кичкә кадәр башында шул уй.

– Мин үзем генә яшәгәч җитә. Бабаңның авылы бик кечкенә авыл, әллә сезнең авылга күченим микән дип тә уйлап куйгалыйм. Заказ күп була минем, монда юл әйбәт, килеп-китеп йөргән кешегә уңайлы булыр иде.

Бераз дәшмичә генә эшләгәч, Нәфис кабат телгә килде:

– Акча дисәң, башта бер фикер туды әле, Рөстәм. Миңа бер бай: «Дачага паровой батареясын кертәсе бар»? – дигән иде. Аннары суын кертәсе, канализация, бассейнга су үткәрәсе... Кыскасы, эше муеннан. Әйдә, мин сине үзем белән алып китәм. Миңа барыбер кулалмаш кирәк.

– Әнигә әйтеп карармын.

– Әйтеп кара.

– Минем осталар ничек монда? – Мунча ишегенә Сәмига башын тыккан икән.

– Ничек дип, Сәмига, эше бетте дисәң дә була, хет хәзер үк як та кер.

– Рәхмәт яугырлары, җәй буе кешегә ялындык. Рәхмәт инде, Нәфис.

Осталар табын артына килеп утыргач, Сәмига өстәлгә бер ярты чыгарып куйды.

– Син моны үзең кара инде, Нәфис.

– Алып куй әле, Сәмига, – дип, кәефе кырылып җавап бирде моңа каршы ир.

– Ник?

– Аракы эчеп карамаган кеше түгел мин, эчеп бетерә алмагач, авызга алмас булдым бу шайтан суын.

– Күптәнме?

– Хәтерләмим, ун елдан артыктыр.

– Эчкән кешене үзем дә яратмыйм, Нәфис. – Сәмига аракы шешәсен алып куйды.

– Әни, мине Нәфис абый шабашкага чакырды.

– Кая, нинди шабашка ул тагын?

– Бер байның дачасын җылытырга кирәк. Сәмига, җибәр минем белән егетне. Акча эшләп кайтыр.

– Мин белмим, Нәфис, моңарчы Рөстәмне үземнән еракка җибәргәнем юк иде.

– Әйдә, борчылма, егет бит инде ул хәзер.

– Әни, барыйм инде.

– Син барырсың да, мин үзем генә нишләрмен монда?

– Рәхилә килгәләп торыр.

– Ярар соң алайса, барып кайт. Нәфис, караштырып тор инде син аны.

– Борчылма, Сәмига, ничек алып китәм, шул килеш китереп куярмын.

Рөстәмгә шул җитә калды, егет өстәлдән торып ук китте.

– Улым, син кая?

– Рәхиләгә барып кайтам.

– Әйтәм аны артыңа ут капкандай торып бастың. Ярар, бар инде, – дип елмайды Сәмига.

Чәйләп алгач, Сәмига белән Нәфис мунчага су ташып ягып та җибәрделәр.

– Менә булды да, – дип елмаеп куйды Нәфис, үз эшенә куанып.

– Әйе, булды. Менә, Нәфис, килешкән акчаны ал. – Сәмига иргә тиешле акчасын сузды.

Нәфис бер акчага, бер Сәмигага карады да,юк дигәндәй, башын селкеде.

– Мин аңламадым, Нәфис, нигә башың селкисең?

– Кирәкми, алмыйм, Сәмига.

– Нигә алмыйсың, үпкәләдең мәллә бер-бер нәрсәгә?

– Юк, алмыйм, кирәкми, кыстама да, көчләмә дә.

– Нигә?

– Әйтә дә алмам инде, Сәмига.

– Әйт, курыкма, каты иттереп әйтсәң дә үпкәләмәм.

– Юк, әйтмим. – Ир, борылып, капкага таба атларга итенде, тик кире уйлап туктап калды.

– Сәмига, әйтсәм, чынлап үпкәләмисеңме?

– Юк, үпкәләмим, Нәфис, әйт.

Ир тирән итеп сулыш алды, ахрысы, ул шулай бар йөрәген уч төбенә җыеп кысты.

– Сәмига, бүген кич Керәшен болынына килә алмассың микән?

Көтелмәгән тәкъдимнән хатын аптырап китте. Ни әйтергә тели бу Нәфис? Хатынны икеле-микеле уйлар таларга тотынды.

– Сәмига, ачуланма, зинһар өчен дип әйтәм, уем начарлыкта түгел. Ошаттым мин сине, бары шул гына.

– Мин, мин... нәрсә дип тә әйтә алмыйм бит, Нәфис.

– Беләм, тик шулай да Керәшен аланында бүген сине көтәчәкмен. Таңга кадәр, китми, сине көтеп утырачакмын. – Нәфис капкадан чыгып китте.

Тормыш, йорт, каралты-кура, бала тәрбияләп гомере үткән Сәмига аптырып калды. Яшь кыз түгел бит инде, егетләр янына «свиданиега» йөрергә. Хатын беренче тапкыр үз тормышы турында уйланды. Күпме гомерен ялгыз башы гына уздырды. Ә куенына сыендырып назлаучы ир канаты юк икәнен сизендеме соң ул? Билгеле, сизенде. Бары тик кемнеңдер иңенә башын салып, тын гына утырасы килгән вакытлары аз булмады. Бу Нәфисе тагын, беренче күрүгә куркыткан иде, тик куркыныч кеше түгел икән лә ул...

– Ярар, кич җитсен әле, анда күз күрер. – Сәмига сәгатькә күз салды.

Һай, кичкә кадәр ерак икән шул әле. Хатын, яшь кызлар кебек дулкынланып, кичне көтә башлады.

Рөстәм мәктәпне бетерде, кулына аттестат та алды. Аннары классташлары белән таң каршыладылар. Классташлар белән дип, егет кочагына Рәхиләне сыендырып таң аттырды инде. Нәфис абыйсы белән ясап куйган тимер эскәмиядә әнисе чыкканын көтеп утыра менә. Ярады бу Нәфис абый белән эшләү. Әнә, койма белән капкасын да эшләп куйдылар. Бүген район үзәгенә барып, ПТУга укырга керү өчен гариза язасы бар. Әнисе, юл уңае, яңа сарай өчен кадаклар ал, дигән иде, егет Сәмиганың акча алып чыкканын көтеп утыра. Әйе, яңа сарайны да булдыра алдылар, шөкер. Эчен генә бүлеп куясы калды.

Сәмига, капкадан чыгып, улы янына утырды.

– Мә, – диде хатын, улына акча белән кәгазь кисәге сузып, – нинди, күпме кадак кирәк икәнен дә яздым.

– Беләм бит инде аны, әни.

– Белсәң дә, кулыңда булсын, онытылып китүе дә бар.

– Ярар, мин киттем.

– Улым, тукта әле, – дип, әни кеше кузгала башлаган малаен туктатты, – һаман-һаман сузып йөрим, сиңа әйтергә куркып.

Рөстәм кире утырды:

– Нәфис абый турында әйтәсең киләме?

– Әйе, шуның турында. Синең белән сөйләшми торып, Нәфискә бернинди дә җавап бирә алмыйм мин.

– Нәрсә дип әйтим инде, әни, мин менә көзгә укырга чыгып китәм, аннары армиягә китәсе, еллар буе үзең генә тора алмассың, килсен дә торсын безнең белән Нәфис абый.

– Улым, аңлавың өчен рәхмәт.

– Ярар, әни, үзең кара инде, алга таба барыбер мин өйдә күп вакыт булмам. Әйбәт кенә яшәгез шунда.

Сәмига белән Нәфис кияү һәм кәләш булып туйлап тормадылар инде. Районга барып язылышып кына кайттылар да, мулла чакырып, никах укыттылар. Шуның белән шул. Яшь кияү эш эзләп йөрмәде, клиентлар аның гаилә мәшәкатьләре беткәнен көчкә көтеп тора алдылар. Нәфискә Рөстәм дә булышты. Ә Сәмиганың дөньясы түгәрәк. Бигрәк тә улы белән иренең килешеп китүләренә бик шат иде хатын.

Билгеле, авыл халкы да чәйнәми калмады бу яңалыкны.

– Сәмига теге тәкәсен суйган иде, үзенең кәҗәсе тәкә сорый башлады, – дип теш агартучылар да булды.

Мондый оятсыз сүзләрне әлеге дә баягы Филүс туктатты.

– Башыгызда бер юньле уй юк сезнең, – дип, авылдашларын сүкте ул, – үзегез шул турыда гына уйлаганга, сүзегез дә шуннан ерак китми сезнең. Ике ялгыз кешегә кара-каршы утырып чәй эчәргә иптәш кирәк!

Шуннан соң Сәмига белән Нәфис турында теш агартучы булмады. Аннары алтын куллы егетнең үз авылларында төпләнеп калуы чынлыкта зур табыш икәнен бик тиз чамалап алды халык. Сабыр, күндәм холыклы Нәфис гозерләнеп килгән берсен дә кире бормады. Хуҗалык булгач, сварщиксыз беркая да барып булмый, ә хәзер, оста эзләп, күрше авылларга чабасы калмады. Моңа авыл халкы бик шат иде.

***

Тальян тавышы яңгырый, әй сызлана, әй моңлана да соң тальян. Рөстәм Рәхиләне күкрәгенә кыскан да сөйгәне белән вальс әйләнә. Бүген аларның хушлашу көне, иртәгә Рөстәм хәрби хезмәткә алыначак.

– Көтәрсеңме, Рәхилә?

– Көтәрмен, Рөстәм, олы юлдан карап, күзләрем талганчы сине көтәрмен. Син кайтасы көннең сәгатен-минутын санап көтәрмен. Сагынырсыңмы мине, Рөстәм?

– Өзелеп-өзелеп сагынырмын, Рәхилә, син көт, яме?

Кыз кабаттан егеткә сыена төште.

Кинәт сабый бала еларга тотынды, Рөстәмнең кечкенә сеңлесе икән. Олылар тавышланганга риза булмыйча, кечкенә Наилә елый.

Рөстәм сеңлесен кулына алды да акрын гына тибрәтә башлады.

– Ә-ә-ә-ә.

Юк, бала туктарга уйламый да, елапмы-елый. Рөстәм катырак тирбәтә башлады:

– Ә-ә-ә-ә.

«Нигә туктамый соң бу бала?»

– Ә-ә-ә-ә-ә.

Кинәт аның җилкәсеннән җилтерәтергә тотындылар.

– Татарин, әй татарин, саташасың.

Рөстәм күзләрен ачты, кабат туган йорты төшенә кергән икән.

Ул, кулларындагы сынҗырларын шалтыратып, ике кулы белән башына ябышты.

– Нәрсә, татарин, – старшина Ныйкин каршында утыра икән, – төш күрдеңме?

Рөстәм, «әйе» дип баш какты.

– Начар төш, ахры, – Ныйкин да, сынҗырларын шалтыратып, кулына китек кувшин алды һәм Рөстәмгә сузды, – мә, эч.

– Юк, – диде Рөстәм, башын селкеп, – туган йортны күрдем төштә.

– Туган йорт төшкә кергәч, әйбәт әле ул, – дип, хайван абзарының баганасына аркасы белән сөялде старшина, – димәк, хайванга әйләнмәгәнсең әле.

Рөстәм сарай эчен күзәтеп чыкты.

– Старшина, син монда күптәнме инде?

– Монда өч ай, ә болай кулдан-кулга йөри башлаганга ел ярым.

– Ничек тилегә әйләнмәдең әле син?

Ныйкин иңнәрен җыерды:

– Адәм баласы хайванга тиң, бар җирдә дә җан саклый ала. Ә Абдулда алай начар түгел. Чынлап әйтәм, минем айлар буе, зиндан дип аталган, өстенә дә япмаган чокырларда да ятканым бар.

– Мин тилегә чыгармын, ахры.

– Юк, чыкмыйсың, татарин, синдә стержень бар. Кичә теге маңкалар сине нишләткәннәрен абзар тишегеннән күреп тордым мин.

Кичә көндез Абдулның малае хайван абзарына килеп керде. Керде дә, бераз каранып торгач, Рөстәмгә таягы белән китереп сукты.

– Урамга чык.

Ә урамда Абдул малае кебек ундүрт-уналты яшьләр тирәсендәге унлап малай аларны көтеп тора иде инде. Рөстәм чыгып баскач, аңа таба төртеп күрсәтеп, ни турындадыр сөйләшеп көлешә башладылар.

Абдулның малае аны шул төркем уртасына кертеп бастырды.

– Тезлән!

Рөстәм кымшанмады да.

– Тезлән, дидем, хайван!

Рөстәм басып тора бирде.

Бу калганнарга ошамады, Рөстәмне җиргә егып салып типкәли башладылар. Ярый Абдулла вакытында күреп алып коткарды. Рөстәмне типкәләгән малайларга нидер әйтеп кычкырырга тотынды. Аннары канга баткан әсирнең якасыннан тотып, кире абзарга кертеп ябып куйды.

– Старшина, синең качып караганың бармы?

– Ике тапкыр.

– Нигә тотылдың?

– Ә кая барасың, монда таулар, юлны таба белмибез. Шуңа бик тиз эләктерделәр. Башка кышлакларга да кереп булмый бит, шундук тотып алып, кире хуҗага кайтаралар.

– Тагын качарга уйламыйсыңмы?

Старшина көлеп җибәрде.

– Конечно, уйлыйм, син что, татарин, монда калырга җыенасыңмы әллә?

– Юк.

– Шулай булгач.

Рөстәм башта Мәскәү астындагы десантчылар полкына эләкте. Анда ярты ел өйрәнүләр үткәч, аны башкалар белән бергә Чечняга командировкага җибәрделәр.

Җибәрделәр дип, барып җитә алмадылар. Хәрби колонна таулар арасыннан алар хезмәт итәсе частька таба бара иде. Кинәт тау башыннан сакаллы баш калыкты.

– Аллаһу әкбәр!

БТРга утырып барган Рөстәмнең каршында кинәт утлы көлтә хасил булды. Шартлау дулкыны аны БТРдан таш өстенә алып ыргытты.

Аңына килгәндә, Рөстәм, кул-аяклары бәйләнеп, ат өстенә салынган килеш каядыр бара иде. Аның ыңгырашканын ишетеп, янына сакаллы бер кеше йөгереп килде. Чәченнән күтәреп, егетнең йөзенә карады.

– Һе, исән, шакал, шулай ит, үлә күрмә. Мин синең хуҗаң булам, Абдулла исемле мин, исеңдә тот шуны.

Аннары Абдулла, читкә карап, үз телендә нидер әйтте. Моңа каршы шаркылдап көлешкән тавышлар яңгырады.

* * *

Соңгы арада Сәмиганың кулыннан эш китте, инде өченче ае узып бара, Рөстәмнән хат килгәне юк. Командировкага җибәрәләр, дигән иде соңгы хатында. Шуннан бирле баладан хат-хәбәр юк.

Өстәл артында кызын ашатып утырган хатын иренә эндәште.

– Нәфис, нигә Рөстәмнән хат-хәбәр юк икән?

– Болай өстәл артында ногыт борчагы белән багып утырып булмас, әнисе, – дип җавап бирде ире.

– Нишлибез?

– Мин район военкоматына барып кайтырмын, Рөстәмне шуның аркылы эзләтми булмас.

– Җаным, исән генә була күрсен, Ходаем!

– Яле, әнисе, юкка ахылдап утырма, бәлки, хатлары берәр җирдә китә алмый өелеп ятадыр.

– Амин, шулай гына була күрсен, әтисе. Амин, амин, шулай гына була күрсен.

Болдыр ишеген каккан тавыш ишетелде.

Сәмига йорт ишеген ачып кычкырды.

– Кер, кызым!

Шәленә төренгән Рәхилә килеп керде, кышкы салкыннан кызның ике бите дә кызарып чыккан.

– Суык ахры бүген, Рәхилә, ялга кайттыңмы?

Кыз, сорауларның берсенә дә җавап бирмичә, Сәмигага карап эндәште:

– Сәмига апа, юкмы?

– Юк, кызым.

Рәхилә, ике битен каплап, урындыкка утырды.

– Апаларыңның адресын беләме Рөстәм?

– Белә.

– Анда да хат килмиме?

Кыз, «юк» дип башын селкеде. Сәмига Рәхиләне кочып алды.

– Рәхилә кызым, кызым бит син минем, әйдә, яхшыга гына юрый күрик.

Кыз тыела алмый үксеп елап җибәрде.

– Нигә язмый ул, Сәмига аппа-а-а?

– Белмим, кызым, Нәфис абыең дүшәмбе район военкоматына барам, диде.

Кыз, яшьле күзен күтәреп, Нәфис абыйсына карады.

– Мин дә барам сезнең белән.

– Ә уку?

– Булсын, барыбер барам.

...Дүшәмбе көнне Нәфис белән Рәхилә район военкоматына килеп керделәр. Нинди йомыш белән йөргәннәрен белгәч, аларны военком кабинетына чакыртып алды.

– Кайчаннан бирле хаты юк, дисез?

– Өченче ае китте, – дип җавап бирде Нәфис.

– Ярар, борчылмагыз, хәзер очына чыгарбыз, – диде. Полковник, кабинетыннан чыгып, Рөстәмнең делосын кулына тотып, кире әйләнеп керде.

– Тәк, – дип, делоны актара-актара дәвам итте военком. – Мәскәү астындагы дивизия, телефон номеры.

Полковник телефон номерын җыйды да элемтәнең икенче башындагы дежурныйга каян, ни йомыш белән шалтыратканын аңлатты.

Аннары бераз көтеп торды.

– Зам по личному составу үзе сөйләшәчәк, – диде дежурный.

Бераз вакыт үткәч, элемтәнең икенче башыннан кемдер тавыш бирде.

– Әйе, тыңлыйм, әйе, әйе.

Военкомга телефон аркылы бик озак нәрсәдер аңлаттылар. Бу вакытта Нәфис белән Рәхилә тын алырга куркып утырдылар.

– Ярый, аңладым, – дип, военком телефонны куйды да, – тәк, – дип торып басты.

Аннары кабинет буенча йөренеп килде.

– Полковник, азаплама.

Военком алар каршына килеп басты, Рәхиләгә карап сорау бирде.

– Ә син, сеңлем, кеме буласың?

– Кәләше, – дип көчкә тын алып эндәште Рәхилә.

– Полковник.

Военком тирән итеп сулыш алды:

– Эшләр менә болай. Сезнең егет утырып барган хәрби колонна боевиклар засадасына эләккән. Бары бер егет, таш арасына качып, исән кала алган. Шул егет сөйләве буенча, боевиклар колоннаны тар-мар иткән, үлгәннәрне һәм яралы солдатларны, машина арбасына ыргытып, ут төрткәннәр. Махсус эшлиләр шулай, туганнары таба алмасын, дип. Тагын ул солдатның сөйләве буенча: дүрт егетне, атка аркылы салып, таулар арасына алып кереп киттеләр, дигән. Янган солдатларны ДНК буенча ачыклау озак эш, сезнең егетне һәлак булган яки әсирлеккә төшкән дип берсе дә әйтә алмый. Монысына вакыт кирәк, шуңа хәбәр бирми торганнар.

Нәфис уң кулының беләге каты авырту сәбәпле айнып китте. Рәхилә, үзе дә сизмәстән, полковникны тыңлаганда, ирнең беләген чеметә башлаган икән.

– Нишлибез инде хәзер, полковник?

– Исән булса, хәбәр бирер, боевиклар, акча сорап, хат язарга кушачаклар аңа. Яхшыга юрый күрегез, бәлки, хаты килеп төшәр.

Рәхилә белән Нәфис, томан арасында йөргән кебек, салкын урамга чыгып бастылар.

– Тукта, Рәхилә, тынычлан, сеңлем. – Телен көчкә әйләндереп, кызга эндәшә алды Нәфис, – бәлки исәндер, хаты килер. Акчасын табарбыз, бар нәрсәне сатып бетерербез, тик аны коткарырбыз.

Ә Рәхилә җавап бирерлек хәлдә түгел, ул сыгыла-сыгыла елый иде.

– Син менә ишеттең яман хәбәрне, ә авылда ут йотып Сәмига апаң көтеп тора мине, аңа ни дип җавап бирермен, сеңлем?! – дип өзгәләнде Нәфис.

***

– Яз! – дип, Рөстәмнең битенә сакалын терәп кычкырды Абдулла.

– Язмыйм.

Абдулла кабат Рөстәмнең йөзенә сугып җибәрде, бу юлы хәйран саллы тамызды. Рөстәм урындыктан идәнгә үк тәгәрәп төште.

– Яз, хәшәрәт! – Абдулла, әсирнең якасыннан күтәреп, кәгазь белән ручка торган өстәл артына җилтерәтеп китереп утыртты. – Яз!

Рөстәмнең авызы тулы кан иде.

– Язмыйм, – дип, ярылган иреннәрен көчкә кыймылдатып, идәнгә төкерде Рөстәм.

– Язма, язма, – дип тәкрарлады Абдулла, аннары, әсир каршына басып, өстәлгә таянып кычкырды, – язма, тере килеш черерсең сарайда, сарыклар, кәҗәләр арасында.

Сарай ишеген ачып, Рөстәмне эчкә этеп җибәрде дә Абдулла тыштан бикләп куйды.

Рөстәм аягына басарга азапланып карады, булмады, кәҗә-сарыклар арасына гөрселдәп барып төште.

Старшина, йөгереп килеп, аны күтәреп алды да, читкәрәк, үзләре салам җәеп әмәлләгән җир ястыкка китереп салды.

– Абау, тагын тетеп ташлаган сине, кабахәт.

Ул китек кувшиндагы суда каралып беткән ниндидер чүпрәк кисәген чылатты да Рөстәмнең иреннәренә тидерде, аннары канга баткан битен сөрткәли башлады.

– Старшина, тимә, бик әшәке сызлый.

– Язмадыңмы?

– Юк.

– Кара әле, Рустик, бәлки, кире татарлыгыңны читкә куеп торырсың, ә? Болай кыйнап үтерәчәк бит ул сине.

– Нәрсә?

– Бәлки, өеңә акча сорап язарсың, дим.

– Юк.

– Соң, үҗәт татар, ичмасам, әниең исән икәнеңне белеп торыр иде. Ярты ел бит инде синең юкка чыкканга.

– Юк, язмыйм, аларны борчымаячакмын.

– Әйе, болай борчылмыйлар ди анда. Аллага шөкер, Рөстәм юкка чыкты, дип, авылыгыз белән көн-төн бәйрәм итәләр, ди.

– Ә син яздыңмы соң?

– Кая инде тагын?

– Өеңә.

– Өй! Ә нәрсә була соң ул өй, татарин?

– Башыңны тилегә салма инде.

– Юк, чынлап юк минем өем, Рустик.

– Ничек юк?

– Менә шулай.

– Аңламадым.

– Мине роддомнан туры ятим балалар йортына олактырган газиз әнкәй. Шунда үстем, аннары армия, кайтыр җирем юк, контракт төзеп, хезмәттә калдым.

– Ә бу тәмугка ничек килеп эләктең?

– Ха-ха-ха. Ну, малай, мине, сине каршылаган кебек, гранатомёттан салют атып, берсе дә каршыламады инде.

– Ә ничек?

– Зарплата бирделәр, яхшы гына частьта юдык зарплатаны, җитмәде, самогон эзләп, якындагы кышлакка чыгып киттем. Менә шул, мине анда бу сакалбайлар каршы алды. Эчкә автомат приклады белән берне дөңгерт. Калганын үзең беләсең. Икенче ел инде кулдан-кулга йөрим. Кемгә кол кирәк, шул сатып ала. Әнә Абдулла ике кол тота, ул – бай.

– Бай, тотып буар идем мин аны.

– Әйе, бар, ябыш бугазына, монда җирле халык ыру белән бер җиргә укмашып яши. Сине минут эчендә сарык кебек, кых.

– Шуңа котырына да инде алар.

– Монда – таулар кануны, сезнең кебек бер-берсен сатып яшәми тау халкы. Ә менә Казаныңда булса, Абдулла сиңа «брат» дип эндәшкән булыр иде.

– Туган, очрый калса, күрсәтер идем мин аңа туганны.

– Әйе, шулай итәрсең, башта башыңны исән-имин килеш алып чык моннан. Ярар, әйдә ят, йоклап алырга кирәк. Яз җитте, иртәгә Абдулла, китмән тоттырып, үзәндәге басуына куып чыгарыр инде, соңгы арада бик котырына башлады әле ул. Бүген сарай тәрәзәсеннән кышлакка карап тордым. Безнең кебек биш колны каядыр куып алып киттеләр.

– Кая икән?

– Әфгангадыр, тагын кая булсын.

– Анда нишләтәләр?

– Мәк басуында эшләтүләре бар. Аннары сүтеп, запчастька да сатып җибәрә алалар.

– Бавыр, бөер.

– Әйе, икебез дә яшь, таза.

– Старшина, качарга кирәк.

– Бик дөрес сүзләр. Слушай, татарин, кайчак башың яхшы уйлый синең. Яз җитте, төнгә җылы, таулардагы карлар эри. Абдулла кышлактан үзәнгә алып чыксын инде. Монда кышлактан качу турында башыңа да китермә.

Төн уртасында ике әсирне дә тонык гөрелдәгән тавыш уятты.

– Язгы яңгыр.

– Юк, – дип башын селкеде старшина. – Синең сугышта булганың юк, «градлар» тавышы бу.

– Федераллар.

– Әйе, шулар.

– Алар безне коткарачак!

– Әйе, шулай итәрләр, мондагы халыкны дурак дип белдең мәллә син? Алар килеп җиткәнче, безне юкка чыгарачаклар. Рәсәй законы буенча, кол тоткан кешегә саллы гына срок эләгә. Безне әллүр, кыя бөркетләренә ризык

итеп. Ә җирле халык, әйткәнемчә, бер-берсен сатмый. Хуҗа, федералларга, боевиклардан коткарган өчен, башын бәрә-бәрә рәхмәт укыячак әле.

Ике әсир дә, таңгача керфек какмый, сугыш авазын тыңлап чыктылар.

Икенче көнне Абдул аларны абзардан куалап чыгарды да ишегалдында торган зур көпчәкле уфалла арбасына төртеп күрсәтте. Аңа ике китмән, аннары Абдулла өчен ризык төялгән иде. Хуҗа автомат көпшәсе белән арбага таба төртеп күрсәтте.

– Җигелегез, ишәкләр!

Абдулла аларны моңа кадәр дә карап торып эшләтә иде, бүген аеруча усалланды. Туктап тын алырга да ирек бирми. Аз гына «аһ» итеп тын алдыңмы:

– Эшләгез! – дип акыра башлый.

– Нишләгән бу бүген? – дип, шыпырт кына иптәшенә эндәште Рөстәм.

– Нишләсен, кичәге атыш тавышын ул да ишетте инде, бүген кичкә кадәр безне куалап эшен эшләтеп бетерәчәк тә аннары, әнә, аска, икебезне упкынга очырачак.

– Димәк, бары кичкә кадәр вакыт калды.

– Әйе.

Кинәт Рөстәм эчен тотып бөгәрләнеп төште.

– Ай, үләм, эчем-эчем.

Абдулла эштән туктаган әсирләр янына йөгереп килде.

– Эшләгез, кабахәтләр, нигә туктадыгыз?

– Тукта инде, Абдулла, әнә егеткә нидер булды.

– Кая? – Абдулла игътибарын, старшинадан алып, Рөстәмгә юнәлдерде.

Шулчак аның муенын Ныйкинның богау чылбыры чорнап алды. Эчен тотып яткан Рөстәм дә кинәт кулына зур таш кисәге тотып сикереп торды да хуҗаның маңгаена шуның белән китереп орды.

– Инде артка юл юк, татарин, – диде Ныйкин, кулларындагы богаулардан арынганда. Ачкычы Абдулланың кесәсендә генә булган икән. – Әгәр дә тотсалар, Абдулла өчен яшәтмәячәкләр безне.

Аннары икесе ике яктан тотып, Абдулланың һушсыз гәүдәсен упкынга аттылар, старшина өстендәге теткәләнеп беткән комуфляжны да ыргыттылар.

– Старшина, безнең күпме вакыт бар?

– Вакыт, дисеңме? – дип сорады иңсәсенә Абдулланың автоматын аскан Ныйкин. – Кичкә кадәр безне көтмиләр әле кышлакта. Аннары, Абдулла кайтмагач, эзли чыгарлар. Төнлә упкынга төшеп, аның гәүдәсен берсе дә эзләмәячәк. Иртәгә иртүк аска төшеп, Абдулла янында безнең гәүдәләрне тапмагач, эшне төшенеп, эзли чыгачаклар. Бар кышлакларга да качаклар турында хәбәр таралачак.

– Кыскасы, егерме дүрт сәгать.

– Әйе, шул тирә.

– Нишлибез?

– Атыш тавышы килгән якны беләсеңме?

– Әйе, беләм.

– На-ле-во! – Рөстәм борылып басты. – Бегом марш!

Ике качкын да үзән буйлап йөгереп китте.

– Старшина, юлга чыгып булмас, әнә теге тау башында куаклыклар тезелеп киткән.

– Аттыр әйдә шунда, – дип арттан тавыш бирде Ныйкин.

Алар төнне куаклар арасында үткәрделәр. Икенче көнне төшкә кадәр, куак

ерып бара торгач, зур агачлыкка килеп чыктылар. Монда хәтсез генә карга оялары бар икән. Качакларны күреп, каргалар, каркылдап, разбой салырга тотындылар.

– Анасын гына инде, – дип аты-юлы белән сүгенеп алды Ныйкин.

– Нәрсә булды?

– Качаклар турында инде бар кышлаклар да беләдер, каргаларның болай тузынганын да күреп алырлар инде. Кыскасы, ярты сәгать эчендә безне чорнап алачаклар.

Рөстәм баш очындагы разбой салып каркылдаган каргаларга күтәрелеп карады. Их, димәк, бетте барсы да. Ул карашын аска төшерде, старшинаны күреп алуга, кинәт сискәнеп артка чикте.

– Старшина, нишлисең син? – Ныйкин автоматын аңа таба төбәгән иде.

– Татарин, мин ялгыз кеше, мине беркем дә көтми. Ә синең әнә әниең бар, кечкенә сеңлең, дөньяда бер чибәр кәләшем бар, дисең. Мин боларны тоткарлыйм, ә син бар кач, котыл.

– Юк, старшина, мин сине монда калдырып китмим.

Ныйкин автомат затворын тарткалап алды.

– Татарин, гөнаһка этәрмә мине, сине көтәләр, ә мине көтеп торган беркем дә юк. Якын килмә, атам да егам, барыбер икебезгә бер автомат белән берни дә эшли алмыйбыз без.

– Старшина!

– Зинһар өчен, кач! – дип өзгәләнеп кычкырды Ныйкин.

Рөстәм агачлык буенча чабып китте. Бераз тын алмый чапкач, Рөстәм арттан атыш тавышларын ишетте. Атыш егерме минут тирәсе барды, аннары таулар арасында тынлык урнашты.

– Ныйкин, мин сине мәңге онытмам, урының оҗмахта булсын, – дип, үзалдына пышылдады Рөстәм.

Кара төн җиткәнче кармаланып бара торгач, Рөстәм тәмам аяк атлый алмас дәрәҗәдә алҗып бетте. Ташларга сөртенә торгач, тез башлары туктамый канарга тотынды. Каяндыр машина тавышы ишетелә. Ахры, якында гына юл.

– Үтерсәләр үтерерләр, – дип, алҗыган качак ике таш арасына ишелеп төште. Бетте, башка бер адым да алга барырлык хәл юк. Җылынырга теләп, Рөстәм ике кулы белән үз-үзен кочаклады. Төнге салкын үзәккә үтәрлек, өстәге теткәләнеп беткән кием җылытырлык түгел.

Их, менә хәзер Нәфис абыйсы белән икесе ясаган мунча миче каршында утырсаң иде ул! Әнә аның эчендә ничек рәхәт итеп ут яна, җылысы бар тәнгә тарала, мунча эченә каен себеркесе исе таралган. Рәхәт, җылы, әнә мунча алачыгында әнисе ясап биргән салкын күәс, ымсындырып, үзенә чакырып тора.

Кинәт Рөстәмнең колагында, ап-ачык булып, Ныйкинның тавышы яңгырады.

– Татарин, йоклама!

Рөстәм дерт итеп уянып китте, таң атып килә икән инде. Якында гына олы юл булган икән, качак гөрелте тавышы ишетелгән якка күз салды. Ә андагы юлдан башта, иртәнге томанны ерып, өстенә солдатлар менеп кунаклаган БТР килеп чыкты, аның артыннан бихисап хәрби техника килгәне күренде.

Рөстәм куырылган килеш торып басты да шул якка таба атлап китте.

Шулчак колонна белән бергә барган «ГАЗ-66» машинасы кинәт юлдан читкә чыгып туктады да аның брезент белән япкан кузовыннан җиргә кораллы солдатлар коелды, офицер да кабинадан чыкты, таудан төшеп барган, чәче иңенә җиткән, йөзен сакал-мыек баскан, киемнәре теткәләнеп беткән ябык әрвахны көтеп тора башладылар.

Качак төшеп җитүгә, хәрбиләр аның әсирлектән качкан Рәсәй солдаты икәнен бик тиз төшенеп алдылар. Шуңа күрә кайсы килеп аның аркасыннан какты, кайсы күшегеп беткән әсирнең өстенә үз өстеннән бушлатын салып япты, кемдер кулына буханкасы белән ипи китереп тоттырды. Аңа таба шикәр, тушёнка банкасы, кабы белән арзанлы тәмәке тоткан куллар сузылды. Моңа кадәр төшендә генә күрә алган мондый сый-нигъмәтне качак үзе дә сизмәстән кочагына җыя барды. Аңа нидер әйттеләр, янында басып торган офицер аннан кат-кат нидер сорады. Тик дөнья байлыгын күкрәгенә кысып, дер-дер калтыранган качак берни дә аңлый да, җавап та бирә алмады. Аның ике күзеннән бертуктамый яшь ага, ә үзе солдатлар аңламаган туган телендә бер үк сүзләрне кабатлый иде.

– Мин котылдым, котылдым, егетләр, мин котылдым ...

***

Гадел Сәмигалар капкасы янында машинасын туктатты да эчкә кереп китте. Нәфис ишегалдында тимер эше белән мәшгуль икән.

– Нәфис, юкмы? – дип сорау бирде Гадел Нәфискә.

Нәфис башын селкеде:

– Юк, Гадел.

...Рөстәмнең хәбәрсез юкка чыккан дигән хәбәре авыл буйлап таралган көнне үк Гадел Сәмига йортына килеп керде. Ачуланып каршы алмады аны Сәмига. Хәер, ачуланыр хәлдә түгел иде елап-шешенеп беткән хатын. Шуңа күрә Гадел йорт эчендә ни кылырга белми йөргән Нәфис белән генә сөйләшә алды. Нәфис Гаделгә барсын да бәйнә-бәйнә аңлатып бирде. Әти кеше гомерендә беренче тапкыр, җаны тетрәп, улы турындагы яман хәбәрне тыңлады. Улы бит ул аның, аның каны, аның дәвамчысы!

– Нәфис, –диде рәис, дулкынлануын җиңәргә тырышып, – әгәр дә Рөстәмнән акча сораган хат килеп төшсә, шунда ук миңа әйт. Мин акчасын табармын, күпме сорасалар, шуның кадәр табармын.

– Акчасы табылыр иде әле, исән генә була күрсен берүк.

Сәмига, ирләр сүзенә кушыла алмый, урын өстендә сулкылдап кына ятты. Күптән ачу сакламый инде ул Гаделгә. Нәфис белән бергә тормыш корып җибәрүгә, элеккеге иренә рәнҗеше су белән юып алгандай юкка чыкты. Үзеңне рәнҗеткән кешегә еллар буе ачу саклап ни файда соң? Бала кайгысы барсын да тигезләде.

Шул көннән бирле, эштән кайтышлый, Гадел, Сәмигага сугылып, Рөстәмнең хәбәр-хәтерен сораштыра башлады.

Гадел, бер сигаретын тартып бетереп, икенчесен кабызды. Сигезенче ае узып бара, малайның юкка чыкканына сигезенче ае узып бара. Исән микән соң инде ул? Кинәт Гадел урам буйлап җан-фәрманга чапкан Сәмиганы күреп алды. Ир, атылып, машинасыннан төште дә хатынга кычкырды:

– Сәмига, ни булды?

– Исән, исән, хаты килде, озакламый кайтам, дип язган! – Сәмига аңа кулындагы хатын болгап күрсәтте.

– Исән, исән! – Ирнең, вөҗдан газабына түзә алмый, иң башлары калтырый башлады. – Исән, улым исән! – Гадел чын күз яшьләре белән елый иде.

Сәмига, Гадел янында туктап калмыйча, Рәхиләләр йортына чапты. Капкадан атылып керүгә, башта Рәхиләләр йортының түр яктагы ике тәрәзәсен шакып үтте. Аннары кухня ягындагы тәрәзәне шакыды. Иң соңыннан болдыр ишеген төяргә тотынды.

Йорттан Рәхилә белән аның әнисе атылып чыкты.

– Сәмига апа, ни булды? – дип каушаган тавыш белән сорады Рәхилә ни эшләргә белми торган хатыннан.

– Рәхилә, сеңлем, кызым! Исән, исән, хаты килде, кайтам, дип язган, менә сиңа да хаты бар.

– Сәмига апа! – Кыз, елый-елый, бәхетле ананың муенынннан кочып алды.

Сәмига Рөстәм язган хатны сузды. Рәхилә хатны кулына алды да, калтырана-калтырана, конвертны ачты. Күз яшьләре сөйгәненең язган сүзләрен укырга ирек бирмиләр иде.

– Сәмига апа, укый алмыйм бит.

Сәмига шулай ук калтыранган куллары белән хатны ачты да укырга тоынды:

– Менә тыңла: «Сөйгәнем Рәхилә! Сиңа сагынуына чыдый алмас булган сөйгәнең Рөстәм хат яза дип белерсең...»

***

Сәмиганың йорты бүген халык белән тулган, монда туган-тумача да бар, күрше-күлән, авылдашлар да хәтсез җыелганнар. Ишекне кем килеп шакый, барсын да йортына чакырып, өстәл артына утырта хатын. Ә өстәлнең иң түрендә бер елга якын юкка чыгып торган солдат утыра. Аның тезләренә сеңлесе – кечкенә Наилә менеп кунаклаган. Рәхилә дә шунда. Йорт эчендә кем бар, барысы берьюлы Рөстәмгә сорау яудыралар. Рөстәм, туган йортына кайтып егылуына сөенеп бетә алмыйча, барсына да җавап бирергә тырыша.

...Кичкә таба Сәмиганың капка төбенә өч ир чыгып утырды.

– Алга таба ни эшләргә җыенасың, Рөстәм? – дип сорады Нәфис үги улыннан.

– Синең белән бергә эшләрмен дип уйлап торам инде, Нәфис абый.

– Ә өйләнергә уйламыйсыңмы?

– Башта өй салыйм инде, аннары.

– Өй салам, дисәң, улым, акчасы булыр, – дип сүзгә кушылды Гадел, – бердәнбер улыма йорт кына салып бирә алам инде мин.


– Бергә салырбыз, эти.

– Әйе, шулай итәрбез, мин бар, әнә Нәфис абыең, үзең тагын, өч ир бер йорт кына сала алырбыз бит.

Алырлар, билгеле. Сәмига, ялгыз хатын була торып, бер башы йорт сала алды, ә өч ир өчен бу эш пүчтәк кенә.

Ә Сәмиганың бар дөньясы түгәрәкләнде бүген. Көн-төн җанын талаган бала кайгысы да юк. Өе тулы кунак, барысы да елмаялар, барысы да аркасыннан кагып китә. Әнә Рөстәме исән-имин туган йортына кайтты, абыйсы алдыннан бөтенләй төшәргә исәбе булмаган төпчеге Наилә утыра. Булачак килене янында, алъяпкыч тагып, бөтерелеп кенә йөри. Бүген барысына да бары тик бәхет кенә тели Сәмига, ул беркемгә ачу да сакламый. Әгәр кайсыгыздыр хатынның хәтерен калдырган булса, килегез Сәмига янына бүген, ул сезне, һичшиксез, кичерәчәк.

Кешеләр, ишетәсезме? Бәхетле ана барча-барчагызны да кичерә бүген!



Фәрит
Габдерәхим

# НАМУСКА ТИМӘСЕННӘР

## Нинди җан бу?

Тарих сөйли: миһербанлы халкым,
Ясин чыгып атар таңына.
Киң дөньяга сыя алмаганнар
Сөңге батырганнар җанына.

Нинди җан ул синдә – бик түбәнме,
Әллә инде бик-бик югары?
Җаның ярып кергән шул сөңгене
Кайнар каның белән сугарып,

Үстергәнсең җил-давылдан саклап,
Гыйбрәт булсын бөтен галәмгә.
Бу – бердәнбер могҗизадыр, бәлки:
Алмагачка сөңге әйләнгән!

Юмарт халкым! Күзләр җиту белән,
Инсаннарның кече-олысын.
Җыясың да шушы алмагачның
Җимешләре белән сыйлыйсың.

Киң дөньяга сыймаганнарның да
Оныклары синең табында.
Нигә өясеңдер алмаларның
Иң сутлысын алар алдына?!

Син чыгасың көрәш мәйданына,
Сөңге түгел, тотып сөлгеңне.
Нинди җан бу: әйләндергәнсең бит
Алмагачка җәллад-сөңгене.

---

Фәрит ГАБДЕРӘХИМ (1933) – *Башкортстанда (Уфа) яшәүче татар шагыйре; татар һәм башкорт телләрендә чыккан дистәдән артык китап авторы.*

## Мәркәз

Мин Казанда. Горур балкый мәркәз.
Сокландыра: гаҗәп үзгәргән.
Дус-ишләрем сорый: «Кайчан килдең?»
Шаклар катам шушы сүзләргә.

«Кайчан килдең?» имеш. И дусларым,
Болай әйтү гүпчим хата ул.
Кайда туып яшәсә дә татар,
Казанына килми – кайта ул.
Мәркәзенә фәкать кайта ул!

## Эш арта

*Дөнья бит ул куласа, әйләнә дә бер баса.*
*Халык сүзе.*

Мәрткә китте теге чикләүләр,
Күтәрелә мәчет, чиркәүләр.
Туар дәһриләргә эш арта...

Утар тулы, әнә, мал-туар,
Теләгәннең – җире, аты бар.
Туар Ысталинга эш арта...

Сүз иреге – тыю юк инде.
Тәнкыйтьлибез хәтта Путинны.
Туар шымчыларга эш арта...

## Картайган, димәсеннәр

И сакаллы сабыйлар, дип,
Тиргәсә тиргәсеннәр,
Җыр җырлап узыйк урамнан,
Картайган, димәсеннәр.

Күкрәкләрне киерик: безнең
Намуска тимәсеннәр.
Дәрт-дәрманы бар, дисеннәр,
Картайган, димәсеннәр.

Без йөк күтәргәндә, җәлләп,
Ярдәмгә килмәсеннәр.
Яшьләр, әйдә, көнләшсеннәр,
Картайган, димәсеннәр.

Хатын-кызлар, безне күргәч,
Тынгылык белмәсеннәр.
«Бабай», дисәләр дисеннәр,
Картайган, димәсеннәр.

## Кайтышрак

*Поэт в России – больше, чем поэт.*
*Е.Евтушенко*

Бар да шигырь язган заман,
Җаһил каләм азган заман.
Тегесеме, монысымы –
Кайсы икән яхшырак?
Бүген шагыйрь Рәсәйдә
Шагыйрьдән кайтышрак.

## Алышынды урыннар

Тарих катламнарын актарганда,
Күп нәрсәнең сере ачылды.
Дардагылар пьедесталга басты,
Ә һәйкәлләр дарга асылды.

## Уңганнар... уңмаганнар

Хатыннан әгәр уңсалар,
Бәхетле була ирләр.
Хатыннан уңмаганнары
Фәйләсүф була, диләр.

## Лаеклымын

Вакыт житеп, ахирәткә күчкәч,
Баш ватарлар әле минем хакта:
«Кая куйыйк моны, кайсы якка?»
Лаеклымын, чөнки оҗмахка да,
Лаеклымын, чөнки тәмугка да.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# ТАШКИЧҮНЕҢ ОЛУГ АБЫЗЛАРЫ



Казан арты, Арча ягының кайсы гына авылына игътибар итмә, аның һәрберсендә татар әдәбияты, мәдәниятендә тирән эз калдырган шәхесләр, галим дәрәҗәсендәге дамелла-муллалар яшәгән. Ташкичү авылы исә мәшһүр, зыялы затлар – имам-хатыйп, мөдәррис һәм шагыйрь Габдессәлам бине Урай (Уразмөхәммәд), татар-башкорт милли-азатлык хәрәкәте җитәкчесе Батырша, «Мәҗмугыл-хикәят» әсәренкүчереп язып, бу мирасның безнең көннәргә килеп җитүенә сәбәпче булган Мөхәммәдрәхим бине Рәфыйк, имам, соңрак Каһирәдә фарсы теле мөгаллиме Шәмсетдин бине Габдрахман, атаклы имамнар Баһаветдин, аның уллары Шиһабетдин, Галәветдин, Садретдин әл-Мәрҗаниләр, беренче тарихи роман авторы Мәхмүт Галәү-Мәрҗани, «Кояш» газетасының баш мөхәррире һәм нашире Зәкәрия Садретдин, үткен телле журналист, галим һәм педагог Рәшит Фәтхераман; атаклы табиб, шагыйрь Фаяз Ибраһимов туган һәм яшәгән җир. Бу мәкаләбездә шул шәхесләрнең фәкать икесенә – олуг имамнар Шиһабетдин әл-Мәрҗани һәм аның бертуган энесе, сабакташы, фикердәше Садретдин әл-Мәрҗаниләрнең, аларның ата-бабаларының тормыш юлын һәм кылган гамәлләрен бәян кылабыз.

## Ата-бабалар

Шиһабетдин Мәрҗанинең әтисе ягыннан бабасы **Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани (1747-1834)** Өшкәтә, Бәрәскә, Мәчкәрә, Урбар авылларының атаклы муллаларында белем алган, остазларыннан гыйлем эстәгән вакытта алтмыштан артык китап күчереп язган. 1776 елда Олы Җәке авылына имам-хатыйп һәм мөдәррис итеп тәгаенләнгән. 1790 елда бу хезмәтен Кысна авылында башкарып, 1801 елда Диния нәзарәтеннән рәсми указ алып дәвам итә. 1810 елдан имамлыгын калдырып, сәүдә эшенә керешә. «Сәүдәләре уңып,дөньясы яхшы ук түгәрәкләнгән, кадер-хөрмәттә бәхет белән яшәгән, барлык әйберләре һәм җиһазлары җитәрлек булган», – дип яза Ш.Мәрҗани бабасы турында. Шуны да, әйтергә кирәк: Ш.Мәрҗанинең әтисе ягыннан әбисе **Бибизәгыйфә Габделбакый кызы** (1835 елда вафат) да затлы нәселдән – анасы Каратайның морза кызы Сәгыйдә булган.

Ш.Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар»дә яза: «Бабабыз, мәрхүм Сөбхан, 1249 (1834) елда, зөлхиҗҗә аенда, сиксән җиде яшендә вафат булды. Җеназасын мелла Садыйк бине мелла Сафакол укып, үзенең васыяте буенча, Хөснәдән чыкканда, олы юлның сул ягына җирләнде, ләкин ул юл, хәзер ташланып, каберлек уртасында калган. Мин фәкыйрь исемен, нәселен һәм туган-үлгән елларын яздырып бер таш куйдым»... «Бабабызның җәмәгате Бибизәгыйфә бинте Габделбакый 1251 (1835) елда вафат булды һәм җеназасын әлеге мелла Садыйк укып, бабабыз янында, кыйбла ягында җирләнде». Хәзерге вакытта Кысна авылы зиратында Сөбхан хәзрәт һәм Бибизәгыйфә абыстай истәлегенә куйган кабер ташы бар. Эпиграфик ядкәрнең уң ягына ташны Шиһабетдин Мәрҗани куйдырганлыгы язылган.

Шиһабетдин Мәрҗанинең әнисе ягыннан бабасы **Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек** хәзерге Чүпрәле районының Иске Чокалы авылында туган. Урбар,

Ашыт, Оры галим-дамеллаларыннан белем ала. Ул 1792 елдан Иске Ашыт авылында имам-хатыйп хезмәтен башкара, зур мәдрәсә тотып, төрле фәннәрдән шәкертләргә белем бирә. Ш.Мәрҗани бабасы турында: «Мелла Габденнасыйр бик тәкъва һәм диндар, изге һәм саф, данлыклы һәм хәрәмнән сакланучы, дөнья эшләреннән ваз кичкән һәм шәригать кануннары белән генә эш итүче кеше буларак шөһрәт казанган», – дип язып калдырган. Әмма ул үзенең суфилыгын, Ор авылының Хәбибулла ишан бине Хөсәен мөриде булып, аннан иҗазәт алганлыгын, әмма түбәнчелек санап, вафатына кадәр моны сер итеп саклаган. Габденнасыйр хәзрәтнең йортында еш кына галим-голамә, шул чорның укымышлылары җыелган, шунда дини мәсьәләләр буенча бәхәс кузгалгач, ул борынгы китаплардан дәлилләр китереп сөйли торган булган.

Габденнасыйр хәзрәт Кызылъяр (Иске Коллар) авылындагы атаклы бай Туктамыш бине **Габделкадыйрның кызы Бибимәхбүбә**гә өйләнеп, 1794 елда Ш.Мәрҗанинең әнисе Бибихөбәйбә дөньяга килгән. Бибимәхбүбәнең анасы Зөбәйдә атаклы нәселдән – Иске Мәңгәр авылындагы мәшһүр морза Гашур бине Мөхәммәтнең кызы.

Ш.Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбәр»ендә Габденнасыйр: «1833 елда чәршәмбе көн Ашытта вафат булды. Пәнҗешәмбе көн җеназасын ахун мелла Фәтхулла бине Хөсәен укып, шул авылның яңа каберлегендә җирләнде. Хатыны, ягъни безнең әбиебез Бибимәхбүбә 1843 елда, якшәмбе көне вафат булды. Кабере – бабабызның аяк очында. Мелла Габденнасыйрның Бибисәйидә исемле кызы 1833 елда, әткәсеннән өч ай элек шимбә көн вафат булды. Кабере анасы янында, төньякта. Җеназасын әткәсе укыды. Мин фәкыйрь, һәр өчәвенең исем һәм вафат тарихларын яздырып, бабабыз баш очына бер таш куйдым», – дип язса да, кызганыч, Иске Ашыт зиратында әлеге таш сакланмаган.

Ш.Мәрҗанинең әтисе – **Баһаветдин бине Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани** 1786 елда Олы Җәке авылында дөньяга килгән. Күәм, Бәрәскә, Ашыт, Ташкичү дамеллаларында һәм Бохараның «Турсуния» мәдрәсәсендә гыйлем эстәгән. Баһаветдин шунда укыганда, Бохара хакиме, әмир Хәйдәр белән дуслашкан, ул биргән аерым бүлмәдә яшәгән. Әмир, дуслык хакына, Бохарада еллык акча биреп, мөдәррис итеп билгелим дисә дә, Баһаветдин 1813 елда туган җиренә кайткан. Алга таба да Хәйдәр Баһаветдин белән элемтәсен өзмичә, аңа Бохарадан бүләк итеп киемнәр җибәргән. Бу турыда Ш.Мәрҗани: «Безнең илебездә әмир илтифат итеп, бүләкләр җибәрелгән өч кешенең берсе – атабыз», – дип язып калдырган. 1815 елда **Баһаветдин Габденнасыйр кызы Бибихөбәйбә**гә өйләнеп, Габделкәрим бай таләбе буенча, Ябынчы авылына имам-хатыйп һәм мөдәррис итеп тәгаенләнгән. 1818 елның 16 гыйнварында (һиҗри ел исәбе белән 1233 елның 7 рабигыль-әүвәлендә[1]) яшь парның беренче баласы Шиһабетдин дөньяга килгән. Хәзерге вакытта Әтнә районы Ябынчы авылында галим туган нигез тимер киртә белән уратып алынган, анда истәлек белгесе куелган һәм йорт ихатасыннан ерак булмаган «мулла коесы» да төзекләндерелгән.

Ташкичү авылының мулласы Шәмсетдин бине Габдеррәшид әл-Кышкарый[2] Мисырга күчеп китеп, шундагы бер мәртәбәле уку йортында фарсы телен укыта башлый. Баһаветдин хәзрәт 1821 елда Ташкичүгә, остазы урынына күчеп, шунда гомере буе – кырык елга якын имам-хатыйп һәм мөдәррис вазифасын башкара, шәкертләр тәрбияли. 1823 елда «акыллы, күркәм мөгамәләле, гыйбадәтчән» хатыны Бибихөбәйбә бала тапканда, егерме яше тулар-тулмас биш яшьлек Шиһабетдинне һәм тагын ике баласын (Гыймадетдин һәм Гафифә) ятим калдырып, бакый дөньяга күчә. Шул ук елда Баһаветдин Бибихөбәйбәнең сеңлесе Бибихәбибәгә өйләнә. Аларның Бибифатыйма, Садретдин, Әхмәд, Бибисаҗидә, Каваметдин, Бибидәрдәнә, Бибисәйидә, Галәветдин исемле балалары дөньяга килә.

Ш.Мәрҗани: «1843 елда яңгыр булмыйча, һавалар бик коры торып, игеннәр, үсемлекләр һәм агачларның зарарлануы чигенә җиткәч, Мәмсә тау башына Ташкичү, Ашыт, Сәрдә, ике Кенәр, Печмәнтау, Хөснә (Кысна) һәм Ашытбаш авыллары халкы җыелып, яңгыр теләде. Атабыз, барлык җыелган халык теләге белән, яңгыр теләү намазында имам булды», – дип язып калдырган. Моннан исә Баһаветдин хәзрәтнең тирә-якта мөхтәрәм имам булуы

---

[1] Татар җәмәгатьчелеге Шиһабетдин Мәрҗанинең 100 еллык юбилеен, хәзерге укучылар уйлаганча, 1918 елда түгел (бу елда булса, үткәрә алырлар идеме икән?!), ә һиҗри ел исәбенә туры китереп 1333 елда, ягъни, миладигә күчергәндә, 1915 елда зурлап үткәргән.

[2] Шунысы игътибарга лаек: Шәмсетдин әл-Габдеррәшид вафат булганнан соң Мисырга хәзерге Наласа авылы имамы Мөхәммәдел бине Сәйфулла килә һәм Ибраһим паша белән дуслашып, шундагы бер гыйлем йортында фарсы телен укыта башлый.

һәм дини эшчәнлектә халыкның борынгыдан килгән гореф-гадәтләрне инкарь кылмавы аңлашыла. «Вафийәтел-әсляф» китабында исә: «Бабам Сөбхан хуш мәҗлесле, мәгълүматы күп, азрак мәзәкчән булып, үткәндә булган вакыйгаларны, тарихи хәлләрне бик күп сөйли иде», – дип искә ала. Сөбхан хәзрәт яшьли ятим калган Шиһабетдинне аеруча яраткан, күп вакыт аны үзе белән йөрткән.Тарихи вакыйгаларны китап сәхифәләренә төшерә башлагач, еш кына бабасы сөйләгәннәрне дә искә алган.

Баһаветдин хәзрәт имамлык иткән, 1817 елда Оры сәүдәгәре Сөләйман бине Назир тарафыннан салынган таш мәчет хәзерге вакытта архитектура ядкаре – Ташкичүнең йөзек кашы булып тора. Авылның зиратында Мәрҗаниләргә бәйле ике эпиграфик истәлек – галимнең әтисе Баһаветдин Сөбхан улы Мәрҗанигә (1786-1856) һәм хатыны Хөбәйбә бинте Габденнасыйр кызына (1795-1823) куелган (ике мәрхүмгә бер) кабер ташы бар. Шәһәр Шәрәф «Мәрҗани» китабында: «Баһаветдин вә Хөбәйбәнең кабере Ташкичүдә, икесе бергә. Соңыннан икесенә Мәрҗани тарафыннан дүрт тарафы язулы бер таш куела», – дип язган. Шулай ук Ташкичү авылында Мәхмүт Галәүнең әтисе, Шиһабетдин Мәрҗанинең бертуган энесе, галим **Галәветдин ибне мулла Баһаветдин әл-Мәрҗани** (1840-1908) каберенә куелган таш та бар.

Кысна авылындагы Сөбхан әл-Мәрҗани һәм Бибизәгыйфә абыстай каберләренә, Ташкичүдәге Баһаветдин әл-Мәрҗани һәм Бибихөбәйбә абыстай һәм Галәветдин әл-Мәрҗани хәзрәтләре каберләренә куелган ташлар – җәмгысе өч эпиграфик ядкарь дәүләт саклавына алынуга һәм кичекмәстән төзекләндерүгә мохтаҗ.Әлеге мөхтәрәм затлар – Шиһабетдин һәм Садретдин Мәрҗаниләрнең мулла, атаклы галим булып җитлегүенә ата-бабаларының йогынтысы чиксез зур икәнлеге шөбһәсез.

## Шиһабетдин Мәрҗани

Башка мулла балалары кебек үк, Шиһабетдин дә, алтынчы яше китү белән, әтисенең мәдрәсәсендә сабак укыган. Нәхү һәм сарыф дәресләрен шул замандагы мәшһүр китаплар – «Бидан», «Шәрхе Габдулла», «Куагыйд», «Әнмүзәҗ», «Кафия» һәм башкалардан өйрәнгән. Фикыһ гыйлемен исә «Мөхтәсарел-викайә», «Шәрхел-викайә», кәлямне «Шәрхе гакаиде Нәсәфи», мантыйкны «Шәмсийә», ысуле фикыһны «Тәүзих вә Тәләүих» китапларыннан укыган. Ташкичү мәдрәсәсендә Әхмәд бине Габделҗәлил-әт-Тинчәли, Әхмәд бине Зөлхиҗҗә әт-Тимерҗани, Корбан бине Мөхәммәд бине Мансур әл-Чүнбәли кебек хәлфә-мөгаллимнәрдән, аннан әтисе Баһаветдиннан белем алган. Кыйрәт, ягъни Коръәнне дөрес итеп уку гыйлемен Казиле авылының имамы, мулла Таҗетдин бине Габделҗәлилдән өйрәнгән. Бер үк вакытта сабагыннан аерылып, йорт эшләрен башкарырга, терлек карарга да өлгергән. Шиһабетдин гаять сәләтле шәкерт булып, остазлары аның талантына, сәләтенә таң калган, зур галим булачагына фараз кылган.

Аңлашыла ки, әлеге кадими мәдрәсәдә тәфсир, хәдис, пәйгамбәрләрнең тормыш юлы, тарих, хисап, табигать фәннәре укытылмаган. Шәкертләр 10-15 ел дәвамында алда әйтелгән 5-10 китап, аның шәрех һәм хашияләрен укып чыгарга тиеш булган. Билгеле, Шиһабетдин болар белән генә канәгатьләнмәгән, атасының, бабасының китапханәсендәге гарәпчә китапларны укыган. Кайчакта атасы, моңа ачуланып: «Минем билгеләп куйган җирләремне югалтасың», – дип шелтәли торган булган. Ш.Мәрҗани үзе бу турыда: «Үзем укымаган китапларны да укып төшенергә тырыша идем. Шуннан ләззәт ала идем. Һәрбер гарәпчә китапны укуны зур дәрәҗә дип уйлый идем. Күпвакыт бер нәрсәне дүрт мәртәбә укый идем. Беренче мәртәбә аңламыйча гына укып чыгып, баш кына авырта иде. Икенче мәртәбә укыганда, кайбер җөмләләрен, өченче мәртәбә укыганда, күп җирләрен аңлый идем. Дүртенче мәртәбә укыганда гына авторның максатын яхшы аңлап, аннан соң икенче китапларны укырга керешә идем», ди. Соңрак болай итеп китап уку «Мәрҗани ысулы» дип, мөгаллим-хәлфәләр тарафыннан башка мәдрәсәләргә дә тарала башлаган. Заманында кайбер хәлфәләр дә үз шәкертләренә: «Мәрҗани ысулы илә укыгыз, аңларсыз», – дип киңәш биргәннәр икән.

Унҗиде яшендә Шиһабетдин атасы Баһаветдиннең мәдрәсәсендә үзе дә укыта башлый. Шунда кайбер дәресләрнең укыту рәвешләрен үзгәртә, элеккеге укыту ысулларының кимчелекләре турында әтисе һәм мөгаллимнәр белән киңәшә. Ташкичү

һәм башка мәдрәсәләрдә гарәп теленең сарыфы фарсы китапларыннан (менә ни өчен борынгылар фарсы телен дә белгән) укытылса, Мәрҗани бу китапны үзе, төркичә язып, шәкертләргә шуның белән белем бирә башлый. Хәтта Ташкичүнең кайбер карчыкларына гакыйдә һәм намаз хакында татар телендә кечкенә китапчыклар да язып тарата[3].

Шиһабетдин, китап уку белән бергә, яшьтән үк язу-сызу эше белән дә мавыккан. Бу турыда энесе Садретдин менә ниләр сөйләгән: «Мәрҗани яшьтән үк гыйлемгә ихласлы, ишеткән нәрсәләренең әһәмиятлеләрен махсус бер мәҗмугасенә яза бара, ул вакыттан ук язган нәрсәләрен гарәпчә язарга тырыша иде. Бервакыт атабыз, Бохараны мактап, төрле-төрле озын вакыйгалар сөйләгәндә, Бохарага ихлас куеп, атабызның сүзләрен дәфтәренә гарәпчә язып куйган иде. Ул вакытта да кайбер иске нәрсәләрне белергә вә тикшерергә һәвәсле иде. Безгә якын бер җирдә кабер ташлары булып, шуларны барып укыган, анасы каберенә үзе дә кечкенә таш язып куйган иде». Шиһабетдин ата-бабасы яки башка укымышлылар арасында берәр гыйльми мәсьәләдә сүз кузгатырга, гыйльми мәҗлес ясап, шуны җентекләп тикшерергә дә яраткан.

Гыйлемгә сәләтле, зирәклеге өстенә, Шиһабетдин гаять шаян һәм шук булган, кешегә белдертмичә, вак-төяк эшләр чыгарырга яраткан, авыл Сабантуйларында «егылган зәгыйфь адәмнәр белән түгел, бәлки егучы баһадирлар илә көрәшүне» өстен күргән, бер мәртәбә егылган кеше белән бүтән көрәшмәгән. Ул гаять тәкъва, диндар булып, биш вакыт намазны калдырмаган.

***

Шиһабетдин Мәрҗани, «олуг галимнәрнең дәресләрендә булып, тынычлык илә гыйлем эстәргә, төрле китапханәләре булган зур белгечләрнең әсәрләрен укырга» теләп, 1838 елның маенда кием-салым һәм юлда укып барырга атасы биргән «Мелла Җәлял», «Тәүзих вә тәлвих», «Шәрхе гакаиде ән-нсәфи», «Шәрхел-викая» кебек китапларны төяп, Мәңгәр авылы сәүдәгәре Мөхтәр бине Мөхәррәмнең йөкчеләре белән Бохара сәфәренә кузгала. Берничә ай Троицк каласында туктала, шундагы галим-голамә белән аралаша, мәшһүр якташыбыз Габденнасыйр Курсави хәзрәтләре турында фикерләр ишетә. Әтисе биреп җибәргән акча Бохарага барып, хөҗрә – яшәр өчен бүлмә сатып алырга җитәрлек булмау сәбәпле, Троицкида кечкенә сандык, бизәкле савыт һәм тартмалар алып, аларны юлда һәм Бохара базарларында саткан. Кайбер урыннарда өчәр-дүртәр, кайбер җирләрдә бер атна-ун көн сәүдә итә. Шулай итеп, алты ай дигәндә, Бохарага барып җиткән һәм Г.Курсавиның остазы, ишан Ниязколый мәдрәсәсендә үз акчасына хөҗрә алып, шунда урнаша. Соңрак иң атаклы мәдрәсәләрнең берсе – «Күгелдаш» хөҗрәсендә яшәп, шунда гыйлем эстәргә керешә.

Шиһабетдин биредә шул чорның атаклы дамеллалары Мирзасалих Әгълам, Мөхәммәд бине Сәфәр әл-Хөҗәнди, дамелла Фазыл бине Гашур әл-Гыйҗдивани, Габделмөэминхуҗа бине Үзбәкхуҗа әл-Бохари, Ходайбирде бине Габдулла әл-Байсуни, Бабарафигъ әл-Хөҗәндиләрдән һәрбер бохари кебек дәрес тыңлый. Аның сабакташлары шәрех һәм хашияләрдә[4] язылганны гына сөйләсә, Мәрҗани яңа фикер уйлап әйтә. Бер елдан соң кайбер остазлар үз шәкертләренә Мәрҗанидән дәресләр алырга киңәш итә башлый.

Аңлашыла ки, Шиһабетдин Мәрҗани Бохарада да укыту тәртипләреннән канәгать булмаган: «Безнең халык, уку-укыту тәртипләрендә Бохараны үрнәк тотып, Бохараны хөрмәт илә генә «Бохараи шәриф», дип сөйләсәләр дә, Бохараның халкы вә хөкүмәт мәгарифтән бик ерак, идарәләре бозык вә хөкүмәтләре мәгарифтән бик ерак, уку-укытулары гаять тәртипсездер», – дип язган. Бохара мәдрәсәләрендә өч ел нәхүдән «Кафийә», «Шәрхе мелла Җами», ике ел мантыйктан «Шәмсия», өч ел «Гакаиде Нәсәфи», бер ел мантыктан «Тәһзиб», аннан өч ел дәвамында «Хикмәтел-гайн», аннан дүрт ел «Мелла Җәлял» укытылган, ә гыйльме ысулдан «Тәүзих», хәдис гыйлеменнән «Мишкятел-мәсабих», тәфсир гыйлеменнән «Тәфсире Бәйзаваи» исемле китаплар нибары бер ел өйрәнелгән. Анда да Коръән, хәдис, гыйльме ысул, хикмәт, җәгърафия, тарих, әхвәле галәм һәм гарәп әдәбияты кебек фәннәр укытылмавына кайгырган.

[3] Ш.Мәрҗани: «Карчыкларның игътикады гыйльме кәлям вә фәлсәфә илә мәшгуль байтак адәмнәрнең игътикадларыннан яхшырак, аларның Аллаһыга иманнары куәтлерәк», – дип язган.
[4] Хашия – китап читендәге язма.

Ш.Мәрҗани Ташкичүдә укыган вакыттагы проблема – дәрес ысулын үзгәртү турында бохари остазлары белән дә киңәшкән, әмма аңа: «Бохарада дәрес тәртипләрен үзгәртү гаять мөшкел эш», – дип җавап кайтарганнар. Шулай итеп, Мәрҗани Бохара голамәләрен һәм укыту тәртипләрен тәнкыйтьләп, «Әгъляме ибна-иддәһр би әхвали әһли Мавәранэннәһер» исемле китабын язган. Әлеге китапта аның тәнкыйди карашлары, галим-голамә турындагы фикерләре бохаралыларга әлләни тәэсир итмәсә дә, казан татарлары, аеруча атаклы имамнар аны бу хезмәте өчен тиргәгән. Китаптагы фикерләр Казан һәм Казан артындагы авылларда «кыямәт кубарган». Ш.Мәрҗани фикерләре тарала башлагач, татар шәкертләре каршында Бохараның дәрәҗәсе төшкән, шуннан соң алар Истанбул һәм Мисыр мәдрәсәләрендә гыйлем эстәүне мәртәбәлерәк саный башлаган.

Ш.Мәрҗани Бохарада торган чагында, яз-җәй айларында Каракүлгә барып, казакъ арасында хәлфәлек һәм мөдәррислек иткән, үзенең матди ягын кайгырткан. Бу турыда: Галиәсгар Чыгатай: «Элек һичбер дөньяга чыкмаган, Казан арты татарыннан башканы күрмәгән пакь вә саф Мәрҗани үз тереклегендә гаять бай вә кызыклы булган казакъ тормышыннан гыйбрәтне, әлбәттә, бик күп алгандыр», – дип яза.

Мәрҗани Бохарада биш ел торгач, Сәмәркандка барып, атаклы «Ширдар» мәдрәсәсенә урнаша, төрки дөньяга мәшһүр Әбү Сәгыйдь хәзрәтләреннән дәресләр ала, аның бай китапханәсеннән борынгы әсәрләр һәм төрле китапларны укый. Әбү Сәгыйдь турында Ш.Мәрҗани: «Тарих гыйлеме белән шөгыльләнүемә бу адәм сәбәп булды», – дип язган. Сәмәркандта яшәгәндә, булачак галим имам Газали, Габденнасыйр Курсави хезмәтләре белән таныша (Курсави китаплары Бохарада тыелган була). Бу галим турында: «Габденнасыйрның бөтен әсәрләрен укып, һәрвакыт диярлек хакыйкатьне аның тарафыннан таптым», – дип яза, борынгы һәм шул чорда язылган китапларны укып, мөселманнарның Коръән һәм сөннәттән тайпылганлыгын аңлый.

Сәмәркандта ике ел гыйлем эстәп, Әбү Сәгыйдь хәзрәтләреннән иҗазәтнамә алганнан соң, Ш.Мәрҗани яңадан Бохарага әйләнеп кайтып, танылган «Мир Гарәб мәдрәсәсенә урнаша, бер җәй шунда имам булып тора. Шактый вакыт бүлмәсенә бикләнеп, күп китаплар укый, гакаид, кәлям, фәлсәфә, һәйәт, һәндәсә гыйлемнәрен өйрәнә, бу турыда төрле китапларны күчереп ала. Шәһәр Шәрәф аның гыйлем дөньясына чумуын, дәрвиш кыяфәтендә йөрүен менә ничек тасвир кыла: «Бохарада чагында вакытның шулкадәр кадерен белгән, гыйлемнән шулкадәр ләззәт алган ки, хәтта иптәшләре илә катнашуны, башка адәмнәр бүлмәләренә барып сөйләшеп утыруны, урамнарда туктап сөйләшеп торуларны файдасызга гомер уздыру дип хисаплап, бөтенләе белән ялгызлыкка бирелгән. Берәр җиргә йомыш илә барганда яки кибеттән әйбер алырга чыкканда, чапаны илә төренеп, үзен танытмаска тырышып, аяк баскан җиргә генә карап йөри торган булган». Садретдин хәзрәт: «Кием-салымга күп әһәмият бирми, шәкертләр арасында булган әшәке гадәтләрдән саклана, үзен бик саф итеп сакларга тырыша, башка шәкертләргә күп катнашмый, атна кичләрдә булган шәкертләр мәҗлесенә бармый, тамаша вә хозур урыннарына йөрми», – дип сөйләгән. Нәтиҗәдә, Шиһабетдин Мәрҗани үзенең күп кенә тарихи һәм дини китапларына, шул исәптән атаклы галимнәр турындагы «Вафийәтел-әсляф»ына мәгълүмат туплый, кайберләрен Бохарада ук яза башлый.

«Мир-Гарәбтә» Шиһабетдин Мәрҗанидән дәрес алучы татар шәкертләре дә бихисап булган. Мәсәлән, Габделхәбир әл-Мөслими әл-Кызылҗари, Тымытыктан Әхмәдлатыйф хәзрәт, Казан имамы Мөхәммәди бине Салих, Шиһабетдиннең үз энесе Садретдин, Хафизетдин бине Насретдин әл-Курсави әл-Бәрәңгеви, Эстәрле мулласы Харрас бине Нигъмәтулла хәзрәтләр аның иң алдынгы шәкертләреннән булган.

Аңлы, зыялы, утыз яшьлек егет теләсә Бохара яки Сәмәркандта да калып, имам, мөдәррис була алыр иде, ләкин ул туган ватаны Ташкичү, Казан тарафына кайтуны өстен күрә. 1849 елны Бохарадан Мәрҗаниләрнең кияве, сәүдәгәр Фәйзрахман бине Габделгаффар әт-Тазларыйга ияреп Русиягә кайтырга чыга, ике айдан Казанга кайтып җитә.

***

Мәрҗани кайтып җиткәнче үк, аның дан-шөһрәте Урта Азия белән сәүдә итүче татар сәүдәгәрләре аша Казан һәм тирә-ягындагы татар авылларында таралып өлгергән була. Бохарадан укып кайтканнарның дәрәҗәсе гаять югары булу сәбәпле, яшь һәм

зирәк Шиһабетдинне Казанның иң абруйлы бае Ибраһим бине Гобәйдулла Юнысов (Озын Ибрай) беренче мәчетнең имамы итеп куячагын белдерә. Шиһабетдин, атасының ризалыгын һәм фатихасын алыр өчен, Ташкичү авылына кайтып китә. Озак та үтми, Казан байлары «сигез ат җиккән өч чана» белән Ташкичүгә, Мәрҗанине алырга бара һәм, приговор ясап, аны 1850 елда беренче мәхәллә мәчет имам-хатыйбы һәм мөдәррисе итеп билгелиләр. Мәрҗаниенең дан-шөһрәтен ишетеп белгән күп кенә шәкертләр аның мәдрәсәсенә күчә. Яңа мөгаллимнең исә иң беренче укыта башлаган дәресе тәфсир гыйлеме була.

Мәрҗанинең дини мәсьәләләрдә кыю фикере, тәнкыйди карашлары, өстәвенә китаплар язып таратуы башка муллаларның ачуын кабарткан. Алар: «Мәрҗанинең шәригатькә каршы сөйләве бар. Аның артында намаз укуның дөреслегендә зур шөбһә бар» яки «Бу кешенең игътикады бозык. Аны Себергә җибәрү хакында мал сарыф итү хаҗга бару кадәр саваплыдыр. Бу юлда тоткан малдан кыяматтә сорау булмас», дип, казанлыларны котырткан һәм, аеруча, Ибраһим байның яшь имамга булган мөнәсәбәтен үзгәртергә теләгән.

1954 елда Шиһабетдин Мәрҗанине, яше җитмәгән кызга никах укыды, дигән сылтау белән, имамлыктан читләштерәләр, аның урынына яңа гына хаждан кайткан, мәчетнең элекке хәзрәте Сәгыйдьне имам итәләр. Нәтиҗәдә, Мәрҗани мәдрәсәсендә биш-алты шәкерт кенә утырып калган, яраткан муллаларының гаепсез икәнен таныган мәхәллә халкы: «Бу кадәр галим кешене аз гына нәрсә өчен, кайбер кешеләрнең хәтере өчен генә төшерү тиеш түгел. Безгә башка кеше кирәкми», – дип, приговор җыйган һәм, полицмейстер Шаһиәхмәт Алкин ярдәме белән, 1855 елда яңадан имам итеп раслатырга ирешкән.

Әмма моның белән эш җайланмаган. Мәрҗани «төрле яктан казылган базларның бәгъзысына басып абынгалый башлый», аңа төрле яла ягулар ешая гына, нәтиҗәдә, башкаларның коткысына бирелеп булса кирәк, Ибраһим бай да мәдрәсәгә ярдәм итүен азайта. Бу турыда «Мөстәфадел-әхбар»да: «Мәдрәсәне Ибраһим бай рәтләп карамый, башкаларга карарга да рөхсәт итми, аннан рөхсәтсез карарга байлар куркалар иде. Мәдрәсәне югары каты агач булып, аның читләре черегән, ишелеп төшмәсен дип, берничә җиргә баганалар куелган, дивары юеш, идән башлары череп сынып төшкән, кыш көннәрендә читләреннән, тәрәзә тирәләреннән буран керә иде», – дип яза. Шиһаб хәзрәт 22 ел дәвамында шушы җимерек мәдрәсәдә шәкертләр укыта, Казанны ташлап ислам мәмләкәтенә, Бәгдад тарафына китәргә дә уйлый, әмма, ташланган пычракны өстеннән төшереп, тагын үзен аклый, дошманнарын игътибарга алмаска тырыша.

1971 елда гына мәхәлләнең байлары, үз акчаларын җыеп, хәзерге «Мәрҗани» мәдрәсәсе урынын бер йорт белән сатып ала, шәкертләр дә шунда күчерелә. Берничә елдан Казан муллалары бер көн алда уразага керде, дип, Диния нәзарәтенә шикаять биреп, Мәрҗанине имам һәм мөдәррислектән алдырта. Әмма тиздән үзенең хаклыгын, Истанбул, Гарәбстан, Бохара мөселманнарының да уразага шулай керүен раслап, указын кире кайтаруга ирешә.

Истәлекләрдә Шиһабетдин Мәрҗанинең хаҗ сәфәре турында еш телгә алалар. Хәтта аның шул чордагы истәлекләрен туплап, Ризаэддин Фәхреддин «Рихләтел-Мәрҗани» исемле китап та бастырган. 1880 елның август аенда, Ш.Мәрҗани мәхәллә эшләрен Печән базары мәчете имамы Хуҗаәхмәд бине Мозаффарга һәм улы Борһанетдинга тапшырып, алай-болай үлем афәте килә калса, дип, васыятен язып, китапларын төяп һәр мөселманга фарыз гамәлне кылырга – хаҗ сәфәренә юнәлә. Одесса, Истанбул, Измир, Искәндәрия, Каһирә, Сүәйес һәм, әлбәттә, Мәдинә белән Мәккә шәһәрләрендә яшәүче зыялылар, дәүләт эшлеклеләре илә очрашкан, аларга үз китапларын бүләк итеп калдырган. Төрле мәчетләрдә булып, мәшһүр кешеләрнең каберләрен дә зиярәт кылып, аларның тормыш юлы турында мәгълүмат та туплаган. Ш.Мәрҗани Казан каласына 1880 елның декабрендә кайтып җитә.

Агач бина тузу сәбәпле, 1881 елда Казан байлары (иң күп ярдәмне Сафа хаҗи Галикәев күрсәтә) ярдәме белән хәзерге көндә барыбызга да мәгълүм таш бина төзелеп бетә. Ш.Мәрҗани гомеренең азагына кадәр шунда укыта.

## ЯҢА ЕЛ БИТ!

**Менә тагын бер ел узды.
Ул, әлбәттә, милади...
Кемнең эте койрык кысты,
Кем бүресе улады?**

**Вак әләмнәр куеп чыккан
Безнең тирәли кемдер...
Ул якта быргы кычкыра,
Гөрселдәп куя дөңгер.**

**Бу шундый уен бугай ла,
Гадәткә кереп киткән.
Ләкин аучы абайламый, –
Без бүре түгел күптән!**

**Кар төшә – ап-ак күбәләк,
Канат очлары юеш.
Тик эремәс инде йөрәк,
Йомылыр бозлы килеш.**

**Күренде шулчак алаша...
Аудым да чанасына,
Кап-караңгы кырлар аша
Кудым җил
чарасыздан.**

**Кыңгыраулар чыңы белән
Чыр китереп дөньяны,
Җилдерәсем килде гелән,
Бәлки кемдер уяныр?**

**Яңа ел бит! Тагын кем бар?
Кушылыр, бәлки, кемдер...
...Тик телен өзеп алганнар,
Челтерәмәде шөлдер.**

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

***

Ш.Мәрҗани Татар укытучылар мәктәбен оештыруда катнашып, 1875-1884 елларда анда дин мөгаллиме дә булып торган. Укыта башлаган көннәрендә мәхәллә халкы аның бу мәктәпкә барганын һәм кайтканын тамаша кылып карап торган, әлеге гамәлен яратмаган, хәтта шәһәр мөдәррисләреннән берсе: «Шиһаб мулла – миссионер. Ул – сатылган кеше. Русча укуга баш сәбәп ул гына булды», – дип сөйләгән. Аны әлеге уку йорты ачылуга сәбәпче булганга горурланасы урынга, киресенчә, тәнкыйтьләгәннәр. Әмма Мәрҗани халыкка: «Мин школага укытырга барсам, андагы шәкертләргә рух бирер өчен барамын», – дип җавап биргән. Әлеге мәктәпне оештырганда, аның хыялы рус телен яхшы белүче муллалар тәрбияләү булган. Мәрҗани: «Үз диненнән, милли тел һәм язуыннан хәбәре булмаган кешеләрнең русча укуыннан зур хәер көтелми»; «Мөселманча белмичә, русча укып калу гына ярый торган эш түгел», – дигән. Шунлыктан галим мәктәпкә ислам гыйлеменнән, татар теленнән яхшы хәбәрдарларны гына кабул иттергән. Әмма биредә дә Мәрҗанинең бу фикер-карашларын өнәп бетермәгәннәр, соңрак татар телен, динне камил белә торган укучыларны кабул итү традициясе бетерелгән, хәтта Мәрҗани киткәч, аның үз урынына тәгаенләп калдырган мөгаллимне дә эшкә алмаганнар.

Казанга мөселманнарның дөньяга карашларын үзгәртү хыялы белән кайткан Шиһабетдин бу өлкәдә дә гамәли яктан әлләни уңышка ирешә алмый. Исламның беренче чыганаклары Коръән, сөннәт һәм, мөҗтәһидләрнең фикерләрен алга куеп, соңгы дәвердә барлыкка килгән схоластика, тәкълид-иярүләрдән арынып, һәр кеше мөстәкыйль, хөр фикер чыгарырга тиеш, дигән карашлары, нигездә, аның китапларында гына кала. Басылып чыккан күп китаплары, мәҗлесләрдә әйткән фикерләре Казан һәм өязнең имам, мөдәррисләре тарафыннан тәнкыйтьләнеп, алар мөфти хәзрәтләренә рапортлар язса, аның имамлыктан алынуын күпләр шатлыклык хәбәр итеп сөйләсә, Һиндстан, Мисыр галимнәре тарафыннан исә Шиһабетдин хәзрәт исеме хуплап телгә алына. Биографиясе турындагы мәгълүмат Британия энциклопедиясенә җибәрелә. Борһан Шәрәф «Шура» журналында басылган мәкаләсендә: «Татарлардан галим сыйфаты илә чит мәмләкәтләрдә танылган кешеләрнең беренчесе Шиһабетдин әл-Мәрҗани булды. Мәдрәсәдә һинд басмасы китабының һамишәдәге кыек язуларын ихлас илә укыганым заманда, шул китапта бер мәсьәләгә дәлил өчен «әл-фәзыйлү Шиһабетдин әл-Мәрҗани»нең фикере аерым зикер ителгәнен күрү миңа шулчаклы шатлык булды, татарлык өчен шулкадәр горурландым ки, тизрәк кычкырып, иптәшләремне җыеп, китапның шул урынын күрсәтмичә чыдый алмадым. Ул китапта татар галимен искә төшерүченең кем идеген белергә телисезме? Рәхим итегез. Мәрҗанинең сүзе илә истидлял итүче кеше Һиндның иң зур вә иң мәшһүр галимнәреннән имам Габделхай әл-Лүкнәви иде», – дип яза. Шиһабетдин, үзен аңлауны чит ил голамәсеннән өмет итеп булса кирәк, дини мәсьәләләр турындагы китапларын гарәп телендә язган. Бу турыда үзе дә: «Гарәп телен галимнәребез вә шәкертләребез беләләр. Китапларыбыз башка өлкәләргә китсә дә, бәлки укучылар булыр. Төркичә язылса, башка җирләрдә файдаланмаслар», – дип җавап биргән.

Истәлекләргә караганда, Ш.Мәрҗани, Бохара укыту ысулын тәнкыйтьләп, үз мәдрәсәсендә укыту ысулын тәртипкә кертергә тырышса да, әлләни үзгәртә алмый, шәкерт-хәлфәләр таләбе белән башка мәдрәсәләрдәге кебек үк укытырга мәҗбүр була. Ул бу турыда менә ниләр яза: «Кышкар мәдрәсәләре, Буа мәдрәсәләре, Казан мәдрәсәләре, диеп, шулар кеби булырга тырышып, мәдрәсәмне юкка чыгардылар. Дәресләр хакында Бохарадан уйлап кайткан бөтен фаразлар бозылды. Юк нәрсәләр илә гомер әрәм итәләр. Кирәкле нәрсәләрне укымыйлар. Һай, шушы заманны, нишләтмәк кирәк. Боларның берсен дә укытмас идем», – дип сөйли. Мәрҗани хәзрәтләре үз идея-мәсләге (исламның беренче чыганаклары, борынгыларның фикерләре һ.б.) өчен кирәкле гыйлемнәр Коръән, тәфсир фәннәрен укытуга ирешсә дә, ислам тарихы, пәйгамбәрнең тормыш һәм шул чордагы вакыйгалар тарихын укыта алмаган.

Мәрҗанинең сәләтле шәкертләре күп булса да, үзенә тиң алмаш әзерләп калдырмаган. Бу турыда үзе дә: «Минем шәкерттән зур бәхетем булмады», – дигән. Шулай да, аның турыдан-туры шәкертләре булмаса да, кайбер яшь имамнарга зур өмет баглаган. Мәсәлән: «Галимҗан хәзрәт Баруди – өмидле кеше»; «Ризаэддин әфәнденең

«Игътибар»ын укыгач, өмидле егет, мәсләгенә дә сәбатле булса, эш эшләр»; «Хәсәнгата Габәшине бу зирәк егет икән, ләкин Вәли хәзрәт мәдрәсәсендә нигә кызыгып тора икән?» – дип сөйләгән. Чутсыз мулла-мөәзиннәрне исәпкә алмаганда, Санкт-Петербург университетының гарәп һәм төрек телләре мөгаллиме Хөсәен Фәезханов һәм аның энесе, «Кәлилә вә Димнә», «Шәҗәрәи төрек» китапларын татарчага тәрҗемә иткән Габделгалләм Фәезханов, «Идел» газетасының баш мөхәррире Габдрахман Гомәриләр – Мәрҗанидән белем алган мәшһүр шәкертләр. Шулай ук Казанның атаклы байлары Садыйк Галикәев, Салих Гобәйдуллин (тарихчы Газиз Гобәйдуллинның этисе), Шакир Казаков, Мөхәммәдрәхим Юнысов, Мөхәммәдҗан Кәримов, Сәедгәрәй Алкин, Габдрахман Кушаевлар да «Казанның Шиһаб ахун»нан белем эстәүне үзләренә зур дәрәҗә дип санаган. Шиһабетдин гомеренең соңгы көннәренә кадәр мөгаллим булган, хәтта өеннән чыга алмаслык хәлгә килгәч тә, шәкертләрне үз янына чакырып укыткан.

1859 елда Шиһабетдин Мәрҗани, дин белгече, галим буларак, басмага әзерләнә торган Коръән китапларының беренче «указлы» рәсми тикшерүчесе итеп тәгаенләнә. Әгәр дә басылып чыккан Коръәндә хаталар китә калса, ул бу гамәле өчен Оренбург Диния нәзарәте һәм Россия Эчке эшләр министрлыгы каршында җавап бирергә тиеш була. Коръәнне төзәтү, басмага әзерләү эше, гарәп телен камил дәрәҗәдә белү өстенә, әлеге өлкәдә ислам дәүләтләрендәге тәҗрибәне дә үзләштерүне таләп итә. Галим бу турыда 1878 елда «Әл-фәваидүл-мөһиммә» исемле әсәрен бастырып чыгара, Диния нәзарәте үрнәк итеп тәкъдим иткән Коръәннәрдән дистәләрчә хата табып төзәтә, һәм яңа басылачак китапларны сәхабәләр язуына, хәзрәти Госман мосхафларының рәсемнәренә туры китереп редакцияли башлый. Моның өчен аны дошманнары: «Коръәнне бозган, сүзләрен төшереп калдырган», – дип сүгә, яла яга, Диния нәзарәтенә төрле шикаятьләр яудыра. Шулай итеп, төрле гаеп һәм сылтаулар табып: «Исламнар арасында гауга һәм талашу белән мәшгуль булганлыктан, хезмәте күптер», – дип, Ш.Мәрҗанине бу эшеннән азат итәләр. Бу турыда Р.Фәхреддин «Асар» исемле мәшһүр хезмәтендә: «Матбагa сахибларыннан *(хезмәткәрләреннән. – Л.Г.)* вә яки бастыручылар тарафыннан «вакытында эшләми, без зарланабыз» кабиленнән шикаять булмаганы хәлдә, «мосхафне тәхрир *(хур. – Л.Г.)* итәдер» дип, рәсем мәсьәләсеннән хәбәрдары булмаган муллаларның сүзләрен гамәлгә кую өчен, берәүне үзе сөеп эшләгән гыйлеме вә дини хезмәтеннән аеруны золым итүдән башка берлә тәүсый кылу урынлы түгел», – дип яза. Галим 1866 елда «бу хезмәтне башкарырга лаек булганлыктан», яңадан әлеге вазифага билгеләнгән. Шуны да искәртү урынлы булыр: бу эштә Ш.Мәрҗанигә гарәп һәм фарсы телләрен камил белгән кызы Галия дә ярдәм иткән. «Мәрҗани» китабында: «Күпвакыт Коръән аның төзәтүләре илә басылган», дип язылган җөмлә бар. Кызганыч, Ш.Мәрҗанинең әлеге юнәлештәге эшчәнлеге дә әлләни дәвамлы булмый. Бу турыда Г.Гыйсмәти: «1859 елда мәрхүм Мәрҗани хәзрәтләре башлап җибәргән рәсемгә иярү, төзәтүгә игътибар итү эше бу көнгә чаклы ахыргы ноктасына җитә алмады», – дип яза. 1905, 1909 һәм 1913 елларда җитди хаталар белән басылган Коръәннәр татар җәмәгатьчелегендә, вакытлы матбугатта шактый бәхәс уятканы мәгълүм.

Ш.Мәрҗани гомере буе тарих белән шөгыльләнгән. Хәтта вафатына ике көн кала «Мөстәфадел-әхбәр» өчен бер шәкертенә Кәче мулласы Габделвәли мулланың тәрҗемәи хәлен әйтеп яздырган. Соңгы сәгатьләренә кадәр Коръән укыган, тәкъбир әйткән, «Коръән мәгънәләре җиңеллек бирә», дип башкалардан да изге китапны укыткан. Казан һәм мөселман дөньясының олуг хәзрәте 1889 елның 18 апрелендә (һиҗри белән 1309 елның 29 шәгъбан ае) «картлык хастасыннан», Г.Баруди язган мәгълүматка караганда, «ашказаны шешеннән» бакый дөньяга күчә, Татар бистәсе зиратында җирләнә. Җеназасын улы Борһанетдин Мәрҗани укый.

***

Шиһаб хәзрәт Бохарадан кайткач, Әлмәт авылындагы Нигъмәтулла ишанның үги кызы Фатыйма белән никахлашкан була. Бу хатыны 1951 елда вафат, балалары булмый. Икенче хатыны – Хөсәен Апанаевның кызы Бибинәгыймә. Бу абыстай белән 19 ел чамасы яши, аларның ун баласы дөньяга килә. Кызганыч, өчесе – Борһанетдин, Галия һәм Хава исемлеләре генә озын гомерле була. Бибинәгыймә абыстай вафат булгач,

1871 елда, Мәрҗани Казан бае Хөсәеннең кызы Бибифатыйма белән никахлаша. Буаның атаклы имамы һәм мөдәррисе Габденнасыйр кызы Зөһрәне исә гомеренең соңгы елларында Бибифатыймага көндәш итеп ала.

## Садретдин Мәрҗани

Тарих фәнендә Шиһабетдин Мәрҗанинең тормыш юлы шактый өйрәнелгән булса, аның бертуган энесе, мәгърифәтче, Ташкичү авылының имам-хатыйбы һәм мөдәррисе Садретдин әл-Мәрҗанинең шәхесе әлегә кадәр күләгәдә кала бирде. Белешмә чыганакларда, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре чыгарган «Татар мәгърифәтчеләре» исемле китапта һәм Татар энциклопедия институты чыгарган фундаменталь хезмәт «Татар энциклопедиясе»ндә дә әлеге олуг дин галиме турында берни дә әйтелми.

Язган китаплары, зур хезмәтләре сакланып калмаса да, шул чор гарәби язулы татар вакытлы матбугаты һәм кайбер басмалар аша Садретдин әл-Мәрҗанинең татар иҗтимагый тормышында, аеруча татар мәхәлләсендә мөһим роль уйнаганлыгы ачыклана. Гомумән, Ташкичү авылы тарихын әлеге шәхестән башка күз алдына китерүе дә кыен. Аның турында Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел әхбар»ендә Ризаэддин Фәхреддиннең биобиблиографик хезмәте – «Асар»да биографик мәгълүмат, 1916 елда углы Зәкәрия Садретдин тарафыннан «Кояш» газетасында вафаты уңаеннан язылган мәкалә, шул ук басмада аның авыруы һәм «Йолдыз» газетасында аның вафаты турында кайгы уртаклашу хәбәрләре дөнья күргән. Әлеге чыганаклар нигезендә Ташкичү авылы имамы һәм мөдәррисе Садретдин әл-Мәрҗанинең тормыш юлыннан кайбер сәхифәләрне ачыкларга мөмкин.

Садретдин бине Баһаветдин бине Собхан әл-Мәрҗани хаҗи 1826 елның (һиҗри белән 1242 елда рәбигыль әүвәл якшәмбе көн (Зәкәрия Садретдин язуынча), рәбигыль ахир пәнҗешәмбе көн төн уртасында (Шиһабетдин Мәрҗани язуынча) Казан өязе Ташкичү авылында дөньяга килә. Башлангыч гыйлемне атасы, Ташкичү имамы, мөдәррис Баһаветдин хәзрәт мәдрәсәсендә ала. Агасы кебек үк Садретдин да зирәк, акыллы шәкертләрнең берсе була. Ш.Мәрҗани аның турында: «Безнең кече энебез, миннән үткенрәк булып, дәресне дә тиз белә, сүзне тизрәк аңлый...» – дип язып калдырган.

Садретдин, яше унсигезгә җиткәндә, Ташкичүнең Бохара белән сәүдә итә торган сәүдәгәрләреннән Җиһанша бине Габделсәлам ярдәме илә, гыйлем алыр өчен, Бохарага сәфәр китә. Юлда кыенлыклар булу сәбәпле, Казакъстанның Кызылъяр шәһәренә барып җиткәч, бер елга туктала. Бу вакыт эчендә Садретдин, иптәшләре сәүдә белән шөгыльләнгән арада, Петропавел шәһәренең укымышлылары, галим-голамә һәм мөдәррисләре белән очраша, алар белән фикер алыша, йортларында кунак була.

Садретдин әл-Мәрҗани Бохарага барып җиткәч, абыйсы мелла Шиһабетдин әл-Мәрҗани укыган «Күгелдаш» мәдрәсәсенә урнаша, аның белән очрашып, дүрт ел бергә яши. Садретдин, агасы Шиһабетдин[5] кайтып киткәч тә, сигез ел гомерен Бохарада гыйлем алуга багышлый.

Садретдинга Бохарада тору вакытында матди ярдәм бик аз гына, хәтта юк дәрәҗәсендә килгән, әмма үзенең тырышлыгы, пөхтәлеге, акылы аркасында хөҗрә тотып, яхшы гына торган. Тиешле фәннәрдән тыш, өстәмә, күбрәк дәресләрдә укытылмый торган фәннәрне укуга игътибар биргән. Ибне Сина, Ибне әл-Гарәби, Ибне Рөшдә, әл-Газали, ас-Суюти, Абү-Хәмидә, әш-Шаһрастани, Ибне Халдун кебек танылган авторларның хезмәтләрен өйрәнгән.

Күп эзләнүе һәм гыйлемлеге аркасында Садретдин әл-Мәрҗани Шәрык һәм Аурупа гыйлемнәреннән хәбәрдар булган. Бу турыда Зәкәрия Садретдин түбәндәгеләрне яза: «Зур сүзләрне күтәрерлек вә аңларлык яшькә малик *(ия. – Л.Г.)* булмаган чагымда, йортка килгән әтрафтагы *(тирә-яктагы. – Л.Г.)* бәгъзе *(кайбер. – Л.Г.)* имамнарга сүз мөнасәбәте белән чыккан бәгъзе хосусый шәргый мәсьәләләрдә әсрар максад исламияне (ислам серләрен. – Л.Г.) бәян итә вә аңлап җитмәсәм дә сүзләре хәтеремдә кала иде. Тора-бара табигый бу сүзләрнең ни дәрәҗәдә кыйммәтле вә никадәр гали

[5] Алда язганыбызча, Шиһабетдин Мәрҗани Бохара һәм Сәмәркандта 1838-1849 елларда гыйлем ала.

*(бөек. – Л.Г.)* сүзләр икәнен аңладым. Соңрак мәшһүр төрек мөhәррире Әхмәд Мидхәд әфәнденең әсәрләрендә вә моннан да соң Мисыр мөфтисе әл-шәех Мөхәммәд Габдүнең әсәр вә дәресләрендә Садретдин хәзрәттән ишеттегем тәхкыйкатнең *(хакыйкатьнең. – Л.Г.)* күбесен, Алланың үзләренә биргән нигъмәтләренә мәмнүният (разый булу. – Л.Г.), Ташкичү карьясында валид *(ата. – Л.Г.)* агызыннан ун еллар элек ишеткән икәнемне хәтерләп гаҗәпкә калдым. Ауропа лисаннарына *(телләрен. – Л.Г.)*, Ауропа мөәллифәтен *(мөхәррирләрен. – Л.Г.)* моталлага итеп *(өйрәнеп. – Л.Г.)*, Ауропа голамәсенең дә фикерләреннән истифадә кыйлу *(файдалану. – Л.Г.)* вә хакаикъ исламиягә вакыйф булган *(асылына төшенүче. – Л.Г.)* бу ике Шәрык галименең, ничә еллар мөкаддәм атам агызыннан ишеттегем хакыйкатьләрне мәмнүнән *(шатланып. – Л.Г.)* вә мөфтәхирана *(мактаган рәвештә. – Л.Г.)* язганнарын вә бәян иткәнлекләрен ишеткәч, күңелемнең иң тирән урыннарына вә бөтен вөҗүдемә *(барлыгыма. – Л.Г.)* атама шулкадәр бөек гыйльми *(угылыкныкы гына түгел. – Л.Г.)* мәхәббәт вә ихтирам урынлашты ки, язып бәян итә алмыйм».

Бохарада булган вакытта Садретдин Мәрҗани абыйсы Шиһабетдиннең Сәмәркандтагы казый Әбү Сәгыйдь китапханәсеннән язып алып кайткан китапларын үзе язган яки өмә ясап эшләткән, ә кайберләрен акча бәрабәренә күчерткән[6]. Галим үзенең Бохарада үткәргән гыйлем алу вакытын китаплар җыю һәм күчерү белән тыгыз үреп барган.

Садретдин әл-Мәрҗани Бохарада унике ел гыйлем алганнан соң, ватаны Ташкичү авылына кайта. Атасы Баһаветдин хәзрәт бакый дөньяга күчкәч, аның урынына имам-хатыйп һәм мөдәррис була. Шунда ул Кышкар имамы Ягъкуб бине Яхъя әд-Дөбьязиның Бибиәсма исемле кызына өйләнә. Нәкъ менә Ташкичү авылында аңа тормышның ачысын-төчесен татырга һәм аның авыр йөкләрен күтәрергә туры килә. Ул һәрдаим уку, өйрәнү, фикер йөртү белән шөгыльләнә, шул сәбәпле һәр мәсьәләгә, һәр бәхәстә үзенең тирән, төпле фикере була. Шулар өстенә ул актив физик хезмәт белән шөгыльләнә: гади авыл кешеләре янәшәсендә бер сафта иген игә, чәчүгә-уракка төшә, мал-туар, кош-корт үстерә. Садретдин Мәрҗани шәкертләр җыеп гыйлем бирү эше белән соң гына шөгыльләнә башлый. Зәкәрия Садретдин язуынча, бу атасының тормыш-көнкүреш, гаилә мәшәкатьләренә, «вакытын мәгыйшәть өчен көрәшкә» сарыф итү белән бәйләп аңлатыла.

Ташкичү имамы Садретдинның тормыш юлы балачагыннан ук абыйсы Шиһабетдин Мәрҗанинеке белән үрелеп бара. Ул һәрвакыт Шиһабетдиннең дусты, юлдашы, ярдәмчесе, фикердәше һәм сердәше булган. Шиһабетдингә балачагында тавыкларга әтәч койрыгы тагуда кошларны тотып китерүче, кардәшләрен, салга утыртып, Кысна авылына алып баруда да Садретдин төп ярдәмчесе булган. Тора-бара Шиһабетдин Мәрҗани үзенең һичкемгә сөйләми торган һәм һәркемнән яшерергә тиеш булган серләрен бары тик энесенә генә ачкан. Казанның беренче җамигъ мәчетенә имам булганнан соң язган хатларында Садретдингә үзенең ялгызлыгын һәм тирә-ягын дошманнар белән уратылганын шикаять иткән. Вафатына кадәр Мәрҗани атнасына өчәр мәртәбә хат яза торган булган, хатлар киная белән языльп, аерым вак кәгазьләргә аерылып беткән (шулай итеп, алар чит кеше укудан сакланган). Шиһабетдин хатларның кереш өлешенең күбесендә бала вакытында бергә уйнап үскән иптәшләренә сәламнәр юллаган. Бу үзе исән вакытта ук дөнья күләмендә танылган галимнең гади крестьян дәрәҗәсендә булган яшьлек дусларын онытмавы, аларга кадер-хөрмәте булуы турында сөйли.

Күренекле дин эшлеклесе, «Шура» журналының баш мөхәррире, тарихчы галим Р.Фәхреддиннең «Асар» хезмәтеннән күренгәнчә, Садретдин әл-Мәрҗани аның белән дә хат язышып торган. Китапта китерелгән хатта 1896 елда аның җәмәгате авыруы һәм вафат булуы турында мәгълүмат бар. Р.Фәхреддин Садретдин Мәрҗанине Казан шәһәрендәге Мөхәммәдҗан Кәриминең табгыханәсендә очратуын әйтә һәм аның турында: «Гыйлем вә фазыл сахибе *(белем иясе. – Л.Г.)* булуы өстенә, вәкарлы, мөтәфәккир *(фикер иясе. – Л.Г.)*, сәламәт табигатьле таптым», – дип яза.

Шиһабетдин Мәрҗани елына өч-дүрт мәртәбә Ташкичү авылына кайта торган булган. Бу турыда Зәкәрия Садретдин түбәндәгеләрне яза: «Бер йөреп киләсе килде исә, Мәрҗани атларын җиктергән дә Ташкичүгә, туганы Садретдин хәзрәткә барган вә авылда кызу эш вакытында тәсадыф иткән *(туры килгән. – Л.Г.)* чакларда килеп энесен күрү илә: «Синең бик кызу печән яки урак вакыты икәнен белсәм дә, эш күп,

[6] Бу чорда Урта Азиядә һәм Идел буенда китап күчереп язып кәсеп итүче шәкертләр булган.

диеп, абыз-агай куып чыгармас әле дип килдем», – дип күрешә, хәл-әхвәл сораша торган булган». Әмма Садретдин абыйсы янына Казан каласына үзе күбрәк, кайбер очракларда гаиләсе белән дә бара торган булган.

Кичләрен бертуган Мәрҗаниләр гыйльми мәсьәләләр турында сөйләшкән. Садретдин хәтта кайбер өлкәдә абыйсыннан да өстен чыккан, үзенең хәбәрдарлыгы белән Шиһабетдинне гаҗәпкә калдырган. Ул хәтта, шикләнеп: «Юктыр, абызагай, ялганламыйсың? Кайда шулай ди?» – дип, чыганагын сорый һәм, Садретдин күрсәтеп биргәч: «Ай, абызагай, хәбәрдарлыгың бик күп, ничә мәртәбәләр чакырып та, Казанга барып, бергә дәрес әйтешмәдек, юкка Ташкичүдә калдың, юкка», – ди торган булган. Әмма татар галиме, дин белгече Садретдин Мәрҗани гомере буе туган авылында, туган нигезендә яшәп, халкына хезмәт итеп, шул ук авылда дөнья куя. Югыйсә бу шәхеснең Казан, Оренбург, Уфа шәһәрләрендә яки чит илләрдә яшәп тә дан-шөһрәткә ирешү, иҗат итү мөмкинлеге, гыйльми куәте булган.

Садретдин хәзрәт Казан һәм Казан артында гыйлеме белән могтәбәр галимнәрдән саналган. Абыйсы Шиһабетдин кебек үк, хак сүзне әйтүдән курыкмаган, һәр әйткәнен, һәр фикерен җиренә җиткереп дәлилләгән. Садретдин гаять тәкъва, диндар шәхес булып, бер намазын да калдырмаган, хәтта яшьлегендә Бохарага сәфәре вакытында калдырган намазларын да каза кылып укып бетергән. Авыл халкы аны үзенә рухи, гыйльми юлбашчы итеп санаган. Садретдин хәзрәт Ташкичү авылы халкын ислам юлына өндәгән, моның нәтиҗәсе буларак, ташкичүлеләр, күрше авыллар белән чагыштырганда, җәмәгать намазына күбрәк йөргән, мөлаем һәм әдәплерәк тә күренгән.

Картлык көнендә Садретдиннең күзе начар күрсә дә, җәйнең бик аяз һәм кояшлы көннәрендә китапларын тәрәзә янына алып килеп укый торган булган, дөньяга чыккан яңа һәр әсәр белән танышып барган. Китапларны Казаннан һәм Көнчыгыш илләреннән махсус кайтарткан. Гомеренең соңгы елларында Җамалетдин әл-Әфгани, Мөхәммәд Габдү кебек философларның әсәрләренә мөкиббән булган.

Картлык көнендә гыйлем иясе авырып китә. Аның авыруы турында «Кояш» газетасында түбәндәге хәбәр языла: «Кичә Казанга Шиһабетдин әл-Мәрҗанинең борадаре *(ир туганы. – Л.Г.)* ташкичүле Садретдин хәзрәт әл-Мәрҗанинең каты авырулыгы хакында телеграм хәбәре алынды. Шул мөнәсәбәт белән, газетабызның баш мөхәррире Зәкәрия әфәнде бине Садретдин әл-Мәрҗани Казаннан ватаны Ташкичүгә сәфәр итте. Садретдин хәзрәт, бу көндә хәяттәге Мәрҗаниләрнең иң карты булып, гыйлем әфзале *(югарылыгы. – Л.Г.)* белән мәгъруф *(танылган. – Л.Г.)* вә бу көннәрдә туксаннарын мөтәҗавиз *(чиктән үткән. – Л.Г.)* бер пир *(карт. – Л.Г.)* мөхтәрәмдер. Хөрмәтле картка тизлектә сихәтләнү телибез. Шәһәр Думасы мәҗелесе». *(Садретдин әл-Мәрҗани хәзрәтнең авыруы. – Кояш. – 1916. – №928. – 6 март)*.

Вафаты турында «Йолдыз» һәм «Кояш» газеталарында түбәндәге хәбәрләр басыла: «Казан өязе Ташкичү авылында имам Садретдин әл-Мәрҗани хәзрәт мартның 6сында вафат булган. Мәрхүм Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең бер тугма кардәше булып, аның белән бергә Бохарага һәм сәфәр иткән иде. «Кояш»ның баш мөхәррире Зәкәрия әфәнде мәрхүм Садретдин хәзрәтнең мәхдүмедер. Аллаһы Тәгалә мәрхүмне үзенең рәхмәтенә мәзъһәр[7] итеп, әһел әүляденә *(нәсел-нәсәбенә. – Л.Г.)* сабыр җәмил (күркәм сабырлык. – Л.Г.) бирсен». *(Йолдыз. – 1916. – №1618. – 9 март).*

«15 нче җомади әл-әүвәл (6 март) якшәмбе көн иртәнге сәгать унда Ташкичүле Садретдин хәзрәт Мәрҗанинең вафат итүе хакында идарәбезгә хәбәр алынды. Агасы Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең мәсләки юлдашы, бу көнне Казан әтрафы имамнары арасында зур әһел гыйлем вә фазыйльдән *(укымышлы. – Л.Г.)* булучылыгы белән мәгъруф *(танылган. – Л.Г.)* бу пир *(карт. – Л.Г.)* мөхтәрәм үз мәгасырларының *(чордашларының. – Л.Г.)* иң ахыргысыдыр. Аның вафаты белән инде бу буын әһел гыйлем тәмама вафат итеп бетеп, дөньяны үзеннән соңгы буынга ташлап киткән буладыр. Мәрхүмнең тәрҗемәи хәле бик күп ноктадарында Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең тәрҗемәи хәлләре белән бергә үрелеп барганлыктан, гомум укучылар өчен әһәмиятле булырлыктыр. Кирәк материаллар җыелып бетү белән, без газетабызга аның тәрҗемәи хәлен язарбыз, иншалла». *(«Кояш. – 1916. – 8 март. – №929).*

[7] Мәзъһәр – бер эш яки хәлнең барлыкка килгән урыны.

Зәкәрия Садретдинның әтисе турындагы күләмле мәкаләсе 1916 елгы «Кояш» газетасының 24, 25 март саннарында (№938, 939) дөнья күрә. Алдан язган мәгълүматларның да төп чыганагы булып татар мәгърифәтчесенең «Кояш» газетасында басылган тәрҗемәи хәле тора.

Садретдин әл-Мәрҗани Ташкичү авылында 60 елдан артык имамлык итеп, 90 яшендә, 1916 елда (һиҗри белән 1334 сәнәдә җомади әл-әвәл унбишендә) көндез сәгать унбердә вафат булган[8], икенче көнне Ташкичү авылы зиратына җирләнә. Авыл халкы имамны зиратка кадәр озата бара, җирләү йоласын, традиция буенча, үзләре башкара. Шунысы кызганыч: Ташкичүнең зиратын аркылыга-буйга йөреп тә, әлеге мөхтәрәм затның кабер ташын таба алмадык. Ул, әллә инде дөньялар үзгәреп китеп, революцияләр шаукымы белән куелмый калган, әллә куелып та, еллар узу белән, җимерелеп, юкка чыккан. Зиратта Кышкар мулласы Ягъкуб бине Яхъя әд-Дөбъязиның кызы, Садретдин мулланың хатыны Бибиәсмага куелган кабер ташы бар. Таштан мәрхүмәнең 56 нчы яшендә, 1896 елның 4 октябрендә вафат булганын ачыклыйбыз.

Шиһабетдин Мәрҗанинең мәшһүр «Мөстәфадел-әхбар...» хезмәтендә Садретдинның унике баласы булуы турында әйтелә, шуларның әсәр язылган вакытка (китап, галим вафат булгач, 1897 елда басылган) алтысы вафат була. Ә Зәкәрия Садретдин язуына караганда, Садретдин Мәрҗанинең үзеннән соң (1916 елда) ике улы, бер кызы калган.Кызы китапчы Мөхәммәдҗан әл-Кәримидә[9] кияүдә булган. Олы улы атасы урынында Ташкичүдә имамлык вазифасын башкарган, ә икенче улы, безгә мәгълүм Зәкәрия Садретдин Казан шәһәрендә дөнья күрүче «Кояш» газетасының баш мөхәррире булып милләткә хезмәт иткән. Димәк, Садретдин Мәрҗанинең үзе вафатына кадәр тугыз баласы бакый дөньяга күчә.

Шунысын да онытмыйк: 1915 елда Мәрҗанинең тууына һиҗри ел хисабы белән 100 ел тулу уңаеннан чыгарылган «Мәрҗани» дигән китапның галим балачагына һәм Бохарада укуы турындагы бүлекләре Садретдин Мәрҗани сөйләгәннәргә нигезләнеп язылган.

Тарихи чыганак һәм әдәбиятны бөртекләп җыеп, андагы мәгълүматны тикшергәннән соң, шул аңлашыла: Ташкичү имамы һәм мөдәррисе Садретдин әл-Мәрҗани XIX гасыр – XX йөз башы татар җәмгыятендә танылган шәхесләрнең берсе булган. Ул – үзенең фикерләре, кылган гамәлләре белән туган авылында гына түгел, ә тирә-якта, Казан шәһәрендә мәшһүр галим. Бу шәхеснең XX йөз башы татар вакытлы матбугатында телгә алынуы гына да аның шул чор татар җәмгыятендә тоткан урынының югарылыгына бер дәлил.

**Чыганаклар һәм әдәбият**


1. Гобәйдуллин Л.И. «Шиһабетдинемез бер иде...» // Безнең мирас. – 2015. – №4. – Б.39-43.
2. «Кояш» һәм «Йолдыз» газеталарының 1915 елгы гыйнвар аенда басылган саннары.
3. Марджани Ш. Зрелая мудрость в разъяснение догматов ан-Насафи (ал-Хикма ал-балига) / предисл. и пер. с араб. Д.Шагавиева. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2008. – 479 с.
4. Мәрҗани: Фәнни-популяр җыентык. – Казан: Җыен, 2010. – 704 б.
5. Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. – 415 б.
6. Фәхреддин Р. Асар: III һәм IV томнар. – Казан: Рухият, 2010. – 648 б.
7. Фәхреддин Р. Коръән вә табагат / Төз., кереш мәкалә авторы Л.Гобәйдуллин. – Казан, 2012.
8. Юсупов М.Х. Шигабутдин Марджани. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2005. – 271 с.



**Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН**


[8] Берничә көн алдан Казан шәһәрендә Шиһабетдин Мәрҗанинең олы улы Борһанетдин Мәрҗани вафат була. Әлбәттә, бу турыда Садретдин Мәрҗани хәбәрдар булган һәм нык борчылган.

[9] Мөхәммәдҗан, Шәрифҗан һәм Хәсән Кәримевләр 1897 елда Казан шәһәрендә «Бертуган Кәримовларның сәүдә йорты» исемендә татар китапчылыгы тарихында беренче китап сату ширкәте, 1900 елда «Матбагаи Кәримия» исемендә беренче хосусый татар басмаханәсе оештырган. Бу басмаханәдә революциягә кадәр «Таң йолдызы», «Тавыш», «Кояш» газеталары һәм меңләгән татар китабы басылган.

# ОСТАЗЛАР ОСТАЗЫ

Халык ул – тарих һәм мәдәнияткә күпмедер дәрәҗәдә үз өлешен керткән шәхесләр бергәлеге. Бу җәһәттән киләчәк буыннарга гаять бай мирас калдырган ике олуг шәхес – күренекле мәгърифәтче, дин белгече, галим Шиһабетдин Мәрҗани һәм аның шәкерте, танылган җәмәгать һәм дин эшлеклесе, нашир, педагог Габдулла Апанаев эшчәнлеге халкыбызның рухани тормыш-яшәешендә аеруча күренекле урын алып тора.

Ул 1862 елның 15 мартында Вятка губернасы Малмыж өязе Сосна авылында (хәзер – Татарстанның Балтач районы) икенче гильдия сәүдәгәр гаиләсендә туган. Аның әтисе Габделкәрим Исхак улы Апанаев (1840-1892) Казанда, Захарьев урамындагы (хәзер – К.Насыйри урамы) 1 нче Җәмигъ мәчете мәхәлләсендә яшәгән, күптөрле күчемсез милек, сабын кайнату заводы һәм кибетләр челтәре хуҗасы булган. Г.Апанаевның бабасы, беренче гильдия сәүдәгәр, сәнәгатьче Йосыф Исмәгыйль улы Апанаев (1770-1840) 1806-1809 елларда ук типография тоткан, анда татар телендә дини әдәбият һәм дәреслекләр бастырылган. Үз чиратында, Йосыфның улы һәм Габдулла Апанаевның туганнан туган бабасы үзенең мәгърифәтчелек эшчәнлеге белән Ш.Мәрҗанинең атаклы «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабында аерым очеркка лаек булган.

Мондый традицияле гаиләдә балаларга кечкенәдән үк яхшы белем бирергә омтылулары гаҗәп түгел. 1870 елда бәләкәй Габдулла шәһәрдәге иң яхшы дини уку йортларыннан берсе – «Мәрҗания» мәдрәсәсенә йөри башлый.

Әлеге мәдрәсәдәге фикер иреге шәкертләрдә иҗтимагый тормыш проблемалары белән кызыксыну уята, аларның белем дәрәҗәсен, дини-дидактик кысаларда гына калдырмыйча, киңәйтә. Тикмәгә генә «Мәрҗания» мәдрәсәсендә укучыларның күбесе соңрак җәдидчелек хәрәкәтенең күренекле әһелләренә, үз чорларының алдынгы кешеләренә әйләнмәгәндер. Бик тырыш һәм сәләтле Габдулла Апанаев та Шиһабетдин хәзрәтнең яраткан шәкертләреннән булган.

80нче еллар азагында мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, Г.Апанаев Төркиягә һәм Мисырга сәяхәт кыла, андагы атаклы ислам мәгърифәте үзәкләрен күрергә, шулай ук шәрык дөньясының рухи халәте белән якыннанрак танышырга ниятли. Һәм бу очраклы түгел. Шәкерт чагыннан ук ул тарих белән ныклап кызыксына башлый. Г.Апанаев татар милләтенең артта калу сәбәпләрен халыкның бик ерак заманнарда кичергән фаҗигасеннән, аннан соңгы көчләп чукындырулардан, эзәрлекләүләрдән һәм хокуксызлыктан күрә. Ул рухи һәм икътисади тупиктан чыгуның бердәнбер юлы татарларны дөнья цивилизациясе казанышлары белән таныштыруда икәнен яхшы аңлый. Сәяхәттән кайткач, үз эшчәнлегендә дә шул мәгърифәтчелек идеяләрен тормышка ашырырга омтыла.

Диния нәзарәтендәге имтиханнардан соң, 1890 елның 15 декабрендә указлы мулла Г.Апанаев Печән базары мәчетенә имам һәм аның каршындагы мәдрәсәгә мөдәррис итеп билгеләнә. Бу мәхәллә мәдрәсәсендә ул реформа үткәрә башлый, аны яңа укыту ысуллары һәм төрле уку программалары булган, дин дә, фән дә өйрәтелә торган заманча уку йортына әйләндерергә тели. Үз хыялларын тормышка ашыру өчен, Габдулла мулла әтисеннән калган мирасның зур өлешен дә кызганмый. Ул үзенең Евангелистлар (хәзерге Татарстан) урамындагы йортын мәдрәсәгә бина итеп бирә, сыйныфларны махсус җиһаз һәм җайланмалар, китап-дәреслекләр һәм башка әсбаплар белән тәэмин итә. Г.Апанаев мәдрәсәсе Казан үлчәмнәре буенча чагыштырмача кечкенә саналса да (бередә 50 шәкерт укыган), аның даны губернадан еракка тарала. Мөдәррис Апанаевның демократлыгы, аның тиңдәшсез педагоглык сәләте бирегә елдан-ел күбрәк яшь егетне җәлеп итә – алар төпле белем генә алып калмый, бәлки үз фикер һәм карашларын курыкмыйча белдерергә дә өйрәнә. Якынча шул ук чорда Габдулла

хәзрәт мәдрәсәсендә күренекле шагыйрь Нәҗип Думави да белем эсти, еллар үткәч, ул биредә уку елларын сагынып искә ала.

Педагоглык эшчәнлегеннән тыш, Г.Апанаев иң зур татар иҗтимагый оешмасының Мөселман хәйрия җәмгыяте белән җитәкчелек итә. Оешма гарипләр йорты, амбулатория, һөнәргә өйрәтү сыйныфы да булган 80 кешелек балалар приюты ачуга ирешә.

Беренче рус революциясе елларында Г.Апанаев зирәк сәясәтче, талантлы публицист буларак та таныла, империя халыкларының милли-азатлык көрәше әйдаманнарының берсенә әйләнә, Россиядә беренче «Иттифак әл-Мөслимин» мөселман сәяси партиясенә нигез сала. Әлеге фирканең өч корылтаен әзерләп һәм үткәреп, ул аның Үзәк комитеты һәм Казан бюросы әгъзасы итеп сайлана, берьюлы ике комиссиядә эшли, шулай ук «Азат» газетасының нашире һәм мөхәррире дә була.

Габдулла Апанаевның активлыгын губерна җитәкчелеге дә «бәяләми» калмый, билгеле: 1908 елда ул Г.Баруди, С.Галиев һәм А.Казаков белән бергә Вологда губернасына сөргенгә җибәрелә.

1910 елда, сөргеннән кайткач, Г.Апанаев кабат иҗтимагый тормышның үзәгендә кайный башлый. Ул шәһәр Думасына гласный итеп сайлана һәм анда берьюлы дүрт комиссиядә эшли, IV Дәүләт Думасына сайлауларда үз кандидатурасын да тәкъдим итә.

Г.Апанаев большевикларның хакимиятне законсыз рәвештә тартып алуына, Учредительное собраниене куып таратуына һәм «Болак арты республикасы»н тар-мар итүенә кискен каршы чыга.

Габдулла Апанаевны 1919 елның 28 июнендә кулга алалар һәм инде «Мөселманнар берлеге» белән җитәкчелек итүен дә, сәүдәгәр нәселеннән булуын да искә төшерәләр. Хәзрәтне контрреволюцион фетнә әзерләүдә һәм Мулланур Вахитовны кулга алуда ярдәм итүдә гаеплиләр, ә инде баш күтәргән Татар запас батальоны солдатлары Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге башлыгы Камил Якубны үтергәннән соң, атарга хөкем итәләр. Хөкем карары шундук җиренә җиткерелә.

Габдулла Апанаевның бөтен эшчәнлегендә аның бөек остазы Шиһабетдин Мәрҗани йогынтысы сизелә. Остаз белән шәкертнең үзара мөнәсәбәтләре аеруча җылы һәм ышанычлы була. Вафаты алдыннан Мәрҗани кече кызы Бибиһаваның (1871-1945) Габдулла Апанаев белән никахына фатиха бирә. Соңрак Һава Габдуллага кияүгә чыга. Мәрҗанидән мирас булып калган материалларның бер өлеше Г.Апанаев кулына күчә. 1920 елларда Апанаевлар гаиләсе эзәрлекләнә, аларны фатирларыннан куып чыгаралар, китапханәләре ташландык хәлгә килә. Габдулла белән Һава Апанаевларның кызы Зәйнәп башка шәһәргә күчеп китә һәм Казанга картайгач кына кайтып урнаша. Ул галим мирасыннан нибары берничә фотосурәтне генә саклап кала ала. Хәзер бу фотолар Зәйнәп Апанаеваның балаларында саклана.

Милли музей фондларында бу ике күренекле шәхеснең истәлекле әйберләре, китаплары, кульязмалары, фотографияләре шактый. Даими экспозициягә Ш.Мәрҗанинең секретёры, юл сандыгы, стена сәгате, таягы, диван-канапесы, тау бәллүреннән ясалган шәхси мөһере, шулай ук үзе исән вакытта басылган китаплары һәм улы Борһанетдиннең, кызы Һава гаиләсенең фотографияләре куелган. 2000 елның 29 сентябрендә Әтнә районы Комыргуҗа авылында Ш.Мәрҗани музее ачылды, аны ТР Милли музееның иҗат төркеме (Ф.Зыязов, Р.Гарифҗанова, А.Хәйруллина, Ф.Дәминова) әзерләде. Әлеге музейга тәсбих, Мәрҗанинең хаҗга баргандагы савыт-сабасы; Габдулла Апанаев йортындагы җиһаз – шкаф, өстәл, урындыклар, комод куелды, аларны музейга мәгърифәтченең туруннары Н.Ильясова, С.Мостафина тапшырды. Музейны төзүгә әзерлек эшләре 1998 елда башланды, Нажия Ильясова белән Суфия Мостафина безгә һәрдаим киңәшләре белән ярдәм итеп торды. Әлеге кешеләр ярдәмендә Ш.Мәрҗанинең 40тан артык варисы табылды, алар атаклы бабалары исемен йөрткән мәчеттә очрашты.

**Флүрә ДӘМИНОВА,**
*ТР Милли музееның өлкән фәнни хезмәткәре*

# МӘРҖАНИ САБАКАЛАРЫ

## Кабыргасы белән

1825 еллар.

Шиһабетдин Мәрҗани сабый чактан ук бик зиһенле вә кызыксынучан була. Ул:

– Нигә, ни өчен? – кебек сораулар белән атасын да, бабасын да аптыратып бетерә торган була.

Кайвакыт атасы да, бабасы да Шиһабетдин куйган сорауларга җавап табалмый җөдәп бетәләр икән. Шул чакта Шиһабетдин:

– Җавап бирә алмагач, нигә мине бу дөньяга китердегез? – дип буза куптаргалый торган була.

Шуннан соң атасы белән бабасы киңәш итәләр дә, бездән алалмаган җавапларны Бохарада алырсың, дип, Шиһабетдин Мәрҗанине 1838 елда Бохарага укырга җибәрәләр.

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМ.**
*«Яшь ленинчы», 1988, 16 июль.*

## Кыйммәтле хатирә

Шиһаб Мәрҗани, Олугбәк китапханәсенә килеп, каравылчы булып урнаша. Шул вакытта бик күп китаплар укып чыга. Мәгълүмат туплый, белем җыя.

**Муса БӘДИГЫЙ** *сөйләгәннәрдән.*
*Ташкент, 1986.*

## Татарстан «герostратлары»

Шиһабетдин Мәрҗанинең ике тапкыр указын алалар. Дошманнар әләкләве буенча, аңа сәяси гаеп ташлана, ләкин икесендә дә Шиһабетдин хәзрәт җиңеп чыга, аның указын ике тапкыр кайтаралар. Алай да булмагач, Мәрҗани хәзрәтнең агач мәчетенә ут төртәләр. Мәдрәсәсе белән мәчет янып бетә. Мәрҗани хәзрәт яңа мәчет, яңа мәдрәсә салдыра. Анысына да ут төртәләр. Өченчесендә Мәрҗани хәзрәт таш мәчет вә мәдрәсә салдыра.

Мәрҗанинең бу мәчете әле һаман да Кабан күле буенда тора. Мөселманнар өчен үзенең изге эшен башкара, Аллага шөкер.

**Җәүдәт МИҢНУЛЛА** *сөйләгәннәрдән.*
*1987. 24 сентябрь.*

## Шәкерт остазын төзәтә

– Әйт әле, тәкъсир, башкортларга тарихи яктан ничек карарга? – дип сораганнар Шиһаб Мәрҗанидән.

Остаз әйткән:

– Башкорт кавеме төрекләргә нисбәт ителә.

Шәкертләре арасыннан үсеп, дан алган тарихчы Хөсәен Фәезханов остазына каршы төшә:

– Юк, остазым! – ди Фәезханов. – Башкорт кавеме төрек кавеме түгел, алар түркчә сөйләшә, тик түрк кавеме имәс, башкортларның фин кавеме булуында һичбер шөбһә юктыр. Киемнәре фин-угырныкы белән бер, удмурт, мари-чирмеш, керәшеннәр шулай бертөслерәк киенә.

**Әнвәр ХӘЙРИ** *сөйләгәннәрдән. 1983.*

## Курсави шәкерте

Мәрҗани остаз:

– Тарих, тел, йолалар белән кайчан кызыксына башладың? – дип сораганнарга болай җаваплаган:

– Мин беренче мәртәбә 20 яшемдә Курсави кулъязмасын кулыма алдым. Минем тарихи гыйлемем, фәлсәфи карашларымның шәкелләшүенә тәэсир итеп, ошбу китап миңа иҗтиһад ишекләрен ачты һәм бу ачыш мине «Хаканнарның танып белүләре турында уч төбе кадәр мәгълүмат» китабын язарга этәрде.

**Әнвәр ХӘЙРИ** *сөйләгәннәрдән. 1983.*

## Без – татар

Болгарчылар татарлыктан ваз кичкән чорларда атаклы галим Шиһаб Мәрҗани бу мәсьәләгә ачыклык кертә:

– Урыс халкының татарларны кимсетеп, хурлау рәвешендә «татар» дип әйтүләренә күрә, ул исемнән чиркanып, без «татар түгел», без – «мөселман», дип тавыш-җәнҗал чыгаручылар да бар. Ни кызганыч хәл, бу исемнәр («татар» белән «мөселман») арасында Нил белән Евфрат елгалары арасындагы ераклык кадәр аерма бар бит. И мескен татар! Татар булмасаң, гарәп, таҗик, нугай түгел, кытай, урыс, француз да, немец та түгел, инде кем булырсың? Яңгыравыклы мәшһүр «татар» исемен, «болагар»га алыштырып кына, сине мыскыл итүдән туктамаслар!

**Нәкый ИСӘНБӘТ** *авызыннан. 1965.*

## Дин белән фәлсәфә

Шиһаб Мәрҗани сүзе:

– Дин – фәлсәфәгә, фәлсәфә дингә каршы килми, чөнки алар икесе дә игезәкләр, бер үк хакыйкать чыганагыннан агып чыга һәм чынбарлык тормышта кулга-кул тотынышып баралар...

– Хәзрәт, гармун уйнау, җырлау-бию гөнаһмы?

– Һәрнәрсәнең үз урыны, үз вакыты бар. Музыка тыңлаудан зәүкый ләззәт алу – гөнаһ түгел. Яу барабаннарында уйнау, быргы-сорнай кычкырту, думбыра, саз чиертү ни өчен гөнаһ булсын? Азан әйтү ул – мәкам, моң – җыр түгелмени; көйләп Коръән уку ул – музыка түгелмени; тәкъбир әйтү ул – җыр сәнгате түгелмени?! Музыкада максат – төрле тавыш һәм көйләрне, бер-берсенә яраштырып, күркәм һәм матур итеп төзү аркылы җанга рәхәтлек бирү, кеше рухын сафлык һәм пакьлек дөньясына этәрү ул – музыка!

– Рәсем ясау гөнаһмы?

– Сурәт, сын, пот ясау Мөхәммәд пәйгамбәр салаллаһу галәйһи вә сәллам заманасында ярамаган эш саналган, хәзер потларга табыну бетте, без бер Аллаһка инанабыз! Шуңа күрә рәсем ясау рәссамнарга гөнаһлы гамәл түгел!

– Дустым! – диде Бакый ага, эшеннән аерылмыйча гына. Ул Мәрҗанинең гипс сынын кискеч-калагы белән кырып маташа иде. – Мәрҗани ул – безнең Геродотыбыз. Күп кешеләр миңа четерекле сорау бирә. Син үзең – мөселман, үзең – Коръәнне бик яхшы белүче кеше, үзең потлар, сыннар ясыйсың, Коръәндә язылган бит, сын-пот ясарга ярамый, ул – зур гөнаһ, рәсем ясаган кеше, үзе үлгәч, ул ясаган рәсемнәр: син безгә үзеңнең җаныңны ярып бир, дип артыннан куарлар, ди. – Бакый абый, калагын куеп, бераз уйланып утырды да әйтте: – Мин гомерем буе Мәрҗанинең рәсем ясаучылар турында әйткән сүзен тоттым. Коръәндә рәсем ясарга ярамый, дигән сүз юк. Хәдистә бар, ләкин аны Мөхәммәд пәйгамбәр салаллаһу галәйһи вә сәллам әйтә: минем рәсememне ясаган кеше гөнаһлы булыр, ди. Пәйгамбәребез бик тыйнак кеше булган. Ул үзенең рәсемен, сынын ясарга рөхсәт итмәгән. Мөселман Бабур солтан үзе дә рәссам булган. Атаклы рәссамнарны сараена туплаган, алардан бик күп рәсемнәр ясаткан. Алар калдырып киткән миниатюралар дөньяны шаккатыра.

**Бакый УРМАНЧЕ** *авызыннан, 1983.*

## Фикерле баш

Мәрҗани бер тәртәгә ике ат җигеп йөри торган булган. Юныс бай моңа әйтә:

– Губернатор кебек, син нигә сыңар тәртәгә ике ат тактың? Ә менә миңа ике тәртәгә бер ат та җиткән! – ди.

Мәрҗани җавапсыз калмый:

– Минем башны тартыр өчен, ике ат та аз әле, ә менә сиңа бер ат та күп, – дигән.

**Бакый УРМАНЧЕ** *авызыннан, 1986.*

## Ыңгырашу

Габдерәхим Утыз Имәни Бохарада укыган чагында бер мөәзиннең азан әйткәндә, «әс-салавате хәйре минән-нәүм», дип, соңгы «м» авазын төшереп калдырганы өчен:

– Ба мим гуй! «М» белән әйт! – дигән. Әлеге мөәзин хатасын төзәтмәкче булып:

– Әс-салавате хәйре минән-нәү ба мимгуй, – дип әйтә. Татарчага әйләндергәндә, эш болай килеп чыга: «Әс-салавате хәйре минән-нәүм», ягъни, «намаз йокыдан яхшырак дигән» сүзне «м» авазсыз «әс-салавате хәйре минән-нәү», дип укысаң, «намаз ыңгырашудан яхшырак», – дигән мәгънә килеп чыга.

«Ба мим гуй» «м» белән әйт, дип тә өстәгәч, ягъни әс-салавате хәйре минән-нәү ба мим, дигәч: «намаз «м» белән ыңгырашудан яхшырак», мәгънәсен ала. Дөресрәге, мәгънәсезлек килеп чыга. Чөнки әлеге бичара мөәзин халыкны болай чакырган булып чыга инде:

– Мөселманнар! Намазга торыгыз, намаз «м» белән ыңгырашудан да яхшырак!

**Шиһабетдин МӘРҖАНИ.**
*«Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар»дан. 1989.*

**Рабит БАТУЛЛА** *тупламасыннан*

# ГОМЕР БУЕ УКЫЙ УКЫТУЧЫ...



*Арча – «Әлифба»ның туган ягы, ә Арча педагогия көллияте – «Әлифба»ны балаларга җиткерүче, киләчәккә милли матбугатыбызның даими укучыларын әзерләүче. Шул уңайдан, Габдулла Тукай исемендәге Казан арты милли кадрлар әзерләү үзәге – Арча педагогия көллияте директоры* ***Гөлнара Фидаил кызы ГАРИПОВА*** *белән әңгәмә кордык.*

**– Мәктәпләрдә туган телне укыту мәсьәләсендә Мәскәү куйган чикләүләрдән соң, Сез җитәкләгән Г.Тукай исемендәге Казан арты милли кадрлар әзерләү үзәге – Арча педагогия көллиятендә вазгыять нинди, коллективның кәефе ничек?**

– 87 еллык бай тарихы булган Арча педагогия көллияте төрле чорларны кичергән. Коллектив өчен бик авыр сынау еллары да булган. Заманның сикәлтәле елларында да уку йортында туган телебезне, милли сәнгатьне, мәдәниятебезне, халык авыз иҗатын һәм халык педагогикасын өйрәтүгә зур игътибар бирелгән. Г.Тукай исемен горур йөртә торган Арча педагогия көллияте, бүген дә үз кыйбласына тугры калып, милли тәрбия һәм белем бирү юнәлешендә нәтиҗәле эшли. Илебез һәм республикабыз мәктәпләре өчен милли кадрлар әзерләүне дәвам иттерәбез.

Көллияттә белем һәм тәрбия бирү ике телдә алып барыла. Барлык төркемнәрдә дә татар теле дәресләре кертелгән. Хәтта рус егетләре һәм кызлары да татар телен бик теләп үзләштерә.

Рус һәм башка милләттән булган студентлар да, татарлар белән беррәттән, татар телендә үткәрелгән класстан тыш чараларда, төрле бәйгеләрдә, бәйрәмнәрдә дә актив катнашып, үзләренең сөйләм телләрен үстерүгә ирешә.

**– Соңгы вакытта Сез Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы делегациясе составында Россиянең берничә төбәгендә, шул исәптән Самара һәм Курган өлкәләрендә булып, алардагы милли мәгариф тармагындагы эш-гамәлләр белән танышып кайттыгыз. Шушы сәфәрләрдән алган тәэсирләрегез белән уртаклашсагыз иде. Аларда уку-укыту процессында милли-этник компонентның тоткан урынын ничек бәялисез?**

– Туган җирнең, туган телнең кадерен беләсең килсә, еракка китеп кара, диләр бит әле. Бу сүзләрнең дөреслегенә, чит төбәкләрдә йөргәндә, тагын бер кат инандым. Тарихи ватаныбыздан еракта яшәгән милләттәшләребез белән горурланып кайттым. Алар, тырышып-тырмашып, телебезне, милли гореф-гадәтләребезне саклау өчен көрәшә һәм яшь буынны шул рухта тәрбияли. Туган телдә аралашу мөмкинлеге чикләнгән булса да, татарча сөйләшәләр. Димәк, әти-әни, әби-бабайлар балалары белән үз телебездә аралаша. Татар теле, әдәбият дәресләрендә укытучылар телнең үзенчәлекләре, милли ядкарьләребез булган әдәби әсәрләр белән таныштыра, дәрестән тыш чараларда катнашып, укучылар милли гореф-гадәтләр, йолалар рухында тәрбияләнә. Укучыларның татар телендә бик матур итеп шигырь сөйләүләрен, җырлауларын күреп сөенеп кайттым.

**– 2018 елда фәлсәфәче, тарихчы, мәгърифәтче, дин эшлеклесе, якташыгыз Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тула. Бу юбилейны лаеклы каршылау максатында, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның**

**махсус Указы игълан ителде. Әлеге вакыйга уңаеннан, Сезнең уку йортында нинди чаралар үткәрү планлаштырыла?**

– Әйе, дөньякүләм билгеле галим, бөек шәхес Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулу уңаеннан, республикабызда бик күп чаралар планлаштырыла. Әлбәттә, без дә читтә калмаячакбыз. Әдәбият дәресләрендә, класс сәгатьләрендә Ш.Мәрҗани тормышы, иҗаты турында тулы мәгълүмат бирү, әдәби лекторийлар үткәрү планлаштырыла. Март азагында Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте базасында фәнни-гамәли конференция үткәрү Министрлар Кабинеты планына кертелгән.

**– Арча – халкыбызга мәшһүр язучылар белән бергә күренекле мәгърифәтчеләрне биргән район. Бу җәһәттән без Мәрҗани, Курсави, Күлтәсиләрне күздә тотабыз. Аларның бай мирасы бүген уку-укыту процессында ни дәрәҗәдә файдаланыла?**

– Арча туфрагы әдәбиятка, сәнгатькә бик күп шәхесләр үстереп биргән. Без күренекле якташларыбыз белән горурланабыз, аларның мирасын сакларга, киләчәк буыннарга җиткерергә тырышабыз. Районыбызда әлеге юнәлештә шактый күп эш башкарыла. Иң беренче эш итеп музейлар, мәктәпләрдә музей почмаклары оештырыла. Арчаның үзәгендә бик бай эчтәлекле әдәбият-сәнгать музее бар. Аның директоры Шәфигулла Гарипов, рухи мирасыбызны халыкка җиткерү максатында, кызыклы очрашулар, радиотапшырулар, экскурсияләр үткәрә. Безнең студентларыбыз да әлеге музей хезмәткәрләре белән тыгыз элемтәдә тора: конференцияләргә, төрле чараларга, дәресләргә әзерләнгәндә, диплом, курс эшләре, рефератлар язганда, музейдагы документларны өйрәнеп, үзләре өчен ачышлар ясыйлар.

**– Арча педагогия көллияте элек-электән, белем бирү белән бергә, иҗат мәктәбе дә булды. Бу мәктәп үзенең музыкантлары, җырчылары, рәссамнары, язучылары белән данлы. Элекке күркәм традицияләр бүген ничек дәвам иттерелә?**

– Үзенең 80 елдан артык эшчәнлеге дәверендә Арча педагогия көллияте илебез һәм республика мәктәпләре өчен 15 меңнән артык укытучы әзерләп чыгарды. Аларның күбесе – Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының атказанган укытучылары, Мәгариф отличниклары. Араларында танылган фән эшлеклеләре, мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләре, дәүләт җитәкчеләре: Татарстан Республикасы Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреатлары, халык язучылары Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, язучылар һәм шагыйрьләр Самат Шакир, Фәрваз Миңнуллин, Флёра Тарханова, Рифә Рахман, Сания Әхмәтҗанова, Алсу Гайфуллина, тәрҗемәче-мөхәррир Яхъя Халит, фән докторлары һәм профессорлар Валентин Беркутов, Мәрьям Хәсәнова, Дания Әхмәтова һәм ике дистәдән артык фән кандидатлары бар. Без алар белән горурланабыз һәм бүгенге студентларыбызны шулар мисалында тәрбиялибез. Аллага шөкер, хәзер дә сәләтле, өметле студентларыбыз күп. Көллияттә алган белемнәрен җилкән итеп, алар да тормыш диңгезендә үз юлларын табарлар, дип ышанабыз. Ә традицияләргә килгәндә, алар бүген дә дәвам иттерелә. Бездә бәйрәмнәр, фестивальләр һәм концертлар, күргәзмәләр, Татарстанның фән һәм мәдәният эшлеклеләре белән очрашулар еш була.

Күпьеллык эзләнүле хезмәт нәтиҗәсендә, көллияттә дәрестән тыш тәрбия бирүнең үз системасы формалашты. Киләчәк заман укытучысына тирән белемгә ия булу гына җитми: аннан иҗадилык, һәрьяклы үсеш таләп ителә. Укытучы, халыкча әйтсәк, 70 төрле һөнәргә ия булырга тиеш. Шуны истә тотып, 22 түгәрәк, 15 спорт секциясе эшләп килә. Телисең икән, бие, җырла, сәхнәдә уйна, иҗат серләренә төшен. Танылган музыка коллективлары – «Арча егетләре» һәм «Ләйсән» халык ансамбльләре, «Мирель», «Язгөл» вокаль ансамбльләре, халык уен кораллары оркестры, «Халык җәүһәрләре» фольклор берләшмәсе, «Талисман» бию төркеме, хор – көллиятебезнең визит карточкасы.

**– Безгә Сезнең Арча халык театры тарафыннан куелган спектакльләрдә уйнавыгыз да мәгълүм. Күңелегезнең бер почмагында артист булу хыялы бөреләнмәгән идеме?**

– Кечкенәдән үк артист булу хыялы бар иде. Шул хыялым, мәктәптә укыганда, драмтүгәрәккә алып килде. Үземә бирелгән рольләрне бик тырышып өйрәнә, образга

керергә тырышып уйный идем. Болар – балачак хыяллары, ә һөнәр сайлар вакыт җиткәч, укытучы булу теләге өстенлек алды. Арча халык театры режиссёры тәкъдим иткәч, үземне артист ролендә сынап карадым. Мин анда судья ролен башкардым. Бу – минем зур сәхнәдә беренче ролем. Минемчә, һәр укытучы – артист. Шулай түгел икән, укучыны җәлеп итеп булмый. Минем хыялым белән һөнәрем тәңгәл килгән дип уйлыйм.

**– Булачак укытучылар укытучысы тагын ни белән мавыгырга ярата, нинди эш-гамәлләргә сәләтле икән?..**

– Укытучы гомере буе укый. Бу – язылмаган закон. Мин дә, аз гына буш вакытым булса, дөньямны онытып, китап укырга утырам. Гомумән, әдәби әсәрләр укырга яратам. Хәзерге чор язучыларын да, классик әдипләрне дә укыйм. Гаиләдә татарча сөйләшәбез. Оныгымны да үз телен белгән, гореф-гадәтләребезне хөрмәт иткән чын кеше итеп тәрбиялисем килә. Һәр көнемне безнең өмет-хыялларны аклый торган дәвамчыбыз булсын иде, дигән теләк белән башлыйм.

Мавыгулар күп инде ул: төрле ризыклар пеширергә, бәйләргә яратам. Кызганыч, вакыт кына җитеп бетми.

*Әңгәмәдәш* – **Вакыйф НУРИЕВ.**

*Мөгаллим мөнбәре*

# ЯЗУЧЫ ДӘРЕС БИРӘ



Киләчәк укытучысы... Ул нинди булырга тиеш? Даими үзгәреп торган заманнан артта калмас өчен, аңа нишләргә? 85 елдан артык педагогик кадрлар әзерләүче, иң катлаулы елларда да үз максатына тугрылыклы булып кала алган Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте коллективы өчен бу сораулар һәрчак актуаль. Бигрәк тә, уку йортына яңа аяк баскан, үз кыйбласын әлегә анык аңлап та бетерә алмаган яшүсмерләргә һөнәри юнәлеш бирү өчен, уку йортыбыз барлык мөмкинлекләрдән дә файдалана: яңа мәгълүмати һәм коммуникатив технологияләрне, интернет ресурсларны файдалы һәм максатчан кулланырга өйрәтү; тематик класс сәгатьләре, төрле кичәләр үткәрү; музейларга, театрларга сәяхәт; гомерләрен укытучы һөнәренә багышлаган ветераннар, танылган каләм ияләре, сәнгать осталары белән очрашу һ.б. Көллият директоры Гөлнара Гарипова һәм коллективыбыз тырышлыгы белән бүген уку йортыбыз, заманнан артта калмыйча, үткән традицияләренә тугрылык саклап яши. Ягъни студентларыбызны заманнан – яңалык, тәҗрибәдән – акыл һәм белем, ә үткәннәрдән үрнәк һәм әхлак алып тәрбияләргә омтылабыз. Шул максаттан, төрле проектлар уйлап табыла. Шундыйларның берсе – «Язучы дәрес бирә» республикакүләм белем бирү проекты. Быел ул өченче тапкыр үткәрелде. Һәр елның көз айларында уза торган бу чара студентларыбыз тарафыннан яратып кабул ителә. Быел кайсы төркемдә кайсы язучы дәрес бирер, кайсысы ни белән шаккатырыр; нинди сорау яки биремнәр тәкъдим ителер дә, аларга кем тизрәк җавап биреп, язучыдан мактау сүзләре, бәлки, әле аның кулыннан китап алыр... Берәүнең дә килгән кунак, аннан да бигрәк, группадашлары алдында үзен белемсез итеп күрсәтәсе килми. Шуңа күрә киләсе кунаклар турында алдан мәгълүматлар барлана, әсәрләре укыла. Темасы гына да нинди бит: «Әдәбият – тел, мәдәният сакчысы».

Студентларга дәрес биргән кунакларыбыз – шагыйрьләр Мөхәммәт Мирза, Нәҗибә Сафина, Сания Әхмәтҗанова, Илсөяр Иксанова, Йолдыз Шәрәпова, Рифат

Сәлах, ТРның халык артисты Миңгол Галиев – һәрберсе әлеге темага үзенчә, иҗади якын килгән. Әйтик, 1977-1981 елларда үзе дә Арча педагогия көллиятендә белем алган шагыйрә Сания Әхмәтҗанова үз дәресендә туган телнең дәвасын, шифасын, сихәтен Марсель Галиевнең «Туган тел сихәте» поэмасы аша ачып бирде. Дәреснең һәр этабы энәсеннән җебенә кадәр уйланылган. Шагыйрәнең чын укытучы икәнлеге әллә кайдан күренеп тора. Шуны раслап: «Арча педучилищесы безне чын педагоглар итеп әзерләгән икән», – диде ул.

Гимназия сыйныфларында Йолдыз Шәрәпованың кемнең күпме татар язучысын белүе турында кечкенә генә ярыш игълан итүе, Мөхәммәт Мирза, Нәҗибә Сафина, Рифат Сәлахләрнең тел мәсьәләсен үз иҗатлары аша ачып бирүе, Миңгол Галиевнең музыка бүлеге студентларының тавышларын тикшерүе укучылар күңелендә бик озак сакланыр әле.

Гомумән, бу гади очрашу гына түгел, ә фикер алышу, дусларча аралашу, бүгенге тормышыбызга бәя бирү, проблемадан чыгу юлларын эзләү иде. Әйтерсең, тел мәсьәләсе белән бәйле соңгы вакыйгалар безне уятып җибәргән.

Кунакларның җидесе җиде төрле дәрес үткәрсә дә, нәтиҗә бер: милләтебезне кайгыртучы язучыларыбыз, әдәбиятыбыз булса, аларны яшь буын укыса, җырларыбыз, моңнарыбыз онытылмаса – телебез бетмәс. Шул ук фикер актлар залында язучылар белән үткәрелгән матбугат конференциясендә дә дәвам итте. Шыгрым тулы зал, укучылар тын калып шигырь тыңлый, әлеге тынлыкка Миңгол аганың яңгыравыклы тавышы килеп кушыла... Күңел төпкелләренә үтеп керерлек мондый рухи азыкны бары тик милли моңнар, милли әдәбият һәм шигъри сүз генә җиткерә ала. Рәт араларыннан кулдан-кулга «Казан утлары» журналы «йөри». Аны бүген көллиятебезнең якын дусты, журналның баш мөхәррире Илфак Ибраһимов (Мөхәммәт Мирза) бүләк итеп алып килгән. Ул үзенең мәһабәт тавышы белән шигырь укый, сүз арасында журналның матур әдәбиятны пропагандалауга керткән өлеше турында да берсеннән-берсе матур җөмләләр тезә. Студентлар үзләрен кызыксындырган сораулар бирә. Ә аларның ниндие генә юк (Телебезнең киләчәге нинди булыр? Язучы булып баеп буламы? Катнаш никахларга сез ничек карыйсыз? Әгәр сез язучы булмасагыз, кайсы һөнәрне сайлар идегез? һ.б.). Менә шундый гади, җанлы, җылы аралашу булды ул һәм бик күпләрнең күңеленә милли горурлык хисләре салды, милли рух уятты. Фатих Әмирхан сүзләре белән әйтсәк, «милли рух кертү, милли рухта тәрбия итү шәкерткә: «Менә син милли бул, үзең әнсат иткән милләтне сөй, аңа мәхәббәт ит», дию белән генә була торган бер нәрсә түгел». Безнеңчә, милли рух һәркемдә кызыксыну уятырлык, игътибарын җәлеп итәрлек әлегедәй чаралар аша барлыкка килә. Очрашу соңында язучылар республиканың һөнәри белем бирү оешмаларыннан җыелган бер төркем татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән үткәрелгән «түгәрәк өстәл»дә дә шундый нәтиҗәләр ясалды.

Студентларыбызда очрашу тәэсире тиз генә сүрелмәде әле, алдагы дәрестә дә, үтелгәннәр янә искә төшерелеп, кичәгә нәтиҗәләр ясалды. Бүләк ителгән китап-журналлардан кемнең нәрсә укуы билгеле булды. Өй эшенә язарга бирелгән мисалларның да күбесен шул китаплардан алуларын күреп сөендем. Аларны бергәләп укып, синоним һәм антонимнарның образ ясау үзенчәлеген тикшердек. Булачак педагогларның сөйләме башка һөнәр ияләренә караганда камилрәк булырга тиеш, чөнки алар – балалар күңеленә матурлык орлыклары салучылар. Бу максатта матур әдәбият әсәрләре – төп ярдәмче (без дәресләрдә ул турыда бик күп сөйләшәбез). Бөек әдибебез Гаяз Исхакый да үзенең «Мөгаллим әфәнделәр дикъкатенә» мәкаләсендә болай дип яза: «Әдәбият аркасында без балаларыбызның күңелләрен нечкәртәбез, балаларны уйларга, төшенергә, кеше хәлен, кеше кайгысын үз кайгысы иттереп уйланырга өйрәтәбез. Әдәбият аркасында балада тәнкыйть хисен үткерлибез, чарлыйбыз, әдәбият аркасында баланың күңелендәге матурлыкка маилне (тартылуын) куәтләндерәбез».

Мондый чаралар, һичшиксез, яшьләрне матур әдәбиятка, китапка якынайтуның бер юлы.

**Әлфия ТӨХФӘТУЛЛИНА,**
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г.Тукай исемендәге Арча педагогия көллиятенең*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*



*Өлкәннәр һәм яшьләр очрашуы. Сулдан уңга: Госман Садә, Зөлфәт, Роберт Миңнуллин, Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Ләбибә Ихсанова, Әхәт Гаффар, Разил Вәлиев, Шамил Маннапов. «Казан утлары» журналы редакциясе. 1973 ел.*



*Әлмәт төбәге язучыларыннан бер төркем. 90 нчы еллар.*



*1990 елның август ае. Азатлык мәйданы. Уртада – Мансур Вәлиев.*




*«Казан утлары» журналының
60 еллык юбилей бәйрәмендә.
Казан университетының
«Каз канаты» татар халык бию
ансамбле әгъзалары чыгыш ясый.
Г.Камал театры сәхнәсендә
«Зәңгәр шәл» биюе. 1982 ел.*



*Алмаз Хәмзин һәрвакыт үз стихиясендә. 2004 ел.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

# КАЙДА ДА ЙӨРӘКТӘ



*Шемкент, Төркестан, Кентау – Казакъстанның көньягындагы чик буе шәһәрләре. Бүгенге көндә бу төбәк дөньяга өр-яңа салынган Ефәк юлы белән танылса, төрки телле халыклар өчен ул – бөек Әхмәт Хуҗа Ясәвинең ватаны, йөзләрчә еллар дан-шөһрәт тоткан Төркестан дәүләте буларак билгеле...*

*Сентябрь аенда Төркестан каласында төрки телле әдәби журналлар баш мөхәррирләренең чираттагы VIII конгрессы үткәрелде. Әлеге халыкара форумның программасы бик тыгыз булуга карамастан, без биредә яшәүче милләттәшләребезне дә барлап, аларның хәлләре белән танышырга теләдек. Дүрт көнлек чаралардан соң, Шемкент-Астана-Мәскәү-Казан маршруты белән 22 сәгатьлек озын сәфәребезгә чыгарга 7 сәгать вакыт калып барганда, телефоннан биредәге «Татар-Башкорт» милли оешмасының Кентау шәһәрендәге җитәкчесе **Фәрит ӘЮПОВ** белән сөйләшә алдык. Бер сәгать дигәндә, ул Төркестанга, без урнашкан кунакханәгә килеп тә җитте. Безнең – Ләбиб Лерон, Фидаил Мәҗитов һәм мин фәкыйрегезнең язучылар икәнне белгәч, шунда ук телефоннан Кентауга шалтыратып: «Казаннан килгән язучылар белән очрашабыз. Бер сәгатьтән җыелып көтеп торыгыз», – дип эндәште. Юлга җыенуыбызны күреп, бер минутка да соңартмыйм дип, машинасына утыртып,утыз чакрымдагы Кентауга алып та китте. Кентауга кадәрге ярты сәгатьлек юлыбыз, мул табын артында 2-3 сәгать аралашып, җырлашып утыруыбыз, кабаттан Төркестанга кайтып, Шемкент аэропортына кадәрге юлыбыз, Кытай чигендә яшәүче өч меңнән артык милләттәшебезнең тормыш-яшәешен шактый якыннан аңларга, аларны Татарстан, татар дөньясы, милли әдәбиятыбыз, мәдәниятебез белән таныштырырга мөмкинлек бирде.*

*Танышу, очрашу, аралашу мизгелләрен, Фәрит әфәндегә юл буенча биргән сорауларыбыз, аның җаваплары белән хәтердә яңартып, сезгә дә җиткерергә булдык.*

**– Фәрит әфәнде, Сезнең телефоныгызны Казакъстандагы милли-мәдәни мохтәрият җитәкчесе Тәүфыйк Кәримовтан алдык. Ул – үзе дә язучы кеше... Татарча укымаса да, татар телендә бик камил сөйләшә. Сезнең дә әдәби телебездә аралашуыгыз бик күркәм. Ана телебезне ничек шул дәрәҗәдә өйрәнә алдыгыз? Безнең белән очрашуга килгән абый-апалар да үз ана телләрендә иркен аралашты. Алар бик зыялы күренде. Шул хакта сөйләгез әле?**

– Әтием – Башкортстанның Гафури, әнием – Бишбүләк районыннан. Икесе дә – татар. Сугыштан соң Казакъстанга күченеп китәләр. Аларга әнинең ике апасы һәм энесе дә иярә. Өчесе дә шушында төпләнеп гаилә кора. Татар гаиләләре. Хатыным Галия дә – үзебезнең милләт кызы. Төркестаннан. Без – туганнар, бер-беребез белән фәкать

татар телендә генә сөйләшәбез, милли гореф-гадәтләребезне саклыйбыз. Балалар да татарча аралаша. Гомумән, бездәге татарлар туган телебезне, мәдәниятебезне сакларга тырыша.

**– Кентау – меңьеллык тарихы булган Ташкент, Төркестан калалары янында бик яшь шәһәр. Аның төзелүе биредә бакыр, кургаш ятмалары табылу, хәрби заводлар төзелүгә бәйлеме? Сез сөйләгәнчә, Бөек Ватан сугышында безнең армия өчен һәр тугыз патронның берсе монда эшләнгән бит... Биредәге милләттәшләрнең тамырлары кайдан? Бүгенге милләттәшләребезнең тормышы, яшәеше ничек? Эшлеме, ашлымы алар? Гаилә йолалары, миллилек ничек саклана?**

– Әйе, Бөек Ватан сугышында атылган һәр тугыз пуляның берсе бездәге Ачисай полиметалл комбинатында эшләнгән. Предприятие эшчеләре арасында татарлар да күп. Элгәрләребезнең тамырлары Татарстаннан, Башкортстаннан, Оренбург өлкәсеннән һәм Россиянең башка төбәкләреннән. Соңгы чорда милләттәшләребезнең тарихи ватанга күченеп китүләре күзәтелә. Ата-бабаларыбызның туган җире тарта, күрәсең. Эшләгән кешегә эше дә, ашы да бар анысы. Телебезне, милли традицияләрне сакларга, бер-беребез белән аралашып, бердәм булып яшәргә татар-башкорт этно-мәдәни үзәге ярдәм итә. Бәйрәмнәрдә, туган көннәрдә без бергә. Хәл итәсе мәсьәләләрне уртага салып сөйләшәбез, җырлыйбыз, биибез, күңел ачабыз. Ел саен Сабантуй үткәрәбез, күркәм традицияләребезне яшьләр арасында пропагандалыйбыз. Форсаттан файдаланып, шушы үзәкнең җитәкчесе буларак, миңа һәрдаим ярдәм итеп торган татарларга һәм башкортларга ихластан рәхмәт әйтәм!

**– Үзегезнең тамырларыгыз Башкортстанның Авыргазы-Толбазы якларыннан икән – Галимҗан Ибраһимов төбәгеннән. Томскида укыгансыз, югары белемле энергетик... Танылган спорт мастеры... Каратэ көрәше буенча Казакъстандагы җәмгыятьнең президенты... Кентауда бу спорт төре буенча мәктәп җитәкчесе... Сезнең шәкертләрегез халыкара ярышларда җиңү яулый... Күп милләтләр белән очрашасыз... Милләтпәрвәр булуыгыз нидән килә? Бу сыйфатларны яшьләрдә ничек тәрбияләргә икән? Сезнең мәктәптә яшь милләттәшләребез дә бардыр, шәт?**

– Мин – Октябрь революциясе һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнарына ия булган Киров исемендәге Томск политехник университетын тәмамлап, инженер-электрик булдым һәм тугыз ел эшләдем. Физкультура һәм спорт өлкәсендә дә югары белем алдым. Бүген – Балалар югары спорт мәктәбе директоры, Казакъстан Каратэ-до Шотокан милли федерациясе директоры, Казакъстан Республикасының мактаулы спорт хезмәткәре, спорт остасы, кара билбау иясе. Шәкертләрем арасында дөнья чемпионнары да, дөнья беренчелегенә үткәрелгән ярышларда призлы урыннарны алучылар да бар. Татар егетләренең көчле, гаярь, кыю булып үсүен телим. Милләтпәрвәрлегем халкымны яратудан, тарихи шәхесләребезнең, әби-бабаларыбызның истәлегенә хөрмәт белән караудандыр.

**– Инде ишеткәнебезчә, Сезнең оешма мәдәни-агарту чараларына күбрәк игътибар бирә. Фольклор-җыр ансамбле дә оештыргансыз... Шәһәркүләм чараларда катнашкансыз икән. Балаларыбызны ана телендә укыту ничегрәк тора? Әлбәттә, махсус мәктәпләр, ана телендә укыту сәгатьләре турында сүз алып барып булмыйдыр. Әллә, бик тырышканда, анысына ирешү дә мөмкинме? Әйтик, мәчетләр каршындагы заман мәдрәсәләрендә?..**

– Кентауда 2000 елдан татар-башкорт этно-мәдәни үзәге эшләп килә. Татар телендә нәшер ителгән байтак китап, журналлар, аудио-видео материаллар тупладык. Аларны һәркем файдалана ала. Мәктәпләрдә – казакъ һәм рус, мәдрәсәләрдә казакъ, гарәп телләре өйрәтелә.

**– Төркестан – төрки халыкларның рухи башкаласы. Бу Казакъстанның Илбашы Нурсолтан Назарбаев тарафыннан шулай билгеләнгән. Шәһәрдәге Әхмәт Хуҗа университетында очрашу вакытында, биредә татар яшьләре дә белем ала, дип ишеттем. Сез алар белән элемтәдәме? Сезнең милли оешма яшьләрне Казанга, Татарстандагы уку йортларына укырга җибәрүдә катнашамы? Әйтик, бездә Кытай, Кыргызстан, Төркиядән укучылар бар...**

– Төркестандагы югары уку йортларында Татарстаннан һәм Башкортстаннан килгән студентларны да очратырга мөмкин. Аларның күбесе табиб булырга укый. Күптән түгел Кентауга концерт белән Татарстаннан җырчы Флүрә Талипова килгән иде. Аның да улы Төркестанда, университетта белем ала икән. Без Флүрә ханымга аның улы аша чыктык. Ватандашларыбызны Татарстан вузларында укытуны күздә тоткан махсус программа бар. Кызларым Динара белән Эльмира шушы программа ярдәмендә Идел буе (Казан) федераль университетында белем алдылар. Хәзер Казанда яшиләр һәм эшлиләр.

**– Казан – Россиянең спорт башкаласы да. Сезнең спорт мәктәбенең Казакъстанда абруе бик зур. Татарстандагы спорт мәктәпләре белән аралашу, хезмәттәшлек итү турында уйлаганыгыз юкмы? Әйтик, милли спорт төрләре, көнчыгыш спорт төрләре, билбау көрәше һ.б., һ.б.**

– Татарстан, шул исәптән, Казан Россиядә спорт өлкәсендә лидерлардан санала. Сездә дөньякүләм ярышларның үткәрелүен беләбез. 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионаты Казанда да узачак. Болар Казанның бөтен Җир шарына танылуы түгелмени?! Хәлбуки, без дә Казандагы спорт мәктәпләре белән бик теләп хезмәттәшлек итәр идек. Кем белә, бәлки, журналыгызда басылып чыгачак шушы әңгәмә безгә юл ачар...

**– Кабаттан Сезнең шәхси тормышыгызга кайтыйк әле. Сезгә – 57 яшь. Иң күбе – 43-45 яшь бирерлек... Мондый саулык, әлбәттә, дөрес яшәү үрнәге алып барудандыр... Глобаль дөньяның тискәре «казанышлары», ни әйтсәң дә, милләтеңә карап тормый. Сез – дөнья күргән, күпне белүче шәхес... Милләтебезгә хас кайсы күркәм сыйфатларны күз карасыдай сакларга кирәк? Нинди сыйфатлардан арыну лазем безгә? Киләчәктә милләтебезнең кешелек дөньясындагы билгеле яклары, билгеле урыны булырмы? Милләттәшләргә, Татарстанда яшәүчеләргә нинди яңа ел теләкләре җиткерәсез?**

– Иң мөһиме – намус кушканча яшәргә, сәламәтлегеңне кайгыртып торырга. Көнчелек, комсызлык, саранлык кебек тискәре сыйфатлардан арынырга. Татар халкының кешелек дөньясында үз урыны бар һәм булачак. Үткәнебез гасырларны колачлый. Дөнья тарихында биниһая зур мәдәни мирасы булган халык без. Яңа елда милләттәшләремә саулык, иминлек, сәгадәтле гомер, барлык теләкләрнең тормышка ашуын, Татарстаныбызның чәчәк атуын телим!

*Әңгәмәдәш* – **Илфак ИБРАҺИМОВ.**

# КИТМӘ, САНДУГАЧ!..



2013 елның җәендә, әле «Чын мирас» журналында эшләгәндә, редакциябезгә бер абзый килеп керде. Үзен, Энциклопедия институты галиме, икътисад фәннәре кандидаты Марс Гаитов, дип таныштырды. «Казанның Хөсәен Мәүлетов урамындагы 13 нче китапханәсендә Гөлшат Зәйнашева музее бар. Ул 2006 елда ачылган иде. Биредә шагыйрә язмышы һәм иҗатына багышланган бик күп кызыклы документлар саклана. Мин Гөлшат апаның туганы булам: аның әтисе Хисам әбием Фәрхисрур белән бертуган. Гөлшат Зәйнашева турында җентекле мәкалә әзерлисем килә. Бастырып булыр микән?!» – диде ул. Без шатланып риза булдык. Бер-ике атнадан шагыйрәнең бар фаҗигасен, казаныш-уңышларын ачкан мәкалә әзер һәм минем өстәлдә иде инде. Ул 2013 елның ноябрь санында «Яралы язмышлы шагыйрә» исеме астында басылып чыкты.

Үзе турында тулы мәгълүмат туплаган автобиографик альбом төзүне дә, кемнәрдәндер, биш елдан биш елга килә торган чираттагы юбилейлары уңаеннан, мәкалә язуларны оештыруны да хупламаган Гөлшат Зәйнашеваның тулы биографиясе белән мин әлеге фәнни-популяр, документаль язма аша таныштым.

Шулай да Гөлшат Зәйнашева шәхесенә бәйле кызыксынуларым күпкә алданрак башланган иде. Педагогика университетында укыганда һәм эшләгәндә, «Илһам» әдәби иҗат берләшмәсенә җитәкчелек иттем. Шунда үзебезнең уку йортын тәмамлаган язучы-шагыйрьләрне утырышларга чакыруны матур бер традициягә әйләндердек. Илдар Юзеев, Ренат Харис, Лена Шагыйрьҗан, Мәдинә Маликова, Зиннур Хөснияр белән очрашуларда булган кызыклы вакыйгалар аеруча да хәтергә уелган. Чаллыда инде өеннән чыга алмаучы, олыгайган Энҗе апа Мөэминова белән телефоннан алып барылган онлайн очрашу-трансляция дә – күңелдә якты истәлек.

Әлеге очрашу чараларына әзерләнгәндә, һәрвакыт остазым Фоат абый Галимуллин белән киңәшләшә идем. Ул мине сабыр гына тыңлый да, үзе кебек олпат, минем өчен аерым бер сихрилеккә ия, күп серләр саклаучы өстәле тартмасыннан альманахлар тартып чыгара. (Шәкертлек елларында гел шулай бит ул: профессорның портфелендә ниләр бар икән; кабинетына кереп, өстәл тартмаларын бер «тентеп» чыгасы иде, дигән хыяллар ниндидер татлы, хулиганый ләззәт бирә!) Кулдан эшләнгәннәр... Тәмләп төпләнгәннәр... Тышлыгына «Яшьлек тавышы» дип язылган. «Син кемнәрнең юлын дәвам иткәнеңне беләсең инде. «Илһам» берләшмәсенең тарихы нинди бай. Галимә Мәдинә апаң Җәләлиева җитәкли иде аны элек. Бу альманахларда Марс Шабай, Хисам Камалов, Энҗе Мөэминова, Илдар Юзеев, Гөлшат Зәйнашева һәм башка бик күпләрнең тәүге – өйрәнчек әсәрләре басылган. Мә, алып карап чык. Бар сорауларыңа шуннан җавап табарсың», – диде Фоат абый. Чыннан да, альманахлар хәзинә иде минем өчен. Элгәрләребезнең юлын дәвам итеп, дәртләнеп, без дә «Яшьлек тавышы»н чыгара башладык. Ул газета буларак дөнья күреп, Казанның педагогика университеты галәмнән гаип булу язмышына дучар ителгәнче шактый еллар басылып килде. Илдар абый, Гөлшат апалар эше дәвам иттерелде...

Ни кызганыч, Гөлшат Зәйнашева белән очрашуга чират җитми калды... Ләкин

мин аның тәүге шигъри тәҗрибәләре хакында да, ни өчен Тукай стипендиясе алып укучы студентның безнең уку йортыннан куылуын да, кире кайтарылып, укып бетерү тарихын да, фаҗигале язмышлы шагыйрә булуы турында да мәгълүмат туплаган идем.

*Тыңлыйсызмы, мин сөйлимен*
*Үткән гомерем турында.*
*Үткәннәрем – бер җыр, бәет,*
*Барысы чагыла җырымда.*

*Барысы, җырларга әверелеп,*
*Сибелеп калган эзләремдә.*
*Җырларыма сыеп бетми,*
*Моңы калган күзләремдә,*

– дип яза ул «Үзем турында» шигырендә. Әлеге юлларга шагыйрәнең балачак елларында, үсмерлек һәм студентлык чорларында күргән бар авырлыгы тулган. Җыр язуның, моң-аһәңне иң нәзек, тирән катламнарында аңлауның асылы да шул строфаларда ачыла.

Фикердәшен шагыйрә Лена Шагыйрьҗан заманында: «Җырлар дәүләтенең башлыгы», – дип атаган иде. Шул дәүләт белән ничек идарә итүе турында сөйләшик әле. Ярдәм рәвешендә, Гөлшат Зәйнашеваның ахирәте Нәсимә Әхмәтҗанова язган истәлекләр игътибарга лаек. Бүген, татар совет җыр сәнгате үсешенә зур өлеш кертеп, сан ягыннан да, сыйфат мәсләгеннән дә алыштыргысыз роль уйнаган Әхмәт Ерикәй, Мостафа Ногман, Илдар Юзеев, Фәнис Яруллин, Гөлшат Зәйнашевалар буыны китеп баргач, матур әдәбиятка катнашы булмаганнар тарафыннан заман шаукымына иммунитеты бик тә зәгыйфь җыр текстлары язылганда, әлеге фикерләр аеруча да әһәмиятле.

«Гөлшат җыр язып йокларга ятты, җыр белән йокыдан уянды. Аларда кунарга калган төннәрдә кәгазь кыштырдаган тавышка уянып китәм дә гаҗәеп бер хәлгә шаһит булам. Кичтән язган шигырь битен бөтәрләп ыргыта да, үҗәтләнеп, яңа вариантын яза башлый. Очына чыкмыйча йокларга ятмый. Катлаулы, югары стильдә дә язмый үзе, гап-гади сүзләр белән гап-гади уйларын сынландыра. Менә шул сәләте аны җыр остасы итеп үстерде дә инде. Җыр аның стихиясе булды, бөтен иҗатын, бөтен вөҗүден биләде. ...Һәр шигырендә «җыр» дигән могҗизага мәдхия яңгырый. Яшәешебезнең төрледән-төрле күренешләре җыр образы белән өртелгән. Табигатьнең һәр бизәгендә җыр күргән, кешенең һәр гамәлендә җыр ишеткән Гөлшат. Гомере буе җыр колы булып, яктылыкка, биеклеккә омтылып яшәгән. «Менәргә иде Урал тауларына» дигән җырында шагыйрәнең бу омтылышы бөтен мәгънәсе белән ачыла» *(Әхмәтҗанова Н. Сайрар кошы идең халкыңның // Гөлшат Зәйнашева: истәлекләр, мәкаләләр / [төз.: Ә.Хөсәенов, Р.Шакирова]. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. – Б.26)*, – дип яза ул.

*Менәргә иде Урал тауларына,*
*Басарга иде кыя ташына.*
*Шул кыядан кушылып җырларга иде*
*Урал бөркетләре таушына.*

Чыннан да, Мансур Мозаффаров тарафыннан киң диапазонлы көйгә салынган, халык беренче яңгыраштан ук үз иткән, Илһам Шакировны зур артист буларак бар татар дөньясына таныткан әлеге җыр шактый бәхәсләр уята. Шул уңайдан, Ләбибә Ихсанова болай дип белдерә: «Бер төркем яшь язучылар әдәбиятка килгән 50нче еллар шигърияттә лириканың читкә кагылган еллары булды. Кешенең рухи дөньясына, эчке кичерешләренә, уй-хисләренә урын аз бирелде. Җырчы шагыйрьләрне «күбрәк мәхәббәт җырлары язасыз», дип шелтәләделәр...

Ә Сибгат Хәким Гөлшатны Язучылар берлегенә тәкъдим иткән рекомендациясендә: «Зәйнашева җырларының халыкка ничек хезмәт итүен белү өчен, берәр атна авылларда булу да җитә. Авылларга чыга алмасаң, радиога колак салу да җитә», – дип язды»

*(Ихсанова Л. «Җырны тиккә җырламыйлар...» // Гөлшат Зәйнашева: истәлекләр, мәкаләләр / [төз.: Ә.Хөсәенов, Р.Шакирова]. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. – Б.45)*.

Әйе, авыл кешесенә, гомумән, безнең татар халкына лирик нечкәлек бервакытта да ят булмады. Халык җәүһәрләре мисалында тәрбияләнгән биниһая күп профессиональ композиторлар, бу үзенчәлекне тирәнтен аңлап, Гөлшат Зәйнашеваның күңел лирикасы төренә кергән җыр текстларын бик теләп, ярыша-ярыша көйгә салдылар. Аеруча да туган якка, аның табигатенә мәхәббәт хисе белән өртелгән ихлас поэзия җәлеп итте аларны. Шагыйрә дә, үз чиратында, туган як образын типиклаштыра белде. Идел буйлары да, Урал таулары да, Кукмара юллары һәм Ык агышлары да, Керкәле таулары һәм туган Минзәләсе дә, гомере узган Казаны, Казансу буйлары да, Яңа Әтнәсе, әле тагын халкыбыз гомер кичергән бик күп төбәкләр – һәммәсе аның туган ягына әверелгән иде. Бу күзәтүчәнлек, кендек каны таммаган, бала чагы гөрләп узмаган җирләрнең дә сихри гәүһәрләрен табу Гөлшат Зәйнашеваның гомере буе сөйгән халкы арасында туктаусыз очрашуларда йөрүдән киләдер.

*Юлда йөрсәм, никтер күңелем*
*Яктыра матур уйлардан.*
*Нинди серләр бардыр офыкта, –*
*Чакыра әллә кайлардан.*

*Юлга чыксам, җырлап барам,*
*Моң уяна йөрәкләрдә...*

(«Бәхет юллары». Луиза Батыр-Болгари көе)

«Бәхет юллары» җыры тексты – шуның мисалы. Гомумән, юл, туган якка кайту юлы, урман юлы, су юлы һ.б. юллар белән бәйле символлар шагыйрә иҗатында әһәмиятле урын били.

Туган як төшенчәсенә тоташкан тагын бер калып – тау символы. Инде алдарак Урал тауларын телгә алган идек. Кукмараның тауларын да бер «ярсытып» тетрәндерә шагыйрә:

*Ярсып поездлар узганда,*
*Тетрәп кала таулары...*
*Эх, Кукмара, Кукмара!*
*Ерагаймасын ара...*

(«Кукмара». Мәсгуд Имашев көе)

«Сәяхәтче җыры» (Зиннур Гыйбадуллин көе) да таусыз язылмый *(«Таныш түгел юллар буйлап / Мин озак йөрдем. / Туган ягым күрнерме дип, / Тауларга мендем»)*, Керкәленең исә таулары биек (Илгиз Закиров көе; *«Керкәле таулары биек, / Биек булса да меник...»)*, «Туган ягымда» (Илгиз Закиров көе) җырында да бер тау бар *(«Туган ягымда бер тау бар, / Түбәсе күккә тигән...)*. Һаман үсештә булу, биеклеккә менеп, туган як гүзәллеген күзәтү әнә шулай гәүдәләндерелә. «...бу шагыйрә – татар сәнгате, мәдәнияте белән шигърияттне тоташтыручы рухи бер ялганыш ул: каядыр югарыда, сәхнәдә йә күңелләр мөнбәрендә мөлаем итеп сөйли, җырлый, каядыр чакыра кебек», – дип яза аның таланты турында Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ *(Гаташ Р. Моңнар бәйрәме // Казан утлары. – 1998. – №1. – Б.115)*.

Шунысы бар: һәр ике очракта – юллар-илләр гизгәндә дә, текә тауларга менгәндә дә, лирик герой төп образ булып кала, аның янәшәсендәге кошлар, урман-күлләр, поезд-машиналар, хәтта сөйгән яры икенчел планда сурәтләнә – төп басым лирик геройның психологиясен, хис-кичереш-халәтен әлеге ярдәмчел образ-символлар аша сюжетчыл җыр текстына салу кыйммәтенә ирешүгә ясала.

«Радио, телевидение, концертларда аның сүзләренә язылган җырлар бик еш яңгырый иде, алар халыкның мәхәббәтен тиз яулады. Чөнки күренекле композиторлар иҗат иткән моңлы көйләр, Гөлшат апа язган тирән фикерле сүзләр халыкчан, аңлаешлы, җырчылар да аларны бик теләп, яратып, оста башкаралар, тыңлаучының күңел

кылларын тибрәндереп, җырга гашыйк итәләр. Ул җырларда чын мәхәббәт, дуслык, туган илгә тугрылык, аны ярату хисләре яңгырый, алар тыңлаучыны уйландыра, моңландыра, дәртләндерә, яшәргә көч бирә» *(Гаитов М. Җырга багышланган гомер // Казан утлары. – 2008. – №1. – Б.119-128)*, – дип яза галим Марс Гаитов.

Урманнарга керик... Гөлшат Зәйнашеваның урман образы – үзе бер стихия. Анда адашыплар бетәсең, үзеңчә сагышланып моңаясың.

*Урманнарда йөрдем*
*Иркен сулап,*
*Бигрәк хуш исле нарат ылысы.*

*Урманнарда йөрдем*
*Җәйге таңда,*
*Басылмасмы дип сагыш күңелдә.*

*Урманнарда йөрдем*
*Бер ялгызым,*
*Баласын җуйган болан эзеннән.*

Өч строфа. Һәммәсе үзенчә яңгыраш ала. Бездә сорау уяткан вак кына вакыйгаларны бер сихрилек белән тезә ул. Нидер булган, нәрсә бар, дип сискәнеп китәсең... Әмма тәҗрибәле җырчы шагыйрә һәммәсенә җавап таба:

*Йөрәк ярасын да*
*Төзәтәдер*
*Күз карашкайларыңның җылысы.*

*Төннәрне яктырткан*
*Ай шикелле*
*Булсаң иде язмышым күгендә.*

*Башларым әйләнеп*
*Китте кинәт*
*«Башканы сөям», дигән сүзеңнән.*

Күрәбез: строфалар ике блокка бүленә. Беренчесендә шәхси хисләр мәнфәгатенә һичнинди ишарә юк та кебек, шулай да соклануның ни өчендер сагышка әйләнүен тоябыз. Ә икенче блок инде беренчесендә әйтелгәннәргә «мин монда», дип җавап кычкыра. Соклану, ярату, өмет хисләрен соңгы юлда үкенү хисе чәлпәрәмә китерә. Шул рәвешле, хисләр дөньясы һәм аларның сәбәпләре ачыла. Йөрәкнең, күңелнең кискен дулкыны ташыганда бәреп чыккан эмоция, милли моң-хис үстерелеше сәнгати позициягә баса. Җыр сәнгатенең сыйфат билгесе – барометры Гөлшат Зәйнашева моны яхшы тоя.

Урман безнең татар халкы өчен аеруча да якын бит. Ул мичкә ягарга утын әзерләү, себерке сындыру, җиләк-җимеш җыю урыны гына түгел. Динебезне мәсхәрәләгән елларда халкыбыз, төпләп-тамырлап, аның иң караңгы төпкелләрендә милләтне бүгенгегә китереп җиткерәчәк татар авылларын корган.

*Кердем карурманнарга,*
*Калдым караңгыларга.*
*Газиз башлар сау булганда,*
*Нигә ямансуларга?*

Халык көенә язылган әлеге җыр шул хакта уйланырга этәрә.

Урман образының лирик-җиңел бер мисалы «Урман юлында» (Илгиз Мәҗитов көе) җырында ачыла:

*Борылдык урман юлыннан,*
*Атладым синең эздән.*
*Җир җиләгенә чык түгел,*
*Яшь тамды минем күздән.*

Шәхсиянә-эротик хәл кичереп укыганда-тыңлаганда, строфаның соңгы ике юлы фани дөньяның реаль чынбарлыгын бәреп төшерә: җир җиләгенә кыз күзеннән яшь тама. Ни өчен? Ә мондый табышларны Гөлшат апа җырларыннан көшелләп табып була: кайнар чишмә; кояш нуры сипкән, эчендә йолдызы булган җырлар; җиләк аралап йөрүче сандугачлар; гөл үбүче кояш; моң булып түгелүче яшь парлар – саный китсәң, шактый җыела.

Барча кыйммәтләрен туплагач, нәрсәдә соң Гөлшат Зәйнашева җырларының гомерле язмышы, диярсез. Әлбәттә, сюжетта. Ул беркайчан да беренче юлларда ук күңелен ачып ташламый – зәвык саклый. Хәзер бит җырларның бик күбесе «шәп-шәрә күңел» рухында башлана һәм төгәлләнә. Алар буенча озакламый биология укытучылары физиология-анатомия укытачак: йөрәк, бавыр, үпкә кайда һ.б. Гөлшат Зәйнашевада иң беренчел – сюжет. Вакыйганы, аның буласы урынын, геройларын ике юлга сыйдыра да бетерә, калган хиссилекне шуларга бәйле ача. Бала чакта җырлаган бер җырны гына искә төшерәм:

*Бер кыз бала җыр чыгарган*
*Багышлап әнисенә.*
*Икәү бергә җырлыйк, диеп,*
*Өйрәткән энесенә.*

«Җыр чыгару», «багышлау», «бергә җырлау», «өйрәтү» фигыль сүзләр – һәммәсе сюжетчыл вакыйгалылыкка этәрә. Һәм бу калган һәр строфада да шулай.

Йөрәк сөенә! Гөлшат апаның чыннан да җыр сандугачы икәнлеген гыйльми дәлилләүче кеше булды – иҗатын диссертация дәрәҗәсендә фәнни әйләнешкә керткән галимә Дания Сибгатуллина-Нигъмәтҗанова хезмәте мәртәбәле һәм мактауга лаек.

Халкыбыз арасыннан артист-җырчылар белән бергә кайтып кермәгән җор, шаян Гөлшат Зәйнашеваның ихлас күңел халәтен тоябыз – чын юмор остасы. Сәхнәләр тоткан алып баручы.

*Ялкау син, дип, кимсетәләр –*
*Үләрсең ачуыңнан.*
*Җәй буена карга кудым*
*Кукуруз басуыннан.*

Шундый шаян шагыйрәнең вафаты 1 апрельгә – көлке көненә туры килү безне тетрәндерүе...

Хәзер кем соң сандугач?!

Сандугач... Сандугач! Нинди кош соң син, Гөлшат Зәйнашева сандугачы?

*Сандугач, сандугач,*
*Китмә, китмә, сандугач!..*
*Курыкма син кышлардан,*
*Кал син башка кошлардан,*
*Саклармын салкын җилдән,*
*Китмә син туган илдән.*

Миллилегебезне, халкыбызның ачы язмышын, моңыбызны ачкан кош син – Гөлшат Зәйнашева һәм... синең сандугачың! Янә шундый сандугачларны үстерсәк иде!

**Рамил ХАННАНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты*

# КЕЧКЕНӘ ӘЗИ – ЗУР АБЫЕМ

Шамил абый, аның иҗаты һәм тормышы турында беренче тапкыр язарга керешү миңа кыен да, рәхәт тә. Бер яктан караганда, без «бергә» үстек: ул минем киләчәк язмышымны хәл иткән олы туганым булса, икенче яктан, мин аның күләгәсенә сыенып, җылы канаты астында яшәмәдем. Гәрчә, Мөхәммәт абый Мәһдиевне әдип итеп таныткан беренче повесть-бәяннарын бабасы (хатыны Лилия апаның этисе – олуг әдип Гомәр Бәширов) «язып биргән» кебек, ул да миңа тәүге каләм тибрәтүләремне «язып биргән» дип санаганнардыр. Университетта үземнән өлкәнрәк сыек буынлы кайбер сабакташларымның «син абыеңа ышанма, таянма, ул печән кибәне (йомшартыбрак әйттем) күләгәсе генә» кебегрәк сүзләре күңелне җәрәхәтләсә дә, күпмедер дәрәҗәдә мин аның юлыннан барганмын. Чөнки безнең илһам чишмәбез бер: икебезгә тиң кадерле шигъри җанлы Әниебез – Дәү әнием. Шуңа күрә Маннапов тамырлы булып тууым, Шамил абыйның пеләмәше икәнлегем белән горурланам. Ике Туфанның – Хәсән аганың һәм Туфан абый Миңнуллинның (ул үзе дә шагыйранә зат иде) – аның иҗатына бәя биреп, «Шамилдәге кебек ихлас шигырьләр бик азларда гына бар», дигән сүзләрен тапшыра алмый калуыма гына үкенәм. Янә бер үкенечем – абыйга исән чагында рәхмәтләремне әйтеп бетерә алмадым шул. Югыйсә, ул үзе дә, ниндидер җил-зәхмәт тимәсен дигәндәй, мине саклагандыр.

*...Кем уйлаган, «әзи, әзи!» диеп,*
*Минем арттан чапкан бу малай,*
*Казан урамында куып тотып,*
*Мине узар, диеп, берзаман.*
*Узу кирәк, –*
*Карт агачлар кайчак*
*Яшьрәкләргә ясый күләгә.*
*Кала инде безгә – өлкәннәргә –*
*Сезгә күбрәк якты теләргә.*
*...Җил уңдыра, яңгыр суы юа, –*
*Бина кала, бина бирешми.*
*Безгә, энем, кешегә җылы биргән*
*Бина кебек булу тиешле.*
*...Бу дөньяда, гыйбрәт алыйм, дисәң,*
*Үз җаныңа күз сал иң башта.*
*Ятлар белән дөнья куганда да,*
*Алар белән җиңел булганда да,*
*Туганнарың юлда югалтма!*

(«Гыйбрәт алыйм, дисәң...»)

Аның бүген инде бөек дип әйтә алырлык шагыйрь-кордашлары да бар иде: Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим һәм әле тагын байтак исемнәрне (әлбәттә, иҗатлары буенча) тезеп китәргә була. Мөгаен, аларның берсе дә каләмдәшләре Шамил Маннаповны «печән кибәне күләгәсе иде», дип санамыйдыр...

Бу истәлек-язмамда мин абый иҗатына ниндидер бәя бирергә җыенмыйм. Аның тәрҗемәи хәле дә (биографик тормышы) аерым китапларда, байтак мәкаләләрдә тасвирланган. Шулар арасыннан, сезгә никадәр генә сәер булып тоелмасын, минем өчен иң мәгънәлесе, иң кадерлесе – якташыбыз (инде үзе дә гүр иясе булган), талантлы журналист, газета редакторы Рәфыйк абый Шәйхетдиновның сүзләрендә уелып



*Уңда – Шамил Маннапов,*
*сулда – Кадыйр Маннапов,*
*уртада – Мөдәррис Вәлиев. 1955 ел*

калган сыман. Район үзәгендә (Базарлы Матакта) узган бер кичәдә ул болай дигән иде: «Шамил абый, аяк очларына басып, зур булып күренергә ымсынмый. Ул үзенең иҗаты белән тиешле биеклекләрне яулады».

Абый, авылдашым Нәби ага Дәүли кебек үк, үзенең туган-үскән Әлки якларын, Мулла авылы дигән бәләкәй ватанын сагынып яшәде. Кызганыч, гомере кыскарак булды шул, газиз туган төбәк Сабантуйларын юньләп күрә алмый китте. Нәби аганың да күңеле, Сабантуй аты кебек, яз саен шул тарафка талпына иде. Ни үкенеч, ул заманда «тимер атым» юк, үземнең дә атаклы Әлки – Алпар батырлары мәйдан тоткан бәйрәмне күрергә тилмергән чаклар... Юллар ябык, Нәби агадай мәшһүр якташларың булса да чакыру, каршы алу турында сүз катып карасам да, моңа исе киткән адәм табылмады. Ул чордагы район түрәләренең колаклары саңгырау, күзләре томаланган, дөньяның «куласа» икәнлеген онытып, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртудан ары китә алмадылар шул. Инде, даһи ятим Тукай сүзләрен чак кына үзгәртеп әйткәндә, «бар да бар, тик юк туганнар. Без ятим анда, ятим...» (Шул ук вакытта миңа кайбер бәндәләрнең: «Синең туганнарың юк бит», – дигән мыскыллы сүзләре ошый, аларны үземчә кызганам, чөнки алар мөстәкыйль, башкортлар әйтмешли, үз һәлмәклегең, ягъни «дәүмәле зур булмаса да, авырлыгы булган»ча, башкалардан бәйсез хәлдә яшәүнең тәмен белми. Дөрес, мин туганнарым юклыгына эчтән сызам. Әмма бу вөҗдансыз, оятсыз заманда кемнең туганлыгы чын икән?!)

Чувашның танылган әдибе, безнең Сихтерма тумасы (хәзер ул авылга Хузангай исеме бирелгән!) Педер Хузангай агай бәйрәменә кем генә чакырылмады, музее ачылган икән, дип тә сөйләделәр, әмма, якташлар үпкәләмәсен, бу – кайсы милләт төбәге, кемнәр ватаны соң? Сүз иярә сүз чыккач, шундый гөнаһлы уйлар да килә күңелгә. Район үзәгендә минем, ничектер, юл уңаенда, шактый бай, матур интернациональ музейга кергәнем бар, аны торгызуда Г.Булатова, Н.Дәүли, Ә.Яһудин, Ш.Маннапов, аннары И.Мәхмүтова, Р.Мотыйгулина, М.Сөнгатуллин кебек күренекле шәхесләребезнең, нинди исемнәребез булуга, нинди вазифалар биләвебезгә карамастан, ул чорда әүхәтебез җитеп бетмәгәнен таныйм. Ихтимал, моңа үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан, бүген бар, иртәгә юк төбәк хакимияте генә түгел, без дә гаепледер.

*Идел суы нигә тәмле,*
*Идел суы ник тирән? –*
*Аңа сулар кушылгандыр*
*Әлки чишмәләреннән...*
*Бу җырларым нигә моңлы,*
*Сагышларым ник тирән? –*
*Аңа моңнар кушылгандыр*
*Җанымны сугарып торган*
*Әлки чишмәләреннән.*

(«Әлки чишмәләре»)

Исәннәрнең – кадерен, үлгәннәрнең каберен белми торган кавемгә әверелеп барабыз шикелле шул.

...Ярый, «сүзебезнең башы иде бит Шүрәле». Нинди күңелсез темаларга кереп киткәнмен, күр әле! Хәер, бу юлы да шул хәлләрне искә төшереп сызланмасак-сыкранмасак-үкенмәсәк, Нәби абзыйлар, Шамил абыйлар кайтып искәртә алырмы икән? Юктыр...

Беренче җөмләмдә үк мин, Шамил абый белән бергә үстем, дип мактанып куйдым. Без, чынлап та, язмыш туры китереп, ул туган йортта – аның әти-әнисе (Дәү Әтием белән Дәү Әнием) ихатасында үстек. Сабый чагымда ул мине караган, уйнаткан кебек булгандыр. Үз әнием сөйләве буенча, Кечкенә әзи (ягъни Шамил абый) иптәшләре белән пәке кадашмы, башка берәр уенмы белән онытылып-мавыгып киткән арада, мин капка төбендәге каз үләне өстендә тәгәрәшеп яткан кәҗә «чикләвек»ләрен авызга тутырырга өлгергәнмен. Моның өчен әни Шамил абыйның маңгаена чирткән дә мине өйгә алып кереп киткән. Аннары инде мин үзем дә абыемны, авыл тузанын куптарып, кыркапкада армиягә озатып калганыбызны хәтерлим... Һәм, ниһаять, аның берзаман, өч ел Мәскәү янында хезмәт иткәч, авылга әйләнеп кайтканын. Оят булса да язам: кышкы төн булса кирәк, мин, аннан унбиш яшькә кечерәк шалапай, кече йомышымны үтәргә ниятләп, ишегалдына чыкканмын. Ә солдаттан кайтучы Кечкенә әзи, әтисе яисә әнисе чыкмасмы (имештер, аларга сюрприз ясарга) дип, чолан почмагына посып торган. Аны, әлбәттә, мин абайламаганмын... Шулай итеп, абыйның абруе чылана яза,«авантюра»сы барып чыкмый. (Кем белә, «Солдатта булган, диләр» җырының оеткысы, бәлки, шул чакта ук тугандыр...)

Дәү Әни читтәге улларына, үзе чыгарган шигырь-мөнәҗәтләрне куша-куша, хатны, ни өчендер, миннән (6 яшьлек оныгы-улыннан) яздыра. Икесе дә заманнар аркасында өч язу (гарәп, латин, кирилл) таныган Дәү Әтигә күңел серләрен чишеп бетерә алмаганмы, әллә Мәгыйз бабайның җыр, мәзәк сүз, әкият яратуына карамастан, шигырьгә беркадәр кырысрак мөнәсәбәтеннән килдеме икән ул тыелу, – тәгаен генә белмим, әмма, шигырь-җырларны үземчә борып җибәрүдән тәм табып, ул хатларны беренче иҗат җимешләре итеп яза идем. Ә мәдрәсә сабагы алган, төп гомерен авылда уздырган Дәү Әнием бер дә уйламаган Крылов мәсәлләреннән татарчалап канатлы сүзләр китерә (аның «Тиле Трушка» дигәне кайдан килгәнен соңрак – үсә төшкәч белдем), алай гына да түгел, Пушкин, Лермонтов кебек шагыйрьләрнең байтак әсәрләрен үз күрә, шуңа күрә әдәби оеткыны (Шамил абыйның рухы шат булсын), иң элек, мин аңардан – кайчандыр, яшьлегендә Дәү Әти белән бергәләп Кавказ якларында тимер юллар төзешкән Дәү Әниемнән алганмындыр, дип уйлыйм.

Дөресен әйтергә кирәк, абый Казанда әллә ни муллыкта, рәхәт гаилә кочагында яшәмәде, дип беләм. Ул – тыйнак, ни барына шөкер итеп гомер кичкән бәхетле кеше. Юклык кичергән чаклары да булгандыр. Мин, әле сабый, яшүсмер чагымда ук, аның Казаннан бүләк алып кайтмавына үпкәләми идем. Бер генә мисал: без мәктәптә укыганда, сызым дәресләре бар, сызымны дөрес итеп эшләү генә җитми, кара тушь белән башкарып бирүне дә таләп итәләр. Авылда, әлбәттә, тушь дигән нәрсә юк, аны калада туганнары булган малайлар-кызлар гына күз карасы кебек саклап-кадерләп тота. Мин абыйдан тушь алып кайтуын сораганымны хәтерләмим, әмма укытучыма рәнҗим: миңа, карандаш белән эшләгән өчен генә, «дүртле» куя... Тушьны башка классташларга дөрес-пөхтә итеп сызып бирсәң яисә мәктәпкә плакат язсаң, табып була-булуын, һәм мин шулай эшләргә мәҗбүр идем. Шамил абый, ихтимал, минем бу «проблема»ны белмәгәндер дә. Шулай да аның бер бүләген – Хәсән Туфанның 1964 елда чыккан «Сайланма әсәрләр» китабын әле дә кадерле ядкяр итеп саклыйм. Ул заманда хәзерге яшьләр ишетмәгән абзыйларның уртакул шигырь җыентыклары шактый күп чыга, авыл кибетендә һәм китапханәсендә исә Туфан яки Дәрдемәнд турында белмиләр дә, Такташ, Җәлил китаплары юк, дәреслекләрдә башлыча «тегеләр» генә түрдә утыра, ә Туфан китабы миңа чын шигъриятнең нинди булырга тиеш икәнлеген аңларга булышты. Менә монысы өчен абыйга рәхмәт укып яшәдем.

...Безнең гаиләдә шундый рәсми булмаган иерархия бар иде: Әти-Әнидән кала, Зур әзи, Шәкерт әзи, Туган әзи, Зур апа (кайчандыр Кечкенә апа да булган әле, тик ул яшьли үлгән), аннары азмы-күпме якын туганнар: Тумачи апа, Туган апа, Матур апа һ.б. Ә Шамил абый – миңа һәм Зур әзи белән Тумачи апаның балалары өчен Кечкенә

әзи. Дөрес, буйга чандыррак булгангамы, ул инде «зуп-зур Апуш» чагында болай эндәшүне бигүк өнәп бетерми кебек тойдык, шуңа безнең балалар аңа Матур абый дип әйтеп үстеләр, ул, чыннан да, матур, нечкә күңелле, игелекле зат иде. Кызларымны да телләре ачылган чакта ук җәмәгатемнең бертуганнарына, аларның үз ягында электән үк Дәү апа, Бал апа кебек якын итү сүзләре булса да, Алма апа, Зур абый дип хөрмәтләп дәшәргә өйрәттек (безнең авылларда әле дә бармы икән мондый тәмле эндәшүләр, әллә, урыс «туганнарыбыз» шикелле, Иван, Мария дип кенә йөртә башладыкмы?!)

Сүз җаеннан гына әйтим, минем белән шаярырга яратканга, кечкенә чагымда ниндидер кушамат таккач, үзем дә «сдача» бирми калмадым: аңа, алайса, син Шаман булырсың, дидем. Үртәүчән кеше үзе дә үртәлүчән, үпкәчелрәк була бит. Ул, чынлап та, моңа үпкәләгән иде. Заман әдәбияты белән танышлар белә: мәзәкләр, шаян хикәяләр яза башлагач, ул Шаман дигән (Шамил Маннаповтан кыскартылган) әдәби кушаматына ияләшеп китте, шундый тәхәллүс (псевдоним) белән китап та чыгарды әле. Алга таба да мин аның шактый кырыс тәнкыйтьчесе булдым. Хәтта яңа шигырьләрен, мәзәкләрен күрсәтми үк башлады. Нашир буларак, китап чыгарырга булышмаганым өчен дә миңа аның хәтере калган иде кебек. Шөкер, мөмкинлекләрем чикле булуга карамастан, гомер китабын – туган якларга, балачагына багышланган «Мәңгелектән елмаю» дигән хатирә-хикәяләрен мин дә чыгарыштым. Баштагы вариантын «тетеп» ташлагач, кереш сүзен, үпкәли-үпкәли булса да, яңадан язган иде ул. Без чыгарган китап «Гаҗәеп хәл: тормышымда ниндидер җитди үзгәрешләр көтелгәндә яисә нәрсәдәндер җаным тетрәнгән вакытларда минем төшемә әни килеп керә», дип башланган ихлас-җылы сүзләр белән ачыла.

*...Күкрәк көчем белән*
*Мул җимешләр җыеп алсам әгәр эшемдә,*
*Әллә нигә, иркәләгән кебек,*
*Әни керә минем төшемә.*
*Кинәт кенә хәсрәт уты кабып,*
*Янып йөрсә әгәр эчемдә,*
*Кемнәргәдер үпкәләгән сыман,*
*Әни керә минем төшемә...*

Икебезнең уртак Әниебезгә багышланган «Керфегеңә тамармын мин» җыры да шул китапның прелюдиясе кебек ишетелә.

Мөхтәрәм әдәби журналыбыз хуҗалары, бигрәк тә укучыларым гафу итсен, абый турында язарга кушсалар да, күбрәк үземә кагылышлы хәлләргә кереп киткәнмен. «Бергә үстек», дип башлавым ук каләмемне шул якка авыштырды бугай.


«Кечкенә» зур абыем турында язмамны түгәрәкләп, аның – иҗатыннан аерылмыйча гомер иткән эш атының – хезмәт кенәгәсендә өч кенә юл булуын искәртәсем килә: «Татарстан яшьләре» газетасы, китап нәшрияты һәм иң кадерлесе дип уйлыйм – ул да булса – «Казан утлары». Урыслар әйтмешли, «әле узмаган узган заманда» («непрошедшее прошедшее время») ун елга якын үзем дә шунда беркадәр хезмәт куйган «Казан утлары»на аерым рәхмәтем – фани гомерен йомгаклап килгәндә, Шамил Маннаповка сыену-иҗат мәйданы һәм, әлбәттә, бүген,«ягез, бер дога», дип, искә алу мөмкинлеге биргән өчен.

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ (Салих МАННАПОВ)**

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез Мөдәррис Вәлиев үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# ТАТАР СӘХНӘСЕНДӘ – АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ ПРОЗАСЫ



Аяз Гыйләҗевнең (1928-2002) таланты (сәләте) татар әдәбиятының бөтен жанрларында да киң ачыла: ул күренекле прозаик, үзенчәлекле драматург, оста публицист, очеркист һәм, әлбәттә, үткен тәнкыйтьче буларак таныла. Татарстанның халык язучысы, Татарстанның Г.Тукай һәм РСФСРның М.Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре, Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби премиясе лауреаты, Татарстанның, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе А.Гыйләҗевнең иҗади мирасы хаклы рәвештә XX-XXI гасыр татар әдәбиятының иң кыйммәтле хәзинәсе, әдәби-мәдәни байлыгы булып санала, чөнки ул – әдәби дәверне яңарыш чорына алып кергән, милли үзаңны, фикер күтәрелешен әзерләгән, яшәү мәгънәсен милләткә хезмәттә күргән әдип. Аның дистә еллар дәвамында тудырылган гаҗәеп киңкырлы, күп катламлы, жанр төрлелеге һәм тема ягыннан гаять бай әдәби иҗаты XX гасыр татар тормышының иҗади елъязмасы булып укыла, милли әдәбиятның гына түгел, дөнья әдәбиятының да бер өлеше булып тора.

Соңгы биш ел эчендә Татарстан Республикасында һәм чит илләрдә бөек язучының исемен мәңгеләштерү буенча зур эш башкарылды: 6 томда «Сайланма әсәрләр»е дөнья күрде, бу исә язучының хатларын, көндәлекләрен, публицистикасын, әлегәчә дөнья күрмәгән әсәрләрен һәм әсәрләрнең вариантларын фәнни әйләнешкә кертергә мөмкинлек бирде; «Йөгез бер дога!» әсәре бер ел эчендә өч телдә: татар, рус һәм мадьяр телләрендә басылып чыкты. Әлеге басмаларны тәкъдим итү кичәләре Татарстанда да, Венгриядә дә үткәрелде; «Әтәч менгән читәнгә» повестьлар җыентыгы «Татар прозасы» сериясендә нәшер ителде; рус телендә «При свете зарниц» повестьлар җыентыгы яңадан басылды (бу җыентык өчен әдип 1987 елда Россиянең Югары әдәби премиясенә лаек булган иде); «Өч аршын җир», «Җомга көн, кич белән» повестьлары, төрек теленә тәрҗемә ителеп, Төркиядә дөнья күрде; «Яра», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәя», «Язгы кәрваннар» әсәрләре исә, төрек теленә тәрҗемә ителеп, үз чиратларын көтә; «Яра» повесте да, рус теленә тәрҗемә ителеп, басмага әзер; әдипнең күренекле әсәре – «Өч аршын җир» повесте хакас теленә тәрҗемә ителде; Татарстан һәм Россия театрлары репертуарына язучының «Өч аршын җир» (Чаллы дәүләт татар драма театры, А.М.Топанов исемендәге хакас милли драма театры), «Кар астында кайнар чишмә» (А.Мөбарәков исемендәге Сибай башкорт дәүләт драма театры, Әлмәт татар дәүләт драма театры), «Ефәк баулы былбыл кош» (К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры), «Югалган көн» (Г.Тукай исемендәге Әтнә дәүләт драма театры) пьесалары кире кайтты; татар театрларында А.Гыйләҗевнең прозасы: «Оҗмах капкасы» («Җомга көн, кич белән» әсәре буенча, Әлмәт татар дәүләт драма театры), «Яра» (шул ук исемдәге повесть буенча Т.Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театры), «Әтәч менгән читәнгә» (шул ук исемдәге повесть буенча Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры) әсәрләре сәхнәләштерелде; «Балта кем кулында?» романын рус теленә тәрҗемә итү буенча эш башланды.

Язучы прозасын сәхнәви интерпретацияләү (ягъни сәхнәгә яраклаштырып интерпретацияләү) проблемасы игътибар үзәгенә куелды. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: әдип үзе әсәрләренең жанрын үзгәртү мәсьәләсенә һәрвакыт бик сак караштa тора. Язучы прозасын татар театры сәхнәсендә 1970 еллар башында, илебез театрының «сәхнәләштерү шау-шуы» («инсценировочный бум») дип аталган дәверендә (1960-1970 еллар), «Өч аршын җир» повесте (1962) Мәскәүдә дан казанганнан соң куярга омтылалар. Марсель Сәлимҗанов инициативасы белән, А.Гыйләҗев үзенең күренекле «Өч аршын җир» повестен (1962) оригиналь пьеса (1972) итеп үзгәртә. Ләкин цензурага бәйле рәвештә, аларның ниятләре бары тик унбиш елдан соң гына тормышка аша. Репетицияләр Камал театрында гына түгел, Мәскәүдәге Станиславский исемендәге театр сәхнәсендә дә үткәрелә (реж. В.Космачевский), тик ТАССР Обкомыннан шалтырату сәбәпле, спектакльнең премьерасы булмый кала. Әлеге спектакльне 1980 елда Ф.Ибраһимов Актаныш халык театры сәхнәсенә чыгара. Тамашачылар режиссёрның спектакльне үзенчә күзаллавын бик югары бәяли («неординарное образное решение»). М.Сәлимҗанов исә әсәрне сәхнәгә куюга бары 1986 елда гына әйләнеп кайта. Бу театр тарихында бик мөһим вакыйга була. 1987 елда Ф.Ибраһимов спектакльне Минзәлә театры сәхнәсендә дә куя. Г.Камал исемендәге театрның актёрлар ансамбле сәхнәдә мәсәл, гыйбрәтле хикәя күрсәтсә, Ф.Ибраһимов трагедияне драмага әйләндерә. Өч дистә елдан соң, Мирвәли карт яшенә җиткәч, Ф.Ибраһимов яңадан А.Гыйләҗев пьесасына әйләнеп кайта һәм Чаллы сәхнәсендә тамашачыларга «тулысынча хатын-кыз тормышы тарихы»н күрсәтә.

А.Гыйләҗевнең юраганы юш килә: «Бу пьеса татар драматургиясенең иң атаклы пьесаларыннан берсе булачак һәм берчакта да сәхнәдән төшмәячәк дип өметләнәм, шарты: әгәр татар калса? Аны шундый олы язмыш көткәнен мин бик яхшы беләм!» – ди ул. Чыннан да, татар театры әлеге гениаль әсәргә, яшәешкә булган карашка, дөньяны кабул итүгә бәйле сорауларга җавап табу өчен, милли традицияләр чишмәсе һәм дөньяның милли образлары чыганагы рәвешендә кат-кат мөрәҗәгать итә. Әсәргә интерпретация ясау диапазоны чиксез: мелодрамадан мәсәлгә кадәр. Җепшеклек дулкынында язылган бу әсәр күпмәдәниятле дөньяда яшәүче замандашларыбыз ихтыярын канәгатьләндерә.

Әлеге әсәрнең Ф.Ибраһимов тарафыннан сәхнәләштерелүе режиссёр Юрий Майнагашевны хакас телендә «Кичер мине, җир!» спектаклен тудыруга этәрә (Татьяна Майнагашева тәрҗемәсе). А.Гыйләҗев әсәрендә күтәрелгән проблемадан этәрелеп, ул үз геройлары Андрус белән Алтынах язмышын Хакасия Республикасында коллективизация һәм сәяси репрессияләр чорында сурәтли. Топанов исемендәге хакас театры спектакле документальлеге, фактларга нигезләнүе белән аерылып тора. Сюжет үсешендә спектакль трагедия төсмерен ала.

1984 елда ТАССР телевидение һәм радиотапшыру комитеты заказы белән, «Җомга көн, кич белән» (1972-1979) повесте буенча телеспектакль төшерелә (режиссёры – Әхтәм Зарипов). Премьерадан соң матбугатта кайнар дискуссияләр башлана, аларга җавап итеп, махсус телетапшыру төшерелә, анда автор бу дискуссиягә йомгак ясый. А.Гыйләҗев укучылардан һәм тамашачылардан ике йөзгә якын хат ала. Язучы Бибинур язмышының укучыларда һәм тамашачыларда шулкадәр зур кызыксыну уятуы һәм алар күңелендә кайтаваз табуына бик шатлана, шул ук вакытта әйтергә теләгән төп фикеренең күпләр өчен табышмак рәвешен алуына борчыла да. Хатларда повестьның әхлакый потенциалы – ялгыз картлык тарихы гына фикер алышу предметы булып кала.

«Җомга көн, кич белән» повесте тексты белән шул ук исемдәге сценарийга анализ ясау прозаны сәхнәләштерүнең иҗади акт булуын күрсәтә. Ә.Зарипов телеспектакленең сценарие оригиналь әсәрнең сюжетына һәм конфликт төзелешенә булган бәйлелеген саклый. Үзенчәлеге исә автор идеясен телеспектакль шартларында тәкъдим итәргә мөмкинлек биргән яңа структур берәмлекләрдә чагыла. Бибинур мәхәббәте темасы телеспектакльдә үзенчәлекле чишелеш таба. Аның Мирзаһиткә, Габдуллаҗанга, Җиһангиргa булган мәхәббәте, бер яктан, авыл гайбәтләре көзгесендә чагылса, икенче яктан, мөнәсәбәтләренең характерын ачарга мөмкинлек биргән аерым драматик күренешләрдә ачыла. Карчыкның соңлаган мәхәббәте С.Садыйкованың

«Көтәм сине» патефон язмасын тыңлау эпизоды аша күрсәтелә. Бу эпизод Ә.Зариповка телеспектакльдә вакыт чикләрен киңәйтергә ярдәм итә. Бибинурның ялгыз биюе әкренләп парлы биюгә әверелә. Шулай итеп, режиссёр иртә тол калган хатынның йөрәк серен, сарыф ителмәгән мәхәббәтенең тирәнлеген, яшьлеге сугыш елларына туры килгән Бибинурның тормыш драмасын ачып бирә.

Ә.Зарипов, авторның оригиналь әсәрдә күрсәтелгән фикеренә каршы килеп, Бибинур һәм балалар арасындагы конфликтның үз версиясен тәкъдим итә. Туган йортларын бөлгенлеккә төшергәннән соң, алар үги әниләрен әтиләре белән никахларын рәсми рәвештә теркәмәгәнлектә һәм моның тиешле ташламаларны алу өчен каршылык булуында гаепли. Хәтимә фикеренчә, бу фронтовик гаиләсен ярлы тормышка дучар итә.

Нәкыя Гыйләҗева әйтүе буенча, язучы телеспектакльдән бик үк канәгать калмый. Күрәсең, автор Ә.Зариповның режиссёрлык концепциясе белән риза булмый. Авторның телеспектакльне ошатмавының сәбәбе тагын да тирәндәрәк ята, дип әйтергә батырчылык итәбез: ул драматургия һәм хикәяләү текстларының тел төзелеше арасындагы аерманы кабул итә алмый. Мондый нәтиҗәгә без телеспектакль сценариена анализ ясаганнан соң килдек. Бәлки, язучы актёрлар уеныннан да канәгать калмагандыр. Татар театры артистлары, телеспектакльне төшергәндә, үзләрен кыюсыз тота. Аларга телестудия шартларында уйнавы кыен икәнлеге күренеп тора. Тамашачылар үз бәяләмәләрендә Бибинур ролен артистка Ф.Хәйруллинаның иҗади уңышларының берсе дип атый. Шулай ук тамашачылар Галикәйне димләү күренешенә сокландуларын белдерә. Бу күренештә Р.Шәрәфиев, Р.Мотыйгуллина һәм Ф.Хәйруллина вакыйганың бөтен нәзакәтлелеген чагылдыра ала.

Язучы үлеменнән соң, легендар повесть Мансур Гыйләҗев тарафыннан трагикомедия итеп үзгәртелә һәм Әлмәт татар дәүләт драма театры сәхнәсендә режиссёр Р.Әюпов тарафыннан куела. Тәнкыйтьчеләр бертавыштан «Оҗмах капкасы»ның оригиналь «мөстәкыйль әсәр» булуын билгеләп үтә. М.Гыйләҗев бу спектакльдә А.Гыйләҗев повестьларында билгеләнгән («Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Өч аршын җир», «Җомга көн, кич белән...») төп мотивларны куллана. Тамашачы кеше тормышының мәгънәсе, туган җир кыйммәте, ана табигате, мәхәббәт һәм нәфрәт хакындагы уйлануларга күмелә. Спектакльнең фабуласын хыянәтсез Бибинурның тууыннан үлеменә кадәрге тормыш-яшәеше тәшкил итә. А.Гыйләҗев повестеның сюжет нигезе генә түгел, Бибинурдан (ул, Н.Игъламов фикеренчә, «милли характер чагылышы» булып тора) кала, персонажлар системасы да кискен үзгәрешкә дучар ителә. Театр белгече аның образын Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» легендар пьесасындагы Әлмәндәр карт образы белән бер рәткә куя.

«Оҗмах капкасы» трагикомедиясенең әйдәп баручы алымы булып гротеск тора, ул чорның үзгәрешләргә бай икәнлеген күрсәтә.

Спектакльнең зур уңышка ирешүе Бибинур ролен уйнаган Наилә Нәҗипованың сәләтенә бәйле. Ул Бибинур образының сәхнәдә «җемелдәве»н осталарча чагылдыра ала: Бибинур һәрвакыт битлеген алыштыра. Тамашачы алдына әле мәхәббәт турында хыялланучы яшь кыз, әле көндәлек мәшәкатьләргә күмелгән төпле фикерле урта яшьләрдәге хатын, әле тормыш йомгагын сүтүче меланхолик карчык рәвешендә чыга. Н.Игъламов бик дөрес билгеләп үткәнчә, бөтен сер – актрисаның гротескка якын торган, героинясының эчке дөньясын чагылдырганда, тирән психологизм белән сугарылган уйнау манерасында.

Председатель Җиһангир трагикомедиядә, М.Гыйләҗев ниятенә бәйле, уңышлы колхоз җитәкчесеннән криминаль дөнья белән бәйле эшкуарга (Р.Минханов) әйләнә. Аксыргакка да ул, уен бизнесы объекты төзү өчен, җир участоклары сатып алырга дип килә. Ләкин үз йортын сатарга теләмәгән ялгыз карчык аның инде күптән төзелгән планнарын чәлпәрәмә китерә. Шундый авыр сайлау алдында («бусага ситуациясендә») калган Җиһангир бизнес-проектын тормышка ашырудан баш тарта.

Н.Игъламов билгеләп үткәнчә, «Оҗмах капкасы»ндагы Җиһангир (Р.Минханов) һәм Зөһрәбану (Г.Вәлиева) рольләре актёрларның иҗади биографиясендә иң мөһим рольләрнең берсе булып калачак. Сатучы (Л.Солтанова), почта хезмәткәре (З.Халикова),

Галикәй (Р.Вәлиев) эпизодик персонажларның барысын характерларның психологик тирәнлеген ачып бирә алулары берләштерә (Р.Вәлиев).

«Яра» повесте буенча куелган спектакль ике театр – Камал театры (режиссёр – Р.Фазлыев) һәм Түбән Кама театры (режиссёр – Р.Галиев) сәхнәсендә куела (2000). Театр белгечләре Д.Гыйматова һәм Р.Солтанова фикере буенча, Казан тамашачыларына мифопоэтик рухтагы спектакль күрсәтелсә, Түбән Кама сәхнәсендә кырыс тормыш прозасы хөкем сөрә. Үзеннән алган интервьюда М.Гыйләҗев сценариенең танылган повесть буенча гына язылуын, шуңа күрә оригиналдан бик аерылып торуын билгели. Бу Камал артистларында канәгатьсезлек уята, һәм алар башка юлдан китәргә була. Камал театрында А.Гыйләҗев әсәрендәге милли образларның потенциалын (йомры таш, капка, үсеп утыручы каеннар белән чагыштырыгыз), татар кешесенең тормыш тәртибен, характер үзенчәлеген төгәл күрсәтергә телиләр. Гаилә бәхетенең сере повестьта татар язучысы тарафыннан бер фразага сыйдырыла: «Сиңа әйтәм!» Бу идиллик контекст Түбән Кама театры спектаклендә югала, һәм сәхнәдә сугыш турында бизәксез, батырлык романтизмыннан азат, еш кына гротеск буяулары белән сугарылган кырыс хакыйкать тудырыла. Әсәрнең дини дискурсы да үсеш алмый. Р.Галиев спектакльнең концепциясен шулай аңлата: «Безнең максат тамашачының күңелен төшерү түгел. Дәһшәтле сугыш еллары, шул дәһшәтне үткән әти-әниләребез, бабайларыбыз халыкның күңелендә саклансын дип тырышабыз».

2017 елның 1 декабрендә Камал театры сәхнәсендә А.Гыйләҗевнең «Әтәч менгән читәнгә» повесте буенча куелган спектакльнең (режиссёр – Ф.Бикчәнтәев) премьерасы булды. Язучы үзе телеинтервьюларның берсендә (17.06.1982) әсәрнең төп идеясен шулай аңлаткан иде: «Муллык белән комсызлык килә икән, бу – хәвефле хәл. Тормыш бөтенлеге һәм күңел саранлыгы, күңел тарлыгы туа икән, бу – бик куркыныч хәл.

Эчүчелек, ялкаулык, халык, ил ихтыяҗларына битараф карау, тәртипсезлек, вак һәм эре караклык, хезмәт куймыйча гына «җиңел яшәргә» омтылу – менә бүгенге көннең безне сагайта, хәвефләндерә торган ямьсез күренешләр. Җир хуҗасының күңеле гомер-гомергә матур булган!.. Авыл үзгәрә...

Йортлар, урам-тыкрыклар, урман-болыннар гына түгел, кешеләрнең кием-салымы, яшәү рәвеше, характерлары заманча яңа төсләр ала. Сөенечләр белән безне көендергән хәлләр дә янәшә, һәм кайчагында алар бердәй тулы хокуклар белән яши. «Әтәч менгән читәнгә» повесте минем соңгы еллардагы борчылулы уйлар нәтиҗәсе буларак туды. Моңарчы байтак әсәрләремдә мин, авыл кешесенең сафлыгына, туганлык хисләрен олылый алуына куанып, байтак мәдхия җырладым. Бу әсәремдә исә сагаю, хәвеф-борчылулар күбрәк урын алды».

Повесть язучы замандашларын авторлык концепциясе һәм үзенчәлекле стиле белән гаҗәпләнергә мәҗбүр итә. Ф.Бикчәнтәев һәм И.Мөхәммәтгалиев, әсәрне сәхнәләштергәндә, повестьны татар әдәбияты классигының рухи васыяте дип кабул итә. Камал театры спектакле тамашачылар һәм тәнкыйтьчеләр тарафыннан бик җылы кабул ителде.

Прозаны драма әсәренә әйләндергәндә, сценарий авторлары текст, А.Гыйләҗев теле белән бик сак эш итә, сөйләк хикәяләү (сказ) манерасын саклап калырга тырыша. Автор сүзе геройларның репликаларыннан ишетелгәндәй була. Спектакль «матур истәлек» (А.Кисилёв) кебек карала. Ләкин тамашачыга, күптән түгел генә булган хәлләргә күз салып, гүя үзенең хәзергесен күргәндәй тоела. Сәхнәләштерүдә урын белән вакыт аерыла һәм тамашачы, гомумән, яшәеш (бытие) дәрәҗәсенә чыгарыла.

А.Гыйләҗев һәрвакыт татар дөньясы элементларын системалаштырырга тырыша, моның өчен үзәк һәм аннан ерагайганда барлыкка килгән үзәктәш әйләнәләрне аерып чыгара. Моңа 1963 елда, күренекле «Өч аршын җир» повестен бәяләгәндә, В.А.Чалмаев игътибар итә. А.Гыйләҗев повестенда СССРның татарлар өчен чит илгә, ә татар авылының туган җиргә әйләнүенә тәнкыйтьченең ачуы чыга. Татар әдәбиятчылары исә язучының иҗатын «авыл прозасы» кысаларына кертергә тырыша.

«Әтәч менгән читәнгә» инсценировкасы авторлары А.Гыйләҗев әсәренә якын бердәм хәрәкәт итүнең төгәл үзәктәш үз юлын төзи: СССР (Чиләбе) – Идел-йорт – Язкилде авылы – йорт. Татар авылының исеме тирән символик мәгънәгә ия: ул үзендә

мәңгелек яңару, яңарыш мәгънәсен туплый, татарларның дөньяны кабул итүләренә, милли календарь йолаларына туры килә. Әлеге тәртипкә салынган Галәмнең төп ноктасы булып йорт – гаилә тора. Ф.Бикчәнтәев гаилә портреты потенциалын уңышлы куллана, бу бер төркем сценографик этюдларда яхшы күренә. А.Гыйләҗевтәге кебек, монда да аерым гаилә портреты татар халкы портретына һәм, гомумән, кешелек портретына әверелә. Гаилә портретын сәхнәгә кую исә символик мәгънәне аңлата, ата-аналарның балалар үсешендәге ролен күрсәтә. Татар халкының язмышы хакында уйланып, язучы укучыларын кеше табигате турында сөйләшергә чакыра. Әлеге сөйләшүдән «дөньяда бары бер ир кеше бар, аның исеме – Бар Ир-атлар. Дөньяда бер хатын-кыз бар, аның исеме – Барлык Хатын-кызлар. Дөньяда бары бер генә бала бар, аның исеме – Барлык Балалар» (Карл Сэндберг) дигән нәтиҗә чыга. Дөнья үзәге А.Гыйләҗев аңында дөньяви тәртип белән бер рәткә куела, һәм бу идеаль дөнья төзелешенең башлангыч ноктасы булып тора.

Башлангыч күренештә үк тамашачыларга җемелдәүче образ – үрмә кәнәфи тәкъдим ителә. Ул – гаиләдә генә була торган рәхәтлек, шулай ук хәллелек, җайлашу символы (кәнәфи үзенә утыручының зурлыгына, авырлыгына җайлаша – йә кысыла, йә җәелә: балалар әтиләре биргән сабакны үзләренчә кабул итеп тормышка ашыра). Эңгер-меңгердә йомры контурлар үрмә кәнәфиләрне әле йомыркага (гомер бирү, яңадан туу идеясе), әле каберташларга (фани дөньяның бетүе символы) әйләндерә. А.Гыйләҗевтә гаилә ул – йомырка – беренчел нигез, аннан, борынгы мифтагыча, дөнья барлыкка килгән, һәм ул дөньяда безнең тормышыбыз үтәчәк тә. Йомырка образы, Язкилде авылы атамасы сыман, тормыш башлануын, бар иҗатның башлангычын, беренчел хаотик дөньяны, Галәмне үз эченә туплаган Мәңгелек Әйләнешне символлаштыра.

Иҗат итү мәгънәсе киртә (көнкүреш дәрәҗәсендә) һәм каланча (яшәеш дәрәҗәсендә) образларында да чагыла. Нәсел-ыру тормышындагы низагларны сурәтләп, Ф.Бикчәнтәев, А.Гыйләҗев кебек, тамашачыларга *«киртә куярга / салырга»* – *«киртәдән чыгарга»* фразеологизмнарының потенциалын ача. Шул ук вакытта үреп ясау безне Шәрык сәнгатенә юллый, үзендә тормышның кабатлану, цикллылык потенциалын туплый. А.Гыйләҗев туган йортларына, ыруг башлангычларына хыянәт иткән замандашлары хакында гына түгел, гомумән, кеше турында уйлана.

Янгын каланчасы – Язкилденең күренекле урыны – спектакльдә, повестьтагыча, сценографиянең үзәк образына әверелә. А.Гыйләҗевтә каланча – мәчет инварианты. Бу – татар милли дөнья образы («каланча» – төрки сүз, «кирмән» мәгънәсен аңлата торган «kale» сүзеннән алынган). Ул үзендә каравылчы каланчасы (Хәйретдин агай (Равил Шәрәфиев) татар халкының яшәү рәвешен саклаучы) һәм сигнал бирә торган каланча (моннан куркыныч хәлләр турында сигнал бирәләр) потенциалын туплый.

Режиссёр Ф.Бикчәнтәев һәм рәссам С.Скоморохов бу образны төзеп бетерәләр. Бер яктан, әлеге каланча – манара (кешенең амбицияләре, дан яратуы символы). Икенче яктан, бу агач конструкциядә күпләр Татлин манарасын (авангардистлар нияте буенча, ул Вавилон манарасын төзегәндә аерылган кешелекнең берләшү символына әйләнергә тиеш була) күрә. Каланчаны киртә артына урнаштырып, спектакль авторлары геройларның хәрәкәт итү траекториясен (көнкүрештән – яшәешкә) төгәл билгеләгән. Компьютер инсталяцияләре ярдәмендә каланча буага әверелә, бу исә тамашачыларга Язкилдедәге елганың амбивалент потенциалын күрергә ярдәм итә: бу – табигый, беренчел, тудыру һәм вату-җимерү потенциалын үзендә туплаган стихия; бу – тормыш башлангычын аңлаткан тере организм. Су ташу вакытында елга апокалипсис мәгънәсе, эсхатологик мәгънә белән дә баетыла. М.Е.Салтыков-Щедрин кебек, А.Гыйләҗев тә җәмгыятьне ялгыш язмыш сукмагыннан саклап калырга тырыша. Әкренләп, су белән тулыландырылган каланча-манара вакыт-вакыт аракы шешәсен – замана чирен, җәмгыятьтә чәчәк аткан алкоголизм символын хәтерләтә башлый.

Гәрәй ханның читәннән егылып төшүе белән бәйле тавыклар тавышлануы күршеләр арасында туган низаг вакыйгасын кабул итәргә әзерли. Тавык елы якынлашуы сизелә. А.Гыйләҗев осталарча милли хронотоп потенциалын уйната: тавык елы төрки календарь буенча муллык һәм низаглар елы дип исәпләнә. Гәрәй

хан вакыйгасы идиллик татар җәмгыяте җимерелүгә ишарә итә. Казан ханлыгының соңгы яклаучы ханының исеме повестьта очраклы искәртелми. Автор шул рәвешле хронотопларны тоташтыра. Идиллик татар чынбарлыгы җимерелү дәүләтчелек бетүгә бәйләнә.


*«Әтәч менгән читәнгә» спектакленнән бер күренеш. Уңнан сулга: Сәләхетдин ролендә – Рамил Төхвәтуллин, Мирфатыйх – Минвәли Габдуллин.*

Ф.Бикчәнтәевтә дә, автордагы кебек үк, әтәч Язкилдедәге вакытны саный. Спектакльдә әлеге образ ир-атның активлыгын, сугышчанлыгын, тәкәбберлеген, горурлыгын символлаштыра. Бу образны тудырганда, режиссёр халык көлке культурасының мөмкинлегенә (скептиклык, хөрлек, карнавал) һәм джаз биг-бэндына мөрәҗәгать итә. Персонажлар системасында симметрия булганлыгы ачыклана: әтәч – кошлар өере башлыгы, Сәләхетдин (Рамил Төхвәтуллин) һәм Мирфатыйх (Минвәли Габдуллин) – гаилә башлыклары, Хәйретдин агай – авыл аксакалы. Шул ук вакытта гаилә башлыклары (әтәчләр) улларын да (яшь әтәчләрне: Хәйдәр (Алмаз Борһанов) һәм Мидхәт (Эльвир Сәлимов)) талашу-сугышуга этәрә.

Бу бигрәк тә «тракторлар сугышы» мизансценасында ачык күренә. Ф.Бикчәнтәевтә бу Сабантуйда таяк тартышу күренеше буларак төгәлләшә. Бер батырның икенчесен җиңүенә корылган халык уены сәхнәдә ике гаиләнең көрәшүен аңлаткан гротесклы образга әйләнә: мизансценаны режиссёр таяк тотып җирәбә тартуга нигезләнгән «Таяк тоту» халык уены кагыйдәләре буенча кора. Шул рәвешле, Ф.Бикчәнтәев барлык бәхетсезлекләрнең чыганагына ишарә ясый. Шунысын да әйтергә кирәк: таяк спектакльдә еш кына күренә һәм тамашачыларны «тәгәрмәчкә таяк тыгу» фразеологизмын искә төшерергә мәҗбүр итә. Гаилә әгъзалары әлеге шөгыльдә бер-бер артлы ярыша.

Спектакльне буеннан-буена бәйрәм энергиясе биләп алган. Актёрларның бик зур канәгатьлек белән уйнаганнары күренеп тора. Репликаларны тыңлаганда, аларның әйбәт татар текстларын сагынганлыгын сизәсең: актёрлар һәр сүзне шулкадәр ләззәтләнеп әйтә! Һәр рольнең – баш рольме ул, эпизодик рольме – яхшы эшкәртелгән булуы күренеп тора. Спектакль актёрлар ансамбле тарафыннан осталарча башкарыла. Р.Төхвәтуллин героеның бар җитезлеген, егетлеген, күңеле колачын күрсәтә. Р.Әхмәтов бик дөрес билгеләп үткәнчә, безнең алдыбызда лубок картинасындагы татар мужигы түгел, ә тулаем тере образ: аңарда характер ныклыгы – хислелек, акыл – кайнарлык, саранлык – кыюлык, мактанчыклык намуслылык белән янәшә бара. Аның башкаруында кыярлар турында блюз (композитор – Эльмир Низамов) бик тәэсирле яңгырый.

Минвәли Габдуллин (Мирфатыйх) нык татар кешесе образын тудыра. Ул – сак, кыю, күп сөйләшми торган һәм нык рухлы шәхес. Актёр, А.Гыйләҗев әсәрендәгечә, сәхнәдә героеның хуҗаларча атлап йөрү рәвешен тулысынча күрсәтә ала («Җомга көн, кич белән» повестенда тол Бибинурның үз ишегалдында Җиһангирның нинди җирсү белән атлавын тыңлаганын искә төшерегез).

Хатыннары (Гөлбикә (Илсөя Төхвәтуллина) һәм Гөлмәрьям (Гүзәл Шакирова)) да ирләренә туры килә. Алар спектакльдә «гаскәр башлыклары» ролен башкара: өйдәгеләргә юнәлеш биреп, яңа батырлыкларга юнәлтеп тора (мәсәлән, Хәйдәрне димләү вакыйгасы). Аларның холык-фигыльләре җиһазлар һәм үзгә көнкүреш кирәк-яраклары сатып алу күренешләрендә ачык чагыла.

Гөлчәчәк Гайфетдинованың көнче героинясы – әнисенең көзгедәге чагылышы. Вәсилә өстендәге халат спектакльдә күп сыйдырылышлы, гротесклы образга әверелә (Н.В.Гоголь шинеленың инварианты). Героиняның кияве спортчы Җәмил

(Р.Әхмәдуллин) турындагы хыяллары – фетиш, ә сыер савучы Сәкинәдән (А.Шәкүрова) көнләшүе урынсыз булып чыга. Вәсилә җырында И.Мөхәммәтгалиев кушып булмастайны («Уфа юкәләре» җыры нигезендә туган лирик образны һәм асфальттан атлаганда ишетелгән үкчәле туфли тавышын) укмаштыра. Кызның иллюзияләрдән котылуы халатын салып кую белән күрсәтелә: Вәсилә беренче тапкыр Язкилде авылы тирә-ягының никадәр матур булганлыгын күреп ала.

«Бишле»гә укучы шат күңелле Мидхәт (Ә.Сәлимов) һәм «икеле»гә укучы караңгы чырайлы Хәйдәр (А.Борһанов) бер-берсенең «alter ego»сы сыман. Ата-аналарының талашуы, тимернең тутыгуы кебек үк, аларның балачактагы дуслыгында булган бар яхшылыкны юкка чыгара. Бу бигрәк тә Сәләхетдиннең Мирфатыйх илә су өчен талашу күренеше белән симметрик рәвештә сурәтләнгән автомашиналар узышу вакыйгасында ачык күренә. А.Гыйләҗевтә дә тимер, Ф.Достоевскийдагы кебек, инферналь образга (җәһәннәм образына) әверелә: мотоцикллар, машиналар – хуҗаларының дан ятратуын белдерүче символ. Алардан кешеләрне үзгәртү көченә ия мәкерле энергия чыга сыман. Машиналар узышуы исә юри карнавал формасында сурәтләнә: вентиляторлар, машиналар, ялтыравыклар, биеп торучы кызлар – барысы спектакльне безнең көнгә күчерә.

Ф.Бикчәнтәев көзгеле композиция алымына мөрәҗәгать итә: геройлар тантаналы рәвештә машиналарда китә һәм табутка охшаш носилкаларда кайта. Кулларына гипс салынган «тормыш хуҗалары» спектакль ахырында үтә сатирик образ тудыруга китерә.

Гротескка корылган кыз димләү күренеше дә бик тәэсирле килеп чыккан. Миңлекамал (Фәридә Сафина), Миңлесорур (Фирая Әкбәрова) һәм Гөлсабира (Айгөл Абашева) сәхнәгә берничә минутка гына чыксалар да, тулы, бөтен образ тудыра ала. Алар авылда кич утыру, аулак өйләрне сурәтләгән рәсемнәрдән төшкән кебек. Ф.Сафина, Ф.Әкбәрова авыл гайбәтчеләрен тасвирлаган күренешкә дә табигый кереп китә. Бу күренештә Кирам (Фәнис Җиһанша) да катнаша.

«Җомга көн, кич белән...» әсәрендәге кебек, биредә дә игезәкләр мотивы кабатлана. А.Гыйләҗев Сәләхетдин һәм Мирфатыйх арасындагы дуслык җепләре өзелүне әрнеп тасвирлый. Сәләхетдин илә Мирфатыйх – милли яшәеш нигезләрен гәүдәләндергән идиллик хронотопның өлешләре: «Нинди матур чаклар бар иде! Ничаклы гөнаһсыз, эчкерсез багланышлар яши иде Сәләхәтдин белән Мирфатыйхлар арасында. Юри дә, күңел өчен дә, кирәктә дә бер-берсенә бик теләп йомышка йөрешәләр, бәрәңге утырту, аны алу кебек олырак эшләр ике йорт арасында ел саен уртак башкарыла иде... Эш җитми тату күршеләргә, башлауга тәмамлап куялар иде!..

Ике йорт арасында какшамас татулык хөкем сөрде.

Ишле бала-чагалы ике йорт арасында бернинди яшерен сер, гайбәт, көнчелек юк иде».

Бөек Ватан сугышы дусларның, тәннәрен гарипләндереп, җаннарын саф-таза калдыра: «Сәләхетдиннең кулы яралы иде, Мирфатыйхның, мина ярчыгы тиеп, сул күзе күрмәс булды. Үткен күз кирәк чакта алдан Сәләхетдин йөрде, кул көче кирәк соралганда, иң читен җиргә Мирфатыйх ыргылды – туганнарча яшәделәр күршеләр, дөрес яшәделәр».

Торгынлык елларында башланган ыгы-зыгылы тормыш әлеге гармонияне әкренләп җимерә. Әсәрдә үлем һәм юкка чыгу мотивы әкренләп көчәйтелә. Язкилде озак еллар дәвамында чит гадәтләргә каршы тора ала (Хәйретдин агайның улына баруы). Ләкин нәкъ менә чит-ят гадәтләр күршеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең тамырдан үзгәрүенә сәбәпче була. Сәләхетдин бакча үстерү белән шөгыльләнә башлый. Билгеле ки, җир эшкәртүче татарлар өчен бу бик үк гадәти кәсеп түгел. Тора-бара кыяр үстерү шөгыль дәрәҗәсен уза. Әлеге мизгелдән Сәхәбетдингә характеристика биргәндә, азык-төлек детальләре хакимлек итә башлый. Кыяр үстерү гаилә башлыгының чиренә, маниясенә әверелә. Әкренләп герой укучылар тарафыннан объектлар дөньясының, кыяр парнигының бер өлеше буларак кабул ителә. Гәзиттәге шалкан сатучы урыс генералы турындагы фельетонны укыгач, Сәләхетдингә кыяр сату җене кагыла.

Талашканнан соң, дошманлык һәм антогонизм негатив симметриясе саклана. Һәр образны әхлак һәм әхлаксызлык, көлке һәм курку берләшә.

Авыл халкы иске зиратта бүтән беркемне дә күмәргә ярамаганлыкны белеп алгач куркуга кала. Барысы да, яңа зиратта беренче булып күмелгән кеше үзе артыннан туган-тумачасын да ияртәчәк, дигән хорафатка ышана. Авыл аксакалы Хәйретдин агай (Р.Шәрәфиев), бу күренешнең киңлеген бәяләп, үзен яңа зиратка күмәргә дип васыять әйтә. Үлемнән курку аның туган-тумачасын туганлык җепләре хакында искә төшерергә мәҗбүр итә. Алар барысы да картны әлеге уеннан баш тартырга өнди. Нәкъ менә Хәйретдин агай Сәләхетдин белән Мирфатыйхка аларның берберсенә туган булуын, нәселләренең Мортазиннарга тоташуын хәбәр итә. Язкилдедә янә тынычлык урнаша. Хәйретдин агайга алмашка авылны, Олимпия уеннарында җиңүчеләр әзерләп, дөньяга танытырга хыялланган Җәмил үсә. Аның «тәхет сүзе»ндә милләтебезнең дөньяга танылган легендар улларының – Роальд Сәгъдиев, Зиннәтулла Билалетдиновларның исемнәре яңгырый. Зөфәрнең (Р.Шәмсуаров) намуслылыгы да тамашачыны сокландыра.

Алтын куллы оста Хәйретдин агай туган авылы пространствосын ата-бабалар йоласына туры китереп кора. Язкилдедә агайның кайгыртучан кулы тимәгән бернәрсә дә юк. Картайгач, ул мәктәпкә урнаша, аны тәртипкә китерә. Авылда пожар каланчасы – мәчет манарасының инварианты да нәкъ менә аның ихтыяры белән барлыкка килә. Хәйретдин агай су ашый башлаган зиратны да саклап кала, аны тауга күчерә. Сәерлеге аркасында түгел, туган җиренә, халкына, табигатькә, эчке намуслылыгы аркасында, бу герой татар авылының үзенчәлекле рухы, аны саклап-яклап торучы көч буларак ачыла.

Финалда яңгыраган җырда таркау татар дөньясы барысы да вакытлы, безгә матди байлык турында түгел, күңел байлыгы һәм юмартлыгы хакында да уйланырга вакыт дигән фикерләрне алга сөргән җырны башкаручы хорга туплана. Берлек һәм бердәмлек, ата-бабалар йоласына тугры калу – киләчәктәге бәхетнең нигезе.

Геройлар артындагы зәңгәр күк сәхнәне киңәйтеп җибәрде. Хәтердә, ирексездән, «Җан җылысы» пьесасындагы сүзләр яңарды. Җыр юллары аша яңа буынга сорау бирүче А.Гыйләҗевнең тавышы ишетелгәндәй булды: «Нәселебезнең, ил-йортның, гомернең, җир-суларыбызның, Идел-йортның тарихын җилкәңдә алып бара алырсыңмы? Тавык елы килә калса, нәселне, телне, исемеңне алыштырып, бәкегә чуммассыңмы?»

Ф.Бикчәнтәевнең яңа спектакле язучы прозасында булган драматургия потенциалын тагын бер кат искәртте, аның иҗади сәләтенең үлемсезлеген күрсәтте. Якын киләчәктә А.Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?» һәм «Йөгез, бер дога!» әсәрләре дә сәхнәләштерелер дигән өметтә калабыз. Автор иҗатының рухын саклап, аның текстларына сак караган режиссёрларның уңышка ирешәчәкләре көн кебек ачык.

А.Гыйләҗев әсәрләренең нигезендә язучының кайнар йөрәге, татар халкын, аның тере җанлы кешеләрен үлеп яратуы сизелә. Мирвәли, Шәмсегаян, Бибинур, Галикәй, Хәйретдин агайлар, Әдилә, Сабираттәйләр – бары тик татар дөньясында гына була алган, шул дөньяның үзенә генә хас үзенчәлекләрен туплаган бөек шәхесләр. Шуларның батырлыгы, кешелеклелеге язучыга якты маяк, мәңге сүнмәс җылылыктыр инде, күрәсең.

**Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

# ҖАННАН БҮЛЕНГӘН КЫЙТГА

ЭССЕ

Миңа еш кына шундый сорау бирәләр: «Кайчан прозага күчәсең?» Җитди әйберләр турында да язарга кирәк, янәсе. Әйтерсең лә тезмә формада җитди әйберләр хакында язып булмый. Ничек кенә була әле...

Прозага күчү-күчмәү – вакыт һәм мөмкинлекләр эше. Прозага күчеп, дөньяның үзгә катламнарында казынганчы, инде «сыны-ысулы» табылган үземнең кыска шигырьләремне – «уй тамгаларымны», дөресрәге, «уй төймәләремне» төймәли торсам, хәерле булмасмы? «Уй төймәләрем» хәтта «дару төймәләре» булып та «бәяләнде» кебек...

Шигырьнең мөмкинлекләре прозаныкыннан ким түгел. Шигырьне аз укыйлар, дип, аны язудан туктау мөмкинме соң? Әлбәттә, юк! Шигырь ул язмыйм дисәң дә яздыра. **Шигърият дөньясы** дигән төшенчә ни рәвешле кулланышка кергәндер, белмим... Әмма аны дөнья шигъриятe белән бутарга ярамый. Дөнья шигърияте – бөтен дөньяга билгеле булган язма һәм халык авыз иҗатындагы шигърият, ә **шигърият дөньясы** – галәмнең үзе кебек, әле ачылмаган, үлчәнмәгән, үлчәнә дә алмый торган чиксезлек ул.

Ә шигырьнең асылында, шигъриятнең нигезендә төгәллек, үлчәнгәнлек, камиллек ята... Мөкәммәл шигырь – олы хис, фикер, тәэсир, акыл, хәтер, уй, осталык. Мөкәммәл шигырь – кыска гына текстта сүз-образ аша дөньяга карашыңны, фәлсәфәңне белдерү мәйданы да. Аның башы, үзәге, азагы бар... Ә үзе – чикле чиксезлек. Менә шушы стихия кызыктыра да, үзенә тарта да инде иҗатчыны... Шигырьне «читтән күзәтүче» буларак та «язып» була, шигырьне – «шигырьнең үзе булып» язып була... «Үзе» булып язу кызыграк:

*Мин көзге шигырь –*
*Араламагызчы*
*Көзге төскә кереп януымнан,*
*Янып ялкынланып,*
*Азаккача*
*Алтын төскә кереп калуымнан.*

Язгы шигырь дә, кышкы, җәйге шигырьләр дә бар... Яңгырлы, болытлы, йолдызлы, карлы... Татлы, ачы, төсле, төссез шигырьләр дә була. Шигырьнең тамчы хәлендәгесе дә, дәрья, океан хәлендәгесе дә очрый. Шулар барысы, барысы бергә **шигърият дөньясына** берләшәдер.

Шигырьнең, ни кызганыч, илаһи булганы да, җаһил булганы да бардыр?! Әллә, илаһи шигырьне кимсетү, җәберсетү өчен, Иблис-ләгыйнь юк шигырьләрне дә бар итеп ятамы? Монысы инде шагыйрьнең иманлы, имансыз булуына бәйледер...

Мин шагыйрьдән Пәйгамбәр ясау ягында түгел. Имансыз олуг талант иясе һичкайчан Пәйгамбәр була алмый... Андый шагыйрьнең хаҗәте юк. Пәйгамбәрлек яки илаһилек инкарь ителгән җаһиллек дәверләре, кинәт «килеп яуган болыт кебек» килә дә каплый кешеләр күген, килә дә каплый.

Имансызлык – туеп сикергәндә җәя үз колачын... Аз гына ачлык, ялангачлык килсен генә, шунда ук табыла яңа «Пәйгамбәрләр» һәм «акыл сатучылар»... Ә иманлылык ул, иң әүвәл, **тәүбә** һәм **мәңгелеккә инану**... Мәңгелекнең көченә инану һәм шул көчкә яраклашып буйсыну...

...Шигъриятне, шигырьне хатын-кыз гүзәллеге белән генә тиңләү аны бик тә кечерәйтү булыр иде. Әмма, хатын-кыз гүзәллеге дә – илаһи төшенчә... Шул

гүзəллекнең күрке буларак сурəтлəнгəн Хур кызларының образы-сурəте – үзе үк шигъриятнең бер чагылышы ласа... Шул гүзəл сурəт-образның илаһилыгын бозып язылган шигырь-сурəтлəр – җаһиллекме? Җаһиллектер! Хатын-кыз гүзəллегенең җисми матурлыгына мəдхия укып, җан камиллеген читкə этəргəн шигърият тə җаһил шигъриятме? Əлеге фикерлəрем үземə-үзем каршы килү булып кабул ителерме икəн? Прозаны «тормышның ваклыклары» дип атавым һич тə шигъриятне идеаллаштыруым түгел иде... Бөтен əдəбиятның «əнкəсе» буларак кабул ителгəн бит инде шигърият. Димəк, прозаның да шигъриятле булуы һич тə начар түгел.

Галиҗəнап **сүз** əсəрне купшы бизəүче генə түгел, ул бизəкле, хисле **уй** булырга тиеш. Уй гына күңелгə, җанга үтə. Уйсыз сүз – сурəт кенə. Нинди сурəт? Җавабын белү өчен, уй кирəк. Уйның чиге юк... Əмма тыелган уйлар да бар, алары турында да язарбыз əле.

Уйны тыеп буламы? Əмма уйның гамəлгə ашып, галимнəр əйткəнчə, материальлəшəсе бар бит əле. Билгесезлеккə алып кереп киткəн уйлар чынга ашса, ягъни шул уйларны «материальлəштерə» башласа, Адəм баласы ни-нəрсəлəр кылып ташламас иде? Тыелган уй дип, бəлки, уйны чиклəүгə əйтелəдер... Уйны чикли белү үз-үзеңне саклау, саклану өчен дə кирəк. Шигъри уй исə көтелмəгəн чишелеше мөмкин булган вакыйгалар хакында ачыш ясардай уй-фикер тудырырга, фикер булмаса, тойгы тудырырга тиеш... Һава чиксез, дибез. Ə аның бер чиге җирдə түгелме соң? Җир өчен һаваның чиге, əлбəттə, җир үзе була алмый. Ə җирдəгелəр өчен:

*Күк-җир арасында*
*Бернинди ара юк.*
*Адəм баласына*
*Шул арасызлыктан*
*Чыгарга чара юк...*

Уйлы шигырь – **уй белəн уйнау** дип карала аламы? Уй белəн уйнап буламы-юкмы, белмим. Сүз белəн «уйнап» була. Сүз белəн уйлы уен корырга да була... Сүз белəн уйлы хисне, тойгыны уйнап булмый... Уй – сүзнең əнкəсе. Уйламый əйтелгəн сүзнең əнкəсе – уен булып чыгамы?

Уй белəн уен болай гына кардəш сүзлəр кебек. Чынында – уй беренчел! Уй аңда, күңелдə – бəлки, җанда ук туадыр да əле. Шуннан соң гына сүз сурəтен-образын (тамгасын) чагылдырадыр...

Уйга бирелү, уйга чуму, уйга бату кебек фразеологизмнар (болар үзлəре үк шигъри гыйбарəлəр) халыкның сөйлəм тəҗрибəсеннəн генə түгел, ə яшəү тəҗрибəсеннəн дə чыгып əйтелəдер, мөгаен...

Уйдан тыелу – уйдан чигенү өчен дə уй кирəк.

*Уйлар тулды башкаема –*
*Башкаем уй чүлмəге.*
*Сугып кына ватар идең –*
*Катлы-катлы күлмəге.*
*Уйлар уядыр җанымны –*
*Сораулар туа тора...*
*Төнозыны керфек какмыйм –*
*Җавап көтеп Ай тора...*

Фикерли, сорауларның җавабын белə торган җиһаз-җайланмалар уйлап табалар... Килəчəктə уйлы-фикерле сүзлəрне шул җиһазлар (роботлар) əйтер, дигəн фаразлар да ишетелə... Əмма роботлар уйлы хисне əйтə белерлəрме, уй тойгысын, татлы уйны əйтə-күрсəтə белерлəрме?! Бу хакта уйлап торуның хаҗəте бармы? Бардыр...

Уена чумып, уеннан чыга алганнар аннан нəрсəдер ияртеп чыкмый калмый. Иң кыйммəтле табыш – əлбəттə, энҗе-мəрҗəннəргə тиң – уйлы хисле шигырь, шигъри сүз.

Хисле сүзне роботлар кайчан əйтер? Инде əйтəлəр бит диючелəр булыр, композиторларның компьютер (робот) ярдəмендə музыка язуларын мисал итеп алып...

Рәссамнар өчен пейзажлар да, рәсем-сурәтләр дә ясый алар – заман могҗизасы булган компьютерлар...

*Уйларым уйларга урала,*
*Уелам, уелам – шул гына...*
*Уйлардан кем мине аралар,*
*Ул гына, ул гына, ул гына.*

Ул дигәнем – шул гүзәллек иясе, хатын-кызлар инде. Уйларны чикләү, тыелу өчен, уйсыз гына соклану, гашыйк булу кирәк микән әллә? Алай дисәң, соклану, гашыйк булу – үзе бер хис, тойгы, үзе зур шигърият инде!

**Уйлы шигырьдән шигъри уй** кайсы ягы белән аерыла? Шигъри уй – үзе бер шигърият. Ә уйлы шигырь – бер шигырьме? Әллә бер шагыйрьнең бөтен шигъриятеме? Шигъри «уй»дан бихисап уйлы шигырьләр «тудырып» буладыр. Уйлы шигырьдә дә хис-тойгы өстенлек итү генә шигырь «тудыра», дигәннәре хактыр... Әмма уйлы шигырьдә хис-тойгы «сурәт» булып күренеп тормаска да мөмкин. Ул очракта хис-тойгылар **уйланганнан** соң туадыр. Мондый хис-тойгыны укып түгел, ә сиземләп тою, уйланып тою кирәктер, ягъни, мөмкиндер...

**Мөнәсәбәт** белән **хис-тойгы** төшенчәләре никадәр тугандаш икән? Уйлы шигырьдә аерылгысыз шарт булып «мөнәсәбәт» торадыр. **Уй = тойгы уяну + тойгы кичерү+мөнәсәбәт белдерү**...

Уйлы шигырьнең формуласымы бу? Шулай дип карарга да мөмкин. Фәндә эстетик кыйммәтләр дигән төшенчә шул мөнәсәбәтнең булу-булмавы, нинди рәвештә булу-булмавы турында да бит! Уйлы шагыйрь мөнәсәбәт-тойгы буларак дөнья фәлсәфәсенең, ягъни, дөнья яратылышы һәм бөтен цивилизациянең көн итү, үсеш процессларын да чагылдыра. Эволюцион үсеш кешелекнең, кешеләрнең үз эчендәге һәм үзара мөнәсәбәтләре җыелмасы да:

*Барысы буйсынган*
*Көтү анасы бар,*
*Адәм баласының*
*Карусыз бүредән*
*Гыйбрәт аласы бар...*

Буйсынмау һәм карусызлык – мәңгелек каршылыктагы мөнәсәбәтләр хәле. Беркемгә дә буйсынмаучылыкның, үҗәт горурлыкның мисалы булып бүреләр тора. Буйсынмас бүреләр өерләре, гаиләләре белән яшиләр. Бернигә буйсынмыйлар. Ә үзләре кабул иткән көтү башына – ыру башына – ил башына – ана бүрегә – көтү анасына карусыз, бернинди шартлар таләп итмичә буйсыналар. Шул буйсыну, шул үзара урнашкан мөнәсәбәтләре белән алар үзләренең табигый сакланышын-сайланышын тәэмин итәләр.

Адәм баласы кешелекнең үсешенә ни-нәрсә белән комачаулый? Кешеләрнең, кавемнәрнең, милләтләрнең үзара мөнәсәбәтләре ни өчен гел кан коешка, көчләп буйсынуга, коллыкка, гаделсезлеккә, кешелексезлеккә этәрә? Бәлки, «карусызлык», бүреләрдәге кебек «буйсыну» кирәк булгангадыр...

Менә бу – **мөнәсәбәтле-уйлы** дип бәяләнгән бишьюллыкның бер формасы. Шушы форма белән бихисап күптөрле мөнәсәбәтләрне, тойгыларны уятып була. «Адәм баласы» тупламалары белән шагыйрь моны инде раслады кебек. Шундый ук хис-тойгы, мөнәсәбәтләрне башка үлчәм-формаларда да күрсәтеп буладыр. Әмма бишьюллык иң кулае кебек... Төрки телле мәдәниятләр, гомумән, Шәрекъ мәдәниятендә бишкә бүленгән үлчәмнәр өстенлек итә. Бу хәл табигатьнең үзендә дә бик еш чагылыш таба. Карагыз, биш таҗлы чәчәкләр никадәр, яисә бишкә бүленә торган саннар санынча күпме җисемнәр бар. Шәрекъ музыкасы биш төрле авазлар тирбәнешендә туа...

Уйлы шигырьнең чагылыш тапмый кала торган өлкәсе юк. Чөнки һәр ни-нәрсәгә **мөнәсәбәт белдереп була, мөнәсәбәт белдерелә**. Шулай мөнәсәбәт белдереп яшәү тәҗрибәсе туплана. Адәм баласы, тулаем кешелек яшәү тәҗрибәсе җыя, акыл-зиһен туплый, җанына камиллек өсти бара.

Уйлы бишьюллыкта бөтен бер тарихи дәвер-чорларга мөнәсәбәт белдереп була. Менә карагыз:

*Садакта – ук җиде,*
*Янында – алмаш ат...*
*Адәм баласының*
*Яулап алган җире*
*Оныкларына ят...*

Шигырьнең баштагы ике юлында XIII гасырда дөньяның иң камил кораллы сугышчысы-яугире турында (монгол-татар сугышчысы) хәбәр ителә. Ул шул алмаш ат (алмаш машина, алмаш танк, алмаш самолёт) бәрабәренә яңа тизлеккә ирешә, бөтен дөньяны чолгап ала. Һәм, җиде гасыр узгач, шул яугирнең оныклары бу җиргә хуҗамы соң? Мөнәсәбәтле сорау куела: яулап алган җире оныкларына ят. Шигырь уйланырга мәҗбүр итә: кан белән яуланган барыбер ятка кала, дигән фикер-хис барлыкка килә. Шул фикер-тойгы кешенең үзенә сабак алсын өчен җиткерелә.

*Бер кат кисәр өчен,*
*Җиде кат үлчәгән*
*Адәм баласының*
*Җиде буыннан*
*Мирасы күчмәгән...*

Бу бишьюллыкта бер кавем, бер халыкның: « Җиде кат үлчә – бер кат кис!» – дигән мәкаленә мөнәсәбәте белдерелә. Ягъни билгеле бер шартларда (тарихи шартларда) тәвәккәллек, ихтыяр көче булмаса, вакыт биргән форсатны кулдан ычкындырасың, барына өстәү урынына булганын да югалтасың, дигән мөнәсәбәт-уй әйтелә. Бүген иманасыз калган халык-милләтләр өчен дә бу – **уйлы-шигырь**. Ул нинди хис-тойгылар уятты?.. Иң әүвәл үкенү хисе, аннан соң хурлык, ихтыяри тәвәккәллек хисләрен булдыру кирәклеген уятты. Шигырьнең эстетик көче шигырьдәге фикернең, хис-тойгының көченә бәйле. Эстетик кыйммәте исә ул тойгы-хисләр гомумкешелекнең гуманлы хис-тойгыларын уятуга тәэсир итү дәрәҗәсе белән билгеләнә.

*Саф алтыннан табут,*
*Күпме яткан сыеп?!*
*Адәм баласының*
*Җанын күрмәкчеләр,*
*Сөякләрен җыеп.*

Бу бишьюллык Мисыр пирамидаларында алтын табутларда табылган сөякләрне күреп, аларга мөнәсәбәт белдерү уңае белән язылды. Фиргавеннәр хакимлек иткән 30 гасыр дәверендә үлемсезлеккә омтылу бик көчле булган. Адәм баласының җаны, һичшиксез, үлемсез булуына бер мисал бу... Әмма җан – Аллаһы ихтыярында. Ул 30 гасыр элек тә шулай булган. Җанны алтын табутта саклап булмый. Ул, ягъни бер җан, җирнең бөтен алтыннарыннан да әһәмиятлерәк. Аллаһыга җирнең пирамидалар хәтле алтыны да кирәк түгел. Аңа үзе тергезгән җан кирәк. Ул аны Адәм баласына «бирә», «ала». Сөякләренә карап кына « җанны» эзләп табу мөмкин хәл түгел. Хәтта биотехнологияләр, имплантацияләр ярдәмендә сөякләргә ит-тире кундырырга да, каннарын булдырырга да мөмкиндер, ә менә «җан»ын фәкать Бер Аллаһы үзе генә «терелтә» ала.

*Акылсыз батырлар,*
*Хәерче тыйнаклар –*
*Адәм баласының*
*никадәр холкына*
*шулкадәр үрнәк бар...*

Яки:

*Яшен яшәгән дә,*
*Ашын ашамаган*
*Адәм баласына*
*Кем дип дәшәргә дә*
*Белми аптыраган.*

Бу бишьюллыкларда мөнәсәбәт-тойгылар туры мәгънәле сүзләр белән әйтеп-күрсәтеп бирелә. Алар да моңарчы халык әйтемнәрендә чагылыш тапкан, уй-тойгылар заманча карап шәрехләнә (интерпретацияләнә).

Уйлы шигырьдә, мөнәсәбәт белдерү, тойгы уяту белән бергә, мәгърифәткә өндәү, әдәп-әхлакка чакыру, әхлак кануннарын җиткерү дә бар. Бу инде – шәрекъ әдәбиятының гасырлардан-гасырларга күчеп килгән традициясе. Һәм, әйтергә кирәк, күркәм традиция.

*Сый-хөрмәт асылы,*
*Сыйдан зур булмый тор...*
*Адәм баласының*
*Хөрмәтсез сыена*
*Кулыңны сузмый тор.*

Яки:

*Ялган сүз – өшетер,*
*Мактау сүз – эретер.*
*Адәм баласының*
*Тел төбендә йөрер*
*Бер кашык дегете.*

Яки:

*Әтәч сугыштыр да,*
*Таракан узыштыр.*
*Адәм баласының*
*Тамагы туйгачтын*
*Уе – азып тузыштыр...*

Шул рәвешле, «Адәм баласы» калыбына салынган бөтен шигырьләрне «сүтеп-җыеп» булыр иде. Һәм уйлы шигырь турында уйлануларны дәвам итеп булыр иде.

Уйлы шигырь нәрсәдән туа? Бу сорауга инде белеп-белмичә җавап бирдем дә кебек... Дөресрәге, үземнең уй-мөнәсәбәтемне белдердем. Әйе, уйлы шигырь шигъри уйдан туа. Ул, ягъни уйлы шигырь, шигъри уйның бер өлеше, миллионнан бер кисәге генә.

Шигъри уй үзе табигый рәвештә «яши». Кеше шул катламга, шул агышка «юлыга» да уйга бирелә. Шул уйлар агышы Җанына кагылгач кына, бәлкем, күңеленә кагылгач кына, уйлы шигырь туадыр.

Шигырьнең дә берничә төрле хәле бар. Матдәнең дүрт төрле хәле – сыеклык, каты җисем, газ һәм ут хәле булган кебек, шигырьнең дә дүрт хәле бар: **уй-тойгы хәле, язма-сурәт хәле (график хәле), аваз яңгыраш хәле һәм ут-нур хәле... Шигъри уй – шул дүрт хәлнең бергә булган мәле**.

Уй-тойгы хәлендәге шигырь – күңелдә, язма-сурәт хәле – китапта, аваз-яңгыраш хәле – **сәхнәдә, эфирда, җырда**, ут-нур хәле **җанда, галәмдә, табигатьтә** чагыла.

Шигырьнең моң хәле дә ут-нур хәлендәдер. Шул дүртенче хәлендәге «мәлен» тойганда гына, чын шигырь туадыр. Шигъри уй – шигъри дөнья бөтен галәмдә, галәмнәрдәдер. Бу хактагы бәхәсле уй-мөнәсәбәтләремне, мөнәсәбәт-тойгыларымны белдереп, мин шундый шигырь язган идем.

*Всё исчезает,*
*остаётся пространство,*
*звёзды и певец…*
О.Мандельштам

*Эфирда җыр:*
*Балачактан таныш,*
*Күңелгә ятыш моң агыла...*
*Биектә-биектә,*
*Ак болытларга терәлеп,*
*Бер нокта талпына...*
*Телиме арынырга Җирдән?*

*Димәк:*
*Җырдан да???*
*Талпына-талпына,*
*Үзенә ул җырны чакыра –*
*Димәк:*
*Ул – җаны вафат җырчының –*
*Сусаган үз җырын тыңларга?!*

Шигырьнең төп уй-фикере – җырга мәдхия, җырны-шигырьне зурлау. Аның фәкать Җирдә генә булу мөмкинлегенә ишарә итү. Хәтта ак болытларга терәлеп талпынган җырчы-тургайның да, вафат булган җырчының Җаны белән чагыштырып, җырлы җирне сагынуын шагыйранә әйтергә омтылам. Моның белән: җырлап яшәгез, гомер бер генә, дип әйтергә телим, чакырам, үгетлим...

Ә үзем, шагыйрь буларак, шигъри уйның, шигъри дөньяның җир кысаларында гына калуына һич тә разый түгелмен. Хәтта үз-үземә каршы килеп язылган, дөресрәге, шул хакта уйланулардан туган тагын бер шигырем бар. Ул шигъри хиссиятне зурлап язылгандыр.

*Аерма татлы газабың,*
*Шигърият, колыңнан.*
*Сине эзләп килде җаным*
*Мең яктылык елыннан?*

Монда да шигъриятнең кешелек бишеге җирдә генә булуына басым ясала. Ә җанның шундый еракtan килүе аның өчен шушы илаһи хис-тойгының, нурның калебкә бик тә хаҗәт булуына ишарәли...

*Читләштеләр күпләр, инде син ят –*
*Сан бирерлек, имеш, сының юк...*
*Тик мин һаман колың, шигърият,*
*Синнән башка сыеныр җылым юк...*

Бу шигырьдәге уй-хисләр дә шигырьнең яшәү-энергиясе, җылылык чыганагы булуына ишарә ителгән, хәтта ишарә ителгән генә түгел, ә тәкрарланган уй-мөнәсәбәт-тойгы белдерелә. Шулай ук бүгенге көндә компьютерлы буынның шул илаһи халәттән читләшүенә рәнҗү-үпкә дә барлыгын тоярсыз дип ышанам.

Кабаттан «Адәм баласы»на кайтыйк.

*Яктылык елының*
*Үзгә фасыллары...*
*Адәм баласының*
*Нурга әверелеп*
*Күрер кайсылары,*

– дигән юллар язылды...

Яктылык елының нур эчендәге серенә компьютерларсыз төшенеп булмастыр да. Неоплатанизм фәлсәфәсе Аллаһ Нуры кешенең акылын, җанын, тәнен яралткан, җир шул илаһи нур аша яратылган, дип саный. Бу хакта Изге китапта, иң якты нур – ул илаһыдан өрелгән Җан нуры, диелә. Шәрекъ әдәбиятында әлеге фәлсәфи тәгълимат һәм нур образы гаҗәп күп кулланыла. Җанның нурын, аның үлчәмен уй һәм хис бердәмлеге, тәңгәллеге, камиллеге аша гына ачыклап буладыр, дип уйлыйм.

Уйлы шигырьне һәр шагыйрь яза. Уйлы шигырь белән фикерле шигырь бер үк төшенчәме икән? Әйе дә, түгел дә кебек. Уйлы шигырь уйлануның агышын, уйлы

халәтне чагылдыра. Һәм шул процесста фикер дә туа. Фикер исә уйлану процессы сурәтләнмичә дә әйтелергә мөмкин... Көчле, яңа фикерләр уйлану, анализлау, чагыштыру, гомумиләштерү процессы күзгә бәрелеп тормас рәвештә язылып, соңыннан укучыны уй-мөнәсәбәтләргә дә этәрергә мөмкин. Мөмкин генә түгел, ә этәрә һәм уйландыра да. Аларның эстетик кыйммәте дә шунда.

Хәзерге заман шигъриятенең иң күренекле вәкилләре булган Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалим, Рәдиф Гаташ, Ренат Харис иҗатларыннан уй һәм фикер сурәтләнешләренең һәр ике очрагына бихисап күп мисаллар табып була.

Р.Фәйзуллинча: «Көрәшчеләр кирәк...» Кеше җаны өчен көрәш бара. Тормышта үлеп тә үлемсезлек яулау бердәнбер юлмы? Татарстан – «дәүләт тимерчелеге» һ.б. **фикере алдан бәян ителеп язылган юллар**.

Р.Мингалимдә: «Кешелек белән сөйләшү», «Минем бәхетем», «Өлеш», «Әрсезләр», «Военкоматта», «Иртәгә», «Минем дәүләт» һ.б. **уйланулы шигырьләр**.

Р.Хариста уй-фикер бердәмлеге аеруча сонетларда тирән фәлсәфи югарылыкта бирелә.

Р.Гаташта хәтта мәхәббәт лирикасы да тулаем сагышлы уйлардан торадыр кебек...

Газинур Моратның « Төнге әверелеш» исемле китабын һәм шул исемдәге шигырен тулаем уй-кичерешләр йомгагы дип атап булыр иде.

Лена Шагыйрьҗан шигырьләрендә уй-фикер аның чәчән буларак язылган әсәрләрендә турыдан-туры әйтелә, ягъни, автор укучысына: «Ач күзеңне – дөнья бу!» – дип искәртә. Минем максатым исемнәре аталган әлеге шагыйрьләрнең олы иҗатына анализ ясау түгел. Шуны гына әйтүем: мин алар язганнарны һәрчак тәэсирләнеп укыйм. Алар белән килешәм дә, бәхәсләшәм дә. Алар белән күпчелек мәсьәләләрдә аваздаш, фикердәш булуымны да таныйм.

Уйлы шигырьләр Гамил Афзал шигырьләренең нигезен тотып тора, дияр идем. Аның хәтта юмор-сатирасы да тулы бер гасырда урнашкан тәртипләр турында уйларыннан килеп чыккандыр. Шагыйрьнең үз биографиясе шул тәртипләр белән җитди каршылыклы мөнәсәбәттә булуының нәтиҗәсе түгел микән әле?! Ул да, уйлы җөмләләрен әйтә дә, фикер-нәтиҗә ясауны укучыга калдырып, «шуннан үзең аңла инде, агай-эне», дигәнрәк фикер калдыра.

*Монда бар да тигез:*
*«Син – абзый», «Мин – абзый»*
*Иңне куеп иңгә,*
*Комсомоллар белән бергә*
*Кичәге кулаклар җир казый.*

Бу юлларда XX гасырда урнашкан тәртипнең башлангыч, 30нчы еллары чагылса:

*Агыйделнең аръягыннан*
*Замана баласы килә.*
*Укымый да, эшләми дә,*
*Алга барасы килә.*

– дигән юллар инде яңа тәртипләрнең искереп, бюрократия, күз буяу, алдау-йолдауга корылган 70-80нче еллар турында уй-мөнәсәбәтләр белдерелә.

Уйлы шигырь – шагыйрь Рәниф Шәрипов иҗатына да хас күренеш. Аның үзгәртеп кору чорына багышлаган шигырь-поэмалары авторның вакыйгаларга мөнәсәбәтле уйлары, бәяләмәләре булып сурәтләнә.

Уйлы-фикерле шигырьнең билгесе, төгәл форма-жанрлары бармы, дигәндә, юктыр, дип әйтәсе килә. Әлбәттә, безнең традицион шәрекъ шигъриятендәге робагыйлар, нәзирәләр жанры моның өчен бик тә кулай. Көнбатыш шигъриятенең сонетлары, Көнчыгыш афоризмнары, мәкальләре һәм, әлбәттә, япон танкалары, хоккулары уй-фикер, мөнәсәбәт-хисне чагылдыру өчен төгәл формула булып тора кебек...

Уйлы шигырь ничек туа, дигәндә, аңа төгәл җавап биреп булмыйдыр. Һәр иҗатчыда үзенчә туадыр... Шул ук вакытта уйга бирелү процессы – үзе үк **шигъри халәт**, дип

әйтсәк, медитация күренешенең чын-чынлап уйлы халәт булуын, эчке энергиянең бер уйга төбәлгән, ниятләнгән булуын **тоемларбыз**... Тоемлау – халәт, дип бәяләнсә, мин аны, һичшиксез, уйлы шигъри халәткә бер башлангыч адым, дип бәяләр идем.

Медитация шигъри халәткә генә хас күренеш түгел. Медитация юлы белән, дөресрәге, ысулы белән кешеләр үзләренең психик энергияләрен бер нияткә туплап, хәтта икенче вакыт яссылыгына сәяхәт кылалар. Үзләренең үткәннәренә, киләчәкләренә «барып кайталар». Күрәзәче-шаманнар бу халәтне кәсеп итеп, тәкъдир китабы – «Ләүхел мәхфүз»гә «үреләләр». Анысы – аларның эше. Иҗатчының медитациясе үзгә... Ул тоемлау, дөресрәге, уйлану аша тоемларга, белергә тели күрәсең...

Медитация процессында иҗатның **аң асты – подсознание** (ә мин аң өсте, дияр идем) кемгә, ни-нәрсәгә мөрәҗәгать итә? Шигъри уйга, билгеле. Ә кайда ул шигъри уй? Кем кая яшергән аны? Шигъри уй «подсознание»дән дә ерактарак – **күңел, рух биеклеге** катламындадыр. **Күңел, рух катламнары – җан нурының** бер яктысыдыр. Медитацияне «илһамлану», дип тә, «моңлану», дип тә атыйлар.

*Моңлан әле, и кешем!*
*Дөнья фани, моңлы мизгел –*
*Мәңгелекнең бер төше...*

Медитация – иҗади халәт буларак, Җанга елышу, Җанга якынаю, Җанны тоемларга омтылу ул. Җан Аллаһ нигъмәте булганлыктан, иҗади бәйләныш, иҗади ният тә, һичшиксез, Илаһи булырга тиеш! Аллаһы, Илаһи сүзләрен генә тезеп язу, ул әле илаһилыкны билгеләми. Каләмеңнең Илаһы нурына манып язылуы фарыз!

*Күзгә-күз багып бирәмсең сәламең,*
*«Туганым», – дип өзеләме камәлең?*

*Нәсел-ыру, ил-йорт йөге иңеңдә –*
*Нык будыңмы билеңдәге камәрең?*

*Дога, бәддогамы вәгазь таләбең?*
*Вәгъдәңә тәңгәл ятышмы гамәлең?..*

*Яктыртмакчы күңлең күген күпләрнең,*
*Кояш, Ай, Йолдызлымы үз галәмең?..*

*Искәндә дулап җаһиллек җилләре,*
*Имангамы чакыра бу әләмең?*

*Уңмас, җуелмас Илаһым нурына,*
*И Мирза, манып язамсың каләмең?..*

«Адәм баласы» исемле шигырьләр җыентыгым басылып чыгу, Аллаһыга шөкер, әдәби җәмәгатьчелекне битараф калдырмады. Бик күпләр, телефон аша да, күрешеп сөйләшкәндә дә, уй-фикерләрен җиткерделәр. Барысы да күккә чөеп мактадылар, дисәм, дөреслеккә туры килмәс иде. Кемдер: «Шигырьдән ребус, кроссворд ясау нигә кирәк? Шигырь һәркемнең колагына җырлап килеп керергә тиеш, җиңел аңлашырга тиеш», – диде. Хактыр. Андый шигырьләрне язу өчен аеруча осталык кирәктер, бәлки. Кемдер: «Адәм баласы сүзе һәр шигырьдә кабатланып килә дә, укучыны ялыктыра», – дигән фикерен белдерде. Ул да хаклыдыр, мөгаен. Кемдер: «Бу өр-яңа шигырь формасы һәм, хәтта, эстетик бәйләнышы белән өр-яңа жанр», – дип бәяләде.

Галимә, шигырь төзелеше буенча белгеч Фәридә ханым Хәсәнова «Адәм баласы»н фәнни-тикшеренү объекты итте. Профессорлар Резеда Ганиева, Фәрит Яхин, Әнвәр Шәриповлар да «Адәм баласы»н **өр-яңа шигъри форма һәм жанр буларак** кабул итүләрен белдерделәр. Рәдиф Гаташ, Ренат Харис, Гәрәй Рәхим, Ркаил Зәйдулла,

Рәшит Бәшәр, Хәнәфи Бәдигый, Шамил Маннапов, Рәниф Шәрипов, Уфадан Марат Кәримов, Тамара Ганиевалар «Адәм баласы»н туплама-цикл буларак «яңа табыш», дип бәяләделәр. Бу табышны киң җәмәгатьчелеккә һәм фәнни даирәдә тарату максатыннан, Россия югары аттестация Комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән «Вестник Поморского университета» фәнни журналында (2009, №9), «Фәнни Татарстан» (2009, №4), «Идель» (русча; 2009, №9) һәм «Казан утлары» (2010, №4) журналларында әдәбият теориясе фәне таләпләренә нигезләп исбатлау тәкъдим ителде.

Галимә Ф.Хәсәнова, «Адәм баласы» тупланмасы шигырьләренең поэтик үзенчәлекләрен күрсәтү максатында, Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты, Казан (Идел буе) федераль университеты, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре, бертөркем шагыйрьләр, студентлар өчен лекция укыды һәм фикер алышулар оештырды.

Бу сорауны минем үземә турыдан-туры бирүчеләр дә бар. Мин әдәбият белгече дә, шигырь төзелеше буенча галим дә түгел. Мин шигырь язарга утырганда, әдәбиятка берәр яңалык кертим әле дип уйламыйм. «Адәм баласы» үзеннән-үзе туды. Минем күңелемә әзер калыпка нигезләнгән шигырь юллары килә башлады. Башта шул ритмика кысаларында берьюлы берничә дистә шигырь язылып та куелды. Аннан соң күңелемдә йөрткән уйларны, хисләрне кәгазьгә төшерәм, дисәм, үзем дә сизмәстән, шул калыпта яза башладым. «Адәм баласы»ның лирик каһарманы кем соң ул, дигәндә, иң беренче чиратта, ул – үзем, дип җавап бирәм. Ул – шулай ук сезнең һәркайсыгыз да, ул – бер ыру, бер милләт, бер кавем, бөтен кешелек тә булырга мөмкин. Ул бәхетле дә, бәхетсез дә, йомык та, сәрхуш тә, батыр да булырга мөмкин.

Шигырьдә кеше, кешелек турында уйланулар, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдыручы мәкаль-әйтемнәрне куллануны мин отышлы күрәм. Әйтем-гыйбарәләрне үзем дә язам. Алар бу шигырь калыбына бик уңышлы гына кереп утырган да кебек тоела. Шигырьдә әйтем-мәкальләрне хуплыйм яки кире кагам, ягъни, заманага карап, интерпретация ясыйм.

Яңалык ачыйм әле, дип язарга утырса, һичкем яңалык **ача** алмаячак. Ул иҗат процессында гына туадыр... Минем «Адәм баласы» кыска шигырьләр язганда барлыкка килде. Яңалыкмы, түгелме – бәя бирү сезнең эш, – дип җаваплanам, уйга калып. Галимә Фәридә Хәсәнова бөтендөнья шигърияте, шәрекъ шигърияте тарихы мисалларында үзенең фәнни ачышының хаклыгын дәлилләде. Профессорлар Резеда Ганиева, Дания Заһидуллина, Фәрит Яхин, шагыйрьләр Зиннур Мансуров, Равил Рахманилар беренчеләрдән булып, аның бу фикерен хуплап, үз бәяләрен белдерделәр. Миңа калса, яңалык буларак кабул иттеләр кебек. Шулай итеп, мин «Адәм баласы»на тагын да җитдирәк карый башладым һәм бер ел дәвамында тулы бер җыентык итеп бастырып чыгарырлык өр-яңа шигырьләр тудырдым. Аларны мин бик җиңел язам, дип әйтә алмыйм. Әмма уй-фикер диңгезенә чып-чынлап чумасың икән, табасы барыбер табыла, иҗат ителә. Аллаһыма мең шөкер!

Әлеге прозаик чигенеш – шигъри уйны, уйлы шигырьне беркадәр кимсетә торган күренеш. Нишләмәк кирәк, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр тормыш-көнкүрешнең вактан-вак мәсьәләләренә мөнәсәбәтле рәвештә туалар. Адәм балалары шул тормышның вактан-вак мәсьәләләрендә вакланып бетәргә дә, шул вактан-вак мәсьәләләрдән өстен дә булып калырга мөмкин. Мөнәсәбәтләр тормышның иң вак, димәк, көн итүдәге **иң хаҗәт** әйберләренә **ихтыяҗ**ның булу-булмавына да бәйле шул.

Адәм баласының ихтыяҗы йөгәнлеме, ягъни нәфесе йөгәнлеме? Бу – мәңгелек сорау. Бу – «Адәм баласы»ның хаҗәт-ихтыяҗ колына әверелүе-әверелмәвенең бер чиге. Шул хакта уйланулар, мөнәсәбәт-тойгылар «Адәм баласы» җыентыгының төп өлешен алып тора да. Әмма, дөнья ваклыгыннан өстен булам, дип, кешеләрнең тормыш итү, яшәү рәвешеннән читкә китеп булмый шул.

*Ике дөньяда да*
*дан, мал бүлеше бар.*
*Адәм баласының*
*тәкъдиренә язган*
*өлеш-көмеше бар...*

Уйлы шигырьләр Адәм балалары арасындагы мөнәсәбәтләргә дә, Адәм баласының, гомумән, үзе хакында, аның галәм объекты буларак бу дөньяда, бу галәмдә кирәклеге хакында да чиксез уйлануларга этәрергә мөмкин.

*Галәмнәрнең үзгә*
*елы фасылында*
*Адәм баласының*
*үзгәреп торадыр*
*каны басымы да...*

– бу юллар Адәм баласының, хәтта тәне-яшәешенең күккә бәйлелегенә ишарә булса:

*Бөек Рух – мәңгелек,*
*чиксез яралышта...*
*Адәм баласының*
*тәнендәге җаны*
*шуңар бәйләнештә...*

– дигән уйлы юллар – аның рухы, җанының галәмгә бәйлелеге хакындагы уйлар...

Гадидән дә гади, һәркемгә дә билгеле тормыш күренешләре, Адәм балаларының шул тирәнлектәге мөнәсәбәтләрен чагылдыру өчен, нинди медитацияләр кирәк булсын, дигән сорау да куелырга мөмкин. Медитация хакында фикерләремне җиткергәндә, мин **«Адәм баласы»**на гына хас уйлы «дөньяга чыгу» турында әйтмәдем. Тирән уйга бирелү һәм ачык ният-теләктә булу билгеле бер халәтне тудыра, шул халәттә уй һәм тоемлау бердәмлеге, тәңгәллегенә ирешелә. Югарыда мин аны инде **моң** дип тә атадым. Моң дәрәҗәсенә, моң катламына күтәрелү өчен, медитация кирәктер, зарурдыр.

*Курыкма, биек оч, кошым,*
*Күк чикне беләмени?!*
*Көл түгел, дөньяның моңы*
*Бер безгә генәмени?!*

Бу юллар – Равил Фәйзуллиннан. Аның «Кош»ы – һичшиксез, рухы, җаны... Ә «моң» дигәне бөтен дөньясыннан чиксез күккә кадәр җәелгән. Бу очракта шагыйрьнең «моң»ы сагыш мәгънәсенә дә тарта. Ничек булса да, бу – **уйлы халәт, уйлы шигырь** процессының бик уңышлы үрнәге. Әле шигырьнең азагы тагы да тәэсирлерәк:

*Оч, оч, кошкай, кис җилләрне,*
*Шан, рухым, дуласын җан...*
*Егылсак, күргән-белгәннәр*
*Яхшыга юрасыннар...*

Рухны, җанны дулатырлык нинди көч бар кошта? Ул – канатлы илһам, иҗади энергия, медитация халәте түгелме? Ул халәттә егылу куркынычы да бармыни, диярләр? Күрәсең, бар. Уйны да чикли белергә кирәк, дигәнгә ишарәдер бу, бәлки.

**«Егылсак, күргән-белгәннәр яхшыга юрасыннар»** – бик күп мәгънәләрне, халәтләрне искәртә торган юллар. Ул «Кайсыгызның кулы җылы» кебек серле гыйбарәгә әверелеп китәргә лаек. Шуңа тиң шигъри табыш бу, «уйлы шигырь»нең матур үрнәге.

**Уйлы шигырьдә «уйлы уен» яки «уенлы уй» да булырга мөмкин**. Бу инде сүз белән «уйнау»га кагыла. Аерым сүзләрнең язылышы, тамыры, кушымчалары аша «Адәм баласы»ның холык-фигыле, үзара мөнәсәбәтләре сәбәпләрен ачарга мөмкин. Әйтик, «ат», «зат» сүзләре. Ат – бик көчле тереклек иясе, кешенең юлдашы. Ат – исем. Ул – кешегә бирелгән код. Зат – сыйфат төшенчәсе мәгънәсендә. Ул – «кеше» сүзенең синонимы да. Атлы – затлы. Атың кем? Исемең кем дигән мәгънәдә. Затың кем? Кем улы, кайсы нәселдән булуны аңлата.

«Атың кем?» дигәндә, бәлкем, «Атаң кем?» дигән мәгънәле сорау куелгандыр. Болай булганда, «Атың кем?» соравы «Затың кем?» соравы белән синонимлаша да. Ат – зат, атлы – затлы. «Аталы – затлы» бик тирән мәгънәләрне аңларлык төшенчәгә әверелә. Шул сүзләрдә шигъри уй бар да бар инде. Атның да төрлесе бар, затның да. Дөньяда болай гына бар да тигез кебек... Ә чынында атына, затына карап бирелә бәяләр.

Әйтик:

*Алашага – тышау...*
*Айгырга – арата.*
*Адәм баласының*
*башында бармы уй*
*шул хәлгә карата?*

Яки:

*Ал бирсә – ат елый,*
*бирмәсә – ул яна...*
*Адәм баласының*
*шуңар ирешкәне*
*ир-ат исемен ала...*

Яки:

*Атына карап та*
*салына солысы...*
*Адәм баласының*
*үз урнын беләме*
*кечесе, олысы...*

Халык сөйләмендә кемнедер орышканда: «Ул затсыз», – диләр. Бу инде ата тәрбиясе алмаган бәндә дигәнгә ишарә. Аты, заты булмаганнарга да « ат» сүзе ят түгел, аларның үзләреннән алда кушамАТлары йөри, ягъни аларның сыйфат дәрәҗәсенә, «затлы» лык дәрәҗәсенә бәя бирелә.

Сүзләр белән «уйнап» булган кебек, моңарчы халык авыз иҗаты булган мәкаль, әйтемнәр, гыйбарәләр белән дә «уйнап» була, ягъни хәзерге көндәге шартларга яраклаштырып яки капма-каршы куеп, аларга яңа төс, мәгънә бирергә, аларны хупларга, инкарь итәргә, яңача интерпретацияләргә мөмкин.

Янә Равил Фәйзуллиннан бер мисал: **«Җаныңның ваклыгын / Сылтама заманга»**. Шагыйрь:

– Һәркем үз заманының баласы;
– Заманына күрә ярый;
– Килде безгә замана;
– Һәр заманның үз чире була;
– Заманасы үзгәрде

кебек шундый һәм шуңа охшаш башка гыйбарәләр хакында уйга чумып, Адәм баласының холык-фигыленә бәя бирә, үз мөнәсәбәтен-тойгысын җиткерә, башкаларны уйларга мәҗбүр итә.

*Эт – дус, Бүре – дошман,*
*һич юктыр бутасы...*
*Адәм баласының*
*теккән эт тиресе –*
*бүрегә, унтасы...*

Минем бу шигырем дә нәкъ югарыдагы мисалга аваздаш. Беренче юлдагы әйтемнән ул көлүгә корылган булуы белән аерыла, ягъни сүз уйнату рәвешендәге уйлы шигырь, фәнни итеп әйткәндә, каламбур.

Уйлы шигырьне әдәпле фәлсәфә, акыллы сүзләрдән торган юллар тезмәсе, дип

карау бик тә примитив бәяләмә булыр иде. Уйлы шигырьдә киная, төртмәле сүз, юмор, каһкаһәгә дә чикләнмәгән мөмкинлекләр тулып ята. Аларны мәсәл, эпиграмма формасына гына түгел, робагый һәм шул ук «Адәм баласы» калыбына да кертеп була.

*Бар гавам күрде гыйбрәтле өч мәлеңне:*
*Үз арбаңнан чит арбага күчкәнеңне,*
*Ятка мәңге бергә, дип, ант эчкәнеңне,*
*Арбаларыннан тибелеп төшкәнеңне.*

Яки:

*Шәп җырладың җырларын – бик мактадылар.*
*Мактадылар, әмма медаль такмадылар.*
*Шәп җырласаң да, үзләре арбасына*
*Сине утыртырлык урын тапмадылар...*

Яки:

*Әйбәт егет булып телгә кергәнсең,*
*Кайсы сөягең сөйкемле – белмәссең?*
*Юкса гомер буе дус-иш, кардәшне*
*Син кәкре каенга терәп йөргәнсең!*

Яки:

*Милли ашың булса төче кыстыбый,*
*Сине һичкем ау чыгарга кыстамый...*
*Тары җирең, киндер җирең – чәч тә ур!*
*Авызыңа тулып торыр бал да май.*

Яки:

*Фәрештә түгелсең – читкә йөргәләдең,*
*Кача-поса уҗымга кергәләдең.*
*Кардәш, дусның маңгаена мөгез куеп,*
*Күрәләтә: «Син мүкләк», – дип сөзгәләдең...*

Яки:

*Үзе – таңнан эштә,*
*акылы – төштән соң...*
*Адәм баласының*
*кайчан, кайда, ничек*
*авызы пешкән соң?..*

Уйлы шигырь, шигъри уй төшенчәләрен гомум фәлсәфи лириканың үзгә бер төре дип карап буладыр. Әлбәттә, һәр иҗатчыны үзеннән-үзе туган уеның әсире, тоткыны дип кенә санау дөрес булмас иде. Уйлы, фикерле иҗатчы булып җитлегү өчен, бөтен кешелекнең үсеш тарихы, җәмгыять һәм шәхес, кешеләре арасындагы мөнәсәбәтләр психологиясе турында фәнни һәм дини тәгълиматтан хәбәрдар булу шарт. «Адәм баласы» авторының дөньяви карашлары формалашуында Ислам мәдәниятенең тәэсире булуы ачыктан-ачык күренеп тора.

*Чиксез мәңгелектә*
*тыгыз янәшәлек...*
*Адәм баласының*
*оясы – газиз җир –*
*кинәнеп яшәрлек...*

Шигырьнең соңгы ике юлы һәркемгә таныш вәгазь булып кабул ителергә мөмкин. Ә беренче ике юлы белән нинди уй бәйлелеге, фикер бердәмлеге һәм тәңгәллек бар

соң? Чиксез мәңгелеккә җир кебек планеталар шыплап-тыгызлап тутырылган, әмма Адәм баласы өчен фәкать Җир генә оя, Җир генә бердәнбер. Баналь фикер, әмма ул яңача туа, яңачалык белән инандыра.

*Котып бозы эреп,*
*җирне туфан басар...*
*Адәм баласының*
*кем атлысы тагын*
*нинди көймә ясар?..*

Яки:

*Килере билгеле –*
*билгесез сәгатьтә...*
*Адәм баласы ни*
*үзгәртә ала соң*
*алдан белеп хәтта?..*

Яки:

*Соңгы барыш – зират,*
*соңгы кичү – сират...*
*Адәм балалары*
*сабыр итеп баскан*
*иң беренче чират.*

Бу шигырь юлларының мәгънәсе ап-ачык, алар турыдан-туры изге китаптан алынган кебек тоела. Әмма уй һәм уйланырга этәрүче «Кем атлысы тагын / нинди көймә ясар соң?» – дигән соңгы ике юл беркадәр үзенчәлекле. Моңарчы күп мәртәбә дөньяны туфан суы баскан. Изге китапта Нух пәйгамбәрнең, зур көймә ясап, бөтен тереклекне саклап калуы бәян ителә. Ә бу шигырьдә, «Кем, нинди көймә ясар?» дигән сорау, «Аллаһы бу юлы да тереклекне саклап калырмы, тереклекне саклап калу өчен, ни-нәрсәне, кемне **сәбәп итәр**?» дигән уйлы сорау куела.

Җир-күк арасындагы яшәеш турында уйларында автор күккә өстенлекне күбрәк бирә. Бу очракта аның нигезендә Аллаһы һәм фәрештәләрнең күктә булуына шагыйранә ышану, күкне Аллаһының нуры булуын тану ята.

Адәм баласының Җиргә килүе, Җирдәге кешелекнең тарихы, кеше, кешелекнең Җир-галәмдәге миссиясе турындагы уйланулар... Кешенең үзенең, дөресрәге, кеше җанының зурлыгы, үлемсезлеге, күкләрдә Аллаһы хозурында булуы һәрчак фәлсәфи уйлануларның багланышы булган һәм булачак та. Дөнья фәлсәфәсенә, галәмнәр фәлсәфәсенә «чыгар» өчен, «Адәм баласы» җирдә үзенең яшәү мәгънәсенә төшенергә тиеш. «Мин» һәм «мин-минлек» кешенең үз-үзенә мөнәсәбәте, үзара мөнәсәбәте, җәмгыять белән мөнәсәбәтен үз эченә ала. Кешенең мәңгелеккә, чиксезлеккә мөнәсәбәте күкләргә, йолдызларга карата мөнәсәбәте белән билгеләнә. Соңгылары Җан, Рух турында уйлануларны тудыра.

Минем максатым «Адәм баласы» җыентыгына кергән, һәм җыентыкка керәчәк дистәләрчә бишьюллыкларымның эчтәлегенә анализ ясау түгел иде. Әйткәнемчә, «Адәм баласы» шигъри формасы аша **шигъри уйлар** хакындагы **уйларым** белән уртаклашу гына. Алар чиксез шигъри дөньяның үзгә бер чагылышы булып бәяләнә икән, моннан беркемгә дә, бернәрсәгә дә, шул исәптән шигъриятнең үзенә дә бернинди зыян килмидер. Бу – уйланулар!..

**P.S.** Шулай да... «Адәм баласы» калыбында башка шагыйрьләр дә иҗат итә башлаган икән, дигән сүзләр ишетелә башлады.

*Бер Адәм баласы* – **Мөхәммәт МИРЗА.**

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# ТУГАН ҖИРДӘ – КАНАТЛЫЛАР...

ОЧЕРК

*Туган җирдә – канатлылар.*
*Туган җирдә – без тамырлы.*
*Яшәтүче, яшәртүче,*
*Саклаучылар без авылны!*
Ф.Дәүләтбаев



Безнең буын кешесе элекке чорның кай якларын сагынып искә ала дисезме? – Якты хыяллар, өмет, матур эшләр һәм матур кешеләр турында күп сөйләнелә иде. Ә бит бүген дә янәшәбездә яхшы кешеләр, яхшы гамәлләр бихисап. Аларны күрә һәм башкаларга үрнәк итеп күрсәтә белергә генә кирәк.

– Исәнмесез!

– Әссәламүгаләйкүм! – дигән җавап алгач, миңа чын-чынлап уңайсыз булып китте. Үземнән яшь, өстәвенә җитәкче кешедән шундый сәламләшү сүзен ишетү гаҗәпләндерде дә, шул ук вакытта кызыксыну да уятты...

«Әнәк» агрофирмасы җитәкчесе Фарис Гаяз улы Фәтхиев хакында язарга дип кулыма каләм алгач, уйларым белән яшьлек елларымнан урап килдем... Усы авылыннан без, ике кыз, ике егет, Пучы урта мәктәбенә йөреп белем алдык. Юлыбыз Әнәк авылы яныннан үтә. Ул чорда әллә ни күзгә бәрелеп торган йортлары да, игътибарны җәлеп итәрдәй урамы да юк иде. Ә бүгенге Әнәк әллә каян балкып, үзенә тартып тора. Мәскәү–Уфа юлы аша узган кеше матур итеп язылган юлкүрсәткечкә игътибарсыз калмыйдыр. Әнәк, дигәч, күбесе, «беләбез, Шәймиев туган авыл», диләр. Асфальт юл түшәлгән урамның ике ягында мәһабәт йортлар тезелеп киткән. Ай саен диярлек яңа нигез барлыкка килә, яңа йортлар калкып чыга. Мәчете, Шәрип Шәймиев музее, кибетләре, җәмәгать үзәге күпләрне үзенә тарта.

Татарстанның атказанган икътисадчысы, Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе иясе Фарис Гаяз улы Фәтхиевның «Әнәк» агрофирмасын җитәкләвенә ун ел тулган. Районда һәм республикада зур уңышлары белән танылган җитәкченең үткәненә – балачагына кайтып килик әле. Чөнки кем генә булмасын, тормыш юлын нинди генә сукмаклардан түшәмәсен, аның юл башы, киләчәгенең нигез ташы балачактан башлана.

Аның кендек каны тамган җире – Актаныш районының Иске Җияш авылы. 1960 елның 13 октябрендә Гаяз Фәтхетдин улы һәм Гөлфинә Сәгадәтулла кызы гаиләсендә беренче бала – малай дөньяга килә. Аңа Фарис дип исем кушалар. Фарис – гарәпчәдән «рыцарь, егет, фидакарь хезмәт итүче» дигәнне аңлата. Чынбарлыкта да бу шәхес үз исеменең мәгънәсенә лаек. Ике энесе һәм ике сеңлесенә – абый, киләчәктә исә барысына үрнәк һәм терәк булачак әле ул бала! Әтисе – районның алдынгы умартачысы, колхозның 130-160 баш умартасын карый. Иртә таңнан кичке

караңгыга кадәр эштә булган әти-әнисенә ярдәм итәргә, ярый әле, күршедә якын әбисе – әтисенең әнисе Шәмсенур бар. Сугышта һәлак булган ирен теленнән төшерми ул, аны бик сагына. Олы яшьтә булса да, әбисенең өе һәрвакыт чиста, җылы. Ап-ак итеп агартылган мич, тимер караваткка өеп куелган чигүле мендәрләр, сап-сары итеп юылган идән такталары – и ул чорның ак күңелле, тырыш, чиста, пөхтә әбекәйләре... Үз янына кунарга кергән оныкларын тәм-том белән сыйларга дигәндә, кулларыннан гөл коела инде. Пешергән коймак-көлчәләр, кыстыбыйларының тәмен бүген дә онытырлык түгел. Ә инде мөнәҗәтләр, бәетләр әйтә башласа, бөтенләй үзгәрә ул. Берсен әбисе бигрәкләр дә өзелеп көйли:

*Күгәрченем, син гөрлисең, хәлләремне белмисең,*
*Моңлы итеп син гөрлисең, мин елыймын, күрмисең.*

Үзенең күзеннән яшь тәгәри. Фарис, әбисенең ни өчен елаганын аңлап бетермәсә дә, куллары белән муеныннан кочып, аны юатырга тырыша. Ул арада Шәмсенур карчык күз яшьләрен кул аркасы белән сөртеп ала да мөнәҗәтләрнең икенче төрлесенә күчә.

*Инандым мин Аллага,*
*Алланың барлыгына,*
*Алланың берлегенә,*
*Бердер Аллаһым бәнем.*

Бу сүзләрне көйләгәндә, әбисе тавышын әкренәйтә, йөзләре нурланып китә. Шул рәвешчә, үзе дә сизмәстән, оныгы күңеленә иман нуры, нечкә күңеллелек, шәфкатьлелек орлыклары сибеп калдыра ул.

...Ә бит тормышта күңелгә шундый орлык салган затлар байтак булды. Күр инде, Иске Җияш башлангыч мәктәбендә укыганда ук саннарга мәхәббәт уяткан Хәкимә, Теләкәй сигезьеллык мәктәбендәге Миләүшә апасын шундый затларга кертмәслекмени?! Укытучы апасы математикадан ярыштыра-ярыштыра мәсьәлә чиштерә. Ул арада иң җитез укучысы булган Фарис белән шахмат уйнарга да өлгерәләр. Шахмат фигураларын тезгәндә, укытучының күңелендә нинди генә уйлар бөреләнмәгәндер: «Тормыш ул үзе шахмат уены кебек, агы да, карасы да бар. Менә бу ат – җигелеп эшләүне ярата, пешка булырга ярамый, филләрнең таптап китүе бар; король икәнсең – үз дәрәҗәңне бел, ләкин үзеңне генә кайгыртма, башкалар турында да уйла...» Фарисның төп сыйфаты – бал кортыдай тырышлык, хезмәт сөючәнлек балачактан тәрбияләнә. Буш вакыт дигәне кечкенәдән үк бик әз эләгә аңа. Иртә таңнан колхоз умарталыгына чыгып киткән әтисе ихатадагы умарталарны карауны олы улы Фариска ышанып калдыра. Кайсы умартага игътибар итәргә, нишләргә кирәклеген өйрәтә. Бал суырту да, аны сату да, алтынчы классларда укыганда ук, малай җилкәсенә төшә. Балның ничек барлыкка килгәнен, ни өчен бәләкәй кашыкның «бал кашыгы» дип аталганын бик иртә төшенә ул. Фарис бер елны мең сумлык бал сата, әтисе киңәше буенча, ул акчаны кассага салып куя. Көненә 20ләп корт чакса да, зарланмый үзе. Арттырып әйтү түгел, чөнки беркөнне иренмичә юри саный аларны! Фарис кортларга яшәү чыганагы, гаилә бюджетының кереме итеп карый. Әнә шул вакыттан ук булачак җитәкченең хезмәткә мөнәсәбәтенә, исәп-хисапка төгәллегенә, тырышлыгына хәйран каласың.

Әнисе Гөлфинәгә ике гектар чөгендер бүлеп бирелгән. Һәр авыл хатын-кызының, бала-чагасының җәе үтә торган урын иде ул – чөгендер басуы. Галәмгә ракеталар очырылса да, кулларда һаман борынгы заман кешесе уйлап тапкан китмән шул. Иптәш малайлары Шәбез елгасында көнозын су коенганда, майка белән балык сөзгәндә, Фарис әнисе белән чөгендер басуында «кызына». Хезмәтне яратуга, ялкауланмаска этәрә торган эшләр күп инде ул авылда, файдалана гына белергә кирәк. Җитәкченең бу мәсьәләгә үз карашы бар. Ул болай ди: «Ялкаулыкны җенем сөйми. Ялкау балалар үзләреннән-үзләре генә килеп чыкмый. Аларны әти-әниләре шулай итеп үстерә.

Кич сәгать унда чыгып китәләр, иртән өчтә-дүрттә кайталар, көндезге уникегә кадәр йоклыйлар. «Йокласын, соң кайтты», диләр. Эшкә өйрәтмиләр. Соңыннан барысына да кыенга туры килә. Ялкау һәрвакыт: «Бир! Бирегез!» – дип кычкырып тора. Биргәндә: «Яратам», – ди. Бирмәсәң, кечерәк чагында китереп сугарга да мөмкин. Әти-әни аның кубызына бии. Тормышыбыздагы бөтен начарлыкның, җинаятьләрнең башы – эш сөймәүдә».

Теләкәй сигезьеллык мәктәбен тәмамлагач, Фарис Иске Кормаш урта мәктәбендә белем алуын дәвам итә. «4» һәм «5» билгеләренә генә укыган, пөхтә, тәртипле, математиканы су урынына эчкән егетне мөгаллимнәре укытучы булырга үгетлиләр. Фарис: «Юк, миннән укытучы чыкмый», – дип, остазларының тәкъдимен кире кага. Инженер-механик булырга хыялланган егетне әтисе дә, «Маяк» колхозы рәисе Мирзәриф Шәйхразиев та икътисадчы булырга өндиләр. Фарис әтисенең теләгенә каршы килми, өстәвенә колхоз рәисе дә, «булышырмын», дип тора. Документлар Казан авыл хуҗалыгы институтының икътисад факультетына тапшырыла. Ләкин конкурс зур булу сәбәпле, егеткә студент шулпасы чөмерү бәхете елмаймый.

Хезмәт сөйгән егет аптырап, каңгырап йөрми, авылга кайтып, терлек азыгы хәзерләү цехында эшли башлый. 120 сум хезмәт хакы ул чор өчен бик югары була. Фарис икенче елны Лаеш авыл хуҗалыгы техникумының техник-планлаштыручылар әзерләү бүлегенә укырга керә. Бер ел укыгач, армия сафларына алынып, Оренбургта хезмәт итә. Кайткач, укуын тәмамлый. Армиядә Нурлат районы Зирекле авылы егете Әлфис белән дуслаша. Шул дуслык бүгенге көнгә кадәр сузыла. Ә Лаешта укыганда исә ул булачак хатынын – Гөлфия Рәхимҗан кызын очрата. Ике арада кабынган мәхәббәт очкынын аеры үткән еллар да, озын юллар да сүндерә алмый. Яшьләрнең берсен – Гөлфияне Свердловск өлкәсе Сосьвин районына юллама нигезендә эшкә җибәрәләр. Нинди урынга әле – каты режимлы колониянең ярдәмче хуҗалыгына! Соңрак өлкән икътисадчы итеп билгелиләр. Туган яклардан еракта яшәсә дә, адәм баласы күп нәрсәгә түзә, әмма сагыну хисләре күзләрдән моң булып түгелә. Кедр чикләвекләре, тайга җиләк-җимешләре мул булса да, үзебездә үскәненә җитәме соң?! Алардан битәр, сөйгән ярыннан аерган чакрымнар да үзәкне өзә. Сак белән Сок кебек үткән гомер йөрәкне әрнетә.

Фарис Гаяз улына Владивостокка юллама бирелә. «Җир читенә китеп бару» дигәннәре шул була, күрәсең. Иске Җияш егетен шунда җибәрмәсәләр, ул якларда кеше беткәнме? Һәркем үз ягында кирәгрәк. Кошлар да бит туган якта гына оя кора, бала үстерә.

...Кулларына икешәр чемодан тоткан Фарис белән Әлфисне Уфа аэропорты колач җәеп каршы алмый, билетлар булмый. Аэропорт залы халык белән шыгрым тулы. Ике тәүлек айларга тиң булып уза, оча алмый дуслар. Шулвакыт аларга бер хәрби кеше ярдәмгә килә. «Егетләр, әйдәгез, безнең белән Новосибирскига очыгыз, безнең самолёт буш, иртәгә Владивостокка очарсыз», – ди ул. Фарис белән Әлфис бу тәкъдимне сөенеп кабул итәләр.

Кеше мыжлап торган Уфа аэропортыннан соң Новосибирск аларны ярымбуш вокзалы белән каршылый. Егетләр, булган бөтен байлыклары салынган чемоданнарын яннарына куеп, йокларга яталар. Кичтән ничек ятсалар, иртән шулай уяналар. Икесенең дә башында бер уй: «Чемоданнар!» Ярый әле Аллаһы Тәгалә яман кешеләр белән очраштырмаган. Әйберләренең югалмавына сөенеп, эчләренә җылы йөгергән егетләр вокзалда юынып, капкалап алгач, Владивостокка очалар. Беренче каршылык әнә шулай җиңелә.

Юллама буенча килгән егетләрне партоешма секретаре кабул итә. Әлфис якындарак авылга эшкә билгеләнә. Фарис Владивостоктан 170 чакрым ераклыктагы посёлок тибындагы хуҗалыкка җибәрелә, тик икътисадчы урыны буш булмый. Аңа яшелчәчелектә икътисадчы-реализатор урынын тәкъдим итәләр, ә егетнең белеме – техник-планлаштыручы. Бу эш – аныкы түгел, югары хезмәт хакы да, тору урыны булу да кызыктырмый аны. Егет монда калмаячак, бу – аның ныклы карары. Ничек кирәк-алай, директордан «вакансия юк» дигән белешмә алып, Фарис кире кайтып китә.

Күңел ятмаган эш, җиде ятлар арасында калу ялгыш булыр иде. Туган җир – үзенең хуҗасын, Гөлфиясе сөйгән ярын әнә шулай яннарына тартып кайтара.

...Тук, тук, тук... Поезд тәгәрмәчләре «юк, юк, юк», дип тәгәрәмәсәләр дә, «кукурузник» самолёты район үзәгендәге аэропортка китереп төшерсә дә, бу юлы Екатеринбург якларында Гөлфиясе белән күрешә алмый егет. Кыз янына барып җитү өчен, тагын 120 чакрым юл үтәргә кирәк икән. Анысы да елга буйлап. Ярдәм итәргә атлыгып торучылар табылмый. Рация аша сөйләшү дә сагынуны басарлык булмый. Хәер, алай дисәң, алар бер-берсенең сүзләрен аңламасалар да, күңел җылысын тоеп калалар. Бары тик Октябрь бәйрәменнән соң гына Бигеш аэропортында очрашу насыйп була үзләренә. Ул вакытта Фарис Гаяз улы «Нур Баян» колхозында экономист булып эшли. Яшьләр Иске Теләкәй авыл советына барып, паспортларына язылышу турында штамп куйдыралар. Бәхетле Гөлфиясе эш урынына кайтып, үзен эштән бушатуларын сорый. Хәзер инде каршы килә алмыйлар! Бөтен бюрократик киртәләрне үтеп, бер-берсен яраткан, тугрылык саклаган ике яшь йөрәк 1984 елның 19 ноябрендә кавыша. Шул көннән башлап, иңгә-иң торып, бер-берсенә терәк булып, авырлыкларны җиңә-җиңә, максатларга ирешеп, туган җир җылысын тоеп яши һәм эшли алар.

Сүз дә юк, туган якка кайткач та, Фариска ярдәм кулы сузучы, туры юлны күрсәтүче кеше кирәк була. Актаныш районының баш икътисадчысы Садә Вафовна «Нур Баян» колхозында эш тәкъдим итә. Егет колхозның баш икътисадчысы Зөһрә Галиева-Мәҗитованың ярдәмчесе булып эшкә урнаша, үз белгечлеге буенча югары белем алуга ирешә. Колхоз рәисе Әхмәев Таһир Зиннур улы белән колхозчыларга хезмәт хакларын түләү буенча «әз чәкәләшми» алар. Ә бүген очрашсалар, «ничек эшләдек бит», дип дусларча елмаеп искә төшерәләр. Шушы урында Зөһрә Мәҗитованың фикерләрен китерү урынлы булыр: «Фарис, ипле гаиләдә үскән егет буларак, үзен тыйнак, төпле фикерле хезмәткәр итеп күрсәтте. Галим-бакчачы Фарсель Зыятдинов «Нур Баян» колхозында гаилә подрядлары оештырган иде. Мин кияүгә чыгып, Качкынга күчкәч, Фарис баш икътисадчы булып калды. Кабат Пучыга кайтуыбызга да ул сәбәпче булды, йорт салганда да зур ярдәм күрсәтте. Фариска мең рәхмәтлебез».

1985-1995 елларда баш икътисадчы «камытын» киеп, җигелеп тарта Фәтхиев. Ул арада колхоз рәисе дә алышына. Фарис Гаяз улын да баш икътисадчы вазифасыннан азат итәләр, икенче бригадага бригадир итеп билгелиләр:

– Бу – минем өчен Аллаһы Тәгалә биргән эш иде. Коллектив белән эшләүгә, кешеләрне белүгә, таныrга өйрәнүдә зур этәргеч булды. Әз генә эшләсәм дә, безнең бригада районда икенче урынны алды.

Ф.Г.Фәтхиевне кабаттан саннар дөньясына – баш бухгалтер эшенә чакыралар. Ун ел баш хисапчы йөген тартканнан соң, аның оештыру сәләтен истә тотып, «Актаныш майсызландырылган коры сөт заводы» ААҖнә директор итеп куялар. Ике елдан артык кына хезмәт куйса да, завод алдынгылар сафына чыга.

1995 елда «Нур Баян» колхозы белән Шәрип Шәймиевнең оныгы – Әнәктә туып-үскән Илшат Шәех улы Фәрдиев җитәкчелек итә башлый. 2001 елны аның инициативасы белән «Әнәк» хуҗалыгы төзелә, аны Тимерҗан Сәлимҗан улы Әхмәдишин җитәкли, баш хисапчы Гөлфия Рәхимҗан кызы Фәтхиева була. Ни сәбәпледер, 2007 елда хуҗалыкның эшләре кирегә тәгәри башлый. Җитәкчене алыштыру кирәклеге мәсьәләсе алга килеп баса. СОМда эшләрен җайга салган Фарис Фәтхиевне «Әнәк» ҖЧҖкә директор итеп күчерәләр.

– «Нур Баян» хуҗалыгыннан аерылу хакындагы җыелыш Әнәкнең машина-трактор паркында булды. Механизаторлар хуплап каршы алсалар да, «аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар» килеп чыкмасмы кебек шикләрен дә белдерделәр. Берничә техника, лизингка алган трактор, Айман, Әнәк җирләре – бар байлык шул. Чәчүгә чыктык, кырдагыларны ашатырга кирәк. Ашханә юк, ашатырга юк, савыт-саба юк. Кыскасы, юктан күп нәрсә юк... Илшат Шәехович хәлебез белән һәрвакыт кызыксынып торды. Ашлама, ягулык, орлык алырга ул ярдәм итте. Иң соңгы булып чәчүне тәмамласак та, үзебез канәгать калдык. Ашханә мәсьәләсен

дә хәл иттем. Сатарга куйган иске йортым бар иде, шуннан ашханә ясадык, ике ел шунда тукландылар. Беренче елны ук тиешле игеннәрне яхшы тәрбия кылып, иң югары уңыш алдык. Актаныш районы хакимияте башлыгы Энгель Нәвап улы Фәттахов тәкъдиме белән, финанс хәле начар булган авыллар «Әнәк» агрофирмасына кушылды. Бүген безгә 17 авыл керә, – ди Фарис Гаяз улы, сүзләрен бер җепкә тезеп. – Проблемалар да күп булды, аларны уңай хәл итүдә Илшат Шәеховичның һәм Альберт Фәндүсович Мостафиннарның, инвестицияләрнең ярдәме тиде. Аннан соң Аллаһы Тәгалә безгә бик булышты. Бар эшеңне «бисмилла» әйтеп башласаң, Аллаһка тапшырсаң, кеше башкара алмаслык эш юк. Коръәндә дә әйтелгән бит: «Мин бәндәләргә эшне авырлатмыйм». Габдулла Тукай да: «Таян Аллага», дип язган. Үзебезнең Актаныш егете Фәнәвис абый Дәүләтбаев шигырьләрен яратам мин. *«Син Аллага сәҗдә кылып, / каршыла һәрбер таңны. / Аллаһыга табынып яшәү / бизи ул мөселманны»*, дигән шигырь юлларын күңелемдә йөртәм. Әбиемнең мөнәҗәтләре дә онытылмаган. СОМда эшләгәндә үк, дингә тартыла башлаган идем. Хәләл ризык әзерләүгә өстенлек бирергә тырыштым. Чынлап торып дин юлына кереп китүемә Марсель абый Шәйхразиев этәргеч бирде. Үзебезнең Әнәк мәчетендә Инсаф хәзрәт тә бик күпләрне дингә тартты. Тәмәке тарту, аракы эчү дигән әйбер күпләр өчен ят нәрсәгә әверелде. Белгечләрне «ураза гаете алдыннан фитыр сәдакаларыгызны җәлләмәгез, мохтаҗларга бирегез, гаеткә барыгыз», дип вәгазьлим. Бисмилла әйтеп, Аллаһ исеме белән башланган эш бәрәкәт китерә ул, – дип фикерен йомгаклады Фарис.

***

Агрофирма да заман белән бер адымда атлый. Күп илләрдә булу, андагы яңалыкларны үзебезгә кертүнең нәтиҗәсе дә югары. Германия, Нидерландия, Төркия, Гарәп Әмирлеге, Франция, Таиланд, Латвия, Венгрия, Белоруссия, Финляндия... Фарис Гаяз улы Россиянең күп төбәкләрендә хезмәт куючы, үзе кебек кызыксынучан коллегалары белән даими аралашып яши. Краснодар крае, Белгород, Киров өлкәләрендә ул еш була. Җитәкче үзе генә түгел, баш белгечләр дә сәфәргә йөреп тора. Максатлары – агрофирма өчен файдалы булырга мөмкин һәр яңалыкны эләктереп кайтып, практикага кертү. Игенчелек, терлекчелек өлкәсендәге уңышлар турында да горурланып сөйләрлек. Ә аның артында җитәкченең, баш белгечләрнең, хезмәтчәннәрнең кулга-кул тотынып эшләве, тырышлыклары ята бит! Агрофирманың баш агрономы, үзебезнең элекке укучыбыз Заманов Айзат Мөнир улына «уңышларның сере нәрсәдә?» дигән сорауны биргәч, ул: «Бездә һәркем үз эше, үз технологиясе өчен җаваплы. Орлыкка, ашламага, агу-химикатларга Фарис Гаязович акча кызганмый. Гомумән, мондый җитәкче белән эшләп, уңышларга ирешми мөмкин түгел. Бер кешегә каты бәрелмәс. Гозер белән керсәң, кире борып чыгармас. Йорт җиткергәндә дә ярдәме бик тиде, төзелеш материаллары алып кайтырга техникасын бирде. Бергәләп мәчеткә йөрдек. Күбебезнең дин юлына кереп китүенә дә җитәкчебез һәм Инсаф хәзрәт сәбәпче булды. Намаз уку, ураза тоту – күбебез өчен хас», – дип телгә ала.

Сүз уңаеннан шунысын да әйтим әле: агрофирманың алдынгылары арасында үзебезнең Качкын мәктәбен тәмамлаган укучыларның исемнәрен ишетү күңелдә, Сибгат Хәким язганча, «бер горурлык хисе уятты». Тракторчы Марат Хәйретдинов, комбайнчы Алмарис Шәрәфиев, шофёр Данил Хәсәнов... Димәк, безнең – укытучыларның да хезмәте бушка китмәгән!

Илебездә үзгәртеп корулар башлангач, колхозлар таралды, ферма, амбар каралтылары күп авылларда таланып бетте. Кайчандыр гөрләп торган фермалар булганлыгын искәртеп, күңелгә шом салып, таш баганалар гына утыра, тирес өемнәре өстендә алабута үзенең бердәнбер хуҗа икәнлеген искәртә. Ә «Әнәк» агрофирмасына кергән авылларда алай түгел, киресенчә, яңалары төзелә. Машина-трактор паркларын да баетып, яңартып торалар. Пучы–Актаныш юлы буеннан үткәндә, түбәләре кояшта ялтыраган корылмаларны да күпләрнең күргәне бардыр. 2013 елда төзелә башлап, ел ярым эчендә сафка бастырылган тавык фермасы ул. Әллә кайлардан килеп хезмәт

куялар монда. Алар өчен 15 йорт төзелгән, 13ендә инде яшиләр. Тагын сигез йорт төзиячәкләр, кем Әнәктә эшли – шуларга тәгаенләнгән. Шулай була күрсен, гөрләп өй туйлары үткәрелсен.

Хуҗалыкны алга җибәрим дисәң – иң элек исәп-хисап дөрес алып барылырга тиеш, дип саный Фарис Гаяз улы. Агрофирманың баш хисапчысы булып 2008 елдан Гөлфия Рәхимҗан кызы Фәтхиева эшли. Күп бүләкләр иясе булган баш хисапчыга 2016 елда «Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы» исеме бирелә.

«Барысын да кадрлар хәл итә» дигән шигарьнең эчтәлеге бүген дә актуаль яңгырый.

– Кадрларны алмаштырмыйм, аларга иркенлек бирәм, мин аларга ышанам. Эшләү, җитештерү – сездән, миннән – ярдәм, дим. Бар нәрсәдә хисап булырга, һәр кеше, һәр белгеч үз эшенә җаваплы карарга тиеш. Техниканы сатып алып була, ремонтлап була, ә менә намуслы, тәҗрибәле белгечләрне табу күпкә авыррак, – дип фикерләре белән уртаклашты берничә тапкыр «Алтын йөрәкле кеше» исеменә ия булган, ТРның атказанган икътисадчысы, агрофирма директоры Фарис Фәтхиев. – Без Шәрип Шәймиев һәм Минтимер Шәрипович ничек эшләгән булса, шул кыйбланы саклыйбыз. Агрофирма акча эшләү өчен генә төзелмәде. Әнәк – әнәклеләр өчен булсын, кешеләр эшле һәм ашлы булсын, яшьләр бәхетне читтән эзләмәсен, дибез. Минтимер Шәрипович та безнең һәр эшебез белән кызыксынып тора, аның киңәшләре алга барырга рухландыра.

Фарис Гаяз улы хатыны Гөлфия ханым белән өч бала тәрбияләп үстергәннәр. Кызлар энергетика институтын тәмамлаган; Зилә декрет ялында; уллары Нияз белән кызлары Алсу, кияүләре дә шушында ук хезмәт куялар.

***

Бу урында мин, Фарис әфәнде белән барган әңгәмәбез вакытында яңгыраган кайбер сорау-җавапларны бернинди шәрехләүсез тәкъдим итсәм, язмам герое укучы өчен тагын да тулырак ачылыр дип уйлыйм. Чөнки ихластан яңгыраган җавапларда – аның тормыш кыйбласы, күңел сафлыгы, башкалар өчен үрнәге.

– Фарис әфәнде, күп җитәкчеләр ауга, балыкка йөрүне хуп күрә. Сез үзегез ялыгызны ничек уздырасыз?

– Минем өчен иң яхшы ял – ул намаз. Коръән ашларына барып, вәгазь тыңлау. Ауга йөрүне күңелем бөтенләй кабул итми. Кайлардан очып кайткан кыр казларын, парыннан аерып, атып алалар. Шуның итен ничек ашамак кирәк? Исән калганының рәнҗешеннән дә курыкмыйлар.

– Күпләр, авылда канат чыгарып, шәһәргә оча, тагы да югарырак биеклеккә күтәрелә. Сезнең андый ниятегез юкмы?

– Һич тә уйлаганым юк. Әгәр теләсәм, андый мөмкинлекләр бар иде. Мин – бөтен җаным-тәнем, рухым белән авылныкы. Авылны яраттым һәм яратам. Гомерем барында туган җиремне, авылны саклау өчен бөтен көчемне куярмын.

Авылны чын күңелдән яраткан, шул мәхәббәтенә тугры калганнар гына: «И авыл, син мең шәһәрдән мең кабат ямьле вә хуш», дип әйтә аладыр шул...

**Гөлзәлифә ӘХМӘТГАЛИЕВА**

# КУШ ЙӨРӘКЛЕ ХӘЛӘФ

ЭССЕ

Һай, бу хәтер кыскалыгы!..

Югыйсә һич тә онытылырлык шәхес түгел иде үзе! Журналист, тарихчы, телче-филолог, мөгаллим, педагогика фәннәре кандидаты, доцент, профессор, прозаик-шагыйрь, иң мөһиме – баш бирмәс җәмәгать эшлеклесе – Җөмһүриятебезгә мөстәкыйльлек даулаган елларда Азатлык әләмен йөртүче инсан. Шушы милләтпәрвәр җанатарны, хәтер кыскалыгы сәбәпле, онытып барабыз икән ич, җәмәгать!

Кулланма әдәбиятка исем-фамилиясе теркәлмәгән. Беренче чиратта, «Әдипләребез» дигән ике томлык энциклопедияне күздә тотып әйтүем. Дистәдән артык шигырь, хикәя китаплары бастырып та Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителмәгән – көнче затлар аяк чалган микән?! Хәер, хезмәттәше, мөхтәрәм галимебез Хәнәфи Бәдигый зур гына мәкалә бастырган икән заманында. Рәхмәт аңа! Ялыктырмыйм, сүзем татарның йөзек кашы саналырлык улы Хәләф Гарданов хакында. Башкортстанда туып-үскән егет. Сугыш елы баласы, дөньяның ачысын-төчесен мулдан татыган. Шулай да авырлыкларга бирешми, гел алга омтыла. Өфе педагогия институтының тарих-филология факультетын «бик яхшы» билгеләренә тәмамлый. Табигый таланты ташып торган егет студент елларында ук әдәби-фәнни эшләр белән шөгыльләнә, кулдан язылган гәзит-журналлар чыгара. Ул чактагы СССР Югары белем бирү министрлыгы яшь талантны Мактау грамотасы белән бүләкли.

Х.Гарданов Казаныбызга ничегрәк килеп эләккәндер, төгәл генә әйтә алмыйм. Бәлки, чакырып китергәннәрдер?! Беркадәр «Татарстан яшьләре»ндә эшләгәч, Татарстан телевидениесендә хезмәт куйды. Аннары без аны «Социалистик Татарстан» гәзите редакциясенә дәшеп алдык. Редакциянең хатлар-хәбәрчеләр бүлегендә Хәләф белән кара-каршы бер бүлмәдә утырып эшләдек. Авторлардан килгән хат-хәбәрләрне (кайбер көннәрдә 500-700 конверт ачтык) җентекләп укып, тиешле бүлекләргә тараттык, күбесен үзебез эшкәртеп, гәзитнең чираттагы санына тәкъдим иттек, каты тәнкыйть дигәннәрен урынга тикшереп чара күрү өчен юлладык. Арып-талгач, бергәләп тәмләп-тәмләп чәй уртладык. Шулай дәрт кундыргач, тел, әдәбият, милләт гаме хакында гәпләштек, үзебезчә җитди планнар кордык. Тирән белемле, җор телле, ихлас табигатьле инсан иде хезмәттәшем.

Шушы урында Гардановка бәйле бер-ике хатирәне искә аласым килә. 1967-1968 еллар бу. «Социалистик Татарстан» гәзитенең ярты гасырлык тарихын барларга керештек. Өлкә комитеты юбилейны зурлап үткәрергә рөхсәт итте. Әмма Мәскәү белән ике арада кытыршылыклар килеп чыкты. КПСС Үзәк комитетында гәзитебезнең тәүге санын күрәселәре килә икән. Җаваплы редакторыбыз (ул чакта шулай аталды) Шәмси Хамматов бөтен авырлыкны хатлар бүлегенә йөкләде. Хәләф белән архив, музейлардан кайтып кермәдек. Хезмәттәшем гарәп имлясын миңа караганда күпкә җиңелрәк укый, шуңа күрә таякның авыр башы аңа төште. Ләкин, ни казынсак та, кулга тотып күрсәтерлек дәлилләр табылмады.

Х.Гарданов редакциягә килгәнче үк инде, минем янга кайчандыр министр булган, сәбәпсез кулга алынып, 18 ел ГУЛАГ лагеренда иза чигеп, соңыннан акланып исән-имин кайткан журналист һәм язучы Мәхмүт ага Бөдәйле кереп йөри иде. Аның улы Әгерҗе тирәсендәге бер совхозда партком секретаре булып эшләде. Дуслар идек. Шуңадыр, күрәсең, Бөдәйле бабай мине бигрәк тә үз итте. Башыбызга төшкән бәла хакында аңа да җиткердек.

– Ярдәм итәм, егетләр, бер авырлыгы да юк, – диде карт бәлшәвик.

Кыскасы, теге чактагы министр, үзенә янаган дәһшәтне сизенеп, шик тудырырлык



*Сулдан уңга: Хәләф Гарданов, Госман Гомәр. 1965 ел.*

кайбер эш кәгазьләрен, шул исәптән, «Эш» гәзитенең 1918 елгың 12 мартында дөнья күргән тәүге санын да (алар берничә данә), ишек тышчасының эчке ягына индереп калдырган була. ГУЛАГтан котылып кайткач, яңа җитәкчедән рөхсәт алып, тегеләй-болай шауламыйча гына, ишекне сүтә. Хәзинә исән-имин сакланган икән... «Эш» гәзитенең беренче санын безгә Бөдәйле күрсәтте. Ә фотохәбәрчебез М.Шакирҗанов кадерле нөсхәнең сурәтен алды. Тегелмә дәүләт архивында сакланадыр дип уйлыйм. Рәхмәт Мәхмүт ага Бөдәйлегә!..

Кызык инде, гәзитебезне Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләү өчен, Мәскәүдә әнә шул «Эш» гәзитен тотып карыйсылары килгән. Табылды, дигәнгә ышанмаганнар, хәтта – Мәскәүгә шул тапкан кешегезне җибәрегез, дигәннәр. Бөдәйлене юлласаң – таш капчыкка яңадан утыртулары да ихтимал бит.

Башкалага Гардановны озаттык. Барысын да көйләп-чөйләп кайтты журналист. Шундый кеше иде ул минем хезмәттәшем. Алай гына да түгел, аңа берәр капиталистик илгә чыгып керергә тәкъдим итәләр. Хәләф, әлбәттә инде, телләр уртаклыгы булган Төркияне сайлый.

...Вакыйганың дәвамы. Бусы – иң хәтәре. Гарданов – тарихчы, галим кеше бит. Октябрь түнтәрелешеннән соң, Төркиядә яшәгән мәшһүр язучыбыз Гаяз Исхакый тормышы, аның иҗаты белән кызыксына, кызы, шулай ук дәрәҗәле галимә Сәгадәт апаны күреп сөйләшә. Төрекләр Совет кешесенә тарихи урыннарны күрсәтәләр. Кибетләренә кергәч, Гарданов, арзанлыгына кызыгып, үзенә һәм җәмәгатенә алтын йөзек-балдаклар сатып ала. Сәфәрдән соң, гәзитебезнең рәттән өч санында Төркия турында «Сәяхәтнамә» язып бастырды ул. Һәм шуның белән бар да түгәрәкләнде, үзе дә чак исән калды. Берничә сүз белән әйтсәк, анысы болайрак килеп чыкты. Беркөнне бүлмәбезгә бик тә кәттә киенгән ике әзмәвер егет килеп керде. Кара портфельлесе, сәлам-фәлән биреп тормастан, хәйран гына таләпчәнлек белән сорады:

– Кайсыгыз Гарданов?

– Сез кемнәр? – дип авыз ачкан идем, шул мизгелдә ишектә җаваплы секретаребыз Шәех Зәбиров күренде. Болай да кызыл чырайлы Шәех тәмам бүртенгән иде. Кунаклар башта аңа сугылганнар, әлбәттә.

– Гумеров, син чыгып тор! – дигән әмерен җиткерде секретаребыз.

КГБчыларның Гардановтан сорау алулары ике-өч сәгатькә сузылды. Керү түгел, коридордан узарга да шүрләдек.

– Уф, котылдым, ахрысы?! – дип, тирән сулады тәмам хәлсезләнгән Гарданов, тегеләр китеп баргач.

– Ни булды соң, Хәләф? – дип сорадым.

– Менә, авызны тектеләр, кулны кистеләр, – диде хезмәттәшем, гадәттәгечә шаяртырга теләп, иреннәрен кысып күрсәтте.

– Миңа ачасыңмы соң? – дип черәштем.

– Ну, Госман, утыртсалар, син генә гаепле булачаксың. Ант эчерттеләр бүген миңа...

– Төркиядә яшәүче татар эмигрантлары белән ник очраштың? Халык дошманы Гаяз Исхакый кызы Сәгадәтнең сиңа нигә керәге чыкты? Аның белән ниләр сөйләштегез? Бүген капиталистлар кибетен мактап язасың. Аннан нинди алтыннар төяп кайттың? – Һәм башкалар, һәм башкалар... Хәләф, җавап йөзеннән, кулындагы түбән пробалы балдагын салып күрсәтә. Мин бүлмәгә кергәндә, аның атна буе язылып, басарга әзерләнгән кульязмалары ерткалап-ерткалап кәрзингә тутырылган иде. Икенче көнне Хәләф Гарданов,

гаризасын сырлап, редакциябездән китеп үк барды. Ансыз ятим калдык, бик тә ямансу булды. Ишектән чыкканда, гел яратып җырлый торган җыруын тагын бер кат кабатлады:

*Уралып-уралып ага*
*Уралдагы елгалар.*
*Урал буена тезелгән*
*Колхозлар, коммуналар...*

Нәрсәгә ишарәдер ошбу такмак юллары – хәзергәчә төшенә алганым юк.

Редакциядән кай тарафка китте, дисезме? Казан педагогия институтына, шәкертләр укытырга. Анда ул тиз арада доцент, профессор дәрәҗәсенә иреште. Куш йөрәкле, башбирмәс милләтпәрвәр Хәләф Гарданов яшьләр арасында колачны тагын да ныграк җәеп җибәрде, иҗтимагый тормышка киңрәк кереп китте. Бөтентатар иҗтимагый хәрәкәтенең даими вице-президенты (шулай аталды) булды. Югары белем бирү иҗтимагый хәрәкәтенең президенты да ул иде. Бу урында тагын шуны искәртергә кирәктер: Х.Гарданов татар халкының Милли университетын булдыру юнәлешендә баһадирларча көрәште. Һәм ул аны ачуга да иреште, һәм әле университетның тәүге ректоры итеп тә сайланды. Татар Милли университеты (ТМУ) ачылу мизгелен үзем бүгенгедәй хәтерлим. Җанатар милләттәшләремнең куанычы Казан каласыннан ташып чыккан иде ул көнне. Шәһәребезнең Профсоюзлар урамындагы 15 нче йорт тирәсе (Укытучыларның мәдәният йорты) халык белән шыгрым тулы. Мәдәният бинасына гына сыярлык түгел иде. Залда – дәрәҗәле кунаклар, фән эшлеклеләре, югары оешма түрәләре, атап әйтсәк, Мәгариф һәм Мәдәният министрлыгы вәкилләре, Татарстан Югары Советы (ул чакта шулай аталды) депутатлары, мөгаллимнәр һәм ТМУның тәүге шәкертләре. Ачылу тантанасында кайнар нотыклар сөйләнде. Мәгариф министры чыгышын зал аягүрә торып, озаклап алкышлады. Куанычның чиге булмады!..

Чиге ул көнне Нариман урамындагы ПТУга (һөнәри-техник училище) барып тоташты. ТМУның махсус уку-укыту бинасы булмаганлыктан, беренче дәресләр, юнәлеш лекцияләре әлеге училищеда үткәрелде. Тәгаенләнгән алты факультетта: икътисад, филология, юридик, тарих-археология, тыйб фәне җиһазлары техник-технологиясе кебек белгечлекләр буенча 700гә якын студент-шәкерт белем алды. Аларны инде мул тәҗрибә туплаган, югары квалификацияле галимнәребез укытты. Белем бирүгә Казан дәүләт университеты, авиация, педагогия, химия-технология, авыл хуҗалыгы, төзүче – инженерлар хәзерләү институтлары галимнәре тартылды. Алар төп эш урыннарыннан алынган хезмәт хакы хисабына ТМУда бушлай укыттылар. Студентларга степендия-фәлән түләнмәде, чөнки дәүләт бюджетында акча каралмаган иде.

Ошбу урында мин кайбер җанатар галимнәребезнең исемнәрен атап китәр идем. Арада иң активлары: шул ук Хәләф Гарданов (ТМУның тәүге ректоры), Хәнәфи Бәдигый (проректор), Вахит Хаков, Гомәр Саттаров, Илдус Әмирханов, Рафаэль Тукшаитов, Тәэминә Биктимирова, Фоат Галимуллин, Кәрим Долотказин, Ким Шакиров, Сәвия Михайлова, Әнисә Мусина, Гөлнара Арсланова, Илһамия Курганова, Фәрдәнә Кулеева, Әзһәр Мөхәммәди, Баһрам Кочкарёв һәм башкалар. Кабатлап әйтәм: ТМУның үз бинасы булмау сәбәпле, дәресләр күбрәк Казан дәүләт университетының каршы ягындагы яңа бинасында (хәтерлим: дүртенче һәм сигезенче катлардагы берничә бүлмәне) авыл хуҗалыгы институтында, 6нчы татар гимназиясендә үткәрелде. Гимназия директоры Таң Мәхмүд улы Еникеев дәресләр үткәрергә уку классларын, хәтта актлар залын да бирде. Рәхмәт аңа! Журналист буларак, мин үзем бу вакыйгаларны теркәп барырга тырыштым...

Ашыгыч рәвештә төгәл фәннәр буенча дәреслекләр язу башланды. Казан авиация институтыннан физика-математика фәннәре докторы Гали Юныс улы Даутов татар телендә 4 томлык физика китабын әзерләде. Автор турында берничә сүз. Гали Юныс улы – Новосибирск шәһәрендәге атаклы фәнни үзәктә, Роаль Сәгъдиевләр белән берлектә, берничә ел эшләп кайткан галим. Казанга кайткач, Искра урамында кара-каршы йортта яшәдек, кунакка йөрештек. Киң күңелле, тирән белемле, ихлас инсан иде. Милләт үсеше өчен тырышты. Урыны оҗмаһта булсын!

Икенче бер шәхесебез, Казан химия-технология институты галиме Абрик

Вәлиуллин «Гамәли механика» дигән дәреслек белән куандырды. Андый галимнәребез шактыйга җыелды. Әйтик, университеттан Равил Һади информатика буенча ике дәреслек, мәгълүм шәхесебез Айрат Арсланов кызы Гөлнара туташ Арсланова инглиз теленнән татарчага күчереп күнегүләр китабын әзерләде. Һәрберсе Татар Милли университетының яшәп китүе өчен тырышты.

Шулай итеп, давыллы елларның нәтиҗәсе буларак, 1993 елның 20 сентябре Татар Милли университетының туган көне буларак тарихка кереп калды. Инде аны гамәли теркәтәсе бар иде. Бу эшләр артыннан шул ук Хәләф Гарданов, Хәнәфи Бәдигый, Илһамия Курганова, Фәрзәнә Кулеевалар күп чапты. Беркадәр уңышка да ирештеләр. Татарстан Республика Югары белем бирү хезмәткәрләренең җәмәгать берләшмәсе тарафыннан (общественное объединение работников высшего образования РТ по поддержке деятельности ТНУ) дигән лицензия алынды.

Татар Милли университетын булдыру мәсьәләсе күптән өлгереп җиткән иде инде. Аны Татар Дәүләт Милли университеты рәвешендә ачу 1990 елдагы Дәүләт программасына кертелгән иде. Университетны 1995 елдан да соңармыйча ачу фаразланды. Димәк, Татарстан дәүләте тарафыннан финансланырга тиеш булды. Кызганыч, монысы ук барып чыкмады. «Менә сезгә Гуманитар институт» дип, авызны томаладылар. Мәскәү кулы уйнады! ТМУны тәмамлаучылар, әйткәнемчә, Мәскәүдән сәмруг кошлы РФ дипломын акча түләп сатып алдылар. Югыйсә, 1993 елның 20 сентябрен котлап, ерак Себердән, Омск өлкәсе, Мара каласыннан милләттәшебез Фәния Фәтхуллина үзенең шатлык хисләрен шигъри юллар белән белдергән иде. Менә аның беренче дүрт юлы:

*Бүген минем күңелем шатлык кичерә,*
*Бу шатлыктан тәмам башым исерә.*
*Чөнки бүген хәбәр алдым Казаннан,*
*Халкым анда олуг җиңү казанган!*

Әйе, уртак шатлыгыбыз иде анысы!..

Сүз уңаеннан, мин үзем дә яңа гына техникум тәмамлаган дипломлы кызым Айсылуны шушы уку йортының икътисад факультетына илтеп тапшырдым. Студентлар дүрт ел эчендә төпле, югары белем алды. Тик менә шәкертләр диплом яклаган елны, Мәскәү кулы белән, университетыбызны ябып та куйдылар. Тышына сәмруг кош төшерелгән дипломны, акча түләп, Мәскәүдән сатып алырга туры килде. Дәрәҗәле, имеш?! Х.Гардановның шомырт кара чәчләренә шул чакларда ак бәс йөгерүенә бер дә гаҗәпләнәсе түгел...

Инде инсанның иң зур батырлыгын тасвирларга урын да тарайды бугай. Җөмһүриятебезгә мөстәкыйльлек даулап, урам-мәйданнарга чыккан гавамның алгы сафында, Югары Совет депутатлары Марат Мөлеков, Фәндәс Сафиуллин, Фәүзия Бәйрәмова һәм башка җанатарлар белән бер сафта, иң алгы рәттә Азатлык әләмен җилфердәтеп баручыларның берсе Хәләф Гарданов иде. Һай, кайнар йөрәкле, көчле оратор иде үзе! Шовинистларның каршылыгына очрагач, Халыкара Гаага судына кадәр барып җитте бит ул! Югары мәхкәмәдә татар халкының мәнфәгатьләрен яклап, аның теләк-омтылышларын дәлилләп, кайнар чыгышлар ясады. Аның батырлыгын тиешенчә бәялиләр, үзен зурлыйлар.


– Анда безне якладылар, – диде Хәләф, ошбу ерак сәфәреннән кайткач.

Ни кызганыч, куш йөрәкле, курку-өркү белмәс милләтпәрвәр кардәшебез озак яши алмады, 75 яшен билгеләп үтәргә җыенган көннәрендә бакыйлыкка күчте. Онытылмас сәхифәләр калдырып... Йөрәге нык тузган иде шул. Урыны җәннәттә булсын! Амин, шулай язсын...

**Госман ГОМӘР**

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Габдулла
Галиев

# КЫРЫНДЫ АВЫЛЫ ТАРИХЫННАН СӘХИФӘЛӘР

### Сукыр Сибгать кулак

Якташыбыз тарихчы-галим Раиф Мәрдәнов «Әгерҗе төбәге тарихы» китабында, бабам Сибгатулланы Кырынды авылының сәүдәгәре булган дип? язган. Дөрестән дә, олы урамга ян белән салынган алты почмаклы агач йортның кече ягын кибет итеп тоткан бабам. Йортыбыз нигезен актара башласаң, көрәктәге туфракка ияреп өрек чикләвеге кабыклары, бакыр тиеннәр чыгар иде. Сәүдәгәр булуы өстенә бабам абзар тутырып терлек тә асраган әле. Мал асрауга бәйле бераз гына күңелемә кереп калган бер хатирә менә. Кышкы таң иртәсе. Киерелеп-сузылып йоклап ятыр вакыт булса да, өйдәгеләр инде күптән аягөсте. Йортыбыз ишеге бер ачыла, бер ябыла. Ачылган саен идән буйлап ыргылып салкын керә. Мин дә йокламыйм, өстемә ябылган шактый авыр толыпның бер почмагын ача төшеп, өйдәгеләрне күзәтәм. Әни белән әбием өйдәге бәрәннәрне имезергә сарыкларны куып керттеләр. Йорт эче бәрәннәрнең елак тавышы, сарыкларның бәэлдәве белән тулды. Әбием бәрәннәргә әниләрен табарга булышып, имчәкләренә кушып йөрде. Төнлә бер сыерыбыз бозаулаган икән, бозавын күтәреп алып чыгып имезеп керделәр. «Мүкләгебез дә бозауга авырган кебек күренә, җылы абзарга кертик, килен», – диде әбием. Икәүләп тагын абзарга чыгып киттеләр.

Мин әле өч яшьлек сабый гына, авыл тормышының тынгысызлыгын күзәтеп, күңелем белән тоеп кына ятам. Бары шул гына. Крестьян тормышының авырлыгын мин үз җилкәмдә татый башлагач аңлармын әле.

Инде Сибгать бабама күчим. Сәүдәгәрлек үҗәте аңа Хәбибулла бабамнан күчте микән, төгәл генә әйтә алмыйм. Шунысы факт: Сибгатулла бабам, күзлеләрне көнләштереп, «Сукыр Сибгать лавкасы» дигән кибет тоткан. Көн кирәк-яраклары: чәй, шикәр, кызыл билле прәннек, өрек чикләвекләре, кер сабыны, хуш исле сабыннар белән сәүдә иткән. Бабам борынгыдан килгән кыпчак нәселеннән булгандыр: калмык битле, пеләш башлы, уртача буйлы, киң җилкәле. Ходай аңа чибәрлекне бирмәсә дә, сөйкемле карт иде ул.

Бабамның язмышы аянычлы булган. Ул сабый чагында ук шул заманның коточкыч авыруы – чәчәк (оспа) белән хасталана, бик авыр ята, терелүенә өмет тәмам өзелгән көннәрнең берсендә кинәт могҗиза була – бабам торып баса! Әмма рәхимсез авыру үзенекен эшләп өлгергән була шул инде. Бабам күзләренә ак төшеп сукырая. Ул, күзләрен бик тырышлык белән хәрәкәтләндереп, яктылыкны бераз гына чамалый торган сукыр иде. Мин кечкенә вакытымда аның тезләренә менеп утырыр идем дә күзләренең нәкъ үзәген каплаган ак тышчага карап торыр идем. Бөтен җаным-тәнем

белән шул шөкәтсез тычканы кубарып атасым, бабамны барыбыз кебек бәхетле итәсем килә иде.

Гафифә әбиемнең сөйләвенчә, сукыр бабама сәүдә итүләр һич тә җиңел булмаган. Бабам, һәр көнне диярлек җилкәсенә аллы-артлы тубал асып, кулындагы таяк очы белән юлны капшап, йорттан-йортка кереп, йомырка җыеп йөргән, атна азагында җыйган йомыркаларын, олауга төяп, Алабуга каласына озаткан. Ә аннан аңа товар алып кайтканнар. Товар ташучы булып безгә (ягъни бабама) кардәш тиешле Садыйк абзыебыз Галимов йөргән. Аның тырышлыгы белән, сукыр Сибгать кибете товарга кытлык кичермәгән. Бабам, кибеткә килүчеләрнең акчалары өстеннән бармакларын йөртеп алганнан соң, ничә тиенлек икәнең җиңел генә әйтеп биргән, бик сирәк ялгышкан, кәгазь акчалар булганда гына янына әбиемне чакырып ала торган булган. Әмма, әбиемнең сөйләвенчә, кайбер мәкерле бәндәләр бабамның сукырлыгыннан файдаланырга тырышканнар, бигрәк тә кешенекен чәлдерергә яратучы агайлы-энеле Әхмәдишаныкылар бабама тынгы бирмәгәннәр. Кибеткә таяк очына кадак кагып киләләр икән: берсе бабамның игътибарын читкә юнәлтеп сөйләштергән арада, икенчесе кибет киштәсендәге каплы чәйләрне, сабыннарны таягы очындагы кадакка эләктереп ала торган була. Кичләрен көнлек сатуына исәп-хисап ясап утырганда, җитмәүчелек чыга башлагач, бабам бик кәефсезләнә, уйлана торгач, шиге Әхмәдишаныкыларга төшә, чөнки «растрата» дигәне кибеткә нәкъ Әхмәдишаларныкы килгән көнне була. Берничә көннән теге караклар тагын кибеткә килеп керәләр, бабам, тавышларыннан танып: «Гафифә! Гафифә, дим, яныма кер әле!» – дип әбиемне чакырып ала.

Әбием Гафифә турында да берничә җөмлә язып китим әле.

Гафифә әбием авылыбызга Олы Барҗыдан дүрт чакрымдагы элек Бигәш, соңрак Мушик дип аталган авылдан килен булып төшкән. Сөйләүләренә караганда, ул шактый нык тормышлы гаиләдән. Әбиемнең бер энесе Габдулла заманына карата укымышлы кеше булырга тиеш. Шулай булмаса, авылларында мәзин булып тормас иде. Габдулла хәзрәт Төрдәледә еш кунак булып киткән. Әтием Галине бик яраткан, әтием дә аны белемле, акыллы кеше буларак хөрмәт иткән. Мин дөньяга килгәч, әтием, аның истәлеге булыр дип, миңа Габдулла исеме куштырган.

Гафифә әбием Мушик авылында иң чибәр кызларның берсе була. Аның шулай кинәт кенә Сибгатькә кияүгә чыгуына күпләр гаҗәпләнә. Кара кыйгач кашлы, күмер кебек янып торган күзле, йөзеннән елмаю китми торган әбиемнең чибәрлеге олыгайгач та сакланды. Бервакыт әнием: «Каенанай, яшермичә генә әйт әле, ничек күрә торып сукыр каенатайга чыктың?» – дип сорады. Әнием аның иң авырткан җиренә кагылса да, җавабын көттермәде әбием, шунда ук: «Дим белән чыктым, килен, дим белән», – диде. Әбиемнең йөзе кинәт боегып киткәндәй булды, әмма шул мизгелдә үк кабат яктырды. «Мине сукыр егеткә бирәләр, дип ишеткәч, ялгызым калып, мендәргә капланып еладым. Берничә көндә сулган гөлгә охшап калдым. Энем Габдулла, Төрдәлегә барып, Сибгатьне алып кайтып, безне күрештерде. Күрешеп сөйләшкәч, ошаттым. Чибәр булмаса да, акыллы иде Сибгатем, тамчы да үкенмим», – диде әбием.

Тагын бабам Сибгатькә әйләнеп кайтыйм әле.

Бабам йомырка җыярга күрше авылларга да йөргән. Беркөнне, эшкә мавыгып, ул Чишмә авылында кичкә кала. Урамны иңләп көтү кайткан вакыт. Кулындагы таягы белән юлны чамалап авылны чыгып баручы бабам артыннан көтү үгезе иярә. Капка төбенә сыерларын каршы алырга чыгучылар, бу хәлне күрә торып, бабама кычкырырга оныталар, ахры. Ул арада үгез килеп тә җитә, бабамның аркасына төртеп тә җибәрә. Бабам йөзтүбән җиргә каплана, җилкәсендәге тубаллары, йомыркалары җиргә тәгәри.

Сабый чагымдагы хәтеремә кереп калган тагын бер вакыйга. Утызынчы елның эссе җәендә авылыбызда зур янгын чыккан. Йолдызлы авылына бара торган түбән урам янып беткән. Безнекеләр, йортыбызга, каралты-курабызга очкын төшүдән куркып, җиһазларыбызны читкәрәк чыгарып өйделәр дә мине зур сандык өстенә утыртып куйдылар. Янгын чыккан урамда әле шушы көннәрдә генә бездән аерылып башка чыккан бабамның бертуган энесе Рәхмәтулла абзыйлар яши иде. Кичен янгыннан кайткан Сибгать бабамның: «Рәхмәтнең хуҗалыгында инәсе дә калмады», – дип үксеп

елап утырганы истә. Көтүдә калган малларын, алып кайтып, безнең абзарга яптылар. Рәхмәтулла абзыйның гаиләсе дә безгә кайтып урнашты. Бергә озак яшәмәдек шикелле, бабам аларга кече күпер янынннан йорт сатып алып бирде.

## Күмәк хуҗалык төзү

Иртән үк кемнеңдер калын-тупас тавыш белән: «Җыенга! Хәзер үк җыенга барыгыз!» – дип, тәрәзәгә кагып киткәнен яхшы хәтерлим. Тәрәзәбез каршындагы урамнан сөйләшә-сөйләшә халык җыенга агылды. Әтием җыеннан күтәренке кәеф белән кайтты. Авылда «калхуз» дигән нәрсә оештыралар икән. Әтием колхозга керергә гариза биреп кайткан. Иртәгә ике атыбызны да колхозга илтеп бирәчәк икән. Өйдәгеләр күңелсезләнеп, тынып калдылар, башларын борып, бабама текәлделәр. Бабам, әтинең оештырылачак колхозны бик мактап сөйләгәнен тыңлап та бетермичә, тамак кырып алгач, телгә килеп, әтинең ул нәрсәгә ашыгып язылуын бер дә хупламады. «Бүген кермәсәк, иртәгә кертәчәкләр колхозга, безгә алданрак керү файдалы», – диде әти. Күрәсең, ул, илдә бара торган күмәкләшү политикасын яхшы аңлагандыр.

Икенче көнне әти, арба-чаналарны, сука-тырмаларны төяп, төпкә җигелгән бурлы биябез кырыена икенче атыбызны бәйләп, колхозга илтеп тапшырды.

Мин инде күп нәрсәне күрәм, аңлый бара идем. Авыл халкын колхозга тарту җиңел булмагандыр. Беркөнне шулай урамнан ярсып-ярсып кычкырган чыелдавык тавыш ишетелде. Өйдәгеләр барыбыз да куркышып тәрәзәгә капландык. Урамда берәү: «Бетерәләр!.. Талыйлар!.. Каравыл!» – дип кычкыра, йортына кайтып барган җиреннән тукталып: «Кире барам. Нигә миңа калхуз дигәннәре? Гаризамны кире алам. Билләһи, кире алам», – дигән сүзләрен ишеткән әти: «Акбаш абзый бугай ул. Көчләп колхозга керткәннәрдер үзен», – диеп, безне тынычландырды.

Берникадәр вакыттан соң авыл халкын тагын җыенга җыеп алдылар. Әти аннан күңелсезләнеп кайтты. Җыенда Сибгать бабамны авыл байлары белән бергә «кулак» дип игълан иткәннәр икән. Әтиемнең сөйләвен колагымны торгызып тыңлавым хәтеремдә. Авыл халкы башта: «Сибгать абзый нишләп кулак булсын инде? Сукыр, гарип көенә авыл халкын шикәргә, чәйгә туйдырып торды. Аның сабыннары белән юынып бетләмәдек», – дигәннәр. Җыенда тавыш, бәхәс китә. Районнан килгән вәкил, өстәл кагып, халыкны тынычландырганнан соң, алдындагы папкасыннан кәгазь тартып чыгара да: «Җәмәгать, тынычланыгыз! Менә сез Хәбибулла улы Сибгатулланы бик тырышып яклыйсыз. Әмма ул кешегез Галимов Садыйкны, Хәтмуллин Гыйззәтулланы үзенең шәхси хуҗалыгында ялчы итеп тоткан бит. Фактмы бу? Факт! Значит, ул – эксплуататор, менә сезнең кебек гади халыкны изүче», – дигән. Аның чыгышыннан соң залдагы халык тынып калган. Тавыш бирүгә куйгач, бабам күпчелек тавыш белән кулак дип игълан ителгән. Әтиемнең әйтүенчә, тиздән безне раскулачивать итәчәкләр, йортыбызны, каралты-курабызны, терлекләребезне тартып алачаклар икән. Әнием борынын мышык-мышык тарта башлады. Әбием: «И Ходаем, йортыбыздан урамга куып чыгарсалар, нишләрбез?» – дип елап җибәргәч, минем дә аңа кушылып елавым исемдә калган.

1931 елда безнең авылыбыздан күченеп утырган янәшәбездәге кече авылларны берләштереп, Кырындыда Сталин исемендәге зур колхоз оештыралар. Колхозда учёт-хисап эшләрен алып бару өчен хисапчылар җитмәгәч, әтине, идарәгә чакыртып, Чистайдагы өч айлык хисапчылар курсына җибәрәләр.

Әтием, Сибгатулла улы Миңнегали Сибгатуллин, 1901 елда Кырынды авылының бер өлеше булган Төрдәле авылында дөньяга килә. Башта авыл мәхәлләсендә оешкан мәдрәсәдә, аннан дүрт сыйныфлы мәктәптә белем ала. 18 яшендә Кызыл Армиягә алынып, Гражданнар сугышында Сивашны аклардан азат итүдә катнаша. Шул заманда белемле генә кеше була.

Чистайдан укуын тәмамлап кайту белән, әтине Сталин исемле колхозга хисапчы итеп куйдылар. Шул елны гаиләбезгә зур кайгы килде: бабамны җирләдек. Җеназасына бик күп кеше килде. «Әйбәт кеше иде, мәрхүм, өстендәге авыр туфрагы җиңел булсын! Йә, Раббым, урынын оҗмахта ит», – дип изге теләкләр тели-тели, бабамны соңгы сәфәренә озаттылар.

Инде язып үткәнемчә, әти – колхозда хисапчы, әнием авыл кибетендә сатучы булып эшли, эштән бик соң кайталар, кечкенә сеңелкәшем Наиләне багу әбием белән минем өстемә төшә иде.

Берничә җөмлә әнием турында.

Әнием Кәшифә Мөхәммәтзарип кызы Көчек авылыннан иде. Әтием аны Төрдәлегә, туганнарына утырмага килгән җиреннән алып калган. Әнием бик чибәр, шуның өстенә зыялы хатын иде. Әтием кебек үк берничә ел мәдрәсәдә укыган, авыл мәктәбен тәмамлаган, мәгърифәтчелек йогынтысында тәрбия алган әдәбиятчы. Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Габделҗаббар Кандалый шигырьләрен яттан бик матур итеп сөйли иде. Авыл халкы әниемне белемле, зыялы кешеләр рәтендә йөртте.

## 1934 ел

Миңа алты яшь тулып килгән вакыт. Ул көнне әти эшеннән нигәдер бик борчылып кайтты. Түш кесәсеннән гәҗит алып өстәлгә куйды да кече якта кичке аш әзерләп йөргән әнине янына чакырды. Әнием чыккач, гәҗитен кулына алып укырга кереште. Минем колагыма: «Ленинградта Кировны атып үтергәннәр», – дигән шомлы сүзләр кереп калды, «халык дошманнары» дигән сүзне генә аңлап җитә алмадым. Әнием кибеткә килгән кешеләрдән бу хәбәрне алданрак ишеткән булып чыкты. «Илебездә әллә нинди куркыныч хәлләр бара, шаукымы безнең якларга гына килеп җитә күрмәсен инде», – дип, бик борчылып, кече якка чыгып китте.

Озак көттермәде ул шаукым. Беркөнне районнан килгән прокурор, колхоз конторында эшләп утырган әтине күреп: «Бу кулак малаен кем рөхсәте белән биредә эшләтәсез?» – дип, колхоз рәисе Ибраһим абзыйга җикеренгән. «Иртәгәдән колхоз идарәсендә эзе дә булмасын», – дип кисәтеп китеп барган. Әти бичара үзен кая куярга белмичә берничә көн өйдә утырды. Хисапчы таба алмагач, Ибраһим абзый белән парторг Хөбби абый, район үзәгенә барып: «Безгә хисапчы җибәрегез», – дип, райкомга керергә мәҗбүр булалар. Әтине, ниһаять, эшенә чакырып алдылар. Әйбәт кенә эшләп йөргәндә, 1935нең көзендә, әтине, кинәт кулга алып, Әгерҗегә алып киттеләр. Өйдәгеләрнең берсе дә кулга алынуның сәбәбен белмәде. Әни, иртә таңнан торып, җәяүләп Әгерҗегә китте. Киткән җирендә ике төн кунып, кичен йортыбызда ут алгач гына бик күңелсезләнеп кайтып керде. Минем: «Әтине алып кайтмадыңмыни?» – дигән соравыма, елмаерга тырышып: «Әтиеңнең эше бетеп җитмәде шул әле, улым. Аллаһы боерса, бер-ике көннән кайтыр», – диде. Үзләре әбием белән кече якка үтеп чышын-пышын сөйләшеп алдылар, миңа күрсәтмәскә тырышсалар да күреп алдым, күзләре яшьле иде. Миннән ничек кенә яшерсәләр дә, әти турындагы борчулы хәбәрне мин барыбер урамнан ишетеп кайттым. Ибраһим абзый ычкындырган, Галине бик зур статья белән гаеплиләр, дип. Әтине кызганучылар да, кулга алынуына шатланучылар да бар иде. «Галигә 58нче статья чәпәгәннәр, тиздән дөпелтәтәчәкләр», – диеп, үзебезгә кардәш тиешле берәүнең урамда гайбәт сатып йөрүен ишетү гаиләбезгә бик авыр булды. Әтине кулга алудан соң күп тә үтмәде, 60 яшьлек Кәримулла абзыйны алып киттеләр. Аның да статьясы әтинеке кебек үк икән. Янәсе, ул да, колхозыбызны тарату өчен «корткычлык» эшләре алып барган. Кәримулла абзый турында төрле имеш-мимешләр белән урам тулды. Имеш, ул, катып беткән дегет белән арба күчәрен майлап торганда, яныннан үтеп баручы бер урыс (безнең авылда урыслар да яшәде) туктаган да: «Каримулла абзый, што у тебя за мазь», – дип сораган. Күчәргә ябышмый торган майга болай да кәефе киткән карт: «Какая влач, такая мазь», – дип ычкындырган, янәсе. Әнием миңа болайрак итеп сөйләде. Авылда уракка төшкән вакыт, эшләр уңайга гына барганда, көннәр кинәт яңгырга керә. Урак өсте авыр барганга борчыласы урында, мәзәк яратучы шаян карт, сүзенең алдын-артын уйламыйча, басуда яңгырдан ышыкланып торучы колхозчылар алдында тыпырдап биибии такмаклап болай җырлый:

*Яу, яңгыр, яу, яңгыр,*
*Калхуз йөрәген яндыр,*
*Калхуз эшләгәнне яратса да,*
*Икмәкне аз тарата... һоп...һоп...*

Колхозчыларның кайберләре, аның мәзәкләрен хуплап, авызларын ерып, чәбәкәй чабып торалар. Әлифне таяк икәнен дә танып белмәгән надан карт, илдә барган куркыныч хәлләрне төшенеп җитмичә, зур хата ясап ташлый. Телең тик тормаса, башың белән аякларыңа авырлык килер дигәндәй, Кәримулла абзыйга үчлекле берәү табыла, басуда күргәннәрен тиешле урынга илтеп җиткерә.

Әти белән Кәримулла абзыйны Әгерҗе милициясендә озак тотмыйлар, этап белән Алабуга төрмәсенә озаталар. Кәримулла абзый кебек, әти дә колхоз төзелешен таратырга тырышуда гаепләнә. Әтинеке болайрак була: колхозчылар җыелган бер урында әти: «Быелгы уңышның тулаем җыемын хисаплап чыгардым, узган елныкыннан кимрәк чыкты, шуңа күрә колхозчыларга икмәкне бераз гына кимрәк таратырга туры килер», – дип ычкындыра. Авыздан чыккан сүз чыпчык кебек пырылдап оча да китә, аны кире кайтарып булмый шул. Әти, үзенең ялгышканын аңлап, иренен тешли, ләкин соң була инде. Шуны гына көтеп йөргән берәү: «Кулак малае Сибгатуллин Гали колхозыбызны тарату өчен астыртын гына «корткычлык» эше алып бара», – дип районга язып җибәрә.

Йортыбызда күз яшьле, кайгылы көннәр башланды. Әниемне дә кибеттән алдылар, ул инде, сохарилар киптереп, пешеренеп, Алабуга төрмәсенә барырга әзерләнә башлады. Атна башында Кәримулла абзыйның уллары, колхоздан ат юллап, үзләре янына әнине дә сыйдырып, иртә таңнан Алабугага чыгып киттеләр. Әбием аларны, елый-елый догалар укып, изге теләкләр теләп озатып калды. Безнең өчен дөнья караңгыланды, йортта ямь бетте, зур түземсезлек белән әнинең кайтуын көттек. Урамга чыксаң, урам берсеннән-берсе куркыныч хәбәрләр белән тулган. Илебездә янәсе халык дошманнары шулкадәр күбәйгән ки, милиция кулга алып бетерә алмый икән. Тагын шунысы: корткычлык эшләүчеләрнең барсы да бай балалары, кулак малайлары икән. Әле кайчан гына бергә кочышып уйнап йөргән дус малайларым да, төрле сылтау тапкан булып, миннән читләшә башладылар. Бу исә мине күздән яшь чыгарып гарьләндерә иде.

Атна азагында әни Алабугадан кайтып төште. Ул бик арыган, йончыган иде. Белгәнен әбиемә генә сөйләде. Әбиемне хәйләләп кыса торгач, ул, күпмесендер яшереп булса да, үзенең бераз кытыршырак җылы кулы белән башымнан сыйпап, җайлап кына сөйләп бирде. Әти кебек гаепләнүчеләр төрмә тулы икән. Төрмәдәгеләрнең хәлен белергә килүчеләр дә күп икән. Төрмә башлыгы бик тупас кеше икән, әнигә этине күреп сөйләшергә рөхсәт итмәгән. Төрмә кырыенда буталып йөрмәскә, кайтып китәргә кушканнар. «Ишеттеңме инде, ишетсәң шул: болай да борчулы әниеңне сораулар белән аптыратма, яме, улым», – диде әбием. Йортыбыз бушап калды, хәл белергә килүчеләр дә, әтинең дуслары да күренмәделәр. Үзен кая куярга белмичә йөргән әни түзмәде, өйдә бер атна торгач, пешеренеп, тагын Алабугага китеп барды. Әбием белән көн саен, бу юлы нинди күңелсез хәбәрләр алып кайтып керер икән, дип, борчылып, әнине көттек.

Әни бу юлы дүрт төн кунып кайтты. Тышта капка шыгырдау белән, бу әни булырга тиеш, мин аны капкабызны ачып керүеннән үк таный идем, өстәл арасыннан сикереп торып ишеккә йөгердем. Алданмаганмын икән, ишектән керүче әнием иде. Ул мине кочып алып, аркамнан сөйде. Йөзе елмаюлы иде әнкәйнең, мин аның кайгысы бераз җиңеләйгәнен тойдым, ничектер рәхәт булып китте. Менә ул: «Исән-имин генә яшәдегезме, әни», – дип, елмаеп, әбием белән күреште. «Без шөкер генә, килен»,- диде әбием. Аннан әнигә чишенергә булышып торган җиреннән, сагаеп кына: «Бу баруыңда Миңнегалине күрә алдыңмы соң?» – дип сорады. Чәй эчәргә утыргач, әнием Алабугада күргән хәлләрен күз яшьләрсез генә сөйләп бирде. Әнине бу юлы да начар кабул иткәннәр. Төрмә начальнигы әнинең үтенечен тыңлап та тормаган. «Соңгы тапкыр әйтәм, синең ireңнең статьясы белән бернинди свидание юк һәм була да алмый», – дип, кайтып китәргә кушкан. Әни икенче көнне килгәч, кабинетыннан куып чыгарган. Шулай итеп, этине күрү өмете юкка чыга, кире авылга кайтып китүдән башка чара калмый. Күз яшьләренә тыгылып чыгып барганда, әнинең берничә көн рәттән өзгәләнеп йөргәнен күзәтеп торган төрмә сакчыларының берсе, кырыеннан узып барганда, шыпырт кына, прокурорга барырга куша. Прокуратураның урнашкан урамын, йорт номерын әйтә. Әни, бу шәфкатьле бәндәгә рәхмәт әйтеп, ашыгып шул

йортны эзләп китә. Ләкин подъезд төбендә торучы сакчылар, прокурорның кабул итү вакыты үтте инде, иртәгә килерсең, дип, әнине кире боралар.

Төнен кысан гына бер фатирда йокысыз үткәреп, әни иртән тагын шул йорт каршына килә һәм үзеннән дә алданрак килгәннәр рәтенә баса. Чираттагыларның сөйләшүенә колак салып, прокурорның бик шәфкатьсез түгел икәнен, татар хатыны икәнен ишетә. Монда инде берничә көн элек килгәннәр дә бар икән. Әни ул көнне дә, прокурорга керә алмыйча, фатирына кайтып китә. Икенче көнне көн кичкә авышканда гына прокурорның кабул итүенә ирешә. «Кыска гына итеп сөйлә, мин үзем аңлармын», – ди әнигә прокурор. Әнине тыңлагач, телефоннан шалтыратып, төрмә начальствосы белән сөйләшеп ала, әңгәмә урыны-урыны белән шактый кискен төстә бара. Яннарына кергән хәрби киемле хатынны янынарак чакырып алып, прокурор аңа нindидер күрсәтмәләр бирә. «Ул хатын мине үзе белән ияртеп китте дә, кабинетына алып кереп, өстәлдәге машинкасындагы кәгазьгә басып алгач, тагын беразга югалып торды, янәдән кергәч, кулындагы кәгазен сузып: «Менә сезгә рөхсәт язуы. Төрмә начальствосына тапшырырсыз», – диде дә мине тышкы ишеккә кадәр озатып чыгарып җибәрде. Шулай итеп, мин Гали белән биш минутлык күрешү бәхетенә ирештем, – диде әни. – Аның исән-сау икәнен үз күзем белән күргәч, йөрәгем бераз тынычланды». «Алдагы хәлем бик яман күренми, миңа ташланган ялган гаепләрдән котылырга өметем бар. Минем өчен бик бетеренмәгез», – дигән әти.

Аллаһы Тәгаләдән күз яшьләребез белән ялваруларыбыз кабул булгандырмы, чыннан да, әтинең язмышы уңай якка үзгәрә. Бу болай була: көннәрдән бер көнне әти утырган камерага өлкән яшьтәге бер кешене кертеп ябалар. Баштарак шактый көннәр бер-берсеннән шикләнеп үтә. Чөнки камераларга махсус провокаторларны да кертә торган булалар. Берникадәр вакыттан соң, сынашу вакыты үткәч, алар якынаеп, танышып китәләр. Әти кебек ул да сәяси тоткын була. Ул әтидән бу замандагы коммунистларның үткәрә торган политикаларына каршы кеше икәнлеген яшерми. Шул тоткынның соравы буенча, әти аңа бөтен автобиографиясен сөйләп бирә. Тегесе, аны дикъкать белән тыңлап бетергәч: «Болар барсы да дөресме? Ялган китмәдеме?» – дип сорый. Әти яңадан бер тапкыр сукыр бабамның лавка дип аталган кибет тотканын, аннан кергән табышның гаиләләрен туйдырырга гына җиткәнен түкми-чәчми сөйләп бирә. Чәчә торган җирләренең күләмен дә, ике ат тотканнарын да яшерми. «Юк, – ди тоткын, – бу сезне кулга алу өчен җирлек була алмый. Сез, колхозда хисапчы булып эшләгән җиремнән алып киттеләр, дидегез, бәлки, эш шундадыр, хәтерләгез әле яхшылап», – ди. Әти, колхозчылар алдында: быел икмәкне сезгә узган елгыга караганда кимрәк өләшергә туры килмәгәе дигән сүзләрен исенә төшерә. «Ләкин мин бит бу сүзләрне коткы тарату нияте белән әйтмәдем. Икмәкнең тулай җыемын хисаплап чыгаргач әйттем. Дөресе шулай иде бит», – ди, ялгышына үкенеп. «Әйе, бик начар эшләгәнсең. Югарылардан ышанычлырагы хәзер Михаил Иванович Калинин. Әйдә, без аңа хат язып карыйк», – ди тоткын. Революциягә кадәр күп тапкырлар төрмәләрдә утырган бу карт коммунист хатны төрмәдән чыгару җаен таба. Ике ай чамасы вакыт үткәч, әтине төрмә начальнигы бүлмәсенә чакырып ала. Бүлмә түрендә чаларган чәчле ир-ат та утыра. Үзен прокурор дигәч, кулындагы конвертны күрсәтеп: «Бу хатны сез яздыгызмы?» – дип сорый. Әти башта каушап кала, куркып кына: «Нинди хатны?» – ди. «Томанага салынмагыз. Михаил Иванович Калининга хат сез яздыгызмы?» Теге тоткынны этап белән башка урынга озаткан булалар. Әти аның исемен әйтсә, хыянәт булачагын төшенеп ала. Һәм, кинәт кыюланып: «Әйе, мин яздым», – дип җавап бирә. Прокурор, шактый вакыт әтигә сынаулы караш ташлап торгач, сакчыга әтине камерасына алып китәргә куша.

Соңрак әтигә шул мәгълүм була: документта Калинин имзасы белән: «Бу тоткынның хаты өйрәнелде, коллегия аның гаебен тапмады, статьясы төзәтелде. Коллегия күчергән статья буенча авылында хөкем итегез», – дип язылган була. Алгарак китеп, шунысын әйтим: әтине 1935 елның май аенда авылыбызда хөкем иттеләр. Әти өстеннән язган кеше авылдан чыгып качкан булып чыкты. Башка шаһитлар хөкем барышында буталышып беттеләр, әти алдында гафу үтенделәр. Парторг Хөбби абыйның әтине яклап ясаган чыгышы бик урынлы булды. Суд әтине аклады.

Сәбәбен ачык кына әйтә алмыйм, әти нигәдер үз эшенә кире кайтмады, Көчек авылы сельпосына хисапчы булып урнашты, без гаиләбез белән шунда күченеп, ике ел шул авылда яшәдек.

Утызынчы, утыз беренче еллар дәвамында минем бабам кебек үк кулак дип игълан ителгән Вәли, Шәймөхәммәт, Закир байларның таш кибетләрен, Матвей байның чәчкеч-ургычларын, ашлык суккычларын, йортын тартып алдылар. Безнең дә каралты-кураны сүтеп алып киттеләр. Өйдәгеләрнең, ярый әле йортыбызны калдырдылар, дип сөенгәне истә.

Көчек авылында мин беренче сыйныфка укырга кердем. Шунысы хәтеремдә: башка авыллардагы кебек үк монда да тормыш бик авыр иде. Авыл халкының авызы икмәккә туймады. Шулай булса да, мәктәп балаларын туйдырырга тырыштылар. Озын тәнәфескә туры китереп, мәктәп завхозы Зәкәрия абый (урыны оҗмахта булсын, ул 1942 елны сугышта һәлак булды), чанага төяп, мәктәп аты белән авыл пекәрнәсеннән парлары чыгып торган икмәк алып кайтыр иде. Аны, зур пычак белән кискәләп (икейөзәр грамм булды микән инде), кулларыбызга тоттыра иде. Болары инде һич онытылмас күңелле мизгелләр.

Әтине көтмәгәндә Әгерҗе райпосына бухгалтер итеп күчерделәр, без, төянеп, кабат авылыбызга кайттык. Кайтуыбызга, «раскулачивать» итеп, йортыбызны сүтеп алып киткәннәр. Алдыбызда – хәрабәләр, туфрак өемнәре, күздә яшь, тилмереп як-ягыбызга карап торабыз: кая барырга? Шунда яныбызга сулышы капкан Садыйк абзый йөгереп килеп җитте. «Әйдәгез, әйдәгез, миңа киттек, оясыз йомран кебек аптырашып тормагыз. Өммегөлсем әбиегезне дә ияртегез, – диде. Әти башта ни әйтергә белми таптанып торды да: «Сезгә кысынкылык ясамабызмы соң, Садыйк абзый?» – диде. «Юк, юк. Бернинди кысынкылык та булмас, йортым иркен, күңелем киң. Сибгать абзыйдан бик күп яхшылыклар күрдем. Кибетенә тауар ташып йөргәндә, аның каршында гөнаһларым да булгандыр, Ходай кичерсен. Әйе, дөньяда яшәгәндә барысы да булгандыр. Менә балаларына яхшылык эшләргә җае чыкты әле», – дип сөйләнә-сөйләнә, безне ияртеп алып китте. Тиздән Садыйк абзый безгә йортын сатып, үзе кече урамнан дүрт тәрәзәле җыйнак кына өй алып, Өммегөлсем әби белән шунда күченделәр.

Әти, безне урнаштыргач, Әгерҗегә – билгеләнгән эшенә китеп барды. Без биредә әби, әнием һәм мин яшәп калдык.

## Онытылмас 1936 ел

Ул елны яз башыннан ук яңгыр яумады. Басудагы игеннәр дымга сусап, тамырлары җиргә укмашып, корып кипте. Тау буендагы үләннәр саргаеп юкка чыкты, тау өсләре сөрелгән җир кебек каралып калды. Минем икенче сыйныфта укыган чагым, мәктәптән кайткач, иптәш малайларым белән ат абзарына йөгерәбез, кесәләребездә бәрәңге, әниләр күрмәгәндә чәлдергән икмәк кисәкләре, кайберләребезнең култык асларында бер-ике учма булса да печән. Колхоз бахбайларының алларында коры улактан башка берни юк. Алар, без абзарларында күренү белән, иңрәп кешнәп җибәрәләр. Алып килгән нәрсәләребезне тизрәк авызларына каптыра башлыйбыз. Коры сөяккә калган бичаракайларга караган саен, үзәкләр өзелеп китә.

Инде ферма түбәләрендәге ярым черек саламнарны ашата башладылар, анысы да норма дигән нәрсә белән генә бирелә икән. Язгы чәчү борын төбендә генә: колхозчылар бу атлар белән чәчүне ничек башкарып чыгарбыз икән, дип кайгыра, шуңа үзләренең авызларыннан өзеп атларга, терлекләргә ярдәм итәргә тырыша.

Утыз алтының язгы чәчүе бик авырлык белән үтүе турында өлкәннәрнең зарлануы хәтердә калган. Шул ук елның көзендә авыл халкына бер-бер артлы күңелсез хәбәрләр ирешеп торды: янәсе, дошманнар язгы чәчүне белә торып «провалить» иткәннәр, атларның арыклануы, терлекләрнең күпләп кырылуы да корылык килүдән генә булмаган, барсы да «халык дошманнарының» колхоз төзелешен астыртын какшатып ятулары икән. Хәбәрләрнең хәтәре, чәчләр үрә торырлыклары безнең районыбыз турында иде. Янәсе, безнең районда да, халыкның борын төбендә генә корткычлык

эшләп яткан җитәкчеләребезне – райкомның беренче секретаре Полютинны, район җир бүлеге башлыгы Уразаевны, тагын аларның берничә иярченен фаш итеп кулга алганнар. Әти, газетадан шул хәбәрне укып, бөтенләй аптырап калды, аннан, кайнарланып, кулындагы газетасын читкә атып бәрде дә: «Фатыйх абый Уразаевны үз атам кебек яхшы беләм, ул нинди халык дошманы булсын, яла бу, яла ягу», – дип кычкырып җибәрде. Йөрәк турын ышкып, тынычлана алмыйча ишекле-түрле йөрде. Ул көннәрдә кулга алулар тагын да ешаеп киткәндер, әнием кибеттән Көчек авылының колхоз рәисе Шәехов Хөбби абзыйның да кулга алынуын ишетеп кайтты. Хөбби абзый, колхозында ашатыр ризык калмагач, атларны вакытлыча колхозчыларга тараткан икән, шул рәвешле, атлар исән калган. Ләкин бу эшне хуплыйсы урынга, киресенчә, ниндидер бер эшәке җанның әләге белән, колхоз малларын тарату итеп карап, Хөбби абзыйны төнлә килеп кулга алалар. Шул көннәрне Чишмә авылыннан Вахрушевны, участок ветеринары буларак, колхоз терлекләренең күпләп үлүенә корткычлык нияте белән юл куйганы өчен дип кулга алынуы ишетелде. Янәсе, бу авыл хуҗалыгына зыян китерүе югарыдан, Уразаевның яшерен күрсәтмәсе белән эшләнгән.

Искәрмә. Полютинны, Уразаевны һәм алар белән бергә гаепләнеп кулга алынган берничә кешене, Верховный судның хөкем карары нигезендә, 1937 елда атып үтерәләр. Сталин үлгәч, Партия Үзәк комитеты каршында төзелгән махсус комиссия, аларның эшләрен кабат тикшереп, гаепләрен тапмыйча, барсын да аклап карар чыгара.

## Кырынды мәктәбе

Мин беренче сыйныфны Көчек мәктәбендә тәмамладым. Икенче сыйныфны үз авылымда, Кырынды мәктәбендә башлап җибәрергә туры килде. Ул елларда мәктәбебез ТБУМ, ягъни мәктәп дип атала иде.

Калай түбәле, агачтан салынган бер катлы бина һәм аның белән янәшә ике катлы шундый агач бина бар иде. Күрәсең, укучылар күп булгандыр инде, бераз читтәрәк ике сыйныф укучы сыярлык тагын бер бина төзеп куйдылар. Авылыбызда революциягә кадәр рус балалары өчен – өч сыйныфлы церковно-приходской, татар балалары өчен башлангыч белем бирүче мәктәпләр була. Бик тырышып сорашып йөрсәм дә, укытучылар кемнәр булганын белә алмадым. Кайберләре вафат, кайберләре каядыр күченеп киткәннәр булып чыкты. Мин укырга кергәндә, мәктәп директорыбыз Ибәтов Гата абый иде. Урын җитмәү сәбәпле, балалар ике смена укыдылар, чөнки беренче сыйныфтан җиденчегә кадәр рус-татар сыйныфлары параллель иде. Ул елларда мәктәптәге укучылар санын ике йөздән артык дип сөйлиләр иде. Тагын шунысы хәтеремдә: Иванов фамилияле укытучыбыз Мәскәүдән түшенә орден тагып кайтты. Ул орденын ялтыратып коридордан үткәндә шул орденны күреп калу өчен, этешә-төртешә алдына чыгарга тырышыр идек.

Һич тә онытылмый торган укытучылар була бит. Шундыйларның берсе – Пермь ягыннан килгән Хәмит абый Әмәтов. Өстендә арзан гына тукымадан тегелгән костюм, ак күлмәк. Күлмәкнең якасы һәр кичне юылгандыр, чөнки ул гел акшарлаган кебек ап-ак була торган иде. Үзенең мөлаемлеге, гадилеге белән безнең күңелләрне бик тиз яулады Хәмит абый. Үзе дә малайлыктан чыгып җитмәгән бу яшь-җилкенчәк тәнәфестә дә, физкультура дәресләрендә дә безнең белән тәгәри-тәгәри уйнар иде.

Безне гашыйк иткән тагын берсе – өлкән пионервожатыебыз Алмазия апа Аматыч булды. Ифрат бала җанлы иде ул мәрхүмә. Үземнең пионерга кабул ителәчәк көнемне түземсезлек белән көткәнемне, шул чибәр вожатый апаның муеныма кызыл галстук бәйләгәне әле хәзер дә күз алдымда.

Хәзер уйлап утырам да, пионерлар оешмасы бик матур эшләр башкарган икән. Бигрәк тә тәрбияви чараларны күз алдында тотам мин. Тәртип бозучы, дәресләрен әзерләп килмәүче, гел икеле алырга гадәтләнгән укучы пионерларны, отряд советында аягөсте бастырып, сәбәпләрен тикшерер идек. Дәресләрен авыррак үзләштерүчеләргә ярдәмгә отличникларны беркетер идек. Һәр атна азагында ялгыз яшәүче әби-бабайларга булышырга йөрдек. Тагын, елмаеп, күңел хисләремне кушып, шунысын өстәп әйтим:

муеннарыбызда – кызыл галстук, чалбар тезләребездә – берничә ямау, аякларыбызда чабата иде безнең. Ленинны яратып җырлар җырладык, шигырьләр сөйләдек. «Пионер! Син, бөек Ленин партиясе өчен көрәшкә әзерме?» – диюгә, кулыбызны маңгаебыз турына күтәреп: «Һәрвакыт әзер!» – дип салют бирдек.

Мәктәбебездә гөрләп әдәби түгәрәк эшләде. Авылдашыбыз яшь укытучы Фоат абый Садыйков кайткач, ул тагын да җанланып китте. Фоат абый музыкага да һәвәс укытучы иде, кулыннан мандолинасы төшмәде. Шигырь язарга сәләтле укучылар һәрдаим игътибар үзәгендә булдылар. Кемнеңдер шигыре мәктәп стена газетасында басылуы шатлыклы бер вакыйгага була торган иде. Әдәби кичәләрдә укучылар, үз шигырьләре белән беррәттән, Нур Баян, Әхмәт Исхак, Муса Җәлил шигырьләрен, поэмаларын укырлар иде. Тагын да күңелле мизгелләр: 1 Май, Октябрь революциясе бәйрәмнәрендә матур концертлар куеп, авылыбыз урамнарыннан кызыл әләмнәр күтәреп, быргылар кычкыртып, барабаннар кагып үтәр идек.

Мәктәп турында язганда, тагын бер яраткан укытучыбызны – Равил абый Гәрәевне әйтми үтсәм, гөнаһ булыр. Равил абый безгә Татар Шаршадысы авылыннан килде. Яшь булгангамы, юашрак иде ул. Татар теле дәресенә чакырып кыңгырау чыңлый, без исә һаман класста пәри туе уздырып шаярабыз. Менә ул, култыгы астына класс журналын кыстырып, ишектән керә дә, биредәге хәлне күреп, бер аягын алга атлап, тукталып калган кинокадр кебек, безнең тынычланганны көтеп тора. Ниһаять, класс тынгач кына урынына барып утыра. Нинди сабырлык! Аның бервакытта да өстәл төеп, кычкырынып безне тиргәгәне булмады. Шунысы үкенечле: без аннан гафу үтенергә өлгерә алмыйча калдык. Равил абый, сугыш башлануның беренче көнендә үк чакырылып, фронтка китеп барды. Һәм без аның кырык икенче елны туган илен, без укучыларын яклап батырларча һәлак булганын ишеттек. Гафу ит безне, Равил абый. Урының җәннәттә булсын!

## Иске тормыштан яңага омтылу

Авыл халкының тормышы гел тетрәнү, кулга алулардан гына тормады, әлбәттә. Авылда колхоз оешып бетеп килгән утыз бишенче еллар. Миңа җиде яшь тулып килә, авылда барган хәлләрне күзәтеп, аңларга тырышып йөргән чагым. Халык авырлык белән булса да яңалыкны кабул итә башлады. Ул елларда клуб мөдире булып Татар Шаршадысыннан килгән Корбангалиев (халык аны Корбангали дип атады) эшләде. Ул бер үк вакытта комсорг та булгандыр, ахры, чөнки гел яшьләрне ияртеп йөрер иде. Бу егет авылда чын культура революциясе ясады, дисәм, һич тә ялгыш булмастыр. Йортларда сәкеләрне бетерү, кандала, таракан кебек паразитларга каршы көрәш, шәхси гигиена кагыйдәләренә игътибар: лаканда юынудан юынгычларга (умывальникларга) күчү, гаиләләрдә һәркемгә аерым сөлге булдыру кебек гадәтләрне максат итеп куйды. Корбангалиев абый үзе белән комсомол яшьләрне ияртеп, һәр йортка кереп, шуларны тикшереп йөрер иде. Яшьләр куелган таләпләрне үтәгән йортларның түренә «Культурный йорт» дигән табличка куярлар иде. Корбангали абый чын-чынлап абруйга ия кеше иде. Үзебезнең өйдәгеләр дә, «Корбангали болай дип әйтте», «ул болайрак кушты» диеп сөйләшерләр иде. Ул оештырган уракка төшү парады хәзер дә күз алдымда тора. Бүген парад була икән дигән сүзне ишетеп, без, парад нәрсә икәнен дә белмәгән малай-шалай, «Нардомга» йөгердек. (Ул елларда авыл клубын шулай, «нардом» дип йөртәләр иде.) Без тыныбыз бетеп килеп җиткәндә, Корбангали абый колхозчыларны сафка тезеп тора, тезелгәннәрнең берсе дә буш кул белән түгел, берәүләре сәнәк, икенчеләре тырма тоткан, кызларның, апа-җиңгәчәләрнең җилкәләрендә – ураклар. Сафлар тигез булып тезелеп беткәч, Корбангали абый колхозчыларны уракка төшү белән тәбрикләп берничә сүз әйтте. Аннан авылыбызның иң оста гармунчысы Шәйхетдин абыйны саф алдына бастырды да, тегесе марш сыздырып җибәрде. Кузгалып киттек, аякларыбыз марш көенә очына-очына атлый. Колхоз идарәсе алдында басып торган җитәкчеләр каршыннан тамак төбебез ертылганчы «Ура» кычкырып үттек. Бу – авыл тормышының иң күңелле мизгелләре иде!

## Авылда – үзгәрешләр

Әкренләп колхоз тормышы уңай якка таба үзгәрә башлады. Авылыбыздагы «Яңалиф», «Будённый» исемендәге ике колхозга «Коммунар» дип аталган ике комбайн һәм «полуторка» дигән машиналар кайтты. Ул көнне мин дә хәтерлим. Бүген басуга комбайнны чыгаралар икән дигән хәбәрне ишетү белән, авылның яше-карты шул могҗизалы машинаны күрергә басуга агылды. Трактор сөйрәп барган шул комбайн дигән нәрсәнең гөрләтеп урып кына түгел, урганын суктырып та яннарыннан үтеп киткәнен үз күзләре күргән халык тел шартлатты. Өлкәннәр, битенә тузан кунган, ак тешләрен ялтыратып елмаеп килгән комбайнчы Иван Иютинның осталыгына сокланып, аркасыннан кагып сөйделәр. Ул көнне кешеләр арасындагы әңгәмә гел шул комбайн турында гына булды. 1938 елның сентябре инде бу. Колхозыбызның комбайнчылары Иван Иютин, Галимулла абый Шәйдуллин, Мөхәммәт Вахитовлар гел сокланулы күз карашларын тоеп йөрделәр.

Өр-яңа «полуторка»га утырып карау да күпләрнең хыялы булгандыр. Октябрь, Беренче Май бәйрәмнәрендә, бигрәк тә 8 март көнендә, колхоз машинасының әрҗәсен кызыл комачка төреп, кызыл әләмнәр, лозунглар белән бизәп, гармуннар уйнатып, җырлап, хезмәт алдынгыларын утыртып, урам әйләнерләр иде. Машинага утыру тәтемәгән хатын-кызларның көнчелектән чыр-чу килеп тавыш чыгарулары хәтеремдә калган.

Колхоз тормышы әнә шулай көйләнгән сыман булып килгәндә, кинәт халыкны тетрәндергән зур вакыйга булды. Колхозчы Нурмөхәмәт абзыйны үтерделәр. Фаҗига булачак көнне комбайн урып-суктырган ашлыкны амбарга ташып бетерә алмыйлар, өелгән ашлык көшеле басуда кала. Нурмөхәмәт абзыйның хатыны бригадир янына йөгерә, бергәләп басуга киләләр. Нурмөхәмәт абзыйны ашлык өеме янында таба алмагач, нидер булганын сизенеп, бригадир, авылга кайтып, кешеләр алып килә. Бергәләп эзли башлагач, төнлә сөрелгән җир ызанынннан Нурмөхәмәт абзыйның үле гәүдәсен табып алалар, шуннан якында гына мазутка, канга буялган чүкеч тә табыла. Ул төнне тракторчы Зиннәт абый белән сукачы яшь егет Мөхәмәтшин Хөсәен ашлык көшеле белән рәттән генә җир участогын сөрергә чыккан булалар. Ләкин авыл халкы аларның шундый коточкыч җинаять эшли алуларына ышанмады. Күрәсең, барсын да мәетнең сөрелгән җирдән табылуы, якында гына трактор маена, канга буялган чүкеч ятуы хәл иткән инде. Авыл клубында булып үткән суд Зиннәт абыйны – сигез, Хөсәенне биш елга ирекләреннән мәхрүм итте. Миңнегулов Зиннәт абый сугышта катнашып, туган авылына исән-сау кайтып егылды. Хөсәен, сугышта дошман белән каты бәрелешләрдә катнашып, авыр яраларыннан чит туфракта мәңгелеккә ятып калды.

Нурмөхәмәт абзыйны соңгы сәфәренә зурлап озаттылар. Безне, галстуклы пионерларны, сафка тезеп авыл советы бинасына, Нурмөхәмәт абзый белән хушлашырга алып керделәр. Бинаның урта бер җирендә кызыл комач белән әйләндереп алынган табутның ике ягында комсомоллар, авыл советы рәисе Вәли абый Әхмәдиев, тагын районнан килгән ят кеше һәм хәрби киемнән Минһаҗ абый Нәфыйков басып торалар. Без кергәч, алар табуттан бераз читкәрәк тайпылды. Без, табут эчендәге башы ак марля белән чорналган, йөзе акшарлаган кебек ак, иреннәре, борын очы күгелҗемрәк кешегә карап, табутны әйләнеп үттек. Авыл советы алды халык белән тулы иде. Мәетне карау тәмам булгач, митингны ачып җибәрделәр. Район вәкиле халык алдында речь тотты. Һәрвакыт уяу булырга, корткычларны, кем булуына карамастан, вакытында фаш итәргә чакырды.

## Авылыбызның тарихы турында

Язмам бер-берсенә терәлеп утырган Кырынды белән Төрдәле авылы турында. Кырынды халкы бередәге кара урманнар арасына, попларның көчләп чукындыруыннан качып, Зәй якларыннан килеп төпләнә.

Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты гыйльми хезмәткәре Раиф Мәрдәновның төбәгебез тарихы язмаларына караганда, шунысы мәгълүм: качып килүчеләр арасында инде чукындырылганнары да булган, шуңа күрә аларны Кырынды

чиркәве побы чукындырылганнар итеп чиркәү кенәгәсенә теркәп куйган. Шуңадыр инде, «Кырындының кырыгына бер иман» дигән әйтем барлыкка килгән. Ләкин алар чиркәүгә аяк та басмаганнар: ураза тотканнар, корбан чалганнар, җомга намазларына йөргәннәр, матур итеп кунаклар җыеп, гает бәйрәмнәре үткәргәннәр. Йөзләгән каршылыкны җиңеп, 1906 елны авыллары уртасына мәчет төзеп куйганнар. Ул елларда мәхәллә имамы булып Касыймхан хәзрәт тора. Мин белгәндә, мәхәллә имамы читтән чакырылган Фәрдетдин хәзрәт иде. Шунысы да хәтеремдә: ул хәзрәтне тирә-яктагы хәзрәтләр арасында бердәнбер Коръән Хафиз диләр иде. Кырынды мәхәлләсе мәчетенең манарасын кырыгынчы елны кисеп аудардылар, аннары мәчетне сүтеп, бүрәнәләреннән колхоз идарәсе төзеделәр. Төрдәле мәчетенең гомере бераз озынрак булды. Яхшы хәтерлим: кырыгынчы елның шомыртлар шау чәчәккә төренгән май ае иде. Көтмәгәндә, Төрдәле авылы халкын колхоз идарәсе алдына җыеп алдылар. Без, малай-шалай да шунда йөгердек. Без барып җиткәндә, йөзләрен борчу баскан халык гөж килә иде. «Бирмибез! Манарасын да аудартмыйбыз, мәчетебезгә дә кагылдырмыйбыз», – дип кычкыралар иде. Ниһаять, авыл советы рәисе Вәли абый, районнан килгән вәкил, идарәдән чыгып халык алдына бастылар да җыелышны ачып җибәрделәр. «Иптәшләр! – диде район вәкиле, – мин сезне район партия комитетының карары белән таныштырырга килдем. Хәзергә безнең яңа клуб төзергә мөмкинлегебез юк, әлбәттә, ул мөмкинлек алдагы көндә булачак. Ә хәзергә мәчетне клуб итеп файдаланырга мәҗбүрбез, иптәшләр». Төрле яктан: «Юк, юк, мәчетне бирмибез! Манарасын да кистермибез! Динне кысарга беркемнең дә хакы юк. Сәвит влачы андый башбаштаклыкка юл куймас, бу – урындагы влачларның эше генә», – дигән сүзләр яңгырады. Район вәкиленә, урыныннан торып, берничә тапкыр халыкны үгетләргә туры килсә дә, авыл халкы, бигрәк тә картлар, нык торды. Сабырлык белән, тавышын күтәрмичә генә, кат-кат төшендереп караса да, вәкилебез, теләгенә ирешә алмыйча, кире кайтып китәргә мәҗбүр булды. (Шактый еллар узгач, мин ул район вәкиленең РОНО бүлеге мөдире Фәррахов икәнен белдем. Ул Зәки Фәррахованың абыйсы булган.)

Хәер, кырык дүртенче елның башында мәчетебезне барыбер клуб иттеләр, манарасын соңрак кисеп аудардылар. 1955 елны авылыбызга колхоз рәисе итеп җибәрелгән утызмеңче Запускалов, мәчетне сүттертеп, авыл уртасынарак күчереп, Мәдәният йорты итеп салдырды. Бичара бина эчендә кылынган гөнаһларны күтәрә алмагандыр, җитмешенче еллар ахырында янгын чыгып көлгә әйләнде.

Артка чигенеш ясап, шунысын да язып китим әле. Төрдәле авылы мәхәлләсендә озак еллар Кече Бәзәкә авылыннан күченеп килгән Гыйззәтулла хәзрәт, аннан соң аның улы Әхмәдулла имамлык иткәннәр. Алардан соң бик тә басынкы холыклы Миннешәех хәзрәт имам булып торды. Мин хәтерләгән утыз бишенче елларда Миннешәех хәзрәт имамлыктан читләштерелгән, каралты-кура, мал-туары конфискацияләнгән, төсле пыяла белән әйләндереп алынган верандалы, гаҗәеп матур итеп тәрәзә, ишекләрен бизәкләп эшләнгән чарлаклы йортлары гына кузгатылмыйча калган иде. Утыз җиденче елны ул йортны да тартып алып, колхоз идарәсе иттеләр. Йортларының кечкенә бер бүлмәсендә яшәп ятучы Кави белән Ләбиб ачлыкка интегеп яшәделәр. (Мин ул хәлләрне үземнең «Хәзрәт малайлары» китабымда сурәтләргә тырыштым.) Ләбиб 1943 елда, унсигез яше тулып килгәндә, сугышка китеп, Польшаны, Белоруссияне азат итү бәрелешләрендә катнашып, Бөек Җиңү көнен Берлинда каршылый, туган авылына исән-имин, күкрәге тулы орден-медальләр белән кайта.

Утызынчы еллар башында Төрдәле мәхәлләсенә имам итеп Актаныш ягыннан заманында күренекле булган Кормаш мәдрәсәсен тәмамлаган указлы мулла Габделхай хәзрәт Җәмиловны алып кайталар, Габделхай хәзрәтнең имамлык еллары совет дәүләтенең муллаларга карата репрессия үткәргән чагына туры килә. Хәзрәт имамлык вазифаларыннан читләштерелсә дә, авылыбызда әхлакый тәртипләрне, гореф-гадәтләребезне саклап калу өчен зур тырышлык куя. Үзенә шелтәләр, кисәтүләр алып булса да, яңа гына дөньяга килгән сабыйларга исем кушу, кавышкан яшьләргә никах укуны, яшереп кенә булса да гает намазлары уздыруны да оештырырга тырыша. Мөлаем, түгәрәк йөзле, кара мыек җибәргән җитез хәрәкәтле хәзрәт һәр кешегә үзе беренче булып «Әссәламегаләйкем!» дип кычкырып сәлам бирер иде. Крестьян

хезмәтенә хөрмәт белән карады, кулында көрәк, сәнәк булыр иде, авыр сугыш елларында, безнең кебек 13-14 яшьлек малайлар белән ат җигеп, элеваторга ашлык, тракторларга ягулык ташыды.

## Авыр сугыш еллары

1941 елның 22 июне. Герман гаскәрләренең илебез чикләрен бозып басып керүләре, инде иртә таңнан ук шәһәрләребезне бомбага тотулары һәм башка шундый куркыныч хәбәрләр авылыбызга көннең икенче яртысында гына килеп иреште. Күп кенә ир-егетләребезгә военкоматтан чакыру да килеп җиткән икән, бригадирлар, атларга атланып, басуларга чапты. Күп тә үтмәде, арбаларга төялеп, атларын куа-куа кайтып та җиттеләр, шул арада авыл урамнары Сабан туендагы кебек халык белән тулды. Әйтерсең лә тормыш мизгелләребезнең шатлыклы минутларын санап бара торган сәгать уклары туктап калды. Бик күпләр бу коточкыч хәбәрнең чынлыгына ышанып та, төшенеп тә җитә алмыйлар кебек иде әле. Урам буйлап өлкән яшьтәгеләр башка чыгып яши башлаган улларының-кызларының хәлләрен белергә ашыкты. Яшьрәкләр, төркем-төркем җыйналышып, кемгә ничә сәгатькә чакыру килгәнен белештеләр. Авыл ирләрен, улларын сугышка озатырга әзерләргә кереште. Йорт, мунча торбаларыннан һавага күксел төтеннәр күтәрелде. Түбән урамда кемдер (гармунчы Касыйм абый булмый кем булсын инде) гармунын сузып җибәрде, берничә ир-егет, авылны моңга күмеп, күкрәк тавышлары белән гармунга кушылдылар. Ул төнне йортларда утлар сүнмәде, барсы да мәңгегә аерылышу иртәләрен каршылады.

Кояш чыгып килгәндә, без малайлар күптән инде урамда идек. Менә урамнар кисешкән авыл уртасындагы мәчет каршына (мәчет манарасы белән үз урынында иде әле) атлары җигелгән берничә олау килеп туктады. Ул арада урам башларыннан, тыкрыклардан төркем-төркем бала-чагаларын ияртеән хатыннар куллары белән ирләренең терсәкләренә асылынып, икенче берләре ирләренең иңбашларыннан кочкан хәлдә олаулар янына җыела башладылар. Гармун, җыр, балаларның үксеп елаулары белән кушылып, мәчет алды гөр килеп торды. Бераздан авыл башына чыгарга команда булды. Ниһаять, моң-җыр төркемнәре, зиратны үтеп, авыл башында туктап калды.

## Хушлашу

Биредә хушлашу митингы кебек нәрсә булып алды. Башта берсе, аннан икенчесе, олау арбасына сикереп менеп безнең мәктәп военругы Хәмәт Галиев белән комсорг Рабигый Саттахиев абыйлар: «Елашмагыз, иптәшләр! Безгә генә килгән кайгы түгел бу, бөтен ил кайгысы. Борчылмагыз, сугыш озакка бармас, безнең Кызыл Армияне җиңә алучы көч юк. Менә тиздән без, ул фашистларны тар-мар итеп, геройлар булып кайтырбыз», – дип сөйләгәннәре хәтеремдә калган. Тыңлап торучылар, аларның сүзләрен хуплап, сүрән генә кул чаптылар. Рус-япон сугышында катнашкан, халыкара хәлләрне газеттан укып баручы Шәйдулла карт, бераз тамак кыргалап торгач: «Алай, аннан-моннан гына уйламыйк әле, җәмәгать. Мин укып барам, ул герман дигән дошман бик гайрәтле күренә, үз әйләнәсендәге илләрне карчыга кебек кенә басып алды», – диде. Үзе, артыграгын ычкындырганын сизенеп, әйткәнен төзәтергә ашыкты: «Хәер, безгә теше үтә алмас, хаклык безнең якта». Сагаеп кына берничә карт тәкъбир әйтеп алгач, китүчеләр команда белән олауларга төялә башладылар. Кычкырып-акырып елаулар тагын да көчәйде. Берсеннән-берсе кечкенә, тузгак башлы балаларын ияртеп озатырга килгән Галимә апа белән Мәчтүрәттәй, ирләренең муеннарына асылынып: «Безне ташлап китүләрегез шушымыни инде? Итәкләребез тулы шушы сабыйлар белән нишләрбез? Ничек яшәрбез?» – дип такмаклый-такмаклый еладылар. Бары бер генә кич бергә кунып кала алган күршебез Җангәрәй абый белән Зөләйха җиңгәбез, өлкәннәр күзеннән читкәрәк китеп, үбешеп-кочышып туя алмадылар. Алгарак китеп шунысын да языйм: бу аларның соңгы тапкыр назланулары булган икән. Яңа ел алдыннан Җангәрәй абыйның сугыш кырында батырларча һәлак булуы турында кара кәгазь килеп төште.

Сугышка озатулар әнә шулай атналар, айлар буена дәвам итте. Инде өлкәнрәкләрне чакыра башладылар. 41 яшенә чыккан әтиемне август аенда без дә әнием белән

елый-елый озаттык. Бик зарыгып көтсәк тә, күңелле хәбәрләр ишетелмәде. Колхоз идарәсенә урнаштырылган батареялы «Родина» радиоалгычы янына кичләрен бик кыска вакытка гына җыелып алган авыл халкы, безнең гаскәрләрнең шәһәр, авылларны калдырып чигенүләрен ишетеп, бик күңелсезләнеп таралалар иде. Тиздән, югарыдан төшерелгән боерык белән, радио тыңлауны бөтенләй туктаттылар. Халык арасында немец Ленинградны камап алган, Мәскәүгә килеп җитә икән дигән имеш-мимешләр таралды. Сентябрь азакларында фронттан үлем хәбәрләре килә башлады. Хәрби госпитальләрдән, култык таякларына таянып, Фәсхетдинов Хөсни, Буторин Иван, куллары яраланып, Гыйльфанов Низамби абыйлар кайтып төштеләр. Һәр яңа көн туган саен, борчулы хәбәрләр ишетелеп торды. Сентябрь башыннан ук, кичләрен ут алу белән, йорт тәрәзәләрен пәрдәләр корып каплап бетерергә дигән катгый боерык игълан ителде. Моны немец самолётларының төнлә очып килүләре һәм бомба ташлаулары мөмкин дип аңлаттылар. Караңгы төшкәч, берәр йорт тәрәзәсеннән яктылык күренсә, авыл советында дежурлык итүчеләр бик тиз килеп җитәрләр һәм, нык кына орышып, икенче тапкыр тагын күрсәк, штраф салабыз, дип кисәтеп китәрләр иде.

## Кырык бернең салкын кышы

Немец гаскәрләренең Мәскәүгә якынлашуын өлкәннәр чамалый башладылар. Чөнки кинәт кенә хатын-кызларны, яшүсмер егетләрне Канаш дигән җиргә окоп казырга озата башладылар. Канашның Казаныбызга ерак түгел икәнен белгәннәр. Немец Казанга ук килеп җитәр микәнни, дип нык кына борчыла башладылар. Ул Канаш дигәннәре бик рәхимсез җир булып чыкты. Миннән өч яшькә зур дустыбыз Рәшит шуннан үпкәсенә салкын тидереп кайтты. Өйдә хәле авырайгач, Рәшитне Вольный Труд участок хастаханәсенә салып карадылар, анда да табиблар: «Даруларыбыз юк. Бу егеткә берничек тә ярдәм итә алмыйбыз», – дигәннәр. Шулай итеп, 17 яше тулып килгәндә, дустыбызны елый-елый җир куенына тапшырдык.

41нең декабре үзенең рәхимсез салкыннары белән кешеләрнең сәламәтлеген нык какшатты. Чи утын, ярым җылытылган өйләр, вакытында йокы, кайнар аш күрмәү үзенекен итте. Ат абзары янында корылган ындыр табагында ашлык сугучылар бик еш авырый башладылар. Хәлсезләнеп урын-җирләреннән тора алмыйча ятканнарны да: «Үлсәгез, эш урынында үлегез, ашлык сугуны туктата алмыйбыз. Фронтка икмәк кирәк!» – дип, урыннарыннан торгызып, ындырга китерделәр. Борын очлары, битләре өшеп күгелҗем төскә кергән, чалбар, башларына яулыклары өстеннән ирләреннән калган бүрек, аякларына йон оекбаш өстеннән кат-кат ыштыр урап чабаталар кигән апалар, эштән башка мәхәббәт тә бар икәнен оныта барган, моны бары тик хыялларында гына йөрткән бәхетсез кызлар, яшүсмерләр дошманны җиңү хакына барсы да түзделәр. Хәлебезнең өметсезлегенә шулай күңелләребез төшеп йөргәндә, кинәт, декабрь урталарында авылыбызга немец-фашист гаскәрләренең Мәскәү астында тар-мар ителүләре турында шатлыклы хәбәрләр килеп иреште. Безнең Кызыл Армиябез дошманны Мәскәүдән 120-150 чакрымга читкә алып ташлаган, әле һаман да тын да алдырмыйча куып бара икән. Бу хәбәрне ишеткәч, авыл халкының күңеле күтәрелеп китте. Үзләрен иң көчле дип санаган фашистларны җиңеп була икәнлегенә ышанычлары артты.

*(Дәвамы киләсе санда)*

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



## Рауза Хәйретдинова

1928 елның 3 гыйнварында Татарстанның Балык Бистәсе районы Яңа Ырга авылында туа. 1948 елда Г.Камал исемендәге театр каршындагы студияне тәмамлый һәм Татар академия театрында эшли башлый.

ТАССРның халык (1970), РСФСРның атказанган артисты (1979).

Уйнаган рольләре: Мәйсәрә – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), Мөршидә – «Казан сөлгесе» (К.Тинчурин), Галиябану – «Галиябану» (М.Фәйзи), Хәдичә – «Гүзәлем Әсәл» (Ч.Айтматов), Клеопатра – «Дошманнар» (М.Горький), Сәрби – «Һиҗрәт» (Н.Исәнбәт), Сания – «Качаклар» (Н.Исәнбәт), Кәләмзә – «Зифа» (Н.Исәнбәт), Гөлбану – «Татар хатыны ниләр күрми» (Г.Ибраһимов буенча), Рәмзия – «Күк капусы ачылса» (Х.Вахит), Фатыйма – «Талак, талак» (Х.Вахит), Нәҗибә – «Монда тудык, монда үстек» (Т.Миңнуллин), Вазифа – «Әниләр һәм бәбиләр» (Т.Миңнуллин), Шәмсенур – «Үзебез сайлаган язмыш» (Т.Миңнуллин) һ.б.



## Ринат Таҗетдинов

1938 елның 1 гыйнварында Татарстанның Чүпрәле районы Кече Чынлы авылында туа. 1961 елда Мәскәүдә Щепкин исемендәге Югары театр училищесын тәмамлый һәм 1961 елдан Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли. 1988-2010 елларда Татарстанның театр әһелләре берлеге рәисе.

Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1967), Татарстанның (1973) һәм Россиянең халык артисты (1982), СССРның Дәүләт премиясе (1985), «Алтын битлек» Россия милли театраль премиясенең беренче лауреаты (2016).

Уйнаган рольләре: Хәнҗәр – «Көзге ачы җилләрдә» (А.Гыйләҗев), Мирвәли – «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев), Дивана – «Ай тотылган төндә» (М.Кәрим), Ильяс – «Гүзәлем Әсәл» (Ч.Айтматов), Надир мәхдүм – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин), Миңлегали – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), Инсаф – «Әни килде» (Ш.Хөсәенов), Кол Гали – «Кол Гали» (Н.Фәттах), Муса – «Моңлы бер җыр» (Т.Миңнуллин), Абдулла – «Без китәбез, сез каласыз» (Т.Миңнуллин), Хәлиулла – «Илгизәр + Вера» (Т.Миңнуллин), Галимулла – «Хушыгыз!» (Т.Миңнуллин), Идегәй – «Идегәй» (Ю.Сафиуллин), Хәнәви – «Күрәзәче» (З.Хәким), Әнвәр – «Мин төш күрдем» (З.Хәким), Сократ – «Баскетболист» (М.Гыйләҗев) һ.б.



## Нәҗибә Ихсанова

1938 елның 25 гыйнварында Татарстанның Азнакай районы Буралы авылында туа. 1961 елда Мәскәүдә Щепкин исемендәге Югары театр училищесын тәмамлый һәм 1961 елдан Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли.

Татарстанның (1982) һәм Россиянең (2000) халык артисты, РСФСРның атказанган артисты (1987), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты (1998).

Уйнаган рольләре: Гандәлиф – «Көзге ачы җилләрдә» (А.Гыйләҗев), Маһисәрвәр – «Чаткылар» (Т.Гыйззәт), Җомабикә – «Кыю кызлар» (Т.Гыйззәт), Гөлчирә – «Әни килде» (Ш.Хөсәенов), Мәйсәрә – «Американ» (К.Тинчурин), Нәгыймә – «Назлы кияү» (К.Тинчурин), Хәдичә – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), Тәңкәбикә – «Ай тотылган төндә» (М.Кәрим), Миңзифа – «Кичер мине, әнкәй!» (Р.Батулла) Миләүшә – «Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә», «Хушыгыз!» (Т.Миңнуллин), Өммия – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин), Гөлфинә – «Әниләр һәм бәбиләр» (Т.Миңнуллин), Мария – «Илгизәр + Вера» (Т.Миңнуллин), Әсимә – «Йөрәк маем» (Т.Миңнуллин) һ.б.

## ФӘТХИ БУРНАШ
*(1898-1942)*



Күренекле драматург, шагыйрь, публицист, әдәбият тәнкыйтьчесе һәм тәрҗемәче Фәтхи Бурнаш (Фәтхелислам Закир улы Бурнашев) 1898 елның 13 гыйнварында элекке Сембер губернасының Буа өязе (хәзерге Чувашстан Республикасының Батыр районы) Кыр-Бикшик авылында мулла гаиләсендә туа. Авыл мәктәбендә башлангыч белемне алганнан соң, 1907 елда әтисе аны Казанның атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә илтеп урнаштыра. 1916 елда ул, мәдрәсә гыйлеме өстенә, үзлегеннән хәзерләнеп, Казандагы Татар укытучылар мәктәбе программасы буенча экстерн тәртибендә имтихан тота һәм татар мәктәпләрендә рус теле укытучысы булып эшләү хокукы биргән таныклык ала.

Ф.Бурнашның әдәби иҗат юлындагы беренче адымнары да әлеге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган шәкертлек елларына карый. Ул Г.Кариев җитәкчелегендәге «Сәйяр» артистлары белән якыннан танышып, аларга башта рольләр күчерергә булыша, ә 1914 елда бу труппа өчен рус драматургы С.Найдёновның «Дети Ванюшина» («Ванюшин балалары») исемле драмасын тәрҗемә итә. Сәхнә тормышы уналты яшьлек авторны тәмам канатландырып җибәрә: шул ук елны ул «Язмыш» исемле пьесасын, аннан соң «Сукбай» (1915), «Саташкан кыз» (1916) дигән драмаларын яза. Бераздан матбугатта аның шигырьләре һәм поэмалары да басыла башлый. «Авылда», «Дулкыннар арасында», «Ятим калды бала гомергә», «Айсылу», «Коркыт», «Казакъ кызы» һ.б. романтик поэмалары һәм шигырьләре белән Ф.Бурнаш инкыйлабкача ук үзен талантлы шагыйрь итеп тә таныта.

1917 елгы Февраль инкыйлабыннан алып Октябрь вакыйгаларына кадәр дәвам иткән демократик үзгәрешләр, милли хәрәкәтләр белән тамгаланган тарихи көннәрдә Ф.Бурнаш күп кенә шигырьләр, поэмалар һәм бөтен иҗатында күренекле урын тоткан, бүгенгәчә театр сәхнәләреннән төшми уйнала килгән «Таһир-Зөһрә» трагедиясен һәм «Яшь йөрәкләр» драмасын яза.


1918 елның апрелендә аны РКП(б)ның Сембер губерна комитеты карамагында чыга торган «Көн» исемле татарча газетага мөхәррир итеп билгелиләр. Шунда эшләгәндә ул, баш күтәргән чех-словак, акгвардияче гаскәриләр кулына эләгеп, тарихта «үлем эшелоны» исеме белән мәгълүм тоткыннар поездында Себер якларына озатыла. Фәкать үзенең кыюлыгы аркасында гына ул, юлда барганда поездан качып, үлемнән котыла һәм ак гаскәриләрдән азат ителгән Сембер шәһәренә кабат әйләнеп кайтып, «Таң» (элеккеге «Көн») газетасы идарәсендә эшләвен дәвам иттерә.

1920 елда Ф.Бурнаш Казанга килеп төпләнә. Әдип, татар поэзиясендә һәм үзенең башлангыч иҗатында тернәкләнгән романтик-героик, тарихи темаларны дәвам итеп, «Чәчәктән һәйкәл», «Гөлчәчәк», «Сахра каны», «Мөкәррәмә», «Ак каен», «Әҗәл», «Бохара» кебек күренекле поэмаларын яза. Ф.Бурнаш, поэзиядән тыш, драматургия жанрларында, публицистика, әдәби тәнкыйть өлкәләрендә дә актив эшли. «Хөсәен мирза» (1919), «Адашкан кыз» (1920), «Шәмсия» (1922), «Камали карт» (1925), «Илһам» («Ташландыклар», 1926), «Авыл яшьләре» («Урам кызы», 1929), «Хатирә апа» (1929) кебек пьесалар егерменче еллардагы татар театрын романтик рухтагы репертуар белән тәэмин итүдә һәм бу сәнгати юнәлешне алга таба үстерүдә мөһим роль уйный.

Утызынчы еллар ахырында алып барылган репрессив чаралар золымына дучар ителгән татар язучылары арасында Фәтхи Бурнашны иң соңгы корбан дияргә мөмкин. Аны 1940 елның 24 августында кулга алалар. Тикшерүләр, сорау алулар 1941 елның гыйнварына кадәр дәвам итә. 1942 елның 1 августында Ф.Бурнаш атып үтерелә.

## ШАМИЛ БИКЧУРИН

*(1928-1991)*



Шамил Мотыйгулла улы Бикчурин – Татарстанның нефть төбәгендә туып үскән, аны чыгару эшенә үзе дә якыннан катнашкан һәм татар әдәбиятына нефть темасын алып килгән язучыларның берсе. Ул 1928 елның 3 гыйнварында Әлмәт районы Миңлебай авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Авылда һәм Әлмәттә укып, ун сыйныф белем алганнан соң, 1945-1947 елларда Казан театр училищесында укый, аннары берникадәр вакыт Әлмәт дәүләт драма театрында актёр булып эшли. 1948 елның декабрендә гаскәри хезмәткә алынып, авиамеханиклар әзерли торган хәрби мәктәпкә җибәрелә, мәктәпне тәмамлагач, 1962 елның ахырына кадәр авиация гаскәри берәмлекләрендә хезмәт итә.

Армиядән кайткач, Ш.Бикчурин башта «Әлмәт нефть төзелеше» трестының коммуналь-торак конторасында ике ел тәрбияче, аннары өч елга якын (1955-1958) шул ук трестта эшче-төзүче, 1958 елның июненнән 1962 елның маена кадәр Лениногорск шәһәрендә чыга торган «Ильич васыятьләре» исемле төбәк газетасы редакциясендә сәнәгать бүлеге мөдире булып эшли. 1965-1967 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларда укый.

Ш.Бикчуринның проза жанрындагы беренче язмалары – Әлмәт төзүчеләре тормышына һәм хезмәтенә багышланган очерклары һәм хикәяләре – 1957 елдан «Казан утлары» журналында күренә башлый. Соңыннан, 1959 һәм 1961 елларда, бу очерклар һәм хикәяләр, «Ташлы тауда» һәм «Истәлекле таш» исемнәре белән аерым ике җыентыкка тупланып, Татарстан китап нәшриятында басылып чыгалар. 1961 елда әдип үзенең «Тальян моңы» исемле беренче музыкаль комедиясен дә яза. Нефтьчеләр белән авыл кешеләре арасындагы дуслык, хезмәттәшлекне шул заман таләпләренчә шактый оста гәүдәләндергән бу әсәр шул ук елны Әлмәт татар драма театрында һәм соңрак Казанда М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры сәхнәсендә куела. Авторның «Бергә гомергә» исемле икенче драма әсәре дә, Татар академия театры репертуарына кертелеп, 1964 елда тамашачыларга күрсәтелә.

Узган гасырның алтмышынчы елларының икенче яртысында басылган «Кайнар чишмә» исемле документаль повесте (1965) һәм «Могҗиза тудыручылар» дигән очерклар (1968) китабыннан соң, Ш.Бикчурин, нефтьчеләр тормышына һәм хезмәтенә бәйле бай мәгълүматын бер фокуска туплап, киң планлы роман язарга керешә. Төрле милли традицияләр җирлегендә тәрбияләнгән, төрле холыклы, төрле язмышлы кешеләрнең тормыш һәм хезмәтен чынбарлыктагы реаль вакыйгалар һәм үзенчәлекле образлар аша гәүдәләндергән «Каты токым» романы киң әдәби җәмәгатьчелекне дә, укучылар даирәсен дә үзенә җәлеп итә. 1974 елда роман татар һәм рус телләрендә аерым китап булып басылып чыга, ә 1977 елда Чехословакиянең Братислава шәһәре нәшриятында словак телендә, бераз соңрак Киев дәүләт нәшриятында украин телендә дә дөнья күрә. Бу романы өчен әдип 1976 елда ВЦСПС Президиумы һәм СССР Язучылар берлеге идарәсенең эшчеләр сыйныфы турындагы әсәрләргә уздырган конкурсында II дәрәҗә бүләккә лаек була.


1980 елда Ш.Бикчурин «Тирән катлам» исемле икенче романын тәмамлый. Нефтьчеләрнең мәшәкатьле хезмәтенә, үзара мөнәсәбәт һәм гаилә тормышы, мәхәббәт темаларына багышланган бу әсәр дә, матбугатта чыгу белән («Казан утлары», 1981), әдәби җәмәгатьчелек фикерендә уңай бәя ала һәм, тиз арада рус теленә тәрҗемә ителеп, ике тапкыр (Мәскәүдә һәм Казанда) аерым китап булып басылып чыга.

Әдәбият өлкәсендәге иҗади хезмәт уңышлары өчен Ш.Бикчурин 1978 елда «Почёт билгесе» ордены белән бүләкләнә, ә 1988 елда «РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек була.

Ул 1991 елның 17 гыйнварында Лениногорск шәһәрендә вафат була.

Ш.Бикчурин – 1962 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

# ЯМАШ ИГӘНӘЙ
*(1938-1997)*



Шагыйрь, журналист Ямаш Игәнәй (Ананий Нестерович Малов) 1938 елның 10 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Ләке авылында колхозчы гаиләсендә туа. 1955 елда – Сарман урта мәктәбен, 1958 елда Лубян урман техникумын тәмамлагач, бераз вакыт Башкортстанның Зианчура урман хуҗалыгында үз белгечлеге буенча эшләп ала. 1958-1960 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. Армиядән кайткач, туган районының Рантамак һәм Азалак авылы мәктәпләрендә балалар укыта, бер үк вакытта Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә читтән торып укый. Аны 1967 елда тәмамлый.

1965-1978 елларда – Ямаш Игәнәй Баулы һәм Мамадыш район газеталарында хатлар бүлеге мөдире, 1978-1980 елларда – Чаллы шәһәрендә чыга торган «Кама таңнары» газетасы редакциясендә тәрҗемәче, 1980-1985 елларда Чаллыдагы ит комбинатында инженер булып эшли. 1986 елда Чаллы төбәге язучылары аны Чаллы Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибе итеп сайлап куялар. Бу эшен ул 1988 елга кадәр дәвам иттерә, аннары, яңадан журналистлык хезмәтенә кайтып, өч ел Чаллы шәһәр газетасы «Чулман-Идел» редакциясендә хатлар бүлеген җитәкли, ә 1991-1997 елларда әдәби-нәфис «Аргамак» журналында әүвәл хатлар бүлеге, соңга таба публицистика бүлеге мөхәррире һәм берара Чаллыда 1993-2001 елларда керәшен татарлары өчен татарча һәм русча чыккан «Керәшен сүзе» газетасының җаваплы мөхәррире вазифаларын башкара.

Ямаш Игәнәй әдәбиятның поэзия һәм публицистика жанрларында иҗат итә. Аның шигъри әсәрләре республика көндәлек матбугатында, күмәк җыентыкларда узган гасырның җитмешенче елларыннан күренә башлый. 1981 елда «Сәфәр чыгам» исемле беренче җыентыгы басыла. Татар поэзиясендә ул тормыш, яшәү турында, үзгәрүчән-катлаулы дөнья хәлләре турында фәлсәфи уйланулар рәвешендә язган лирик һәм публицистик яңгырашлы шигырьләре белән билгеле. Ямаш Игәнәй балалар өчен дә шигырьләр яза («Йолдыз булып ян!», «Ике койрыклы төлке», «Мин әтигә охшаган» җыентыклары). Шагыйрь мирасында шулай ук проза әсәрләре – публицистик мәкаләләр, керәшен татарларының тормыш үзенчәлекләре, гореф-гадәт һәм йолалары турында очерк язмалары, Кырым татар халкының туган җиреннән сөрелү фаҗигасе белән бәйле драматик вакыйгаларны, тоталитар режимның вәхшәтләрен бәян иткән «Бәддога» исемле публицистик китабы да бар.

«Һәр язучының тормыш юлы, иҗади язмышы аның үзенә генә хас, беркемне дә кабатламас була. Берәүләрнең тормышы, язгы ташкын кеби ашкынып, давыл кеби атлыгып, шаулы уза. Ә инде икенчеләрнең яшәве – салмак кына, уйчан гына, үзенең тирән, киң колачлы суларын горур рәвештә тирбәтә-тирбәтә, ерак-еракларга юл тотучы елгага охшаган. Андыйлар үз эшләрен тыйнак кына, артык тавыш, шау-шу чыгармыйча, җиренә җиткереп башкаралар. Талантларын, көчләрен, хисләрен җәлләмичә, халыкка тугры хезмәт итәләр.

Шагыйрь, публицист, милләтпәрвәр Ямаш Игәнәй шундыйрак тыйнак холыклы, көчле рухлы, зур талантка ия булган шәхесләрдән иде. ... Ямьле-аһәңле шигъри юллары белән ул замандашларының рухын терелтергә тырышты. Сөекле халкының тарихын вә мәдәниятен тулырак яктыртырга ашыкты», – дип яза аның турында дусты, хезмәттәше Мансур Сафин *(Сафин М. Дустымны юксынам // Казан утлары. – 1998. – №1. –184-185 б.)*.

Шагыйрь 1997 елның 1 мартында Чаллыда вафат була. Кабере – туган авылы зиратында.

Я.Игәнәй – 1982 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

* Сәхифә «Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек» (төзүчеләре: Р.Даутов, Р.Рахмани. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2009) китабы нигезендә әзерләнде.

# «КАУРЫЙ КАЛӘМ» ЭЗЕННӘН

Арчабызда яшәп иҗат итүче Радик Хәбибрахман улы Фәизов (1931-2011) 1980 елда ТР Язучылар союзына кабул ителгәч, аңа үзе яшәгән төбәктә әдәби иҗат эшен тиешле югарылыкка күтәрү бурычын йөклиләр һәм районда «Тукай якташлары» исемле әдәби түгәрәк оештырыла.

Радик Фәизов вафатыннан соң, бу эшне берничә китап авторы, һәвәскәр шагыйрә Наҗия Саттарова дәвам итә. 2011 елдан башлап өлкәннәр группасы «Каурый каләм» исемен йөртә башлый.

2012 елда түгәрәк Арча үзәк китапханәсе каршында эшли торган иҗат берләшмәсенә әйләнә һәм аның җитәкчесе итеп Халидә Фәйзрахманова билгеләнә.

Берләшмә үзенең эшен, планлы рәвештә районда үткәрелә торган әдәби, мәдәни чараларда актив катнашып, эзлекле алып бара. Бүгенге көндә берләшмәгә 30дан артык һәвәскәр тупланган. Шуларның ун-унбише актив иҗат итә. Соңгы елларда дистәдән артык китап басылып чыкты. «Каурый каләм»челәр тагын ниләр белән шөгыльләнә соң?

Айга бер тапкыр китапханәдә утырышларыбыз уза, яңа язмалар анализлана, фикер алышулар үтә. Арча радиосы һәвәскәрләрнең тормышы һәм иҗаты турында айга ике тапкыр унбиш-егерме минутлык махсус тапшыру алып бара. «Арча хәбәрләре» район газетасы иҗатыбызны даими яктырта. Һәвәскәрләрнең китаплары басылып чыгу уңаеннан, танылган язучылар катнашында үзәк китапханә һәм «Казан арты» тарих-этнография музее белән берлектә, иҗат кичәләре үткәрелә. Яшьләрне иҗатка тарту максатыннан, мәктәп, һөнәри уку йортлары укучылары белән очрашулар да бездә еш уза.

«Каурый каләм»челәрнең кайберләре үз иҗатларын сезгә дә тәкъдим итә, хөрмәтле «Казан утлары» журналын укучылар.

**Халидә ФӘЙЗРАХМАНОВА,**
*әдәби берләшмә җитәкчесе*

## Көтмә, язмыш...

Күңелемнән куам әле
Сагышлы уйларымны.
Көтмә, язмыш, тик син куйган
Рольләрне уйнавымны.

Язмышларны сылтау итеп,
Туктамам көрәшүдән.
Туя алмам йөрәгемнән
Мәхәббәт өләшүдән.

Сагышларны таратуның
Бер чарасын табармын.
Сүнәр, димә, киресенчә,
Дөрләп-дөрләп янармын!

Язмышыма язылганны
Күрми калмам, килешәм.
Бирешмәмен, дусларым күп
Хисләремне бүлешкән.

Сагышларга күмеп җанны,
Телисеңме сынарга?
Тик онытма, үзең мине
Өйрәттең бит чыдарга!

***

Син кояшның берәр туганыдыр,
Бу кадәрле җылы булмас идең.
Яктылыгың белән, нурың белән
Йөрәгемә кереп тулмас идең...

Тулган айның газиз улыдыр син,
Булмас идең шулкадәрле серле.
Айга сөйлим шуның өчен, җаным,
Сиңа дигән иң кадерле серне...

Син җилләрнең якын дустыдыр ла,
Талгын җилдәй назлы булмас идең.
Мин дә шулай җилгә каршы басып
Иркәләнеп шулай тормас идем...

Синдәйләр юк, башка булмастыр да,
Җылы, якты, серле, назлы ярым.
Тормыш гөлем синең кулларыңда,
Синдә яши чөнки ярты җаным!

**Гөлара ШӘРИПОВА**

## Безнең Арча

Кай тарафтан килсәң дә,
Колачын ул киң ача.
Изгелектә булса ният,
Кунакчыл безнең Арча.

Тау өстендә балкый Арча,
Түбән җәйри Казансу.
Су буйларын бер иңлә,
Булса күңелең ямансу.

Мәгърифәт нуры бирелә,
Иҗат рухы мәңгелек.
Дан җырлый Казан артына
Бөек Тукай иң элек.

Саклап килдең шәһрилегең
Күпме гасырлар аша.
Яза яңа сәхифәләр
Чал тарихлы яшь Арча.

## Сагыну

Ак күбеккә баткан юргалар
Чапмый шул инде күптән.
Яңа гасыр болгый камчы –
Кануннары да бүтән.

Гореф-гадәт, йолаларны
Бармы чара сакларга?
Гадәти хәзер күренеш –
Килен – тимер атларда.

Басыла сусаулар моңга,
Заман алга ашкына.
Гармун хәзер туйларда
Тыйнак бер кунак кына.

Кызыл башлы чигүле
Сөлгеле сандык чоры –
Калды инде тарихта,
Кайтмаска, диеп, кире.

Мул сый-нигъмәтләрдән
Тора сыгылып өстәлләр.
Тик бераз аптырашта
Калган кебек өлкәннәр.

Юк кара-каршы җырлау,
Биюләре дә үзгә.
Кайтасы килә яшьлеккә,
Керсә дә гомер көзгә...

Бирелмик төшенкелеккә,
Китсен борчулы уйлар.
Укыла никах мәчеттә,
Шәрабсез уза туйлар.

Тыйнаклык – тәүфикъ сыйфаты
Хас булсын һәрбер кызга.
Милли үзаңлы егетләр
Кайтыр асылыбызга.

Нигез итеп киләчәккә
Күркәм эшләрне алыйк.
Җәүһәрләребез орлыгын
Җир куенына салыйк.

**Дамир НУРИӘХМӘТОВ**

## ЯШЬЛЕКТӘН СӘЛАМ

ХИКӘЯ

Кызу-кызу адымнар белән эштән кайтып барган Лилияне таныш тавыш туктатты. Каршында класссташын күреп, ул гаҗәпкә калды:

– Кадрия, нинди җилләр ташлады үзеңне шәһәргә?

– Ышанырсыңмы, юкмы, махсус синең янга, кунакка килдем. Сыйныфташлар белән очрашуга да кайтмадың, хатларыма да җавап язмыйсың, телефоныңның номеры да үзгәргән булса кирәк. Кызың, хәзер кайта, дигәч, каршы алырга чыктым. Сагындым.

Алар, шулай сөйләшә-сөйләшә, өйгә таба атладылар. Бергәләп гөрләшә-гөрләшә ашап-эчеп алганнан соң, Лилия Кадрияне үз бүлмәсенә алып керде. Беравык бер-берсенә карашып, сүзсез калдылар. Аннары китте гәп… Балачакның кызыклы мизгелләрен дә искә төшереп көлештеләр, мәктәп елларын да урап үттеләр, сыйныфташлар очрашуы турында да онытмадылар. Дамирны телгә алганда, Кадрия күз астыннан гына Лилияне күзәтте. Аның бурлаттай кызаруын күреп елмаеп куйды. Онытмаган! Дөрес, сер бирергә теләми, әмма аның турында сөйләшү аңа ошый.

– Монда кызы, оныгы барын белсә, нишләр иде икән ул? – дип әйтеп куйды Лилия.

– Ләйлә – Дамирның кызымы? Ник шушы вакытка кадәр берни әйтмәдең?

– Мин икенче кызга гашыйк булдым, без өйләнешәбез, дип торган кешегә шундый хәбәрне әйтә ала идемме? Бала белән үзенә бәйләп куярга тели, диячәк иде, иманым камил.

Ике дус, күрше, сыйныфташ төн уртасына кадәр сөйләшеп утырдылар, ниләрне генә искә төшермәделәр. Ләйлә берничә тапкыр ишекне ачып карады, аларның шулай гөрләшеп утыруларын, әнисенең бәхетле йөзен күреп сөенде. «Бу арада эш белән тәмам алҗыган иде. Кадрия апаның килүе яхшы булды әле», дип уйлады. Аннары кызы Алинәне йокларга яткырды да, аның муенына борынын төртеп, үзе дә изрәп китте. Әнисе килеп өстенә япканын тойды, тик йоклаганга сабышты Алинә.

Иртән Ләйләне йокыдан тәмле коймак исе уятты. Ул торып кухняга чыкты һәм, уйга бирелеп, өстәл янында утырган әнисен күрде. Лилия дә башын күтәреп аңа карады. Ана белән кыз бергә утырып чәй эчтеләр, аннары һәрберсе үз бүлмәсенә кереп китте. Лилия өйгә эш алып кайткан иде. Шуңа тотынып карамакчы булды. Тик нигәдер кулы бармады. Бераз мендәргә башын төртеп алырга уйлады. Әмма күзләренә йокы кермәде. Истәлекләр тәмам башын әйләндерде.

– Әни, Дамир абый кем ул, сыйныфташыңмы? Ул минем әтиемме?

– Ишеттеңмени? Әйе, кызым, ул – синең әтиең. Моңа кадәр әйтмәвем өчен гафу ит, белмәвең хәерлерәк, дип уйладым.

Лилиягә ничектер уңайсыз булып китте. Моңарчы кызыннан яшерен сере булмаса да, бу хакта әйтергә базмый иде. Менә бит, җае чыкты. Ләйлә генә әлеге хәбәрне ничек кабул итәр?

Көн артыннан көн үтте, тик Ләйлә, авызына су капкандай, башка бу хакта сүз куертмады. Ә көннәрдән бер көнне ул әтисе белән күзгә-күз очрашты.

Кичке як иде. Өйдә кыңгырау чыңлады.

Ишек ачылды. Зур чәчәк бәйләме тоткан Дамирны күреп, оныгын җитәкләп

урамга чыгарга җыенган Лилия бер мәлгә югалып калды, аннан, әдәплелек саклап, чакырылмаган кунакны түргә дәште.

Кечкенә Алинә моңа кадәр күрмәгән, әмма әбисенә таныш абыйның, түргә узып, диванга утыруы булды, кыз аның алдына менеп кунаклады. Дамир аны кысып-кысып кочаклады, чәчләреннән үпте. Аннан Лилиягә күтәрелеп карады. Дамирның күзендә яшь иде. Моны Ләйлә дә күрде. Күрде дә, кырт борылып, үз бүлмәсенә кереп китте. Өйдә авыр тынлык урнашты. Өлкәннәрнең берсе дә сүз башларга батырчылык итмәде. Алинә, аларның сөйләшмичә утыруларына сәерсенгәндәй, әле берсенә, әле икенчесенә карады. Бераздан ят абый алдыннан акрын гына шуып төшеп, әбисе итәгенә үрмәләде, аның агып төшкән яшьләрен сөртә башлады. Һаман да үзенә игътибар итүче табылмагач, үпкәләгәндәй, икенче бүлмәгә – әнисе янына кереп китте.

– Мин сезне эзләдем... – диде Дамир, авыр сулап.

– Каян? Мин котыпта яшәмим. Ялгышмасам, икебез бер шәһәрдә гомер итәбез. Ә теләге булган кеше җәһәннәмнән дә эзләп таба.

Дамирга акланырга урын калдырмады Лилия. Ни әйтә ала ул? Бар да дөрес. Юк, гафу итәрлек түгел аны. Яраткан кешесе, кызы, оныгы ялгыз яшәп ятканда, ул сөймәгәне белән гомер итте. Мин бала көтәм, дип алдады. Чынлыкта ул түгел, ә Лилиясе йөкле булган икән. Хәзер нишләргә? Ничек аларның бәхиллеген алырга?

– Лилия, зинһар, гафу итегез мине, – диде Дамир, тезләнеп. – Гаебемне аклау өчен ни эшлим? Байлыгым да җитәрлек, эшем дә бар, сәламәтлегемнән дә зарланмыйм, тик бәхетем генә булмады. Мин ялгыз, беләсеңме, ялгыз?!

Лилия бу хәлне көтмәгән иде. Бер мәлгә каушап калды. Тик үзен бик тиз кулга алды. Күңеленнән күпме йолкып ташларга тырышты ул мәхәббәтен, тик булдыра алмады. Бу хис аны гомере буена озата килде. Ә бүген, Дамир каршына тезләнеп гафу сорап торганда, йөрәгендә аңа карата бернинди ачу, үпкә калмавын тойды. Ничек алай булды соң әле бу? Вакыт үзенекен иттеме? Әллә төннәр буе мендәрен юешләгән күз яшьләре хисләрен юып төшердеме? Ничек кенә булмасын, кирәкми аңа бүген Дамир. Ул, яшь чактагы кебек, аның назларына, мәхәббәтенә мохтаҗ түгел.

– Гафу итәм мин сине, Дамир, шул гына кирәк булса, борчылма. Тынычлап яшә.

– Читтә балам, оныгым булуын белеп, тыныч яши алырмын, дип уйлыйсыңмы?

– Алар синеке түгел, бары минеке генә. Моңарчы шулай булды, моннан соң да берни дә үзгәрмәвен телим. Минем йөрәгемнән китмәсәң дә, син – Ләйлә өчен үлгән эти. Хәзер, үзеңне күреп сөйләшкәч, аңладым – син минем өчен дә юк икән инде. Оныт безне, моңарчы ничек яшәдең, шулай дәвам ит. Беркемгә үпкәләр урының юк, үзең сайлаган язмыш. Хуш, Дамир. Хәзер инде мәңгегә.

Дамир тагын нидер әйтмәкче иде, Лилия аны кул ишарәсе белән туктатты. Иргә ишеккә таба атлаудан башка чара калмады. Ул ишекне ачты, бусагада бераз таптанып торды да чыгып китте. Лилия озата чыкмады, ишек ябылган тавышка дерт итеп куйды. Аннан урындыкка утырды да бер ноктага текәлде. Ни уйлаганын хатын үзе генә белә иде. Бераздан бүлмәдән Ләйлә белән Алинә атылып чыкты. Оныгы әбисенең алдына елышты, кызы әнисенең җилкәсеннән кочып, битен аның чәчләренә яшерде. Лилиянең йөзенә елмаю җәелде. Менә алар – аның шатлыгы, бәхете, бәһасез байлыгы! Ул аларны беркайчан да, беркемгә дә һәм бернигә дә алыштырмаячак.

**Гөлсинә ЗӘКИЕВА**

## И, гали тел!..

И, гали тел! Синең белән
Яшимен дөнья көтеп.
Аралашып дуслар белән,
Алтын чорларга җитеп.

Масайганга, мин-миннәргә
Туры ярып сүз атам.
Боекканнарны иркәләп,
Сүзем белән юатам!

Берәүләрне шул тел белән
Назлыйм, сөям, иркәлим,
Дөньясыннан туйганнарга,
Кайт үзенә, китмә, дим!

Тормышны бутаганнарга
Тәнкыйть уты да атам.
Ә кемгәдер сүзем белән
Сары май булып ятам!

Кемгә ошый, ә кемгә юк,
Әмма газиз тел эшли,
Кирәк чакта сөя-назлый,
Битараф җанны тешли.

И, гали тел! Хак юлда бул,
Иярмә, булма куштан!
Юк-барларны сөйләп ташлап,
Дошман ясама дустан!

## Үлемсезлек

Мин Казанда. Таныш баскычлардан
Кремльгә таба юл тотам.
Тиз күрәсе килеп дулкынланам,
Эчтән генә үзем ут йотам.

Мәрмәр ташка ап-ак кар түшәлгән,
Яңа гына чәчкә салынган.
Мин һәйкәлгә киләм, йөрәк дулый,
Күңел көткән, җаным сагынган.

«Җиңәм», дигән җәллад, төртенгән дә,
Ун татарның башын кискәндә.
Юк үлмәде, җиңелмәде алар,
Яши алар, димәк, исән дә!

Биш шагыйрьнең башын кисү белән,
Хөрлек җыры бетәр, дигәнсең.
Җәлилчеләр исән, үлемсез җыр
Туган илдә яши, күрәмсең!

Мең елдан да алар исән калыр,
Ә Җәлилгә әле йөз генә.
Мин сокланып карап торам бүген
Батыр лачын горур йөзенә.

**Минһаҗ КАШАПОВ**

## Язмышым бүләге син, Татарстан!

Көчем бетсә, басуыңа чыгып,
Икмәк исе иснәп көч алам.
Рухым төшсә, урманыңа кереп,
Кошлар моңы тыңлап таң калам.

Татарстан – туган җирем минем,
Сиңа хезмәт итеп яшәдем.
Хәлем китеп, арып, туктап калсам,
Чишмәң суын эчеп яшәрдем.

Миңа күчкән язмыш бүләге син,
Изге җирем – мирас бабамнан.
Җәннәтләргә сине тиңләсәм дә,
Башка газиз урын табалмам.

Кая барсам, мине озатып йөри,
Сине сөю, сине сагыну хисе.
Язгы ташу, җәйге болыннарың,
Көзге алма, җир җиләге исе.

Татарстан! Горурлыгың чиксез,
Чал тарихлы, нурлы, и Казан!
Милләтемнең үлмәс моңы булып
Яңгырасын синдә гел Азан!

## Гомер көзе

Гомер уза, без дә картаябыз,
Картаймыйбыз, алга барабыз.
Кем соң әйтер сезне, әбиләр, дип,
Чибәр кызлар утыра, карагыз.

Һөнәребез шундый булды инде,
Гел яхшыга гына өндәдек.
Теләсә кем алып укысын ла,
Чиста безнең намус-көндәлек.

Урамнарга чыгып бер әйләнсәк,
Сәлам җыеп кайтып керәбез.
Кая баксак – безнең укучылар,
Нәтиҗәне шунда күрәбез.

Әти-әни дәшә, танымасак:
«Улым укыды сездә, тәгаен.
Сагынам, ди, һаман мәктәпне, ди,
Шук булгандыр әле, мөгаен!»

Елмаешып бергә утырабыз,
Без бит әле исән, күрегез.
Көз җитте, дип, бер дә моңаймагыз,
Чәчәкләрдән бәйләм үрегез.

Килмәсен гаиләгә борчулар,
Авырмый яшикче үзебез.
Матур көзләр насыйп булсын,
Озын булсын гомер көзегез.

**Халидә ФӘЙЗРАХМАНОВА**

## Чүлмәктән чыккан пәри



Мансур Вәлиев. Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН шаржы

Гариф абый Ахунов Язучылар берлегенең рәисе булып торганда миңа биш ел дәвамында (1975-1981) аның кул астында эшләргә туры килде. Башта әдәби консультант булып, аннары – «Идел» альманахы редакторы вазифасында. Нинди генә эшләр майтармадык без ул чагында яшьләр белән!

КПСС өлкә комитеты бер дә сөймәгән әдипләр – Әмирхан ага Еники, Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләҗев, Ибраһим Нуруллин кебек башбирмәс шәхесләр белән очрашу-әңгәмәләр үзләре генә дә ни тора! Кеше дә күп килә иде, хәтта коридорлар шаулап торды. Бу бит торгынлык еллары әле, шуңа күрә мондый хәлләр кемнәргәдер ошамагандыр инде – өлкә комитетына хәбәр иткәннәр... Ә җавапны, әлбәттә, Гариф абый бирергә тиеш була... Шулай берничә мәртәбә кабатлангач, көннәрдән бер көнне Гариф абый түзмәде, мине матбугатка чыгарган Фәрваз абый Миңнуллинга карап:

– Фәрваз! Бу пәрине чүлмәктән син чыгардың – менә хәзер чүлмәгенә үзең куып керт инде! – диде.

## Сергей Михалков татарларны яратты

Русия язучыларының башлыгы һәм атаклы шагыйрь Сергей Михалков татар язучыларын ярата иде. Беренчедән, ул үзе бик киң күңелле әйбәт кеше, ә икенче яктан, бездәге йөздән артык язучы аңа Мәскәүдә бара торган үзара гауғаларга каршы тору өчен дә кирәк иде. Шуңа күрә без делегация булып аның бүлмәсенә барып кергән чакларда ул:

– Что хотят мои татары? – дип елмаеп каршы ала иде. Аның турында шундый мәзәк тә ишеткәнем бар. Туган көнендә, янәсе, аны ел саен Леонид Ильич Брежнев үзе телефоннан шалтыратып котлый икән. Алдан секретариаттан әйтеп, кисәтеп куялар, билгеле: «Урында булыгыз», – дип. Мондый кисәтүне ишеткәч, Сергей Владимирович бөтен аппаратны ашыгыч рәвештә үз бүлмәсенә «киңәшмә»гә җыя. Төп серне әйтмичә генә! Ә «киңәшмә» барганда, Үзәк Комитеттан телефон шалтырый һәм Михалковны Леонид Ильич ҮЗЕ котлый. Моны инде бүлмәдәге һәркем ишетеп тора, шакката һәм бу хәбәр шул ук көнне бөтен Мәскәүгә тарала! Михалковның бөеклеге тагын бер мәртәбә раслана.

Без Михалковка берсендә татар яшьләре журналын оештыру мәсьәләсендә кердек. Документлар бик күп тупланган иде, мин аларның кыскача сөземтәсен бер биткә тупладым, әлбәттә. Ләкин барыбер күп саннар, күп дәлилләр килеп чыкты. Шуңа күрә Сергей Владимирович телефоннан КПСС ҮКы белән сөйләшә башлагач, мин, аның янына ук барып басып, бармагым белән аеруча мөһим булган саннарга төртеп күрсәтергә тотындым. Мин күрсәтеп торам, Михалков ул саннарны телефоннан ҮКка җиткерә тора, безне яклап сөйләшә. Хәзер инде үземә дә кызык тоела – шундый җитди кешене ҮК белән ничек сөйләшергә өйрәткәнмен түгелме соң?!

## «Адашыр идем...»

Иҗат йорты дип аталса да, анда гел-гел язып кына утыру мөмкин түгел, билгеле. Чып-чын урман уртасы, табигать кочагы бит... Шуңа күрә андагы сукмакларны байтак таптадык без. Көннәрдән бер көнне, Мәскәүдән килгән шагыйрә ханым белән, матур гына әңгәмә кыла-кыла, урман сукмагыннан бара идек, каршыбызга Мостай ага килә

бит. Үзе генә. Һәрвакыттагыча уйчан, моңсу күренә бу. Безне таныды ул, билгеле – инде бирегә килгәнгә байтак булды бит... «Мостай агага нәрсә дип әйтергә микән?» дип баш вата башлаган идем, ә ул безгә елмаеп:

– Бу сукмактан барып адашмассызмы икән соң? – дип сорап куйган булды.

Ә мин инде моны бик тә җитди сүз санап:

– Юк, юк! Без бу сукмакның кая барганын беләбез... – дип, аны тынычландырырга ашыктым.

– Ә мин сезнең урында булсам – адашыр идем! – диде Мостай ага һәм тыныч кына үз юнәлешендә китеп тә барды.

Бөек шагыйрь белмичә әйтмәгәндер шул?!

## Партиягә кергәндә

Коммунистлар партиясенә керү безнең Язучылар берлегендә бик тә җитди эш итеп куелган иде. Бу иҗади халыкка ышаныч чамалы булудан килә, билгеле.

Шулай, үткән гасырның җитмешенче еллары ахырында, мине дә партиягә алмакчы булдылар. Ә анда керү өчен, иң башта бюро аша үтәргә кирәк. Иң элек сине җиде кешедән торган бюро тикшерә. Төрле яктан «капшап» карыйлар, лаекмы-юкмы икәнеңне ачыклыйлар.

Иң четерекле сорауны өлкән яшьтәге бер язучы ханым бирде бит.

– Мансур, синең эчү яклары ничек тора?

Ә мин мондый сорау булырын һич тә көтмәдем, аңа алдан әзерләнмәгән дә идем. Чөнки яшьләрнең «Идел» альманахында эшләгәч, төрле-төрле чаралар үткәргәч, бераз гына яшьләрчә булырга туры килә. Авызга алмыйча һич тә мөмкин түгел! Ничек дип җавап бирергә икән соң?

Байтак кына вакыт дәшмичә тордым, ахрысы...

Бер мәлне Сибгат ага Хәкимнең салмак кына тавышы ишетелә:

– Ә без... Мансур белән... «Аккош күле»ндә... «Вермут» эчәбез...

Шул сүзләрдән соң бүлмәдәге бөтен халык күтәрелеп көлде, четерекле сорауга җавап та бирелде шикелле.

Чыннан да, шундый хәл булган иде шул, Сибгат ага ерак Венгриядән алып кайткан затлы «Вермут» шәрабен эчәргә чакырган иде!

## Усмановка шелтә

Татарстан язучыларының дүрт елга бер уза торган Корылтае бара. Президиумда – Өлкә Комитетының беренче секретаре Гомәр Исмәгыйль улы Усманов, безнең рәисебез Туфан ага Миңнуллин һәм башка хөрмәтле шәхесләр. Мин, трибуна артына басып, бездә әдәби тәнкыйтьнең торышы турында доклад сөйләп маташам. Бераздан ишетәм – безнең Туфан абый белән Усманов нәрсә турындадыр гәпләшә башладылар, мине тыңламыйлар! Президиум бик якын булгач, ишетелеп тора, минем ачуны китерә! Шундый хәлдә бераз сөйләгәч, түзмәдем – туктадым да, урысчалатып:

– Гумер Исмагилович, я и для вас говорю! – дип әйтеп салдым! Һәм тагын үземнең сүземне дәвам иттем...

Әлбәттә, Туфан ага белән Усманов ниндидер проблеманы хәл иткәннәрдер инде, эш турында. Аларныкы да юк-бар сүз булмагандыр. Ләкин мине дә аңларга тырышыгыз!

Тәнәфескә чыккач, үзебезнең хатын-кыз язучылар миңа шелтә ясады-ясавын. «Шундый олы кешегә андый сүз әйтмиләр инде!» – диделәр.

Ә мин ул сүзем өчен үкенмәдем шикелле...

## Чын авторы кем икән?

Авыл мәктәбен тәмамлагач та, мин башта Әгерҗе район газетасы редакциясендә эшләдем. Аннары, ике ел стаж туплагач, университетның журналистика бүлегенә укырга кердем, матбугатта усал гына мәкаләләр бастыра башладым... Әдәби тәнкыйтьтә

беренче адымнар ясалгач, Әгерҗедәге дусларымнан менә мондый эпиграмма килеп төште:

*Хәсән Хәйри пычак кайрый –*
*Кемне суярга микән?*
*Кашшаф Гази кабер казый –*
*Кемне куярга икән?*
*Мансур Вәли пәке сайлый –*
*Кемне уярга икән?*

Минемчә, әйбәт язылган эпиграмма бу. Ләкин менә чын авторы кем икән? Чөнки кайдадыр элегрәк тә күргәнем бар кебек иде.

## «Хәлләрегез ничек?»

Шулай бервакыт Казанның Пушкин урамы буйлап аска таба төшеп киләм, каршыма өлкә комитетының мәдәният бүлеге мөдире М.Мусин очрады бит. Ул инде безнең халыкны бик тә яхшы белә. Яшь кенә булсам да, туктап, минем белән дә кул биреп күреште, хәлне дә сорады. Мин исә каушый-каушый җавап бирәм:

– Менә, китап кибетенә барган идем дә, мин көткән китап килмәгән икән әле, – дим. Аннары инде, күнегелгән гадәт буенча, аның да хәлен сорамакчы булдым.

– Ә үзегез ни хәлләрдә? – мин әйтәм.

Хәзер, күп еллар үткәч, көлә-көлә искә алып утырам. Минемчә, ул нәрсә дип җавап бирергә тиеш иде икән инде: «Мәскәү бик каты кыса бит әле, Мансур! Өлкә комитетында эшләве бик кыен ул – әллә эштән китим микән?» – дисенме...

Ул чагында Мусин да гадәттә әйтелә торган җавап белән котылды:

– Рәхмәт! Хәлләрем әйбәт кенә әле! – диде.

## Шпионнар диярсең...

Узган гасырның сиксәненче еллары... Безнең, яшьләр журналы сорап, КПСС ҮК секретаре М.А.Сусловка керергә җыенып йөргән чак. Шушы «Малеевка» дигән иҗат йортында тупланабыз да аннары Мәскәүгә китәбез, янәсе. Без дигәнем – Г.Бәширов, Р.Мостафин һәм мин. Т.Әйди дигән бик тә фидакарь җанлы әдибебез Казаннан торып безгә ярдәм итә. Беркөнне кичен, шушы иҗат йортыбызга кайтып, ашханәгә керсәм – Рафаэль абый, ашыга-ашыга, минем каршыга килә:

– Мансур, синең исемгә килгән бик сәер телеграмма ята анда. Күзге каршында. Бөтен кеше укый да көлә, укый да көлә! Тизрәк барып ал инде син аны! Үзем дә аптырадым инде, билгеле. Кемнән булыр икән, дим. Укысам – анда: «Вариант Равиля отпадает», дигән сүзләр. Телеграмма – Казаннан, Тәүфикъ Әйдидән. Безнең ул иҗат йортында телефон юк диярлек иде, бик тә сирәк эшли иде ул. Шуңа күрә телеграмма бирергә мәҗбүр булган икән бахыр Тәүфикъ! Ә ул сәер сүзләрнең мәгънәсе исә: «Равил Фәйзуллин безнең белән бара алмый», дигәнне аңлата иде.

Менә шундый «шпионнар...»

## Ярый әле таныдылар

Иртән иртүк торып, башта урманны, күл буйларын айкап кайтырга яратам... Ул көнне бигрәк тә иртә уяндым ахрысы. «Җәйге иртә матур да инде», дип соклана-соклана, күл буйлап атлый идем, бермәлне каршыма ике егет килеп чыкты. Бик кыю рәвештә миңа таба якынлаша болар... Килеп тә җиттеләр, тиз арада туктаттылар да! «Хәзер ни була инде?» – дип уйларга да өлгермәдем, миңа болай диләр болар:

– Ә сезнең бәхетегез бар икән! Без сезне таныдык бит – сез редакциядә эшлисез!

Һәм ничек күренгән булсалар, шулай кинәт кенә юкка да чыктылар. Әгәр дә танымаган булсалар? Болар иртән иртүк кеше үтерергә дип чыккан булдылар микәнни?!

## Тере мишень

Ерак Көнчыгышта Совет Армиясе офицеры булып йөргән чагым. Безнең полкның үзебез яшәгән шәһәрдән еракта, урман эчендәге бер ачыклыкта урнашкан полигоны бар иде. Солдатларны шунда алып барып, автоматтан атарга өйрәтәләр. Фанерадан ясалган кеше фигуралары мишень итеп рельслар өстенә көйләп куелган. Пульттан бирелгән командага буйсынып, ул фигуралар хәрәкәт итә – солдатлар шуңа атып тигерергә тиешләр!

Көннәрдән бер көнне бер фигурабыз йөрми башлады бит. Нишлисең, бер чакрым чамасы араны үтеп, шунда барып тикшерергә кирәк! Бер сержантны алдым да мишеньнар ягына таба киттек. Гаебен табып, байтак кына гомер төзәттек. Инде кайтабыз дип торганда, кинәт якында гына нәрсәдер выжылдап оча башлады. Монда инде күптәннән хезмәт итүче сержант тәҗрибәлерәк булып чыкты:

– Иптәш лейтенант, аталар бит! Тизрәк җиргә ятыгыз! – дип кычкырды.

Нишлисең, җиргә ятып, әлеге хәвефле минутларны көч-хәл белән үткәрдек. Кире пульт янына әйләнеп кайтсак, анда шундый хәл: полктан бер взвод солдат килеп төшкән, боларга тиз генә ату күнекмәсен үтәргә кирәк! «Офицерлары бик ашыктырды, шуңа күрә без өч мәртәбә гудок бирдек тә (бу инде «качыгыз» дигәнне аңлата), алар ата башлады», – дип аңлаттылар безгә. Ә без ул гудокны ишетмәгән икән...

## Уйнап йөргәндә – гонорар!

Мәктәпнең өченче сыйныфында укыганда ук, мин үзебезнең район газетасына мәкаләләр яза башладым. Һәм аларны бастырып чыгара иделәр! Ул чагында әле – Әгерҗегә кушылмаган Красный Бор районының «Ленин юлыннан» дигән газетасы. Иң кызыгы шунда: мин – ун яшьлек малай – тыкрыкта иптәшләрем белән уйнап йөрим, шул чагында хат ташучы апа килеп чыга да якындагы бүрәнә өеменә килеп утыра, зур сумкасын салып куя да мине үзе янына чакыра. Аннары, нindiдер кәгазьгә кул куйдыргач, миңа кәгазь акчалар тоттыра! Әле бу 1961 елгы реформага хәтле, шуңа күрә минем кулга байтак кәгазь килеп керде бугай. Тыкрыкта уйнап йөргән ун яшьлек малайга гонорар бирү, чыннан да, бер дә уен түгел бит! Баш күккә тигәндер ул чагында.

## Сабир Шәрипов эзеннән...

Безнең авылдан чыккан Сабир Шәрипов Казакъстанда бик зур кеше санала. Ул анда Совет властен урнаштыру өчен көрәшкән, бик күп китаплар язган. Иранда безнең илче булып эшләгән... Әмма соңрак кулга алынган һәм 1942 елда Ташкент төрмәсендә җан тәслим кылган... 1970 елда, шуның язмышы белән кызыксынып, мин ерак Алма-Ата шәһәренә барып чыктым. Ул чагында Татарстан Язучылар берлегендә рәис урынбасары булып эшләгән шагыйрь Ренат Хариска зур рәхмәт инде! Миңа, студент кешегә, шунда барырлык һәм бер атна яшәрлек акча табып бирә алган бит! Байтак нәрсәләр ачыклап кайттым мин туган якка. Әмма, кайтуга, мондагы танышлар миңа сорау арты сорау яудыра:

– Син нәрсә эшләдең? Нәрсә эшләдең?!

Баксаң – мине КГБ тикшерә башлаган икән! Танышларымны шул борчыган. Ни өчен дисәгез – беренчедән, төрмәдә үлгән Сабир Шәрипов – гаепләнгән кеше. Аның язмышы белән кем кызыксына? Икенчедән, Алма-Ата ул – чик буендагы шәһәр, анда кем килеп чыкмас!

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез, озак еллар журналыбызда тәнкыйть бүлеген җитәкләгән ветеран хезмәттәшебез үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Чир

*(Бүредән сарык туамы?)*

Ерак араны якын итеп килгән Уфа татары Мәскәүдә халык депутаты Зюгановны көч-хәл белән генә эзләп тапты. Беренче карашка кырыс күренгән Зюганов, «илдә бердәнбер чын коммунист бит Сез», дигәч, мәктәп дәреслегеннән сеңеп калган тарихи үчен онытып, татарга елмаеп карады. Танышу, гадәттәгечә, киеренкелекне йомшартудан башланды.

– Адольф Хөҗҗәтович дисез инде... Исемегез кызык... Адольф татарча нәрсәне аңлата?

– Безнең татар яңгыравыклы исемнәр яратучан. Мин үскән авылда өч Рузвельт, ике Черчилль, тагын... Блюхер белән Макнамара ишле-сыңарлы иде. Ә минем исемгә килгәндә... Сталин белән Гитлер, бер-берсен котлап, телеграммалар алышкан көннәрдә туганмын мин. Сталинның якын дусты кебек зур кеше булып үссен дип, миңа Гитлер исемен кушканнар. Кем белгән бит аның киләчәктә дошман буласын...

– Алай икән... – Зюганов, ирен чите белән елмаеп, Адольф Хөҗҗәтовичка карады.

Төп мәсьәләгә күчтеләр. Зюгановның өстәленә бихисап белешмәләр өелде.

– Мин Сезгә зур гозер белән килдем бит әле, Геннадий Әндриеч. Ярдәм итегез, зинһар, күпмилләтле гаиләләргә берәр төрле льгота бардыр бит?!

Күпмилләтле гаилә дигәнне аңышмыйчарак торган Зюгановка Адольф Хөҗҗәтович төшендереп бирде:

– Уфада яшим мин. Хатыным татар, үзем дә татар идем элек. Ике кызымның берсе – татар, икенчесе башкорт булып туды...

– Икенче хатынга өйләндегезмени? – диде Зюганов.

– Юк ла, беренче бала тугач...

– Ә-ә-ә, димәк, хатыныгыз хыянәт итте... – дип сак кына сорады Зюганов.

– Хыянәт итеп кенә карасын, бәреп үтерәм бит мин аны! Гафу итегез, нервылар какшаган. Аңлагыз хәлемне, Геннадий Әндриеч, мин бит Башкортстанда яшим. Икенче балаңны башкорт дип яздырсаң, ике бүлмәле фатир бирәбез, диделәр дә... Булгач-булгач, өч бүлмәле булсын инде дип, үземне дә берочтан башкортка әйләндердем. Бүгенге көндә ике кызым да үсеп җиттеләр. Берсе чувашка, икенчесе удмуртка кияүгә чыкты. Өчәр бала таптылар. Балалары бер-бер артлы урыс булып тудылар, рәхмәт төшкере. Яһүд белән әрмән кушылса, шахматист дигән милләт туа, диләр бит әле, ә безнең татар... үзегез күрәсез, минем ике кызым гына да илгә алты урыс үстереп ята! Булачак сугышка бер взвод солдат бит ул! Тик торганда гына йөз кырык миллионга җитмәгән бит ул бөек урыс халкы. Аның санын безнең кебек фидакарь татарлар үрчетешә. Моның өчен безгә льгота булырга тиештер бит?! Зинһар, дип сорыйм, күпмилләтле татарның хәлен аңласагыз иде. Карап-карап торам да, Геннадий Әндриеч, сез үзегез дә... Зюганов дигән фамилиягезне әйтәм. Кайчандыр дөрес әйтелеше Җиһанов булган инде аның. «Зюган» дигән сүз урыста юк бит, шулаймы? Шулай... Холкыгыз да татарныкы: коммунизмга ышанып йөрүегездән әйтәм.

«Булыр да... Урысның маңгаена чиртсәң, татар каны чәчрәп чыга, дип, Наполеон чукынчык белми әйтмәгәндер», дип пошаманга калды Зюганов. Әмма, тәҗрибәле коммунист буларак, эчендәге уен сиздермәскә өйрәнгән иде ул. «Кара син аны, үзе үтенеч белән килгән, үзе кинаяләп сөйләшкән була... Коммунизмга ышанам, имеш, татар хәтәр халык шул, инде бетә дигәндә дә яңадан калкып чыга, каһәр... империя тоткан халык шул», дип уйлады Зюганов һәм үзе дә кинаягә күчте:

– Мин шуны һич кенә дә аңлый алмыйм: табигатьтә бар да уйланылган югыйсә. Бүредән бүре туа, сарык тумый бит. Төлкедән – төлке, куяннан – куян. Хәтта күке булып күке дә теләсә нинди кош оясына күкәен салып китә, әмма аңардан барыбер күке чыга. Менә Сезнең карга оясында үскән күкенең карга булып кычкырганын күргәнегез бармы? Юк бит! Шулай булгач, Сез, татарлар, табигать законына каршы килеп, ничек алай җиңел генә төрле милләт кешесенә әверелә аласыз, ә?! Әллә соң бу социализм казанышымы? Чөнки капиталистик илләрдә яшәүче татарларның үз милләтен саф килеш саклаганын яхшы беләм мин. Болай булмый, генетик яктан тикшертергә кирәк сезнең халыкны! Берәр төрле чир-зәхмәт түгел микән бу? Чирегезне без – урысларга йоктыра күрмәгез тагын. Мисалга алыйк: урыс татар кызына өйләнде дә, балалары татар булып туды ди. Күз алдына китереп булмый бит моны. Гаиләгездә ничә милләт вәкиле, дидегез әле?

– Тә-әк, хатыным белән бер кызым татар, үзем башта татар идем, хәзер башкортның халык санына керәм, икенче кызым башкорт, тә-әк, ире чуваш, балалары урыс, тагын... удмурт кияү...

– Ярый, ярый... ярдәм итүләрен сорап, мин биш республикага хат язармын, ничек дидегез әле, күпмилләтле татар, дидегезме? Кызык... – дип, Зюганов алтын очлы каләмен кулына алды.

Күп кирәкмени, ике чабата бер кием, дигән татарга. «Түшеңә медаль тагабыз, «ням-ням» кабиләсенә күчәсеңме?» – дисәләр, «Юк, кирәкми!» – дип каршы төшмәс иде Адольф Хөҗҗәтович. «Мин – грузин!», «Мин – латыш!» дип, күкрәк суга торган киребеткән милләттән түгел ич ул. Андый чакта татар юаш кына сорап куя:

– Медальне хәзер үк тагасызмы, әллә «ням-ням» булгачмы?..

*1989 ел*

## Акча кемгә кирәк?

Камил Кәримовның сигез йөз дә кырык мең тиражлы «Чаян» журналында эшләгән чагы. Җаваплы секретарь буларак, гонорар язу көне җиткәч, аның кабинетыннан журнал хезмәткәрләре өзелми. Берәү дә: «Миңа гонорарны бигрәк күп язгансың», – дип керми, әлбәттә. Танылган рәссам Леонид Елькович та, йомшак кына басып, бусагадан уза.

– Бу санга кергән рәсемнәрне өч тапкыр күчереп ясадым, ике-өч тәңкәгә арттыра алмассызмы, Камил Адгамович, – дип үтенечен белдерә.

– Эчмисез, тартмыйсыз, Леонид Яковлевич, нәрсәгә сезгә акча?! Сиксәнгә җитеп килгәндә, хатын-кыз да кирәк түгел инде сезгә...

– Хатын-кыз мәсьәләсендә алай кистереп әйтмә, – ди Леонид Елькович, бармагын чөеп, яһүдләрчә мут карашын төбәп, – менә сез күз алдына китерегез әле, Камил Адгамович, хатын-кыз белән якынлык кылганнан соң, карават кырыенарак шуышып, түшәмгә карап, бөтен нәрсәгә битараф булып, хәлсез рәхәтлектә чалкан яткалыйсыздыр бит?.. – Камилнең күзләрендә тояклар уйный башлавын күреп, ул өстәп куя: менә мин унбиш ел инде гел шундый халәттә яшим, – ди ул.

## Кайчан бәреләчәк?

Бер төркем язучы кавеме, Ркаил Зәйдулланың тәмәке тартканына тәтендәш булып, гәпләшеп тора.

– Ишеттегезме әле, безнең галактика, коточкыч зур тизлек белән очып барып, Андромеда галактикасына килеп бәреләчәк икән, – ди Рамил Ханнанов.

Моны ишеткәч, Ркаил Зәйдулла иреннәре арасыннан ялкау гына чыгып килгән төтен божрасын селтәп төшерә дә тел очыннан сүгенеп куя:

– Блин... Мин йорт төзергә тотынгач кына!

Аннары, бөтен гаеп синдә, дигән сыман, Рамилгә өнәмичә генә карап:

– Синеңчә, кайчан килеп бәреләчәк инде?

– Минемчә түгел, галимнәр әйтүенчә – дүрт миллиард елдан соң.

Ркаил Зәйдулла шаркылдамыйча гына көлеп куя:

– Алай булгач, төзеп өлгертәм икән әле...

### ПУТИН ҮЗ КАНДИДАТУРАСЫН КҮРСӘТТЕ

Түбән Новгородтагы ГАЗ предприятиесе хезмәткәрләре белән очрашуда Владимир Путин 2018 елда Россия Федерациясе Президентын сайлауларда үз кандидатурасын тәкъдим итәчәген белдергән иде. Инициатив төркем үзенең җыелышында бу тәкъдимне бертавыштан хуплады. В.Путин Үзәк сайлау комиссиясенә документларын тапшырды.

В.Путин үз кандидатурасын тәкъдим итүгә, аны Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов та яклап чыкты. Ул бүгенге гадәти булмаган вазгыятьтә берләшү, В.Путин кандидатурасын хуплау зарурлыгын искәртте.

### СЪЕЗД

Мәскәүдә «Единая Россия» партиясенең XVII съезды кысаларында Югары һәм Генераль советның берләштерелгән утырышы булды. Аның төп темасы – 2018 елның мартында РФ Президентын сайлау. Утырышта ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты.

### ЖУРНАЛИСТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның журналистлар белән традицион очрашуы булып узды. 2017 елга йомгак ясап, Рөстәм Нургали улы Татарстанның киләчәктә үсеше өчен зур потенциалга ия булуын әйтте. Президентның сүзләренә караганда, киләсе елда 38 республика программасын гамәлгә ашыру күздә тотыла.

### ЯҢАДАН АЧЫЛДЫ

Зур күләмле реконструкция эшләрен башкарганнан соң, Казандагы Ленин исемендәге мәдәни-ял итү комплексы яңадан ачылды. Яңартылган комплексны ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов карады, балалар өчен оештырылган чыршы бәйрәмендә катнашты.

### ЯҢА БАШКАЛА

2018 елда төрек дөньясының яңа башкаласы билгеле булды. Ул – Төркиядәге Кастамону шәһәре.

### ӘДӘБИ ЕЛГА ЙОМГАК

Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары «Казан» милли-мәдәни үзәгендә әдәби елга йомгак ясадылар. Ел дәвамында башкарылган эш-гамәлләргә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов хисап ясады. Җыелышта филология фәннәре кандидаты, КФУ доценты Нурфия Юсупова (шигърият турында), филология фәннәре кандидаты, КФУ доценты Гөлфия Гайнуллина (чәчмә әсәрләр), филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов (драматургия), язучы Айгөл Әхмәтгалиева (балалар әдәбияты), язучы, мөхәррир Галимҗан Гыйльманов (әдәби тәнкыйть), педагогика фәннәре докторы, КФУ профессоры Әлфия Галимуллина (рус телендәге әдәбият һәм әдәби тәрҗемәләр) докладлар белән чыктылар. Чаллы, Әлмәт язучылар оешмалары җитәкчеләре Факил Сафин, Рәфкать Шаһиев ел дәвамында башкарылган эш-гамәлләр турында сөйләделәр, хәл итәсе мәсьәләләргә тукталдылар. Докладлардан соң фикер алышуларда каләм ияләре Рабит Батулла, Фәүзия Бәйрәмова, Илфак Ибраһимов, Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Хатыйп Миңнегулов, Хәнәфи Бәдигый, Нурулла Гариф, Нәҗибә Сафина, Фирдәвес Хуҗин һ.б. катнашты.

2017 елда Язучылар берлегенә сигез кеше кабул ителгән. Данил Салихов аларга Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы таныклыкларын тапшырды. Болар арасында Казаннан Алсу Шамсутова, Ләйсән Могътәсимова, Наилә Яхина, Түбән Камадан Нурзия Мирхазова, Мөслимнән Лилия Садриева, Әтнәдән Гөлүсә Батталова бар. Марат Морев белән Ольга Овчинниковага таныклыклар алданрак тапшырылган иде. Җыелышта Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең әдәби премияләре тапшырылды. Гаяз Исхакый премиясенә – Мәдинә Маликова, Фатих Хөсни премиясенә – Госман Гомәр, Җамал Вәлиди премиясенә Лирон Хәмидуллин лаек булды. Моннан тыш драматург, прозаик Рәдиф Сәгъдигә Туфан Миңнуллин премиясе бирелде.

Әдәби ел йомгаклары киләчәккә бурычлар тәгаенләнгән резолюция кабул итү белән тәмамланды. Җыелышта ТР Президентының эчке сәясәт мәсьәләләре департаментының милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе башлыгы Данил Мостафин катнашты.

### КОНКУРСТА ҖИҢҮЧЕЛӘР

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан оештырылган әдәби әсәрләр конкурсына йомгак ясалды.

«Повесть» номинациясендә

I урын – Айгөл Әхмәтгалиева («Ак читек» әсәре өчен)

II урын – Вакыйф Нуриев («Кышның озын бер төне»)

III урын – Ркаил Зәйдулла («Алтын кашыклы яңгыр»)

«Хикәя» номинациясендә

I урын – Рөстәм Галиуллин («Дәвам»)

II урын – Әмирҗан Моталлапов («Чоңгыл»)

III урын – Фәнзәлия Бәдретдинова («Кәсеп кадере»)

«Әдәби очерк» номинациясендә

I урын – Рабит Батулла («Безнең заман каһарманы»)

II урын – Гөлзәлифә Әхмәтгалиева («Туган җирдә канатлылар»)

III урын – Альберт Хәсәнов («Бал корты»)

***

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Бөтендөнья Татар конгрессы тарафыннан оештырылган «Татар рухы һәм каләм» VII Бөтенроссия журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары бәйгесенә йомгак ясалды.«Милләт шәхесләре» номинациясендә журналыбызда 15 ел дәвамында даими чыгып бара торган «Казан утлары» архивыннан» циклы өчен Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин җиңүче булды.

## ХАЛЫКАРА ШИГЪРИЯТ ФЕСТИВАЛЕ

Казакъстанның Төркестан шәһәрендә XII халыкара төрки шигърият фестивале булды. Ул суфи шагыйрь Хуҗи Әхмәт Ясәви истәлегенә багышланды. Әлеге форумда төрки дөньяның йөзгә якын каләм иясе, шул исәптән Татарстаннан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, шагыйрь Рәмис Аймәт, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы мөхәррире, шагыйрә Сания Әхмәтҗанова катнашты. Өч шагыйрь фестиваль лауреаты булды. Шуларның берсе – Рәмис Аймәт. Аңа үзбәк шигърияте классигы Хөсәен Байкара исемендәге әдәби бүләк тапшырылды.

## ЮБИЛЕЙЛАР

ТР Милли музееның әдәби салонында Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Җ.Вәлиди исемендәге әдәби бүләк иясе, галим, исламият белгече, тәрҗемәче, публицист Әнвәр Хәйринең тууына 70 ел тулуга багышланган «Гыйлем диңгезеннән бер тамчы» дип исемләнгән кичә булды. Анда чыгыш ясаган ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, академик Индус Таһиров, тарих фәннәре докторы Фаяз Хуҗин, Казан шәһәре Думасы депутаты, табиб Рөстәм Бакиров, гарәп теле белгече Лена Таҗиева, язучылар Шаһинур Мостафин, Хөсәен Вәлиәхмәтов, журналист Риман Гыйлемханов, галимнең хатыны Альмира ханым Әнвәр Хәйринең күп гасырлык рухи мирасыбызны кайтаруда, аны хәзерге әдәби телгә күчерүдә гаять зур хезмәт куюын әйттеләр, истәлек-хатирәләре белән уртаклаштылар. Кичәдә җырчылар Рөстәм Маликов һәм Әнвәр Хәйринең кызы Айгөл Хәйри тарафыннан башкарылган җырлар яңгырады. Кичәне ТР Милли музееның өлкән фәнни хезмәткәре Флүрә Дәминова алып барды.

***

Танылган башкорт шагыйре, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Сәләм бүләге иясе Хисмәтулла Юлдашевның 60 яшьлек юбилеен бәйрәмдарның туган төбәге – Оренбург өлкәсенең Шарлык һәм Александров районнарында зурлап билгеләп үттеләр. Бәйрәм чараларында Уфадан килгән зур делегация белән бергә Казаннан шагыйрь Газинур Морат та катнашты.

***

Минзәләдә, Муса Җәлил исемендәге педагогия көллиятендә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрә Эльмира Шәрифуллинаның юбилеена багышланган «Әдәби туган як» дип аталган республика фестивале булып узды. Аның кысаларында фәнни-гамәли конференция һәм шагыйрәнең шигырьләрен сәнгатьле уку бәйгесе үткәрелде.

***

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында язучы-прозаик, юмор остасы, автор-башкаручы, режиссёр Алмаз Хәмзинга 70 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт А.Хәмзинның тормыш һәм иҗат юлы турында сөйләде. Кичәдә язучылар Рабит Батулла, Равил Фәйзуллин, Тәлгат Галиуллин, Вахит Имамов, җырчылар Рафаэль Сәхәбиев, Фәрит Мирзануров, байтак еллар ТР Милли китапханәсе директоры булып эшләгән Наил Камбеев, бәйрәмдарның кызы, җырчы, мөгаллимә Алия Хәмзина һ.б. чыгыш ясады, юбилярга матур теләкләрен ирештерделәр. Алмаз Хәмзинның җырлары, шигырьләре автор башкаруында тәкъдим ителде. Кичәне сатирик язучы Камил Кәримов һәм Алмаз Хәмзин үзе алып барды. Хәмзинның юбилей кичәсе Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залында да үткәрелде. Шул көнне көндез аны ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин котлады.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Слово главного редактора И.ИБРАГИМОВА.*
*«Проза и поэзия»: сатирическая повесть В.НУРИЕВА «Долгая, длинная зимняя ночь», повесть Х.БАДИГИ «Лукошко для ягод»; стихи Ф.ЯРУЛЛИНА, К.БУЛАТОВОЙ, С.АХМЕТЗЯНОВОЙ, В.ФАТИХОВА, Ф.ГАБДРАХИМА.*
*«Новые имена»: повесть З.ТИМЕРГАЛИЕВА «Самига».*
*«200 лет со дня рождения Ш.МАРДЖАНИ»: статья Л.ГУБАЙДУЛЛИНА «Почтенные абызы Ташкичу», Ф.ДАМИНОВОЙ «Наставник наставников», «Уроки Марджани» (из сборника Р.БАТУЛЛЫ).*
*«100-я страница»: Р.ЗАЙДУЛЛА. «Новый год!»*
*Интервью В.НУРИЕВА с директором Арского педагогического колледжа Г.ГАРИПОВОЙ.*
*«Слово педагога»: А.ТУХВАТУЛЛИНА. «Писатель ведёт урок».*
*Интервью И.ИБРАГИМОВА с руководителем татаро-башкирской национальной организации города Кентау Ф.АЮПОВЫМ.*
*«90 лет со дня рождения Гульшата Зайнашева»: статья Р.ХАННАНОВА.*
*«80 лет со дня рождения Шамиля Маннапова»: статья М.ВАЛИЕВА.*
*«90 лет со дня рождения Аяза Гилязова»: М.ХАБУТДИНОВА. «На татарской сцене – проза Аяза Гилязова».*
*«В литературных объединениях»: стихи членов Арского литературного объединения (с предисловием Х.ФАЙЗРАХМАНОВОЙ).*
*«Публицистика»: эссе М.МИРЗЫ «Мой поэтический мир»; очерк Г.АХМЕТГАЛИЕВОЙ «Своя земля и в горсти мила»*
*Г. ГУМЕР. Эссе, посвящённое 80-летию Халяфа Гарданова.*
*«Воспоминания»: Г.ГАЛИЕВ. Странички жизни села Кырынды».*
*Юмор-сатира: юморески М.ВАЛИЕВА.*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Шигабутдин Марджани». Картина Ильяса Айдарова;*
*Родник Марджани в деревне Ташкичу Арского района. Фото Ленара Губайдуллина.*

# IN THIS ISSUE:

*The editorial of I.I.BRAGIMOV.*
*«Prose and poetry»: satirical novel by V.NURIEV «Long, long winter night», story by H.BADIGI «Bowl for berries»; poems by F.YARULLIN, K.BULATOVA, S.AKHMETZYANOVA, V.FATIKHOV, F.GABDRAHIM.*
*«New Names»: story by Z.TEMERGALIEV «Samiga».*
*«200th anniversary of S.MARJANI»: article by L.GUBAYDULLIN «Venerable Abysy Tashkichu», F.DEMIDOVA «Mentor of mentors», «Marjani's lessons» (from R.BATULLA's collection). «Mentor of mentors».*
*«100th page»: R.ZAYDULLA. «New Year!»*
*Interview by V.NUREYEV with the Director of the Arsk teachers college G.GARIPOVA.*
*«Teacher's word»: A.TUKHVATULLINA. «The writer is teaching a lesson».*
*Interview by I.IBRAGIMOV with the head of the Tatar-Bashkir national organization of Kentau city F.AYUPOV.*
*«90th anniversary of Gulshat Zainasheva»: article by R.KHANNANOV.*
*«80th anniversary of Shamil Mannapov»: article by M.VALIEV.*
*«90th anniversary of Ayaz Gilyazov»: M.HABUTDINOVA. «On the Tatar stage – prose by Ayaz Gilyazov».*
*«In literary associations»: the poems by the members of the literary Association of Arsk (with a preface by H.FAIZRAKHMANOVA).*
*«Publicism»: essay by M.MIRZA «My poetic world»; essay by G.AKHMETGALIEVA «Own land and in a handful is cute».*
*G.GUMER. The essay dedicated to the 80th anniversary of Khalaf Gardanov.*
*«Memoirs»: G.GALIEV. «Pages of life in the village of Kyryndy».*
*Humoresques by M.VALIEV.*
*«Pages of humor»: column is conducted by M.GALIYEV.*
*Diary of social-cultural life.*
*On our covers: «Shigabutdin Mardjani». Painting by Ilyas Aidarov;*
*The Mardjani spring in the village of Tashkich in the Arsk district. Photo by Lenar Gubaydullin.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Шиһабетдин Мәрҗани». *Ильяс Айдаров картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Арча районы Ташкичү авылындагы Мәрҗани чишмәсе. *Ленар Гобәйдуллин фотосы.*